# казан утлары

3. 1992



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ПРЕЗИДЕНТЫ
# УКАЗЫ

**Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды булдыру турында**

Мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләреннән кергән мөрәҗәгатьләр уңаеннан, шулай ук базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында республика предприятиеләре һәм учреждениеләренең мәдәниятне үстерүгә үз теләкләре белән акча күчерү турындагы тәкъдимнәрен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, 1992 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды турындагы положениенең проектын эшләп, Дәүләт советы каравына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу Указның үтәлүен тәэмин итә торган карарлар кабул итәргә.

4. Бу Указ аңа кул куелган вакыттан көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. ШӘЙМИЕВ.**

Казан, Кремль.
17 февраль, 1992 ел.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

3

(833)

1992

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Х. ӘЮП. Кош-славы. *Шигырьләр* ... 3
Р. МӨХӘММӘТҖАН. Бүре сагышы. *Детектив әсәрдән өзек* ... 7
Ш. МАННАП. Кышым белән язым күрешкән мәл. *Шигырьләр* ... 63
С. ЙОСЫПОВ. Әсир истәлекләре ... 68
Ф. МОСЛИМОВА. Корьән арасында сакланган борынгы хат-шигырь. *Шигырьләр* ... 92
ИДЕЛБИКӘ. Идсалыма. *Шигырьләр* ... 95
Ф. ӘҺЛИЯ. Җанымны саклап. *Шигырьләр* ... 97
Р. НИЗАМИЕВ. Билгесез кыз сурәте. *Хикәя* ... 99
Г. ӘХТӘМОВА. Ташлар эзлим Алабугада. *Шигырьләр* ... 106
Д. БУЛГАКОВА. Алдылар күңел күлемнән. *Шигырьләр* ... 108
М. ГОСМАНОВ. Чәчелгән орлыклар ... 110

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. ЯРУЛЛИН. Таныштыру сүзе ... 140
Р. ӘХТӘМОВА. Ә син беләсеңме? *Шигырьләр* ... 140

ПУБЛИЦИСТИКА

К. ТИМБИКОВА. Хәлең ничек, ил кызы? ... 142

ӘДӘБИ МИРАС

З. РӘМИЕВ. Милли мәдәниятне яклап ... 155
Г. ИБРАҺИМОВ. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? ... 157
Г. ШАМУКОВ. Язучы архивыннан ... 177

КИТАП КҮЗӘТҮ

К. ТИМБИКОВА. Ихлас җан ... 180

Р. МОСТАФИН, Р. ДАУТОВ. Репрессияләнгән татар язучылары ... 182

Котлыйбыз ... 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Рөстәм Мингалимов**

**Фәрваз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

***(баш мөхәррир урынбасары)***

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

***(җаваплы сәркатип)***

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: детектив Р. МУХАМЕТЗЯНОВА «Волчья тоска», «Воспоминания пленного» С. ЮСУПОВА, рассказ Р. НИЗАМИЕВА «Портрет неизвестной»; стихи Х. АЮПОВА, Ш. МАННАПОВА, Ф. МУСЛИМОВОЙ, ИДЕЛБИКИ, Ф. АГЛИУЛЛИНОЙ, Г. АХТЯМОВОЙ, Д. БУЛГАКОВОЙ. «Творчество молодых»: стихи Р. АХТЯМОВОЙ.

«Публицистика»: статья М. УСМАНОВА «Татары в Китае», интервью К. ТИМБИКОВОЙ, посвященный к Международному женскому дню.

«Литературное наследие»: статья Г. ИБРАГИМОВА «О судьбе татарской культуры в условиях пролетарской революции и социалистического строительства».

«Из архива писателя»: письмо А. ШАМУКОВА об усовершенствовании национальной культуры и родного языка, адресованная в ЦК КПСС в 1969 году.

«Книжное обозрение»: К. ТИМБИКОВА рецензирует первую книгу молодой поэтессы И. Иксановой.

«К истории литературы»: репрессированные татарские писатели.

«На наших обложках»: картина Р. Нуруллина «Мадонна»; известная татарская писательница М. Маликова.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 31.01.92 ел. Басарга кул куелды 09.03.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 39399. Заказ В-57. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# Харрас Әюп

## Кош елавы

Яланнардан бер әйләним дисәң,
Кошлар елый...
Нинди коштыр алар? —
Баш очында бөтерелеп һаман,
Җан ачысы белән кычкыралар.
Синнән шулай курыктылар микән,
Бу тирәдә бармы оялары?
Югыйсә бит бер дә елатырга
Теләмәгән идең син аларны.
Үзәк өзгеч итеп кычкыралар —
Капланып хет ела, яланнарга.
Сизгәннәрме әллә — яшәвеңне
Хәвеф-хәтәр тулы заманнарда?
Кычкыралар...
Белгәннәрме әллә —
Синең дә бит бар иде лә канат!
Киселгән шул. Тик күнегеп булмый,
Егылсаң да инде ничә кабат...

Талпынасың кошлар булмасаң да.
Башың килеп ташка бәрелүгә,
Йөрәккәең күккә томырылып,
Мәңгелек бер кошка әверелә:
Җан ачысы белән кычкыра ул,
Шул кошларга кушылып, яланнарда.
Кошлар елый, хәерлегә булсын...
Сабырлыклар бирсен заманнарга!

## Әнкәйгә кайту

Инде юлга төштем бугай, дисәм,
Тагын ялгыш... Тагын буталдым! —
Гомерем буе сиңа кайтам, әнкәй,
Тик һаман да кайтып җиталмыйм.

---

Харрас ӘЮП (1946) — *шагыйрь, «Ышаныч», «Төнге кояшлар», «Кояшлы яңгыр» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Сабый җаннар каян аералсын:
Хакыйкать бар җирдә, ялган бар, —
Күзебез дә ачылмаган килеш
Безне синнән тартып алганнар.

Без синеке булмаганбыз, әнкәй,
Җылынсак та канат астыңда.
Яратылганбыздыр гомерлек бер
Хәсрәт итеп газиз башыңа.

Калдырмадың намаз-ниязыңны —
Гамәлләрең безгә ят иде;
Өйрәткәнең, имеш, хата синең,
Аларныкы гына хак иде.

Балаларың берүк ятка бирмә,
Туры юлга күндер, инандыр!
Ходай гына белә — ике иман
Бер куышка ничек сыйгандыр?!.

Агачыннан ерак төшми диләр
Иде дә бит, болай, алманы,
Безне ерак,
ерак, ыргытканнар...
Кайта-кайта хәлләр калмады.

Күпме аналарның, минем кебек,
Балалары бүген юлдадыр.
Кайталардыр...
Каршы чык ла, әнкәй,
Юл башына, яулык болга бер!

Бүтән беркем коткаралмаячак,
Халкым җирдән мордар китәчәк —
Табалмасак әгәр тамырларны,
Әнкәйләргә кайтып җитмәсәк...

## Кайтып барган чакта Мөслимгә...

Газиз әнкәй!
Кош тоткандай булып,
Китеп барган чакта Мөслимнән,
Китеп барган чакта Мөслимнәрдән,
Алъяпкычың салып өстеңнән,
Җиргә җәеп намаз укыгансың,
Теләк теләгәнсең син безгә:
Эзкәйләре берүк суынмасын,
Кайтсыннар, дип, туган нигезгә.

Газиз әнкәй!
Ут йотардай булып,
Кайтып барган чакта Мөслимгә,
Кайтып барган чакта Мөслимнәргә,
Үзәк өзеп искә төштең дә,
Бала чактагыча син җитәкләп

Алып киттең... Инде адашмам:
Кыйбламны мин — туган туфрагымны
Бүтән кыйблаларга алмашмам!

Газиз әнкәй!
Күңелләрем җирсеп
Йөргән чакта бүген Мөслимдә,
Йөргән чакта бүген Мөслимнәрдә —
Иман сеңгән туфрак өстендә,
Синең җылың, назлавыңны тойдым,
Сөенечләреңне, кайгыңны —
Җирдән киткән чакта, урыныңа
Калдыргансың туган ягымны...

## Соңгы күмер

Шушы агачлыкка китерәсең
Кайткан саен, күңел, тотасың да.
И тәкъдирләр!
Хәйран калып, менә,
Басып торам зират уртасында.

Янып беткән учак урынында
Әйтерсең лә бүген басып торам:
Ни хәлләрдә, ничек янганнарын
Күргән кеше бит мин, йа бер ходам!

Исемнәрен күлдән эзләп йөрим...
Карашлары кинәт искә төшә.
Янып беткән учак.
Ә урыны,
Ә урыны кайнар — табан пешә!

Пешә хәтер — бәреп тора әле
Монда һаман авыр еллар уты.
Яндылар шул инде...
Булдымыни
Кайгы-хәсрәтләрнең чама-чуты?!

И тәкъдирләр! —
Җил тузгыта көлне.
— Тузгытма, җил, тукта, күзгә керер...
Авылдашларыма карап торам,
Учак урынында — Соңгы күмер!

## Куш Чишмә

Печән чапты халык, урак урды,
Ашлык сукты ел да шул төштә —
Куш Чишмәдән эчтек.
Нидер ушкан
Кебек иде безгә Куш Чишмә.

Нидер кушкан — колак салмаганбыз.
Бу малайлар нигә тискәре?
Инде, мөнә, бер үкенеч йөри
Күңелемдә минем, әчкәре.

Тыңламадык чишмә кушканны без,
Әллә кая китеп олактык;
Әйткәннәрен искә-санга сукмый,
Әнкәйләрне күпме елаттык!

Аптырыйдыр чишмә, аптырыйдыр:
«Ә үзләре миннән эчтеләр...»
Болганып ла беттек бу дөньяда —
Безгә дә бит балчык иштеләр...

Чишмәләрнең рәнҗеше микән —
Ни хәлләргә инде төшмәдек!
Чишмә суы гына эчмәдек шул...
Бигрәкләр дә әллә нишләдек.

Томаланып калган чишмәм елый
Җаннарымда минем, тирәндә.
Нигә тискәредер бу малайлар?! —
Тазартасы, мөнә, ирләргә.

Алай сансыз булмас идем сиңа
Урак урган җирдә — шул төштә,
Җаннан беркөн бәреп чыгарыңны
Белгән булсам әгәр, Куш Чишмә...

* * *

«Җидегән Йолдыз!» — Җиде әйтсәң — савап, имеш...
Шушы сүзен әбиеңнең онытмадың.
Изге әби! —
Абындырмас өчен җирдә,
Йолдызларга табындырган оныкларын.

«Җидегән Йолдыз!» — Җиде әйтсәң — савап, имеш...
Ничә кабат әйтелгәндер — санамадың.
Бер булса да ярлыкарга җитәр микән
Гөнаһлы бу бәндәләрсн замананың?

Җитәр микән күктә йолдыз? —
И әбекәй!
Белгәнсеңдер — нигә әйтми китеп бардың?
Инде күккә очып бетеп килә бугай
Язуы да синнән калган китапларның.

— Җидегән Йолдыз!
— Җидегән Йолдыз!
— Җидегән Йолдыз!.. —
Әллә савап иңә җиргә, әллә җавап:
Яшь җемелди күзләрендә йолдызларның,
Бу җиһанның газиз баласына карап...

## Руслан Мөхәммәтҗан

# БҮРЕ САГЫШЫ

ДЕТЕКТИВ ӘСӘРДӘН ӨЗЕК

Хорошевтан сорау алуны ни өчендер иң ахырга калдырды Озерцов. Ул үзенең бөтен күңеле, җаны-тәне белән тоя: Павелны үтерүче кеше — өчесенең берсе, ләкин кайсысы? Чихирев, шыттырса да, күзләрендә бераз шәфкатьлелек нурлары чагыла, ә менә калганнарның күңелендә тыелып торган яшерен вәхшилек, имансызлык сизелә.

Пономаревтан сорау алу берни дә бирмәде. Ул, башын тинтәккә салып, Павелны машина таптаган дигән булып, берни дә белмәгәнгә сабышты һәм, мәсхәрәле елмаеп, җавап бирүдән баш тартты.

Әйе, тикшерү барышы үзенең хәлиткеч ноктасына якынлашып килә, ә чишелеш өчен детальләр җитеп бетми иде. Әһлиуллин һәм аның белән булган шаһитлар да беравыздан мәетнең үтерелгән җирдә каска кигән булуын инкарь итәләр. Әгәр дә шулай икән, кем соң аның башына каска кидергән? Ни өчен элеккеге тикшерүдә шундый мөһим детальне иско алучы булмаган? Павелны кыйнаганда, караңгылыктан файдаланып, кайсысыдыр авыр әйбер белән суккан бит. Нинди әйбер булган ул — тимерме, ачкычмы, кастетмы? Бәлки, Чихирев сөйләгән пистолеттыр? Күпме генә уйлансаң да, бөтен шикшөбһә, Пономарев, Горелов, Хорошев өстенә төшә. Чыннан да шулай булса, ул төнне кыр уртасында ниләр кылган алар? Юктан-бардан гына сугыша башлап, кеше үтерү — акылга сыймый. Бәлки, сәбәбен башка җирдән эзләргәдер?

Озерцов сугышу картинасын күз алдына китерергә тырышты.

Өч егет — ә Чихирев читтә карап тора — уратып алып, бер яшүсмерне кыйныйлар, ди. Павел, эшнең үзе өчен бик начар тәмамланачагын сизенеп, кесәсеннән отвертка алган булса кирәк. Бәлки, кемгә дә булса эләктереп тә өлгергәндер. Менә шул мизгелдә кайсысыдыр аның башына суга һәм ул, үлем ачысы белән кычкырып җиргә егыла. Шуннан соң сугучы, эшнең мөшкел икәнен сиздермәс өчен, калганнарны тизрәк җинаять урыныннан алып китәргә тырыша. Бәлки, ул, әйдәгез, дигәндер, аңына килгәч кайтыр әле, дигәндер. Авылга җитәрәк, төрлесе-төрле юл белән таралалар һәм, әйтик, кастет белән сугучы, үзенең корбаны янына әйләнеп килә. Павелның чыннан да үлгән икәнлеген күреп, аның башына үз каскасын кидерә һәм үтергән урыннан чокыр янынарак илтеп, машина юлына ташлый.

---

Руслан МӨХӘММӘТҖАН (1944) — *иseме газета-журналларда күренә кылган яшь әдип. Проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша. Казанда яши.*

Әйе, барысы да дөрес кебек. Вакытында суд медицина экспертизасы килгән булса, бәлки тикшерүченең монда йөрүе кирәк тә булмас иде.

Озерцов, уйларыннан арынып, Габдрахман Наримановны чакыртты. Бер минут та узмагандыр, карт, эшләпәсен кулына тотып, тикшерүче каршына килеп басты.

— Габдрахман Рәшидович, бер бик тә четерекле сорау килеп чыкты бит әле,— диде ул.— Павел каскасын гадәттә кая куя торган иде?

— Мотоцикл руленә элә иде.

— Үлгән көнендә каскасының кайда булуын хәтерләмисезме?

— Ничек инде кая булсын — башында.

— Сезнең өегездә ничә каска?

— Бер генә, Павелныкы.

— Павелны кырдан алып кайткач, өегездә тагын берәр артык каска күрмәдегезме?

— Андый нәрсәләргә игътибар бирерлек хәлдә идекмени, Александр Сергеевич.

— Бәлки, исегезгә төшерерсез?

— Һич тә хәтерләмим, Катерина гына берәр нәрсә белсә инде. Катя бездә. Кирәксә, хәзер алып киләм.

— Шулаймыни?— дип шатланды Озерцов.— Хатыныгыздан да сораштырыгыз. Бәлки, ул да берәр төрле үзгәреш сизгәндер. Минемчә, ул көнне сезнең өйдә ике каска булырга тиеш иде. Бу — бик мөһим нәрсә, Габдрахман Рәшидович. Тагын бер нәрсәне беләсе килә. Павелны машина таптаганын беренче булып кем әйтте икән?

— Сатый Гөргерие, ягъни Григорий Радионович Ильин, ул җәйләүдә каравылчы булып эшли. Әнә, аты да идарә янында тора,— дип тәрәзәгә ымлады Нариманов.

— Габдрахман Рәшидович, әйтегез әле үзенә, тиз генә минем янга керсен.

Бераздан Озерцов янына үрдәк кебек атлап кысык күзле, сипкелле, җәлпәк битле Сатый Гөргерие керде.

— Чакыргансыз икән?— диде ул, күзләрен йомгалап.

— Григорий Родионович, сөйләшәсе бар иде, утырып җибәрегез.

— Нәрсәгә чакырганыгызны төшенәм инде, иптәш нәчәльник,— диде керәшен карты, аның каршындагы урындыкка утырып.

— Григорий Родионович, узган ел унтугызынчы июль көнне Павел Наримановны машина таптаганын беренче булып милициягә сез әйткәнсез. Андый мәгълүматларны каян белдегез?

— Болай булды ул, иптәш нәчәльник.— Карт авыз кырыйларын сөртеп алды.— Кичтән Рөстәм машинасы белән урман каравылчысы Низамга барганда, ферма янында туктап, машиналарына елгадан су салдылар. Аннары Әһлиуллинны кем белми?! Ул бит безнең керәшен көйләрен, ай-яй, зәһәр уйный баянда. Юл фермага якын, үткән-сүткәннәрнең барсын да мыекка урап барасың.

Карт, сөйләвеннән туктап, изүен чишеп җибәрде:

— Башта, төяләп, Павеллар уздылар Үрлегә. Аннары тагын дөбершатыр колхозның ике машинасы китте.

— Үрле ягыннан нинди транспортлар узды?

— Кичтәнрәк безнең колхоз машинасы кайтып бара иде. Мин аны тавышыннан таныйм, иске җилгәргеч кебек дыңгырдый. Сатукай түти малае йөртә. Ярты төннән соң, таң алдыннан узганы — сельпо машинасы кебек иде. Аның артыннан Әһлиуллин машинасыннан башка беркем дә узмады. Мин, уйладым-уйладым да, Әһлиуллиннан башка кем таптатсын, дидем.

— Сельпо машинасы узганнан соң мотоцикл-фәлән үтмәдеме?

— Узуын узды да, кечкенә матай бишекле мотоциклны таптап китә алмый ла, иптәш нәчәльник.

— Кечкенә мотоциклда кем булырга мөмкин иде?

— Ерактан ничек күрәсең инде. Сөйләшсәләр, тавыш буенча шәйләр идең мужет, ә болар пыр-пыр киттеләр дә, озак та узмады, пыр-пыр кире кайттылар.

— Мотоцикл сәгать ничәләр тирәсендә узды?

— Чуртым белсен.

— Григорий Родионович, монда төгәллек кирәк. Әһлиуллин машинасы таң аткач уздымы, әллә караңгыдаракмы?

— Рөстәм машинасын таныйсың инде аны. Ул бит килбәтсез озын, лафет диләр. Биш чакрымнан таныла, шалтыр-шолтыр килүеннән.

— Бәлки, ул бөтенләй Әһлиуллин да булмагандыр, ә башка берәү?

— Аныкы! — диде карт, кул селтәп. — Артыннан тимергә тимер тиеп чинаган тавыш чыгарып бара.

— Шулай да булсын ди, ә мотоциклны күрмәдегезме?

— Күрсәм — күрдем дияр идем, арыш арасыннан күренми дә бит әле ул, зәхмәт.

— Әһлиуллинның катырак яисә киресенчә әкренрәк узганын сизмәдегезме?

— Җәй көне машиналар самолет кебек, тузаны — монда, ә машинасы әллә кая киткән була бит аның.

— Бу бит көндез булмаган, төнлә каян тузан күрәсең?

— Күзгә күренмәсә, борынга керә аның тузаны, иптәш следователь.

Озерцов, сорау алудан туктап, карттан имза куйдырып озаткач, рәхәтләнеп бер киерелде. Алҗыган булса да, хакыйкатьнең ачыкланганнан-ачыклана барганына күңеленнән шатланды. Ничәмә көнлек хезмәте, ниһаять, ачыклана башлаган иде. Нәкъ менә шул мизгелдә, келт итеп, күңеленә «Штирлиц» карчык керде. Ул, ару-талуларын онытып, язуларын тиз-тиз генә җыештырды да, карчык янына ашыкты.

Анастасия әби бу юлы томлап, карлыган кайнатмасын каба-каба, сөтле чәй эчеп утыра иде. Озерцовның керүен күреп, күптәнге якын кешесен каршылагандай, аһ-ваһ килеп, чәй эчәргә утыртты. Чәйләр эчкәч, хәл-әхвәлләрен сорашкач, Озерцов читләтеп кенә:

— Анастасия апа, теге вакытта сөйләми калган серегез тәки күңелне кытыклап тора бит әле, — диде.

— Ә-ә-ә, Сиргиләрне әйтәсеңме?

— Нинди Сергейлар?

— Сез арест иткән.

— Мин әлегә беркемне дә кулга алмадым, ялгышасыз, — дип көлемсерәде Озерцов.

— Алмасагыз — алырсыз, әй. Озакмыни ул.

— Озагын-озак түгел дә, кешене кулга алыр өчен гаебен ачыклап, исбатларга кирәк.

— Исбатлыйбыз хәзер аны.

— Ничек? Сез аларны үз күзегез белән күрдегезме соң?

— Вәт инде сиңа, ник күрмәсен, бодайлар арасыннан күреп калдым.

— Аңламыйм, Анастасия апа, ачыграк сөйләп бирмәссезме?

— Ачыгы-караңгысы шунда, балам, сер итеп кенә әйтәм, әгәр ычкындырсаң, оят, — диде карчык. — Болар бодай белән янәшә вике чәчкәннәр иде авыл башына. Сыерым чирләп китте. Көн дә иртәнге караңгыдан малкаема вике йолкырга чыга идем. Гел сорап та кыен, көндез яхшы түгел. Вике дип чыккан идем. Болар, хәтәр генә киттеләр дә әйләнеп тә кайттылар. Соңыннан гына акылга килде. Вәт шул.

— Кем белән иде Сергееӊ?

— Пономарь малае инде.
— Бәлки, ялгышкансыздыр? Горелов түгел идеме?
— Карчык дигәч тә, син нәрсә?! Мин әле укуны да күзлексез укыйм. Пономарь малаен танымаска.
— Гаҗәп булды бит әле бу...
— Мин дә шулай уйлыйм шул, нигә тиз борылып кайттылар икән, дип. Ләм-мим, ник шунда берәр кешегә сүз сөйләсеннәр!! Карчык булсам да, баш эшли.
— Моны беркемгә дә сөйләмәдегезме?
— Кем тыңласын карт җуләрне. Милициягә әйтермен дигән идем дә, үзләре үк, Павелны таптап үтергәннәр, дигәч, безгә нишләргә кала? Безнең урын — мич башында.
— Мотоциклга кадәр тагын берәр нәрсә уздымы? Хәтерләмисезме?
— Матай белән шул таптаткан дигән машина бер тирәдәрәк булдылар кебек. Башта — машина, аннары болар барып кайттылар.
— Ярый, Анастасия апа, рәхмәт сезгә...
— Тагын килегез. Мин ялгыз карчыкка кем керсә дә бәйрәм, сөйләшеп утырырга иптәш була.
Озерцов, хушлашып, авыл советына кире кайтты. Әмма сорау алуны бүгенгә туктатып торырга булды.
Димәк, Әһлиуллин машинасы узгач, мотоциклда Горелов түгел, ә бәлки Пономарев белән Хорошев барып кайткан булып чыга. Монысы көн кебек ачык. Иртәгә ниятләгән эксперимент ул дигәнчә уңышлы килеп чыкса... Әйе, уңышлы булырга тиеш. Җинаятьче ул ташлаган «кармак»ны йотарга тиеш. Озерцов моны җаны-тәне белән сизә. Әһлиуллинның, мин таптаттым, дигәне генә эчне пошыра. Менә кайда баш ватасы була икән әле...

* * *

Озерцов кунакханәгә авыр һәм чуалчык уйлар белән кайтып керде. Кайткач та, бер чәшке кофе эчеп, чишенмәгән килеш караватка барып ятты.
Ул күк күкрәгән тавышка уянып китте. Яшен уты өй эчләрен яктыртып алды. Озерцов, күзләрен ачып, як-ягына каранды. Кунакханәнең калай түбәсендә басылып кына яңгыр шыбырдаганы ишетелә. Кайдадыр якында гына чарт итеп яшен сукты, күк күкрәүдән өй селкенде. Озерцов, бертын тыңлап кына ятты да, торып утырды. Бүлмәдә дөм караңгы. Ялгызлыктан эче пошып, күңеленә моңсулык зәхмәте кереп утырды, хатынын, кызын кочагына аласы килде. Бер мизгелгә, үзен читлектә кебек хис итеп, талпынып куйды. Ул лап итеп кире урынына ятты, күзләрен йомып, гаиләсен күз алдына китерде һәм шунда гына бөтен тәне, җаны белән хатынын тансыклаганын, сагынганын тойды. Кызы, бәлки, бабасының бакчасындадыр. Җәй җиттеме, бабасы янына китә. Җир эшләрен ярата ул. Рәхәтләнеп, тирләп-пешеп түтәлләр ясый. Хәзер чәчәкләр, яшелчәләр үстерү белән мәшгульдер. Ниләр генә уйлап тапмый, кайларга гына утыртмый ул чәчәкләрне...
Кинәт, келт итеп, хәтер почмагыннан университетта диплом яклап кайтканда зәңгәр күзле бер яшь чегән кызының кулыннан алып юравы калкып чыкты. «Егеткәем, наныем, илле генә тиен бир, үтәли күрәм мин сине, барысын да беләм. Яхшы кешеме, каты бәгырьлеме, усалмы, мәрхәмәтлеме, әллә гаделме син — барысын да әйтеп бирәм, акчаңны кызганма, бир илле тиенеңне!» — дигән иде ул.
«Син игелекле, йомшак табигатьле булып тугансың, үзеңнең горур, ышанучан булуың аркасында тормышта шактый зур кыенлыклар

кичерәчәксең. Баш ияргә яратмаган кеше бервакытта да зур түрә була алмый. Сиңа тормыш итүе җиңел булмас...»

Чегән кызы шул урында туктап калды.

— Йә, әйткән-әйткән — күпме яшисен дә әйт инде,— дип, Озерцов аңа өч сум акча бирде. Шул чак чегән кызы, җитдиләнеп, аның күзенә карады да:

— Озын гомер яшәрсең, тик яхшы кеше, артык гадел булуың аркасында үз-үзеңне харап итүең дә бар,— диде...

Озерцов, торып, чишенеп, урынын җәеп яңадан ятты. Тышта күк күкрәү кими төште, ә яңгыр туктарга җыенмый иде. Йоклый алмаганлыктан төрле хатирәләргә, уйларга бирелде, әмма бөтен уй-фикерләре Павел Наримановның үлүенә бәйләнешле эшләргә килеп терәлде. Юк, бүген ул тыныч йоклый ала иде. Каравылчы карт: «Бәләкәй матай бишекле мотоциклны таптата алмый»,— диме? Күпме эзләде шул җеп очын Озерцов, ә ул уйламаган-көтелмәгән җирдән үзе килеп чыкты.

Төштән соң бераз аязланып алган күкнең кәефе кичкә таба янә бозылды. Бүрек-бүрек сибелеп торган болытлар, чүпрә салган сыман кабарынып, күк йөзен каплый башладылар. Кисәк-кисәк искән җил көч-куәт белән агачларны бөгә. Колхозның көтүе җәйләүгә кайтып кергәндә, көн төмсәләнеп өлгергән иде инде. Ак халат кигән кызлар, иңбашларына сөлге салып, чиләкләрен тоткан килеш, улак буйлап тезелгән сыерлар янына киттеләр, көтүчеләр, атларын киртәгә бәйләп куеп, кайтырга җыена башлады. Кич клубта һинд киносы буласын белеп, кызлар да эшләрен тизрәк тәмамларга ашыктылар. Сөт заводына сөт ташучы шофер егет кенә, машина кабинасын ачып куйган да, утыргычына сузылып, битенә фуражкасын каплап, гырылдап йоклап ята. Якынлашып килгән яңгырны сизепме, кабина эченә чебен тулган. Сыер савучылар, эшләрен төгәлләп, кайтырга җыенып торганда, аты белән этен ияртеп, каравылчы Григорий карт та килеп җитте. Ул, ашыкмыйча гына, тәмәкесен авызының әле бер, әле икенче ягына йөртеп, бармаксыз уң кулы белән азаплана-азаплана, атын тугарырга керешге.

Йокысыннан уянган шофер, картның азапланганын күреп, кабинасыннан сикереп төште дә булышырга тотынды.

— Бармакларым булса, азапланмас та идем, анасының даңгырдоңгыры... гомер буе бит,— дип, карт шулай сугышны каһәрләп алды.

— Кәефең юк ахыры, Гөргери абзый,— диде шофер егет.

— Колхозда авыл советы персидәтеленең генә кәефе яхшы була, энем.

— Әллә тартырыңа беттеме, Гөргери абзый?

— Вәт, бәдбәхет, каян беләсең?— диде карт, гаҗәпләнеп.

— Беренче көн генә эшләсәм икән.

— Магазинында папирос та булмагач, ни пычагыма ул?! Аракы кайтарып план ясыйлар... Ат абзарындагы митла белән куарга барысын да. Бер барсам, райкумын пыр туздырып чыгар идем едрет-кудритларның! Шул пристройкалары белән бергә...

— Гриша абзый, иртәнгегә кадәр берәр пачкы җитәрме?

Егет утыргыч артыннан башланмаган «Беломорканал» чыгарып бирде. Папиросны күргәч, картның авызы ерылды:

— Әй, рәхмәт яугыры. Бөтенесе дә синең кебек булсалар икән, Роберт. Барыбер яхшы кеше син. Мин үзебезнең керәшеннәрдән, валлаһи дип әйтәм, яхшылык күрмәдем.

— Ай — уртак, көн — уртак, яхшы кеше — гел уртак, Гриша абзый,— дип көлде егет.

— Дөрес әйтәсең, улым, яхшы кеше ул — ай белән кояштай, яхшылыгы — һәркемгә бердәй.

Карт, арба тәгәрмәченә таянып, канәгать йөз белән папирос көйрәтеп җибәрде.

— Болай булгач яшәргә була,— диде ул, борыныннан тәмәке төтенен чыгарып.

Сөт машинасы белән сыер савучылар киткәч карт буа кырыендагы эскәмиягә барып утырды, сүнә башлаган тәмәкесен тагын көйрәтеп җибәрде. Бүген аның ни өчендер күңеле тыныч түгел, эче поша иде. Көне буе карчыгына юкка-барга бәйләнүләре, котырынулары да, бәлки, шуңардан булгандыр. Тәмәке тарткач, бераз тынычланган кебек булса да, күңеленең әллә кайсы бер җирендә хәвеф бар төсле иде.

Карт, күтәрелеп, һавага карады. Болытлар куерганнан куера, карала бара. «Яңгыр булачак»,— дип, тәмәке төпчеген буага ыргытты ул. Буаның өсте болытлардан да караңгырак, шомлырак булып тора. Көндезен сугаручылар шушы буадан кырга су сиптергәннәр иде. Карт, чүгәләп, аяклары янында яткан этен сыйпады: «Нәрсә, Шарик, йокыга тартамы әллә?..— диде.— Әнә яңгыр да килә, керик әйдә...»

Киртә белән әйләндереп алынган җәйләү эчендә сыерлар — кайсы баскан килеш, кайсы ятып — әкрен генә күшиләр. Карт, тирә-якны әйләнеп чыккач, атын тышаулап, төнгегә кырга җибәрде.

Каравылчы карт инде йокымсырап ята иде. Шулчак кинәт Шарик каты итеп өрә башлады. Карт, бер кулына — мылтык, икенчесенә электр фонаре тотып, тышка чыкты. Вакыт-вакыт, тирә-якны яктыртып, яшен яшьнәп куя. Эт өргән яктан кешеләр килгәнен шәйләп, фонарь яктысын шуларга таба борып: «Кемгә нәрсә калган монда?» — дип кычкырды карт.

— Бу без, Гриша дәдәй, үзебезнекеләр. Үрледән кайтып килә идек. Лампа яктысын күреп, кереп чыгарга булдык.

Карт, егетләрне таныгач, фонарен сүндерде.

— Ләңгелдәмә әле, тукта!— диде ул, этен куып.

Каравылчы өендә тынчу, тәмәке төтене, атыш лампа корымы исе аңкый иде. Өстәлдә — ипи кисәге, пешкән өч йомырка, кружка, чәйнек.

— Ничек, Гриша дәдәй, сыерлар сөт бирәме?— диде егетләрнең берсе.

— Сыер савырга килмәгәнсеңдер лә?

— Яшьрәк савучы булса, савып карарга ярар иде анысы!..— дип хихылдап куйды егет.

Карт кесәсеннән каралып беткән чүпрәк алып, борынын сеңгерде. Икенче егет:

— Белмәгәнне белмәү яхшы, Гриша дәдәй. Син, лучше, безгә стаканнар алып бир. Безнең монда бер ярты калган иде,— дип, кесәсеннән шешә чыгарып куйды.— Закуска өстәлдә. Өчебезгә — өч йомырка.

— Сез эчегез, балалар, минем кәеф юк,— диде карт, кулын селтәп.

— Ну, Гриша дәдәй, без сине якын итеп, хөрмәт итеп кердек, ә син... Аракы чәй түгел, кәнишне. Шулай да, эчәбез бит үзен, сабакыны. Давай, давай, кәнфитләнмә.

Карт егетләргә сәер генә карап куйды:

— Сез, алай-болай берәр төрле этлек белән йөрмисезме?— дип туп-туры сорады.

— Син нәрсә, Гриша дәдәй, әллә болайракмы?— диде егетләрнең беренчесе, бармагын чигәсе тирәсендә бөргәләп.— Без синә нәрсә, әфган дошманнарымы әллә?! Әйдә, әйдә, кыстатма...

Карт, кружканы алып, эчә башлады. Егетләрнең берсе, карт төбенә кадәр эчеп бетерсен өчен, кружканың төбеннән этеп торды. Карт ипи кисәген борынына терәп, озак итеп иснәп торды да:

— Күбрәк китте, файдага булсын,— диде.

— Ничава, болай булгач, әле йөзгә кадәр яшисең икән!— дип, егетләр бер-берсенә карашып алдылар. Аннан соң, берсе кинәт сорап куйды:

— Теге Мәскәү следователе сине дә допроска чакырган ди, дөресме шул, Гриша дәдәй?

— Ә... Утыра шунда, чүпсез җирдән чүп эзләп.

— Нәрсәләр сораштыра соң? Югыйсә, сыерларның андый эшкә катнашы да юк кебек...

— Эслидовател нәрсә сорасын инде, стандарт...

— Нинди стандарт?

— Стандарт сорау дим, салам башлар. Паулны таптаткан көнне кайчан, нинди машиналар узды юлдан, ди. Бөтен сораганы шул. Күрәзәчемени мин?!

— Ә син?

— Мин нәрсә, теге вакытта ничек булса, шулай әйттем.

— Ул тонне Әһле машинасыннан башка бернәрсә дә узмадымыни?

— Нишләп узмасын, узды. Тик ул матай гына иде.

— Следовательгә әйттеңме соң?— диде егетләрнең икенчесе, картның күзенә керердәй булып.

— Ни пычагыма әйтим ди!?— карт нидер сизенгәндәй, алдашып җавап кайтарды.— Сорамаганда нигә авызына керергә?

— Юкка әйтмәгәнсең, Гриша дәдәй, әйтергә иде. Тикшерүче өчен һәр пүчтәк тә мөһим. Әйдә, тагын берне тотыйк, шул хөрмәткә...

Карт, аракыдан тәмам йомшарып, хәлсезләнеп төшкән иде. Барысын да сискәндереп, гөрселдәп, күк күкрәде; караңгы төнне яктыртып, яшен яшьнәде.

— Яңгыр башланганчы китик,— дип, егетләр урыннарыннан кузгалды.— Бер тотынса, иртәнгә кадәр утырырга туры килер. Әйдә, Гриша дәдәй, берәрне көйрәтеп керик.

Тышта күзгә төртсәң дә күренмәслек дөм караңгы иде.

— Монда кайдадыр эскәмия бар иде,— диде егетләрнең берсе.— Гриша дәдәй, яктырт әле. Бер утырып көйрәтик тә элдертик.

— Фонарьны алмадым шул, каһәр,— диде карт, чайкала-чайкала атлап.

Буа суы өстенә тәмәке утының шәүләсе төшә. Сүзсез генә шактый утырдылар. Тартып бетергәнче каравылчы карт бөтенләй йомшарды...

— Балалар, исерүем җитте ахры,— дип, карт утырган җиреннән аягүрә торып басты.

Караңгыда кинәт ниндидер өзек кенә аваз ишетелеп алды, буа суына шапылдап нәрсәдер килеп төште. Ярты сәгатьләрдән соң коеп яңгыр ява башлады...

Озерцов ишекне дөбердәтеп шакуга уянды. Тышта күптән инде яктырган, ләкин, төнге яңгырдан соң, кояшны болытлар каплаган, күренми. «Иртән уңмасаң, кич тә уңмассың...— дип, мыгырданып, ишекне барып ачты ул. Каршысында колхоз рәисе басып тора иде.

— Керегез, рәхим итегез,— диде Озерцов, аның болай иртә кузгалуына гаҗәпләнеп.— Әллә берәр нәрсә булдымы?

— ЧП, Александр Сергеевич, каһәр генә суксын.

— Тынычланыгыз, нәрсә булды?

— Каравылчы батып үлгән.

— Кайда?

— Җәйләүдәге буада. Котучылар белән савымчылар, баргач, эзләп карыйлар икән картны — юк. Эте яр кырыена килеп шыңшыган-

ны күреп барсалар, судан кулы гына күренеп тора икән. Ну, тартып чыгарганнар. Менә шул. Мин инде тизрәк сезнең янга йөгердем.

Озерцов, колхоз рәисенең сөйләвен тыңлый-тыңлый, ашыгып киенде.

— Районга хәбәр иттегезме?

— Милициягә шалтыраттым шалтыратуын, юлга чыгабыз, диделәр.

— Дөрес эшләгәнсез. Сез үзегез буа янында булдыгызмы?

— Көтүчеләр кайтып әйтүгә үк бардым. Кешеләргә әйттем: бернәрсәгә дә тотынмаска, кагылмаска куштым.

— Рәхмәт.

— Ун елга якын каравылда торып, бер тапкыр да суга егылып төшкәне булмады. Бу юкка гына түгелдер дим, Александр Сергеевич.

— Экспертизадан башка берни дә әйтеп булмый. Кем белсен, бәлки, аракы эчкәндер дә, менә сиңа — ЧП. Ничә яшьтә иде соң үзе?

— Җитмеш тула иде көзгә.

— Фамилиясе ничек?

— Ильин.

— Григорий Родионовичмы? — Озерцов галстук таккан җиреннән туктап калды. — Ялгышмыйсызмы? Кичә генә сөйләшеп торган идек аның белән...

— Сезне көтәләр анда...

— Алайса, киттек.

Озерцов белән колхоз рәисе җәйләүгә килеп җиткәндә, каравылчы картны арба өстенә куеп, өстенә ак халат каплаган иделәр. Сыер савучылар, эшләрен бетереп, агитпункт кырыена тезелешеп утырганнар. Сыерлар, иркенгә чыгарга теләп, мөгрәшәләр, сөзешәләр.

Озерцов, көтүчеләр белән сөйләшкәннән соң, каравылчы карт баткан урынны барып карады, аннары каравыл өенә керде.

Өстәлдә, чәйнек янында — ипи сыныгы, калай кружка, тапчандагы түшәктә каравылчы картның мылтыгы белән электр фонаре. «Ни өчен ул төнлә фонарен алып чыкмаган? Димәк, хаҗәте булмаган, — дип фикер йөртте Озерцов. — Карт — кем өчендер куркыныч шаһит? Ләкин шулай да нәтиҗә ясарга ашыкмаска, сабыр итәргә кирәк. Экспертиза ни әйтер бит әле... Бәлки, чыннан да, карт яңгыр вакытында, егылып төшеп батып үлгәндер?» — Шулай дип, үз-үзе белән киңәштабыш корып алды тикшерүче.

Бераздан соң ул, каравылчы өеннән чыгып, савымчы кызлар янына килде.

— Каравылчы өенә миңа кадәр керүчеләр булмадымы? — дип сорады ул.

— Юк, — диештеләр кызлар, беравыздан.

— Бәлки, ишекне генә булса да ачып караучы булгандыр?

— Юк, — дип, янә шаулашып алды савымчылар.

— Кичә кичтән Григорий бабайда берәр төрле үзгәреш сизүче булмадымы? Ихтимал, чирләгәндер, яисә салмыш-фәлән түгел идеме?

— Гриша бабай бик сирәк эчә, эчсә дә, бер тиенлек эчеп, өч тиенлек исерми иде, — дип сүзгә кушылды көтүче егет. — Минем аны гомеремдә исерек хәлендә күргәнем булмады.

— Кичә аның ни өчендер кәефе кырылган иде, — диде савымчыларның берсе, кинәт сүзгә катнашып.

— Нәрсәдән алып әйтәсез моны?

— Кәефе күтәренке булса, ул шаяртмый калмый иде, ә кичә, килгәч тә, атына да сүгенеп алды. Аннары тагын кемнедер каһәрли иде.

— Кибетчене сүкте ул, кибеттә папирос юк, — дип өстәде көтүче егет.

— Григорий Родионович, гадәттә, ашарына нәрсәләр алып килә иде?

— Ипи, тоз, биш йомырка. Җиләк-җимеш вакытында — ике кыяр белән ике помидор.

— Ни өчен шулай — төп-төгәл биш йомырка, ике кыяр, ике помидор?

— Ансын инде Варвара әбидән сорагыз... Без Григорий бабайның батып үлүенә ышанмыйбыз.

— Нигә?

— Ышанасы килми.

Нинди авыл булып чыкты соң әле бу. Башта Наримановның тапталуына ышанмадылар, инде хәзер монысына ышанмыйлар...

Озерцов, нәрсәдер аңларга-төшенергә теләгәндәй, тезелешеп утырган кызларның йөзләренә күз йөгертеп чыкты. Барысы да ашыгып-ашыгып сагыз чәйниләр, тик берәү дә әңгәмәгә аерым гына керергә батырчылык итми.

Озерцов буа буйларын, җәйләү тирәләрен карап чыккач, көтүне яланга чыгарып җибәрделәр. Берничә кешедән кала, башкалары машинага төялеп кайтып китте.

Бераздан районнан бер-бер артлы ике милиция машинасы килеп төште.

Экспертиза нәтиҗәләре әле тиз генә әзер булмаячагын аңлап, Озерцов прокурор янына кереп чыгарга ниятләде.

Бизәнгән-төзәнгән секретарь кыз чәй эчеп утыра иде.

— Прокурор үзендәме? — дип сорады ул, кызның ваемсызлыгына гаҗәпләнеп.

— Занят, — диде кыз эре генә.

Мөһим сөйләшүләр булганда бүлдергәнне үзе дә яратмаганга, көтәргә булды Озерцов. Кыз, чәен эчеп бетергәч, табынын пөхтә итеп, ашыкмыйча гына җыештырды да, чәшкесен бер читтә торган тумбочка өстенә куйды. Унбиш минутлар узгач: «Кайчан бушар икән прокурор, әйтмәссезме?» — дип сорады. «Миңа әйтмәде, белмим», — диде кыз. Тавышы салкын иде.

— Ләкин мин озак көтәлмыйм, белешмәссезме?

— Барысы да көтә, кирәксә — көтәрсез. Прокурор берәү генә, сез күп.

Озерцов, көлемсерәп, торып басты.

— Айназар Арсланович эшеннән бушагач та... — дип әйтә генә башлаган иде, ишектә прокурор үзе күренде.

— Александр Сергеевич! Сез нәрсә, әллә керми китеп барасыз инде? — диде ул, кул сузып.

— Секретарегыз бик усал булып чыкты шул, — дип кинаяле елмайды Озерцов.

Прокурор секретарь кызга усал итеп карап куйды.

— Гафу итегез, — диде ул Озерцовка. — Үзеңнең хезмәткәрләрең өчен менә шулай кызарырга туры килгәли инде, рәхим итегез, узыгыз.

Секретарь кызга беркемне дә кертмәскә һәм телефонны да тоташтырмаска кушып, прокурор Озерцов каршына кереп утырды.

— Нәрсәләр булганын — барсын да беләм, Александр Сергеевич. Миңа калса, сезнең эш катлаулана бара.

— Үзем дә шундыйрак фикердә. Болай, очраклы рәвештә батып үлгән булса — бер хәл. Әмма монда ниндидер сер бар кебек.

— Экспертиза нәтиҗәсе бераздан әзер булыр, шәт. Тизләтергә кушкан идем, — диде прокурор, сәгатенә карап.

— Әгәр дә Ильинны үтергән булсалар, димәк — Павел Нариманов белән дә бер-бер яман хәл эшләгәннәр. Гел сорармын дим дә,

хәтердән чыга, республика прокуратурасы эзли торган теге «Ява» мотоциклы табылдымы, юкмы?

— Юлда яндырылган шоферга бәйләнешлесен әйтәсезме?

— Әйе.

— Ул «Ява» печән кибәнендәге энә кебек булды. Әле тагын дистәгә якын кешене тикшерәсе калган, ди. Шуларның икесе шиклерәк. Берсе сез тикшергән егетләр тирәсенә барып бәйләнә кебек. Икенчесе монда, район үзәгендә. Икесе дә начар репутацияләләр, икесенең дә мотоцикллары ГАИда теркәлмәгән. Полянка егетенең «Ява»сы, гомумән, номеры белән бергә күрше республикадан алынган. Кыскасы, эзлибез. Бозра кечрәйгәннән кечерәя бара кебек.

— Юлда яндырылган шофер, Павел Нариманов, Ильин — барысы бер төенгә бәйләнгән йомгактан түгел микән дим мин.

— Мөмкин түгел, — диде прокурор. — Логикага сыеп бетәрлек нәрсәгә охшамаган. Унҗиде яшьлек егет, юлда яндырылган шофер, инде каравылчы карт. Кулда тотып селкерлек фактлар да юк.

— Анысы шулай, логикага, бәлки сыеп та бетмидер, ләкин фикер-фараз кылып карау ярый. Мисал өчен, акча мәсьәләсен алыйк. Әйтик, Павел кайдадыр, кемдәдер бик зур суммада акча күрә. Әгәр шулай икән, димәк, ул кемгәдер куркыныч тудырып торган, ягъни шаһит булган. Җинаятьче андый шаһиттан теләсә нинди юл белән котылу ягын караячак. Минем бу фикер шактый нигезле.

— Чынлап сөйлисезме, Александр Сергеевич, әллә бу — фараз итү генәме? — диде прокурор, күзлеген салып.

— Бу — минем ышанычлы фикерем. Инде, яндырылган шоферга килгәндә, монысы — фәкать фантазия җимеше генә. Шофер егет — йә җинаятьчеләр төркеменең бер әгъзасы, йә ул Нариманов кебек, кем өчендер, шаһит буларак, куркыныч кеше исәпләнгән. Ильинның үтерелгән булуы расланса, бер генә фикер дөрескә чыга: ул, һичшиксез, Павелны кем үтергәнен белгән. Һич югында — сизенгән. Григорий Родионович белән мин кичә сөйләшкән идем. Күрәсең, нидер әйтми калган карт. Бәлки, әнә шул әйтергә тиешле сүз ычкынмасын дип, аны йомдырганнардыр да.

— Хәер, шулай да булсын ди, тик барысын да ничек бер ноктага җыярга соң?

— Бу бит — әлегә фараз итү генә. Шырпыдан төзелгән өй сыман, барысының да бер мизгелдә җимерелүе мөмкин. Аннары, Айназар Арсланович, миңа Хорошев белән Пономаревның соңгы өч елдагы тормышын һәр деталенә кадәр белү кирәк.

— Ә Әһлиуллин? Аның белән ничегрәк?

— Әһлиуллинны, колониядән кайтарып, аннан гафу үтенергә, шул.

— Ашыкмыйсызмы?

— Хәзерге вакытта ашыккан — ота, артык нык сакланган — артта кала, Айназар Арсланович. Тикшерү эшләренең хәлиткеч вакыты якынлашып килә кебек. Әйтмәм дигән идем дә, хәзер барыбер әйтергә туры киләчәк: Әһлиуллин машинасы узганнан соң, Полянкадан Үрлегә таба бер мотоцикл да үткән. Һәм нәкъ Павел һәлак булган җирдән борылып та кайткан. Әһлиуллиннан соң тагын кемгә кырга барып кайту кирәк булган? Нариманов тапталган булгач, ни өчен мотоцикл хуҗалары шундук милициягә хәбәр итмәгән?

— Бусы минем өчен яңалык.

— Икенчедән, — диде Озерцов, алдында яткан газетаны читкә этәреп, — Павел Наримановның үтерелгән булуында минем, гомумән, шигем юк. Павелның көндәлегендә бик серле бер нәрсә бар: ул күп суммада акча күрә.

— Акча?!. Кемдә?

Прокурорның гаҗәпләнүе чиктән ашкан иде. Ул, әллә куанычыннан, әллә тынычлыгын җуеп, утырган җиреннән сикереп куйгандай итте. Әмма Озерцов ашыкмады, хәйләкәр генә елмайды:

— Әлегә сер булып калсын,— диде ул.— Сезгә керүемнең сәбәбе шул иде: колхозга командировкага дигән булып, ярдәмгә бер-ике егет җибәрсәгез икән. Шәпләрен генә.

— Эш шул кадәре җитди дип уйлыйсызмыни?

— Бүре, йонын алыштырса да, бүре булып кала, диләр. Җинаятьченең юашы да яман.

Экспертиза нәтиҗәсе эш көненең азагына әзер булды. Озерцов, документ белән танышып чыккач та, уйга калды.

— Димәк, карт батып үлгән булып чыга. Гаҗәп,— диде ул бераздан, сөмсере коелып.— Юк, монда нәрсәдер дөрес түгел...

— Ләкин картның батып үлүе факт, Александр Сергеевич.

Прокурор, урыныннан торып, сигарет алды да, авызына кабып, кабинет буйлап йөри башлады. Экспертиза нәтиҗәсе прокурорның үзенең дә кәефен бозды.

— Монда, Айназар Арсланович, йә җинаятьче шул кадәре оста, нечкә һәм профессиональ эшләгән, йә...— Озерцов тукталып калды.— Бәлки, аңа шул гына кирәктер дә. Дөресрәге, шулай буласын белеп эшләнгән эш бу. Күрәсезме, Ильин аракыны күп эчкән булган, ә колхоз председателе белән савымчыларның әйтүе буенча, карт каравылчы беркайчан да исереп, эчеп килми торган булган. Серме? Бусы — бер. Ильинның хатыны раславынча, күптән аракы алганнары булмаган.

— Аракыны эшкә барышлый да алып була. Аракысы булмаса, беткәнмени көмешкәсе.

— Соң ул чагында аракының яисә көмешкәнең шешәсе кайда?

— Ничек кайда? Шешәсе юк идемени?

— Хикмәт тә шунда шул менә!..

— Бәлки, ул аны буага ыргыткандыр?

— Юк, Айназар Арсланович, иләк белән су сөзеп азапланасы түгел. Мин аны каравылчы өстәлендәге кружканы карагач та уйлаган идем. Картның аракыны берүзе эчмәгәнлеге әллә каян күренеп тора. Киткән чагында җинаятьче эзләрен яхшылап сөрткән, ә аракы шешәсен алып киткән. Бу — рас. Картны буадан табалар да, тавышсыз гына күмеп куялар, дип фикер йөрткән ул. Инде экспертизафәләнгә китсә, дип, бернинди эз дә калдырмаган. Ишек тоткасында көтүче егетнең бармак эзеннән башка беркемнеке дә юк. Чиста эшләнгәнме?

— Шулай дип фараз итик,— диде прокурор.

— Икенчедән. Игътибар иттегез микән — мин моны экспертларга аерып әйткән идем — монда Ильин ике, иң күбе өч йомырка ашаган, диелгән. Бу детальгә ике куллап ябышырга мөмкин. Карт, гадәте буенча, җәйләүгә күп еллар буена биш йомырка ала торган булган. Моны хатыны да әйтте. Шулай булгач, кая киткән калган ике яки өч йомырка? Ашаганнар дисәң — кабыгы юк. Димәк, җинаятьче монысын да үзенчә хәл иткән. Кыскасы, кемдер безне үзенең алдавыч бавына тотындырып коега төшерергә ниятләгән. Хәер, без шартлы рәвештә аның ул бавын тоткан булыйк; үз бавына тотынып, үзе төшмәсме?

— Нишлибез? — диде прокурор.

— Минем арысланга тычкан тәбәсе куярга кирәк дигән ният бар. Ә авыл халкына, әлбәттә, бу фараз итүләрне хәзергә сиздермәскә тырышыйк.

— Халык шикләнерлек урын калмасын өчен, колхозга шалтыратып, председательне бик каты ачуланган булырмын, киләчәктә мондый фаҗига кабатланмасын өчен буа тирәсенә киртә тотарга кушар-

мын. Югыйсә, үтергәннәр икән, дигән гайбәт чыкса, сезнең эшкә зарар килүе мөмкин.

— Әлбәттә.

Тикшерүче белән прокурор урыннарыннан кузгалдылар.

— Шулай да, сак булыгыз, Александр Сергеевич,— диде прокурор хушлашыр алдыннан.

* * *

Сергей Хорошевтан сорау алуны еракган, җинаятькә бәйләнеше булмаган вакыйгалардан башлады Озерцов. Иң элек, кем икәнлеген аңлар, ачыклар өчен аның эчке дөньясын капшап карарга кирәк иде. Әнә ул йөнтәс сары каш астыннан сөзеп карап утыра. Үтерүдә шик төшкән кешеләрнең һәрберсеннән сорау алынган, ул — соңгысы. Күрәсең, мондый хәл аны да борчый. Билгесезлектән борчылмаган кеше шыр юләр булыр иде. Әнә бит, бүренеке кебек яшькелт күзләре тирә-якны айкый, бармаклары урындыкның йомшак утыргычында уйнап тора. Егетнең карашында ерткычлык, усаллык чагыла. Куе чәче тар маңгаен каплаган, салынкы итләч колакларын, чыннан да, бүре кебек шәлперәйткән, нидер котә. Битенең уң ягында чалыш яра җөе.

— Хорошев, яңагыңдагы яра каян?— дип башлады Озерцов.

Көтелмәгән сораудан соң Хорошев, ышанмаган сыман, яра эзен тотып карады.

— Ә-ә...— дип елмайгандай итте.— Малай чакта ат тешләгән иде.

— Шулай ат ярата идеңмени?

— Кем яратмый инде атларны, иптәш следователь.

— Димәк, яраткан хайванны кыйнарга да мөмкин түгелдер.

— Ничек кыйнныйсың инде, хайван бит.

— Ә менә синең хакта өченче ел, үзегезгә печән алып кайтканда, «Янбаш» дигән атны кыйнап, колынын төшергән дип ишеттем.

— Кыйнаганнан түгел иде ул, авыр йөк тартканнан.

— Шулай шул, үргә таба йөген тарталмагач, кыйный-кыйный куагансың. Анна Куянованың егетен ни өчен кыйнадың?

— Гафу итегез, мин беринди егетне белмим, бу нахак бәла, иптәш следователь.

— Хәер, хәзер Аннаның әнисен чакырабыз...

Башына ак яулык бәйләгән урта яшьләрдәге хатын-кыз, курыккандай, Хорошевтан читкә китебрәк басты.

— Сез бу кешене беләсезме?

— Соң, бу Мәкчем малае Сирги,— диде хатын, кабаланып.

— Дарья Петровна, сөйләп бирсәгез икән, гражданин Хорошев сезнең кызыгыз янына килеп йөргән егетне ничегрәк кыйнады?

— Кыйнады инде, иптәш нәчәлник. Башта урамда кыйнадылар, җыйнаулашып, тибеп-тибеп. Ач бүреләр дә шулай ташланмыйлар, болар кебек.

Хатын, сөйләвеннән туктап, яулык очын иреннәренә тидереп алды. Аннан соң дәвам итте:

— Кызым менә бу җанварга,— дип, Хорошевка төртеп күрсәтте,— барып ябышкач кына Валентин, торып, йортка кереп качты, аннары алар, аны эзләп, өйгә үк керделәр. Урында чирләп яткан иремне сөйрәп төшерделәр, ни генә җикеренмәделәр. Ахырзаман җитте дип торам.— Хатын, шулай дип, балавыз сыгып алды.

— Сездән җавап көтәм, гражданин Хорошев,— диде тикшерүче коры тавыш белән.

— Шыттыра карчык, кемгә кирәк аларның өенә керү?! Бер сүз урынына, авызыннан күбек чәчә-чәчә, мең сүз әйтә. Егетләр арасында ни булмас яшь чагында.

— Менә бу аңлатманы Дарья Петровнаның ире язды, ул боларның барысын да раслый.

Хорошев күзләрен усал итеп кысты.

Озерцов, хатынны чыгарып җибәреп, Хорошев белән генә калды. Төп сорауны юри суза төшәр өчен, ашыкмый гына сигарет чыгарып, өстәлгә куйды.

— Гражданин Хорошев, хәзер исә җинаять булган кичтә нәрсәләр эшләгәнегезне топ-төгәл итеп сөйләп бирегез.

— Нәрсәсен сөйлисең аның,— дип, җиңелчә генә җилкә сикертте Хорошев.— Ул көнне бераз эчтек, кәнишне.

— Күпме?

— Ике кешегә бер кызыл.

— Башка дусларыгызның әйтүенә караганда, ике кешегә бер ак аракы эчкәнсез. Соңыннан Үрледә сез клуб кырыендагы Ибраһимовларда, Гореловның дуслары өендә, ачы бал да эчкәнсез.

— Әллә кайчан бит, онытылган инде,— дип килеште Хорошев.— Җыйнаулашып Үрлегә бардык. Павел кайтканда кырда ватылып калды. Без барыбыз да җәяү киттек, менә шул.

Озерцов, бераз уйланганнан соң, Пономаревны чакырып кертте. Алар бер-берсенә карашып алдылар. Шаһит буларак бүлмәгә Хорошевларның күршесен, Сатукай түтине дә чакырттылар. Ап-ак чәчле карчык, кулындагы иске сумкасын әйләндерә-әйләндерә, сорау биргәнне көтә иде.

— Сатукай түти, узган елның унсигезенче июлендә күргәннәрегезне сөйләсәгез иде?

Карчык усал итеп егетләргә карап алды да тамак кырды:

— Теш сызлады минем ул төнне,— диде карчык, авыз кырыйларын сөртеп.— Үзегез беләсез, теш сызласа — нинди йокы керсен күзгә. Кыскасы, таң алдыннан мотоцикл белән чыгып киттеләр, менә бу җүнсез иблисләр.

— Кире кайтканнарын хәтерлисезме?

— Теш сызлавы басылгач, йоклап кителгән, улым,— диде карчык. Озерцов соравын Хорошевка юллады:

— Үрледән кайткач, мотоцикл белән кая бардыгыз?

— Үрлегә барып, Казан егетеннән үч алмакчы идек тә, кире борылып кайттык.

— Кайсы урыннан?

— Авылны чыккач та, мотоцикл «йөткерә» башлагач, туктадык.

— Мотоциклның кайсы җире ватык иде?

— Бензонасос. Аннары, бөтенләй кабынмый башлагач, кире этеп кайттык.

— Павелның башына кем кастет белән сукты?

— Кастет белән?— Хорошев, гасабилануын тышка чыгармаска тырышып, үзе дә сизмичә, икенче урындыкка күчеп утырды.— Дәшми утырсаң, сез, бәлки, машина белән дә мин таптаткан диярсез?

— Юк, алай дип әйтергә хакым юк, Хорошев. Чөнки Наримановны машина таптап үтермәгән, аның гомерен сезнең вәхшилек өзгән.

— Хыялыгыз бай икән сезнең,— дип сузды Хорошев.— Тик мин беркемне дә үтермәдем. Суд Әһлиуллинның гаепле икәнен раслады.

— Ашыкмагыз, Хорошев, вакыты җиткәч, суд башкасын да дәлилләр. Әйтегез әле, кеше өстеннән «Колхида» машинасы узса, ни калыр иде?

— Пәрәмәч,— диде Хорошев кызулыгы белән.

— Ни өчен ул вакытта Нариманов пәрәмәч булмаган?

— Кем белсен инде аны.

— Менә эксгумациядән соң ясалган экспертиза нәтиҗәсе,— Озерцов Хорошевны экспертиза нәтиҗәләре белән таныштырды.— Павел Наримановны машина таптамаган, ә бәлки ул

мәрхәмәтсез рәвештә кыйналудан вафат булган. Үрледән кайтканда сугышны сез башлагансыз. Ни өчен Наримановны бер гаепсез килеш кыйный башладыгыз?

— Сукмадым мин аңа.

— Горелов белән Чихиревны чакырту кирәкме?

Хорошев, ни өчендер, бер мәлгә агарынып китте. Яңакларын уйнатып, Озерцовка төбәлде:

— Ну, булды ул кичне, булды! Егет чагында кем сугышмас?! Кызлар өчен сугыштык. Павел яшь, чибәр, акыллы егет, минем кызымны тартып алган иде.

— Исеме?

— Валя Муханова.

Озерцов, икенче бүлмәдән кеше чакырып, тиз генә Мухhistoанованы табып килергә кушты.

— Чакырмагыз Валяны,— дип туктатты аны Хорошев.— Миңа ул кыз ошый иде. Павел миннән алданрак өлгерде. Әйттем, Павел, йөрмә аның артыннан, дип, тыңламады.

Тикшерүченең чираттагы сорауларын бүлдереп, алдан сөйләшкәнчә, бүлмәгә, тирләп-пешеп, Габдрахман Рәшидович килеп керде.

— Белдем, Александр Сергеевич, барысы да сез әйткәнчә,— диде ул.— Катерина әйтә, мин аны берәрсеннән алып торган да оныткандыр, дип уйладым, ди.

— Хәзер икесе дә сездәме?

— Әйе.

— Бик яхшы, бик хуп, безгә аның нәкъ Павел башындагысы кирәк иде дә. Хәер, калганы экспертиза эше инде. Габдрахман Рәшидович, зинһар, беркемгә дә бирә күрмәгез, урынында торсын. Иртәгә үзем барып алырмын, ярый, хушыгыз.

Аны озаткач, Озерцов янә Хорошевка текәлде:

— Хорошев, үзара сугышып та алдыгыз ди, әйтик, мәхәббәт аркасында. Ни өчен Наримановны юлда, кыр уртасында калдырып киттегез?

— Отвертка белән кабыргаң арасына китереп манчыган кешене үбәргә идеме әллә?

— Сугыш вакытында разведчиклар, хәтта әсирлеккә алган дошман яраланса да, үзләре белән бергә күтәреп, сөйрәп, ут астыннан алып чыкканнар. Ә сез, кан дошманыгызны түгел, иптәшегезне ташлап киткәнсез. Кайсыгызның башына шундый тинтәк уй килде?

— Ну, миңа,— диде Хорошев, күз карашын яшереп.— Айнып акылына килгәч, кайтыр әле, дидем.

— Экспертиза Павелның эчкәнлеген инкарь итә.

— Экспертизага шулай кирәк булгандыр. Без барыбыз да салган идек.

— Шулай да, Павелның башына кем тимер белән сукты? Чихирев карап торган, сез өчәү генә каласыз, Хорошев.

— Кызлар янына барганда кем инде кесәсенә тимер тыгып йөри, иптәш следователь?! Үзегез әйтмешли, чуалыш вакытында кастет белән суксалар гына.

— Димәк, Наримановның үтерелгән булуы белән килешәсез?— диде Озерцов.

Шул вакытта Хорошевның шәлпек ирене дерелдәп, сөмсере коелып төште. Аның йөзендәге үзгәрешне тикшерүче дә сизми калмады, әлбәттә.

— Юк, килешмим,— дип кырт кисте Хорошев һәм аның тавышы җир астыннан чыккан кебек тонык ишетелде.

Озерцов, Хорошевны чыгарып җибәреп, кабат Гореловны чакыртты. Аннары, алдан сөйләшкәнчә, тәрәзә янына килеп шартлы хәбәр бирде дә урынына утырды.

— Гражданин Горелов, сезнең иптәшләрегезнең барысы да унсигезенче июль төнендә Павел Наримановны кыйнаганнары турында сөйләп бирделәр. Сезнең инкарь итүегезнең файдасы бар микән?

Шулвакыт телефон шалтырады. Озерцов телефонны алды.

— Әйе, тыңлыйм, иптәш прокурор. Шуңа таба бара. Әлбәттә. Юк, сезнең санкция кирәк булачак. Кайчан? Ярар. Минем сезгә тагын бер үтенеч бар иде. Иртәгә монда эксперт җибәрегез. Юк. Бик мөһим нәрсәне хәл итәсе бар. Наримановның кабере өстенә кемдер «Ахыры юк» һәм «Ахыры бар, ул — мин» дип язган. Кабердәге һәйкәлне куптарып алып булмый лабаса. Ну. Әйе. Иртәгә. Рәхмәт. Ярар. Хәзер машина белән чыгабыз. Көтегез.

Озерцов, ашыкмыйча гына кәгазьләрен җыеп, егетләрнең барысын да чакыртып кертте.

— Бүгенгә сорау алу тукталып тора. Беркемгә дә авылдан чыгып китәргә рөхсәт ителми. Иртәгә барыгыз да сәгать тугызга монда киләсез,— дип чыгарып җибәрде.

Сорау алу тәэсиреннән арынмаган егетләр сүзсез генә өйләренә таралдылар.

Озерцов, сержантларның икесен генә чакырып алып, төнлә уздырылачак операцияне аңлатты: «Сезнең төп эш — Габдрахман Рәшидовичларга барып, аларга бүген верандада йокларга ярамаганлыгын әйтү. Тавыш-фәләнгә игътибар итмәсеннәр. Ә үзегез барысын да мин аңлатканча эшлисез. Аңлашылдымы? Менә сезгә кунакханә ачкычы»,— дип, үзе китеп барды.

* * *

Милиция «Волга»сы, кыр капкасыннан чыгып биш-алты чакрым узгач, юлдан читкә борылып, наратлык эченә кереп туктады. Кояш, тамчыгөл чәчкәседәй кып-кызыл булып, офык артына кереп бара. Көн сүрелгән, һава бераз салкынча.

Озерцов машинадан төште, ялгыз имән төбенә килеп, аягыннан туфлиләрен салып, костюмын элеп куйды, як-якка кулларын сузып, куе үләнгә ятты. Менә ул дөньяның җәннәте: һәр нәрсәнең үз матурлыгы, үз рәхәте бар. Тирә-якта тынлык. Ник ичмасам берәр төрле кош сайравы ишетелсен! Булыр икән шундый тынлык. Әллә яшьлеге белән моңа кадәр табигатькә колак салмаганмы, күңелне кыса торган мондый тынлыкка игътибар иткәне булмады. Малай чакта күккә карап ятканда ярыша-ярыша узышкан ак болытлар гаҗәпләндерде аны. Нинди генә җәнлекләргә охшатмый иде ул ак болытларны...

Озерцовны уйларыннан машина кычкырткан тавыш арындырды. Ул, эндәшмичә генә, яткан җиреннән күтәрелеп карады.

— Гафу итегез,— дип акланды шофер егет.

Озерцов сәгатенә күз төшереп алды. Караңгы төшәргә кимендә сәгать ярым чамасы вакыт бар. Профессиональ сизгерлеге аның өметен аклармы, юкмы? Инде каберлеккә берәү дә килмәсә? Ул вакытта эшләр катлауланачак, эзә белән кое казуны дәвам итәргә туры киләчәк.

Аның шулкадәр өмет иткән кармагына килеп капмаслар микәнни? Әгәр дә каска хуҗасы белән кабер ташына әлеге сүзләрне язучы бер үк кеше булып чыкса, нишләргә? Алай булуы да ихтимал. Ул чагында җинаятьче өчен каска мөһимрәк. «Аһ,— дип куйды Озерцов.— Нишләп соң әле ул монысын уйлап бетермәде? Ашыкмыйк әле, верандада Павелның үз каскасы ятса? Җинаятьчене бер вакытта да аңгырага санарга ярамый. Инде каска версиясе ул уйлаганча булса, җинаятьче үз каскасын теләсә ничек кире алырга тиеш. Аны шул Әһлиуллинның кулга алынган булуы тынычландырырга мөмкин. Әгәр

дә бик үҗәт кеше булса, ул бер үк төнне тегендә дә, монда да өлгерергә тырышачак. Үтерүче өчен аларның икесе дә телсез шаһит. Әгәр җинаятьче каска артыннан барып, егетләр аны эләктерсәләр, кабер саклап утыру бер тиенгә дә кирәкмәячәк. Нишләтәсең, бушка саклап утырган чаклар аз буламыни ул...»

— Александр Сергеевич,— дип эндәште аңа Булатов.— Хәзер нишлибез?

— Караңгы төшкәч, авылга кайтып, Наримановның каберен саклыйбыз.

— Кабер сакларга? Йа хода, анысы тагын нигә?— дип гаҗәпләнде Булатов.

— Сезне тоткарлавымның һәм сездән телефоннан шалтыраттыруымның хикмәте дә шунда иде.

— Ә-ә-ә,— диде Булатов.— Нигә миңа «прокурор» дип эндәшәсез икән дип, гаҗәпләндем тагын.

— Ышаныч әз, дускай. Шулай да, Горелов үз дусларына кабер ташындагы язуга экспертиза ясаячаклары турында барыбер сөйләячәк дип уйлыйм. Кайсыныңдыр нервасы ычкынып китеп, минем кармакка эләгәчәк, дип өмет итәм.

Озерцов белән Булатов, сөйләшкәнчә, капитанны машинада, кукуруз эчендә калдырып, рәшәткә өстеннән сак кына сикереп кереп, каберлек арасында югалдылар. Озерцов, кесәсендәге фонарен кулына алып, Павел кабере янындагы сирень агачы төбенә чүмәште. Колак төбеннән генә черки безелдәп узуга, костюм кесәсеннән Вьетнам бәлзәме алып, муен, маңгай тирәләрен сөртте. Хәзер таңга кадәр утырсаң да була, дип уйлады ул. Менә шулай, аучы шикелле, үз гомерендә төрле җирләрдә күпме җинаятьчене сагалап утырырга туры килде аңа. Тәмәке тартуны да шуның аркасында ташлады. Кайвакыт, эчең аркаңа ябышканчы, көне-төне, менә-менә килер, дип көтеп утырган кешең, бүре тозакны сизгәндәй, килми дә кала. Җинаятьчеләрнең дә «даһилары» бар. Шулай уйланып, йокымсырап утырганда, кинәт аяк астында шартлап агач ботагы сынганы ишетелде. Озерцов шул тавышка сискәнеп куйды. Кесәсендәге пистолетын янә капмалап алды. Бераздан, каберләр өстенә утырткан тәреләр арасыннан, бөгелә төшеп, сак кына атлаган кеше шәүләсе күренде. Ул Нариманов кабере янына килеп, чүгәли төште. Каберләр арасындагы караңгылыкта, шом тудырып, шырпы уты кабынды. Килүче иелеп, шырпы уты яктысында, калай һәйкәлгә язылган сүзләрне бетерергә кереште. Озерцов, мәче саклыгы белән сирень куаклары төбеннән чыгып, кулындагы фонарь утын кабер өстендәге кешегә таба юнәлтте. Әлеге кеше елан өстенә баскандай, ут яктысыннан читкә — тәреләр арасына сикерде. Зираттагы каберләр тынлыгын ярып, ату тавышы яңгырады. Озерцов фонарен сүндереп, берничә адым читкә сикерде дә фонарь уты белән каберләр арасын капшап узды. Кабат колак яныннан сызгырып ядрә узды. Озерцов, пистолетын алып, җинаятьченең игътибарын җәлеп итәр өчен һавага атты һәм, як-якка житез хәрәкәтләнеп, фонареның утын төнге кунакның йөзенә төшерде. Шул мизгелдә зиратта җан тетрәтеп акырган тавыш яңгырады.

Озерцов килеп җиткәндә лейтенант Булатов, «төнге кунак»ның кулын каерып, үзен җиргә терәгән иде.

— Лейтенант!— диде тикшерүче.— Син бу адәм актыгын бәйләп, машинага алып бар, ә мин Хорошевларга йөгердем. Әгәр дә ул, Наримановларга бармыйча, пистолет тавышын ишетсә, ычкыначак. Машинаның утын яктыртмыйча гына шунда килерсең. Озаклама!

Озерцов белән Булатов каберлек саклап утырган вакытта, Хорошев Наримановларның веранда тәрәзәсенә чиртте. Тавыш бирүче булмагач, берара көтеп торып, катырак шакылдатты. Верандада кеше юклыгына ышанган, пәкесе белән әкрен генә веранда тәрәзәсенең

пыяласын алып, җиргә куйды да, эчкә үтеп, үзенең мотоциклда киеп йөри торган каскасын алып кире тышка сикерде һәм, аягына тураеп басканчы, ике яктан ике кешенең кулларыннан элэктереп алуын тойды. Нәкъ шул вакытта зират ягында бер-бер артлы ату тавышы яңгырады. Каска каядыр читкә тәгәрәп китте. Хорошевның миеннән: «Беттек!» — дигән уй йөгереп узды һәм ул, үзен тотып торучыларның игътибарын җәлеп иткән ату тавышыннан файдаланып, кинәт кенә алга ыргылды, ычкынып, үзен тотарга килүчеләрнең берсен читкә бәреп, икенчесенең ике бот арасына тибеп, караңгылыкка югалды.

Ул, эзәрлекләүдән качкан ерткыч сыман, тыкрыклар һәм бәрәңге бакчалары аша үтеп, абына-сөртенә, өйләренә кайтып керде. Аның уенда бер теләк иде: мөмкин кадәр тизрәк авылдан чыгып югалырга һәм кая да булса посарга, тын да алмаска, тавыш-гауга тынычлана төшкәч, Себер якларына китеп сеңәргә, хәтта исемеңне дә, фамилияңне дә, кем булуыңны да онытырга! Ул, сыер абзарына кереп, идән тактасын балта белән каерып ачты да, көрәк белән казып, бер чиләк тартып чыгарды. Аннары, чиләк эчендәге төргәкне чишеп, костюм кесәләренә ике пачка унлык, бер пачка йөзлек акча тыгып, тирәякка колак салды. Шылт иткән тавыш та ишетелми. Ул маңгаендагы тир бөртекләрен сөртте. Әгәр дә исән-сау котылса, белер иде нишләргә икәнен. Шәһәргә генә барып җитәсе. «Кыяфәтне, йөзне үзгәртүе берни тормый,— дип фикер йөртте ул.— Ә калган акчаны кайчан да кайтып алырга була».

Хорошев, төргәктә калган акчаларын кире урынына урнаштырып, идәннәрне япты да, сарайда торган мотоциклын урамга этеп чыгып, өч йөз метрлар чамасы кабызмый гына барды. Халык йоклаган, караңгы. Аңа бары тик олы юлга кадәр генә җитәргә кирәк, ә аннары — син күр дә, мин күр. Милиция түгел, эте дә табалмаслык урында булачак ул. Мотоциклны кабызам дигәндә генә, аның күзләрен чагылдырып, йөзенә фонарь уты төште. Ул, куркуыннан артына утыра язып, бөтен тәне, җаны белән калтырана башлады.

— Хорошев! — диде Озерцов, кискен тавыш белән.— Болай соңлап кая таба җыендың?

Хорошев, каушавыннан теле көрмәкләнеп, ни әйтергә белми торды. Аннан соң гына, үз-үзен кулга алырга тырышып, әйтте:

— Түбән очка бер мәткә янына төшеп менәргә дигән идем. Әгәр каршы икәнсез, кертеп куям,— дип, мотоциклын кире борды.

Озерцовның аны кулга алырга килгәнлеген ул шундук аңлады. Тик менә кесәдәге акчаларны нишләтергә? Кая ыргытырга? Ничек итеп котылырга? Акча тарихы Павел эше генә түгел иде. Җитмәсә, фонарен дә сүндерми бит, каһәр.

— Хорошев, хәтереңдәме, беренче көнне мин сезгә, гаепне таныму — җинаять, дигән идем.

— Хәтердә, иптәш следователь.— Ул бу сүзләрне теш арасыннан, ачу белән сыгып чыгарды.— Бөкренең бөтен хыялы — чалкан ятып бер йоклау, ди. Сез дә шуның кебек. Сезнеке җиңде, начальник. Тик протоколга «органнарга үз теләге белән бирелде» дип язарга онытмагыз.

Хорошев, гаепсез кешедәй, кулларын алга сузып, катып калды.

— Онытмабыз, Хорошев.— Озерцов сак кына аңа якынлашты, сузылган кулларына богау кидерәм дигәндә генә Хорошев, һич искәрмәстән, бар көченә аның аяк астына сугып, урам буйлап йөгерде. Озерцов җирдән сикереп торганчы, урамны яктыртып, милиция «Волга»сы килеп туктады. Машинадан чыгып, лейтенант Булатов белән шофер качып барган Хорошевның каршысына ташландылар. Хорошев, бу юлы инде котылуга тәмам юл киселгәнлеген сизеп, кесәсендәге акчаларны аяк астына ыргытты да, үзе урам коймасына таба чапты. Ләкин, коймага сикереп менеп җиткәндә генә Озерцов аның үкчәсеннән эләктереп алды, кискен хәрәкәт белән үзенә таба

тартты. Эт сыман ырылдап җиргә килеп төшкән Хорошевны, бер мизгел эчендә кулларын богаулап, машинага утырттылар, халыкны йокысыннан уятмас өчен, тизрәк китеп тә бардылар.

Иртән авылга район прокуроры Айназар Арсланович белән районның эчке эшләр бүлеге начальнигы полковник Исмәгыйлев килеп төште. Бер-бер артлы янә ике милиция машинасы килеп туктады. Авыл советы алдында җыелган халык бер мәлгә гөжләп куйды. «Килделәр, алып китәргә килделәр! Асарга гына аз аларны, энә белән тунарга кирәк!» — дигән тавышлар яңгырады.

Хәл-әхвәлләрне сорашкач, Исмәгыйлев, фуражкасын салып, урындыкка куйды.

— Бөркү, яңгыр булыр, ахрысы,— диде ул, кульяулыгы белән маңгай тирен сөртеп.

— Яуса да ярар иде, мондый эштән соң,— дип сүзгә кушылды прокурор.

— Иртәрәк түгел микән, иптәш прокурор,— дип көлемсерәде Озерцов, башын күтәреп.

— Юк, иртә түгел,— диде кинәт җинаятьчеләр арасыннан берәү. Барысы да шул тавышка борылып карадылар.

— Гриша дәдәй белән Павелны кем үтергәнен сөйләп бирәсем килә. Суд моны искә алыр дип уйлыйм,— диде Пономарев.

— Пистолет хуҗасы,— дип аңлатты Булатов Исмәгыйлев белән прокурорга.

Озерцов, сакчыларга Пономаревның кулыннан богауларын салдырырга боерып, аңа язарга дип кәгазь бирде.

— Пономарев пистолетның үзенеке булмавын белдерә,— диде ул прокурорга.— Аның әйтүе буенча, пистолетны аңа Хорошев биреп торган. Мин моңа ышанам да. Хорошевта корал барлыгын белә идем.

— Ничек белә идегез?— дип гаҗәпләнде Исмәгыйлев.

— Әлегә сер бу...

— Бу пистолетның тарихы озын,— диде прокурор, кулындагы коралның номерын карап.— Чын хуҗасы старшина Әгъзәмов иде, Александр Сергеевич.

Озерцов, ишеткәннәренә ышанмагандай, бер Исмәгыйлевкә, бер прокурорга карады.

— Берничә ел элек, Васильево дачаларының берсендә аеруча куркыныч җинаятьчене эзәрлекләп киткәннән соң, Әгъзамов юкка чыга,— диде Айназар Арсланович һәм урындык артына таянып, аңа төбәлде.— Сез биргән акча номерларының тарихы бик катлаулы һәм тирәнгә киткән булып чыкты. Кыскасы, болай: өч ел ярым элек, Себердә леспромхоз эшчеләренә эш хакы алып кайтканда шофер белән кассирны һәм сакчы итеп җибәрелгән бер эшчене атып үтереп, зур суммадагы акчаны алып качканнар. Үтерү — нәкъ безнең райондагы кебек. Юлда утырган кеше өчесенә дә берьюлы арттан аткан...

— Гаҗәп...

— Гаҗәп кенәме, Александр Сергеевич?! Себер һәм безнең район.

— Димәк, монда булган җинаять вакыйгасының игезәге дә табылды. Әйе, эш әле муеннан икән.— Озерцов, урыныннан торып, Пономаревның гаризасын укып чыкты да, Хорошевны башкалардан аерым машинада озатырга боерык биреп, графиннан салкын су салып эчте.— Ихтимал, эш, ягъни бу эш башланган гынадыр,— диде ул, тәрәзәгә күз салып.

Авыл советы каршына җыелган халык — кечесе, олысы, картыяше — барысы бергә төркем-төркем булып гәпләшәләр. Берәүләре, чүмәшеп, тәмәке көйрәтә. Урамның икенче ягында, рәшәткәгә бәйләп куелган ат арбасының өстендә, тибенә-тибенә тавыклар җим чүпләгәндәй итә. Арба астында кечкенә генә йонтәс йонлы кара эт

ята. Озерцов ат белән этнең җәйләү каравылчысыныкы икәнен танып алды. «Их, Григорий Родионович, синең сугыш газраиленнән котылып калган кешегә, яшәргә дә яшәргә иде бит, тик саклап калмадык»,— дип, ул әрнеп куйды һәм, өстәлдәге документларын җыештырып дипломатына салгач, күрше бүлмәдә утырган авыл советы секретаре янына керде. Бүлмәгә тәмле хушбуй исе таралган иде.

— Ниһаять, эшләрем бетте шикелле, Светлана,— диде ул.— Хушлашырга кердем.

— Шулай тизмени? Тагын бер генә көнгә калсагыз, мин дә сезнең прокурор «Волга»сына утырып киткән булыр идем. Казанга чакырганнар,— диде кыз.— Бер атналык пропагандистлар семинарына чакыралар,— дип өстәде.— Әйтергә дә онытылган, бер сәгать элек Казаннан шалтыратканнар иде сезгә.

— Миңа? Кем?— дип гаҗәпләнде Озерцов.

— Ир-ат тавышы иде. Сезне сорады. Чакырыйммы дигәч, кирәкми, диде, Хорошевларны озаттылармы әле, дигәч, мин әле яңа гына кузгалдылар, дидем. Ул, барысын да бер машинада озаттылармы, дип сорады. Мин, юк, Хорошевны аерым, дип җавап бирдем. Ул, дөрес эшләгәннәр, диде дә телефонны куйды.

— Гаҗәп! Мондагы хәл Казанга каян билгеле? Ә... Могаен, Айназар Арсланович хәбәр биреп куйган булгандыр. Хәер, бу эш беткән. Мин сине, Светлана, рәсми рәвештә Мәскәүгә чакырам. Инде, Мәскәүгә килеп тә, безгә керми китсәң, үпкәләячәкмен,— диде ул, дусларча кулын кысып.

— Җылы сүзегез өчен рәхмәт, Александр Сергеевич. Әйбәт кеше сез,— диде кыз, моңсу карашын яшереп.

Озерцов, ишеккә таба борылгач, кыз:— Александр Сергеевич!— дип янә дәште.— Павел турында сорасалар, халыкка ни әйтергә соң инде?

— Халыккамы? Тикшерү эше тәмамланмыйча, берни дә әйталмыйм, Светлана. Миңа, могаен, Казанда берәз булырга да туры килер әле. Павелны үтерүченең исемен хәзер дә әйтә алыр идем, ләкин безнең эштә кайвакыт әллә нинди көтелмәгән борылышлар булып куя.

Озерцов урамга чыкты. Урамда аяз, җылы, матур җәйге көн тора иде.

* * *

Соңгы бер-ике көндә, чыннан да, вакыйгалар һич көтелмәгәнчә үзгәрде дә куйды.

Хорошевның милиция хезмәткәрен үтереп качуы, Озерцовны гына түгел, бик күпләрне аптырашта калдырды. Эчке эшләр министрлыгы белән прокуратура хезмәткәрләренең төрлечә гөман корулары да берни бирмәде. Хорошев иректә йөри иде.

Озерцов милиция майоры Иштугановны кабинетыннан чыгып килгәндә очратты.

— Сезне тагын борчыйм инде,— диде ул майор янына тукталып.

Майор, сәгатенә күз төшереп алгач, кулындагы ачкычын йозак тишегенә тыгып, ишеген ачып, бүлмәгә узды һәм өстәл тартмасыннан папка чыгарып, аны тикшерүче алдына куйды.

— Сезне кызыксындырган барлык мәгълүматлар шунда,— диде ул коры гына.— Әлегә әчкә җылы салырлык берни юк.

Озерцов, әйтергә сүз табалмыйча, «һым» дип кенә куйды да, папкадагы кәгазьләрне карарга кереште. Керкәле авылының кибетчесе аңлатмасы: «Кибеткә башта кызыл төстәге «Жигули»да килгән ике егет керде. Өсләрендә джинсы чалбар, берсе—кызыка җиңле зәңгәр

кулмәктән, икенчесенең өстендә шакмаклы кулмәк иде. Кыяфәтләре — сорамасаң да күренеп тора, бандитский. «Жигули»дән соң унунбиш минут соңарып, «Нива» машинасы килеп туктады. Берәү яшел төстәге кулмәк сатып алды. Урта яшьләрдәге ир кеше иде. Буй-сыны таза, беренче карашка мөлаем, яхшы кешегә охшаган иде. Мин әле, тәрәзәдән машинасына карап, бар бит бәхетле кешеләр, дип уйлап та куйдым. Бераздан милиция машинасы туктап торды, ләкин кибеткә кермәделәр. Әз генә басып тордылар да, китеп бардылар. Юл өсте булгач, барысын хәтерләп тә бетермәссең. Кемнең нинди икәне маңгаена язылмаган. Йөк машиналары да туктады. Кемгә — сигарет, кемгә башкасы кирәк».

Озерцов, укуыннан туктап, майордан нәрсәдер сорамакчы иде дә, кире уйлап, тагын берничә битне карап чыкты. Аннары, сорау алу кәгазьләрен өстәлгә куеп, майорга мөрәҗәгать итте:

— Тикшерү процессында үзегез берәр төрле фикергә килмәдегезме?

Майор юан баш бармагы белән ияген кашыды:

— Бар инде ул логикага сыймый торган кайбер шикләр.

Озерцов, майорга сораулы караш ташлаcа да, эндәшмәде.

— Мәсәлән,— дип дәвам итте майор,— өч-дүрт кеше кырда ПМГ машинасы артыннан барган «Нива» машинасын күргәннәр. Лесхоз трактористы әйтүенчә, ун-унбиш минутлардан «Нива» кире борылып кайта.

— Ничек? — дип бүлдерде Озерцов.— Сезнеңчә, Хорошевны коткарган җинаятьчеләр, милиционерларны үтереп, эзне югалту өчен бернинди дә чара күрмичә р булып чыга түгелме?

— Бәлки, ашыкканнардыр? Әгәр дә яндырсаң, юлдан ерак түгел. Урманда төтен күренүгә, хәзер килеп җитәләр. Ә аларга, киресенчә, җинаять урыныннан сиздермичәрәк, ераграк китәргә кирәк булган.

— Ихтимал. Бүлдердем, гафу.

— «Нива» машинасын якыннан күрүчеләр дә бар.

— Шулаймы?

— Әмма дә ләкин «Нива»ның номерлары ялган булып чыкты.

— Күрүчесе кем?

— Көтүче. Хәзер көтүне күп җирдә чиратлап көтәләр. Авыл малае күргән. Малай-шалайлар, үзегез беләсез, бик кызыксынучан булалар.

— Номерын карагач, димәк, кешеләрен дә күргән булырга тиеш,— диде Александр Сергеевич.

— Көтүче малайның әйтүенчә, машинада өч кеше була. Икесе — милиция формасында, ә өченчесе, әгәр мин уйлаганча булса, Хорошев.

— Шаккатыргыч кыю һәм оригинал фикер,— диде Озерцов.— Саташырсың да: милиция хезмәткәрләре һәм Хорошев! Форма табуы, әлбәттә, пүчтәк нәрсә. Форма җинаятьчеләрдә дә булырга мөмкин. Ә ни өчен Хорошев дип уйлыйсыз? Төсмерләпме?

— Юк. Керкәле кибетеннән ак «Нива»дагы берәү яшел кулмәк ала. Көтүче малайның сөйләвенчә, «Нива»ның арткы утыргычында Хорошевка охшаган яшел кулмәкле егет утырган. Әгәр игътибар иткән булсагыз, Керкәле кибетчесе дә шул турыда сөйли. «Нива»дан соң ПМГ машинасы туктый, ләкин кибеткә кермиләр. Монда уйланырга урын бар.

— Һем. Гаҗәп.— Озерцов бер урындыктан икенче урындыкка күчеп утырды.— Йә, йә, сузмагыз, сөйләгез.

— Көтүче малай әйтүенчә, «Нива» килгәндә көтү юл аркылы чыга торган була. Малай, тегеләрдән папирос алып калырга ниятләп, машина янына килә. «Тартырларына бар иде, кызгандылар, сволочлар»,— ди. Димәк, ул аларны якыннан ук күргән.

— Хорошевның фоторәсемен күрсәтмәдегезме?
— Охшатуын охшата, әмма тәгаен генә әйтә алмый. «Артта утырганы карак кебек гел як-якка карана иде»,— ди.
Майор белән Озерцов бер мәлгә уйга калдылар.
— Нәрсә әйтергә дә белмәссең. Хет шартла!— диде Озерцов, авыр сулап.— Формадагыларның дәрәҗәсен танымаганмы?
— Берсе капитан, ди, икенчесен хәтерләми.
— ГАИ постлары ни сөйли?
— Алардан ни он, ни тоз суы. Яталар шунда, җыен чүп-чарга бәйләнеп.
— Төп шикне ни өчен «Нива»га ташладыгыз, интуиция беләнме?
— Алай гына дип булмый. Сез ничек уйлыйсыз, куркыныч җиназтьчене алып барган ПМГа машинасы кемгә туктарга мөмкин?
— Фикерләр уртак безнең,— диде Озерцов.— Аларны йә белгән кеше туктаткан, йә туктатырга мәҗбүр булганнар. Өченчесе — сез фараз иткәнчә.
Озерцов, китәргә җыенып, урыныннан торды:
— Четерекле хәл. Хәер, әлегә шушы информация белән канәгатьләник. Рәхмәт, майор,— диде ул, саубуллашып.
Чихирев, Пономарев һәм Гореловларның сорау алу беркетмәләре белән танышып, тикшерү эшләренә файда китерерлек берни дә тапмаганга, гаепләнүчеләрне кабат үзе күрергә ниятләде Озерцов. Горелов белән Чихирев һаман да билгеле булган хәлләрне генә сөйләделәр, ә менә Пономаревның нидер әйтеп бетермәгәне сизелде. Әнә хәзер дә ул, өшәнгән кебек, гасабиланып, Озерцов алдында утыра.
Озерцов, авторучкасын тоткан килеш торып басты да, нидер уйлап, кире утырды:
— Дөрес аңлагыз, мин сезгә начарлык теләмим.
Пономарев, мәсхәрәле көлемсерәп, башын чайкап куйды:
— Кемгә ышанырга, сезгә што ли? Гафу итегез, сез нормаль кешеме, гражданин следователь? Минем әлегә кадәр милиция халкына ышанган бәндәне очратканым булмады. Анда бит миннән дә тегеләйрәкләр. Сезнең өчен мин, бәлки, бүре белән бердер, ләкин сез дә миннән әллә ни аерылмыйсыз, сезне тик киемегез генә каплап тора.
— Күпме ачу-үч сезнең җанда, Пономарев. Яшәргә авыр булыр.
— Яшәүнең аның җиңел булганы да юк. Сезгә җиңел булса гына инде. Сездә власть...
Озерцов, егетнең эчен бушатуын сизенеп, каршы төшмәде, тыныч кына тыңлый бирде.
— Армиядән кайткан ел иде, хәтерләмим, январьмы, февральме. Хорошев белән танцыдан кайтып килә идек. Икебез дә ап-ак. Мин шунда, шаярып, Сергейга «козел» дигәнгә, әллә каян мильтон килеп чыгып, милициягә алып кереп китмәсенме. Икенче көнне, хулиган дип, миңа егерме биш сум штраф салдылар. Штрафы чукынсын, кыйнаулары онытылмый. Кыйнап туйгач, йомгак итеп бәйләделәр. Аңыма килгәндә торая алмый идем. Менә шулай бер гаепсезгә изсеннәр әле. Милициядән чыккач та, исерек булмаганлыктан экспертизадан справка алып, прокурор Әмировка киттем. Тикшерербез, диде дә онытты.
Пономарев тынып калды.
— Соң, нәрсә булып бетте?— диде Озерцов.
— Старшинаны лейтенант иттеләр, Әмировны сөйлисе дә юк. Хайван. Аның чын йөзен соңыннанрак белдем. Минем ишеләр пүчтәк ул, гражданин начальник. Әнә, Әмиров белән Мәүлетов ишеләрне җир ничек тота, күптән юк итәргә кирәк.
— Кем ул Мәүлетов?
— Участковый. Шту сез, аллам сакласын. Ул «пәйгамбәр» белән бер. Өч ел милициядә эшләп ике машина алды да, ярты гектар җирдә ой төзеп куйды. Җитмәсә, семьясында да биш кеше. Каян килгән аңа

шулкадәр байлык? Югыйсә, отпускасындагы шабашкада эшләп алган акчасы да безнекеннән күп түгел кебек иде.

— Нинди шабашка?

— Шабашка — шабашка төсле була, кызыл да, яшел дә түгел.

— Кайда эшләдегез?

— Себердә.

— Сез бит Хорошев белән икәү генә бардык дигән идегез?!

— Барганда икәү булсак, өченчебез соңыннан килде.

— Кем белән?

— Алла белсен.

— Форма белән барган идеме?

— Күрмәгәнне күрдем дия алмыйм.

— Һем,— Озерцов тамак кырып алды.— Тикшерү эшләрен кыек юлга кертер өчен сөйлисеңме, Пономарев, әллә участковыйга бер-бер ачуың бармы?

— Төкердем! Ачу кусам, «Якты тау» колхозының акчасын ул гына талап-үтереп алды, дияр идем.

Озерцов, ни әйтергә белмичә, авызын ачып, күзләрен тасрайтып, аңа текәлде.

— Сөйләвен сөйлә дә син, Пономарев, әмма артыгын шыттырма! Нигә «Якты тау» колхозын китереп тыктың әле монда?

— Тыгасы килгәнгә. Миңа нәрсә сөйләсәм дә бата. Әгәр Мәүлетовның жулик, бандит булуын аңлагансыз икән, пардон, әйттем исә кайттым.

Тикшерүче уйга калды. Пономаревны кылана дип тә исәпләп булмый иде. Һәр шаяруда хаклык бар, диләр. Шаярумы, чынмы — әә Мәүлетовның Себердә булуы хактыр, мөгаен. Озерцовның уенда бер-бер артлы төрле фикерләр туа башлады. «Тукта әле, ярсыма,— дип үз-үзен тынычландырды ул.— Нәрсә сөйләмәс бу бәндә, тел сөяксез. Шулай да, нидер бар аның сүзләрендә». Озерцов, уйларыннан арынып, капыл гына күтәрелеп, күзләренә керердәй булып, Пономаревка карады:

— Пономарев, сез монда ничәнче тапкыр утырасыз, ләкин Хорошев турында адәм рәтле бер сүз булмады. Бернинди ачыклык та кертмәдегез. Нәтиҗә ясарга вакыт. Бераздан, тикшерү эшләре тәмамланып, бөтен кәгазьләр суд карамагына тапшырылачак.

— Ә Хорошев?

— Хорошев кулга алынгач җавап тотар... сез үзегез турында кайгыртыгыз!

— Кайгыртасы калмаган инде, бирәсен бирерләр.

— Бирерләр, Хорошевка да бирерләр, анысына шикләнмәгез. Тик бөтен хикмәт тә шунда — нәрсә бирерләр бит...

Пономарев бөкерәеп утырган җиреннән тураеп китте. Йөзенә курку бәреп чыкты:

— Наримановны мин үтермәдем, гражданин следователь.

— Суд бит, пистолетны каян алдыгыз, дип сораячак? Пистолетның хуҗасы старшина Әгъзамовның сөяге күптән җирдә. Хорошев, бәлки, бу минутларда кайдадыр кәеф-сафа корып утырадыр. Яисә, авыз ерып, сездән көлеп ятадыр. Ә сезнең суд алдында җавап тотасыгыз бар. Акланырга бернинди дәлилегез дә, шаһитыгыз да юк.

— Сез бит авылда чакта үзегез үк, пистолетны Хорошевныкы, дидегез.

— Мин судта катнашмыйм, Пономарев. Инде, катнашам дип фараз итсәк тә, минем дәлилем юк. Беләсезме, юк! Дәлил булсын өчен, Хорошев кирәк. Ә сез әле һаман да шуны аңламыйсыз. Үз кулыгыз белән үзегезгә кабер казып маташасыз. Кайда яшеренеп ятарга мөмкин ул?

— Белмим, гражданин начальник! Ул безгә әйтеп йөрми иде.

— Сездән башка дуслары булгандыр бит?
— Әйтәселәрен әйттем, өстәрлек бүтән сүзем юк.
— Яхшырак уйлап карагыз, Пономарев. Кеше, үләр өчен туса да, яши башлагач, үләсе килми. Сез мине куркыта дип уйлыйсыз, әлбәттә. Юк, Пономарев. Йөз процент җинаятьнең туксан проценты сиңа каршы, сине гаепли. Мин моны юрист буларак әйтәм. Беренчедән, пистолет — милиция старшинасыныкы. Икенчедән, пистолетны Хорошев бирде дигәнгә кем ышана? Ул сезнең кулда иде. Суд фактлар белән эш итәргә ярата. Инде, чыннан да, пистолетны Хорошевтан алгансыз икән, аның кулына ничек килеп кергәнен ул гына аңлата ала.
— Ботен чуп-чарны бер чүмәләгә өяргә булдыгызмыни, гражданин начальник? Юк, барып чыкмас!
Озерцов, ачуы килеп, тешләрен кысты, ләкин дәшми калды.
— Каравылчы картны ни өчен үтердегез? — диде ул бераздан.
Көтелмәгән сораудан Пономаревның йөз-кыяфәте үзгәреп китте.
— Менә, күрәсезме, сезнең өстә күпме гөнаһ. Старшина Әгъзәмов, Нариманов, каравылчы карт. Һәм берсен дә инкарь итәрлек бер кәлимә сүзегез юк. Йә, ничек, сөйлибезме, әллә һаман шулай, бүре сыман, мине ашардай булып утырачаксызмы? Шыр ахмак кына гомернең кадерен белмәскә мөмкин. Сезнең тормыш алда.
Пономаревның икеләнгәнен сизеп, Озерцов шул ук мизгелдә һөҗүмгә күчте:
— Хорошевның яшерен квартирасы булырга мөмкин бит? — диде ул туп-туры аның күзенә карап.
— Белмим, имандыр белмим. Ул, сирәк кенә, Васильевога — кемнеңдер дачасына бара иде. Тик мине алып кергәне булмады, гел капкаңың тышкы ягында калдырды.
— Мин бит сиңа начарлык теләмим, Пономарев.
— Яхшылык теләгән милиционерны да күргән юк, — дип, авыз кырые белән генә мәсхәрәле көлемсерәде Пономарев.
— Күрәм, сез яхшылыкны аңлый белә торган кеше түгел икән. Хорошев турында сөйлисегез килмәсә, сөйләмәгез. Без аны болай да тотачакбыз.
— Иң элек тотыгыз, аннары сайрарсыз.
— Минем башка сүзем дә, сезнең белән сүз боткасы ясап утырырга теләгем дә юк, — диде Озерцов. Аннан соң сакчыны чакырып, Пономаревны алып китәргә боерды. Тик аның нәрсәдер әйтәсе бар иде бугай. Урыныннан торып, ишеккә атлаган җиреннән генә:
— Мин, чыннан да, аның кайда икәнлеген белмим. Минем артта зур дәрәҗәле кешеләр тора, дип сөйләгәнен генә хәтерлим, — диде.
— Әгәр сүзең булса, утырып сөйлә, — диде Озерцов.
Пономарев, кире үз урынына утыргач, Озерцовтан сигарет сорап алды. Кулларының дерелдәгәне сизелә иде.
— Йә, — диде тикшерүче, каләме белән өстәлгә шакылдатып.
— Мин, чыннан да, белмим аның кайда икәнен. Ул сез уйлаганча пүчтәк кеше түгел. Вакыты-вакыты белән аның акчасы муеннан була иде. Каян алганын әйтә алмыйм. Дөресрәге, белмим.
— Ул үзе моны ничегрәк аңлата иде инде?
— Кызыксынганны җене сөйми иде. Шулай да, бер тапкыр, премиальный алдым, дип, ресторанга чакырды. Ташкент ягына барып кайткач, акчасы күбәя иде аның.
— Бәлки, премияне эшеннән биргән булганнардыр? Хорошев өчен нинди йомышлар башкара идегез?
— Берничә тапкыр «Москва—Томск» поезды проводнигыннан чемодан алып кайтып бирдем. Ә бер тапкыр Ташкент поездыннан алтымы, әллә җидеме карбыз алып кайттым.
— Кемгә?

— Хорошевка, әлбәттә.
— Ә ул сезгә нәрсә бирде?
— Соңыннан, синең өлешең дип, биш йөз сум бирде.
— «Москва—Томск» поездындагы чемоданда нәрсә иде?
— Чуртым белсен. Гап-гади бер сары чемодан шунда.
— Авыр идеме?
— Әллә ни авыр түгел.
— Проводник хатын-кыз идеме, әллә ир-атмы?
— Минем яшьләрдәге егет. Дөресен әйткәндә, ул әле, бәлки, проводник та булмагандыр. Проводниклар аламарак киенәләр, ә бу интеллигентный, кыяфәте нахальный.
— Хорошев чемоданнарны кая илтте, ягъни ул аларны кемгә бирергә мөмкин?
— Алла белсен,—дип, иңбашларын сикертте Пономарев.—Бер тапкыр аның апаларыннан чыгып килә идек. Урамның икенче ягына кара «Волга» килеп туктады. Хәтеремдә: номеры обком машинасыныкы иде. Хорошев сәер генә, бер «Волга»га, бер миңа карады да, барасы җир бар иде, дип, машинада китеп барды.
— Хорошевның шәһәрдә сездән башка дуслары кемнәр иде?
— Аның дуслары күп тә иде, юк та иде.
— Ә яраткан кызы?
— Ә...—дип кул селтәде Пономарев,—кызларны ул бер атнадан да артык йөртмәде.
— Тансыкка, яисә ач вакытта йөри торганы булгандыр бит?
— Бүрене белер өчен, чын бүре гадәтен өйрәнергә кирәк сезгә, гражданин следователь.
Дөрес сөрә бит бу, хәчтрүш, дип көлемсерәде Озерцов. Кушаматны белми кушмыйлар. Кушамат—кешенең көзгесе. Ул, каршында яткан кәгазь битен әйләндереп салды да, баш түбәсен кашып: «Син үзең кем соң, Пономарев? Адашып, бүре көтүенә килеп кергән төлкеме? Хорошев янында ролең нинди? Хәйләкәр син, Пономарев, хәйләкәр. Бүре янында йә бүре, һич булмаганда—төлке булырга кирәк. Син шуларның кайсысы?»—дип фикер йөртте. Аннары, кинәттән генә, җинаятькә бернинди бәйләнеше булмаган сорау бирде.
— Сез миңа Себер якларында нишләп йөргәнегезне төгәлрәк итеп сөйләгез әле.
— Беләсез бит, нигә сорыйсыз тагын,—диде егет, башын читкә борып.
— Шулай да, кайвакыт яңабаштан ишетү файдалырак.
Пономарев, стакан белән торган суны өстәлдән алып эчте дә, сорап та тормый сигарет алды:
— Мин сезгә, икәү генә бардык, дигән идем бит.
— Ни өчен икәү, өчәү яки дүртәү түгел?
— Сергей, кирәк кешеләрне анда да табып була, диде. Башта ниндидер бер станциядә төштек. Аннары Кудымкарга киттек. Кудымкардан—Юрлага, Юрладан соң ниндидер бер авылда булдык. Анда эшләр пешеп бетмәгәч, кире Кудымкарга кайттык.
— Кудымкарда кайда тордыгыз?
— Тулай торакта.
— Ни өчен кунакханәдә түгел?
— Кем белсен, урын булмагандыр. Аннары тети-мети дә санаулы гына иде.
— Кудымкардан кая юл тоттыгыз?
— Гайна ягына. Аннары, шунда эш табып, ике ай эшләдек.
— Нинди леспромхозда?
— Хәтерләмим. Исеме әллә ничек шунда, безнеңчә түгел.
— Сезнең янга килеп йөрүче кем иде ул?

Пономарев, гаҗәпләнеп, тикшерүчегә карады:

— Безгә килеп йөрүчеләр булмады, сез нидер бутыйсыз, иптәш следователь. Дөрес, кайтып киткәндә сөйләшеп тордык берәү белән, анысы да Сергейның Кудымкарда танышкан кешесе булып чыкты.

— Ягъни?

— Милиция капитаны.

— Каян беләсез капитан икәнен?

— Сергей әйтте.

— Капитан икәнен үзегез күрмәдегезме?

— Көн яңгырлы булганга күрә, өстендә хәрби плащ иде.

— Портретын тосмерләп сөйләп бирә аласызмы?

— Юк, ул миңа гел арты белән торды. Тавышыннан таныр идем.

— Ни өчен тавышы хәтердә калды?

— Алла белсен. Хатын-кыз тавышына миндә аеруча талант.

— Нәрсә, милиция капитаны хатын-кыз идемени?

— Әйе. Нигә гаҗәпләнәсез? Егет кеше, кесәдә сәмән бар, нигә типтереп алмаска.

— Шул гынамы?—диде Озерцов җитди һәм кырыс итеп.

— Ул тавышны минем монда да ишеткәнем булды кебек.

— Ягъни?

— «Дворяннар оясы»ннан чыгып киләләр иде. Түлке гражданский киемнән. Бәлки, мин ялгышканмындыр. Охшаш тавыш азмыни?

— Ялгыштыгызмы, әллә юкмы?

— Дөресен әйткәндә, шул капитан иде ул...

— Бер үземе?

— Прокурор Әмиров белән иде.

Озерцовның йөрәге кысылып куйды, күкрәгендә һава җитми башлады кебек. Нәрсә бу? Әллә дөресен сөйлиме, мөртәт? Әгәр шыттырса, ялганлавында нинди максат булырга мөмкин? Озерцов, уйларына раслау эзләгәндәй, Пономаревка сынап карады:

— Тагын нәрсәләр өсти аласыз?

— Сезнең яшисегез киләме, гражданин начальник?

— Һәр кешегә гомер бер тапкыр гына бирелә, Пономарев.

— Шулай булгач, ни өчен мин мәхрүм булырга тиеш?

— Уйлан, Пономарев, хәтереңне капшап кара, бәлки, тагын нәрсә булса да исеңә төшерерсең. Хорошев кулга алынса, синең мәгълүматларыңның бәясе бер тиен дә тормаячак.

— Сез, миңа акыл сатканчы, Хорошевны яхшылап эзләгез. Аннан соң күз күрер.

* * *

...Озерцов Пономаревтан тормәдә сорау алганда Сергей Хорошев, кулына буш рюмка тотып, тугыз катлы өйнең тәрәзә каршында басып тора иде. Аның инде ничәнче көн урамга, һавага чыкканы юк. Әнә, урамда бала-чагалар, терекөмешмени, уйнап чабалар. Менә кемгә ул дөнья түгәрәк, берниндй хәсрәтләре, тормыш ыгы-зыгылары юк. Кайчан гына әле үзе дә шулар кебек иде. Әйләнеп карасаң, утыз ел гомер артта җәйрәп ята «Күпме сөйләмәсеннәр, әмма малай чактан да күңелле вакыт булмаган икән»,—дип уйлады ул. Өстенә, нәрсә бирсәләр шуны киде, нәрсә пешерсәләр шуны ашады, кыйтакланып тормады. Шәһәр балалары сыман иза чигеп, агач тартмасындагы комда тибенеп ятмады, рәхәтләнеп чирәмдә чапты, ындыр табагына йөрде, яшьтәшләре белән уйнады. Их, заманасы, нинди генә уеннар юк иде! Булган бит кайгы-хафасыз көннәр. Өс-баш алама булып, ачлы-туклы йөрсәләр дә, бәхетле булганнар. Тормышың яхшырып, кесәңдә акчаң арткан саен, тынычлыгың җуела, куркак карачкыга әвереләсең. Каян

басты шул аждаһалар белән дәҗҗал юлына! Үзе рәхәт, үзе куркыта, үзе шикләндерә. Кесә тулы акча булу да начар түгел. Әнә, алар — урам тулы мескен-хәерчеләр. Хорошев хәзер эш хакына гына яши алмас иде. Әмма капчык белән акча тотуның ни хаҗәте бар? Түзәргә, әз генә түзәргә дә шылырга һәм кая да булса сеңәргә, югалырга... Хәзинәсе үз гомеренә җитәрлек. Җитми дисә, «Шахмара»ның бугазына басып алачак. Яшереп куйган фоторәсемнәрне чыгарып күрсәтсәң, кемнәрнеңдер кесәсе шактый югарачак.

Хорошев, рюмкасын өстәлгә куеп, бүлмәне әйләнеп чыкты. Җанын ниндидер тынгысызлык, хәвеф тоеп, шуның каян килгәнен, ни өчен борчылуын аңламыйча, эчтән калтырануын баса алмыйча, читлектәге ерткыч сыман әрле-бирле йөрде.

Сергейның уйларын ишектәге кыңгырау тавышы бүлде. Роза килсә, звонокка басып тормый. «Кем булыр?» — дип уйлап, Хорошев, шикләнүеннән, ишеккә барырга икеләнеп торды. Ишек ачылып, Розаның тавышын ишеткәч кенә, иркен сулап, каршыларга чыкты.

— Сәлам,— диде ул, кулларын күтәреп.

— Җенем сөйми шушы кыланмышыңны!

— Миңа синең җенеңнең сөюе кирәкми, үзең сөйгән дә бик җиткән.

— Сөю кайгысы гына синдә. Быгыр ботка, киш-миш кебек дөньясы! Муеннан эш.

— Үзгәртеп кору уйнасаң шулай ул. Котырган эт кебек, бер-берегезне тешли башладыгыз инде әллә?

Чәйдән соң Сергей, үз бүлмәсенә кереп, кулына «Кеше һәм закон» журналын алып, диванга сузылып ятты. Роза, сөлге алып, ваннага юынырга кереп китте.

Бераздан, кулына сумка тотып, Хорошев янына Мария Афанасьевна керде.

— Сергей улым, Розага әйт әле: юынып чыккач карасын, кәстрүлгә пешерергә тавык салган идем. Мин базар тирәләреннән әйләнеп кайтам,— дип, чыгып китте.

Журналның рәсемнәрен өстән-өстән генә карап чыккач, Хорошев, кухняга барып, кәстрүлне карады да ванна ишеге янына килде.

— Розочка, принцессам, аркаңны ышкырга кирәкмиме? — диде ул ишек аркылы.

— Иртәрәк селкенәләр аны, җаным, чыгам. Әни кая китте?

— Базарга.

Роза, ишекне ачып, халатының сәдәфләрен элэктереп кенә, Хорошев каршына килеп, сөлгесе белән аның муеныннан эләктереп үзенә тартты.

Сергейның бер мизгелгә дәрте кузгалып, чигәләренә кан дулкыны китереп бәрде. Куллары үзеннән-үзе Розаның халат астына кереп китте, нечкә, сыгылмалы биленнән күтәреп алып, үз бүлмәсенә алып керде. Розаның тулы, йомры күкрәкләре, аяклары ачылып китте, Сергей шашынып-шашынып аның күкрәкләреннән үбәргә тотынды...

Аннары алар дөнья хәлләре, эш турында гәпләшеп яттылар.

— Роза,— диде Сергей аны кочкан килеш.— Сиңа бераз куркыныч түгелме? Минем нигәдер эч поша.

Роза, әллә җавап бирергә теләмичәме, бераз эндәшми ятты. Аннан соң:

— Ахмак кеше генә курыкмый, сорыкаем,— дип елмайган булды.— Кая басма, аяк астындагы җир, баткаклыктагы кебек, дерелдәп тора.

— Әгәр, чыннан да, эзгә төшсәләр? Әнә, безнең кебекләрне хәзер КГБлар капшый.

— Ике аяклы әкәм-төкәм кайда да бар, Серёжа. Безнең дуслар әлегә тәмуг белән оҗмахта гына юк. Калганы өчен борчылма. Хәтер

лисеңме, АТП начальнигы Робинзоны, уникe ел бирделәр. Ай саен диярлек өенә кайта, кирәк икән — хатын-кызлар үзләре, янына баралар. Начармыни? Хәзер тоткынлыкта булу рәхәтрәк тә әле.

— Кемгәдер, бәлки, рәхәттәдер, пардон. Миңа монда да начар түгел. Исхаков, Сабиров, Ивановлар кайтып та йөрсеннәр, минем кайтып йөрергә аппетит юк.

— Без барыбыз да бер дисбе төймәләре шикелле, акыллым. Затлы чылбырларны йә кулда тоталар, йә муенса итеп йөртәләр.

— Кызык кына әйтеп салдың бит әле, ә? Алайса, кем безне кулында тота, Фәхрулла што ли? Әллә Сальниковмы? Әллә синме?

Роза ясалма рәвештә көлеп җибәрде.

— Озак уйладыңмы моны, тилекәем?! — дип, Сергейның борын очыннан кысты. — Фәхрулла белән Сальниковлар — дисбе төймәсе арасындагы зиннәтле ташлар гына алар.

— Шыттырма, ышанмыйм, — Хорошев, гаҗәпләнеп, яткан җиреннән терсәгенә таянып, Розага карады.

— Ә син ничегрәк дип уйлаган идең? Алар хуҗа дипме? Безнең илдә кем хуҗа? Халык, — диде Роза, чытлыкланып.

— Кемгә саныйсың син мине? Халык, имеш. Тот капчыгыңны, халык ул сарык көтүеннән дә аңгырарак!

Розаның йөзе кинәт кырысланды, күзләре усалланды:

— Мондый сорауларны Фәхрулла алдында ычкындыра күрмә. Заманында кем сине аяк астына салып таптады?

— Сальников.

— Сальников... — дип мәсхәрәле елмайды хатын. — Викторга шулай итәргә киңәш кенә бирделәр. Кем дисеңме? Ул, туганкаем, горкомның беренчесе белән дә санга санамыйча гына сөйләшә. Сөйләшмәс иде, тагын да өстәрәк әшнәсе утыра. Без синең белән зур түшкә янындагы кырмыскалар кебек кенә. Пүчтәк кешеләр. Зур түшкә янында, гадәттә, арысланнар, юлбарыслар була. Менә сиңа дисбенең хуҗалары. Арыслан, юлбарыс, филләрне халык күрми, ә җыен мыраулаганны, өргәннәрне күрә! Өстәгеләр алар актерлардан да тегеләйрәк, халык алдында бер-берсен сүгәләр, тавышлананалар, тәнкыйтьлиләр, бер-берсен эшеннән алган булалар; бераздан, эмоцияләр басылып онытыла башлагач, тагын да зуррак урынга куялар. Зур җинаятьчеләр шундыйрак була ул, дустым. Шуларга карап, без дә үзебезгә кәсеп итәбез. Зур түшкә өстендә мыраулый-мыраулый тыгынып утырган арысланнарның бер-ике калҗасын өзеп алганнан гына аларга зыян килми. Так што, голкәем, үз-үзеңне интектермә. Бу илдә һәркайсы үз калҗасын каерып кәсеп итә. Берәүләр, алдын-артын карый-карый булса да, бүксәсен киереп, кара икра ашауны хуп күрә, икенчеләргә суган суы суырып тыныч йоклау ошый. Тормыш закончалыгы, дустым. Үзгәртеп кору ул — җыен акылга сайлар өчен. Доньяның үзгәрмәячәген барысы да яхшы аңлый. Басудагы шайтан таягын бетерер өчен, аны тамырыннан ук суырып алып ыргытырга кирәк, ә басуның өстен аска китерергә.

Аларның иркенләп, рәхәтләнеп, тәмләп гәпләшүләрен ишектәге кыңгырау тавышы бүлдерде.

— Үзем ачам, — диде Роза, халатын киеп. — Кайсы собакысы икән?

— Мать якасыннан, ачма, рәхәтләнеп ятарга да бирмиләр.

— Бәлки, әни янына килгәннәрдер.

— Килсәләр, китәрләр әле.

Роза, җәһәт кенә торып, ишеккә барып ачты.

Ишек төбендә урта буйлы, гәүдәгә нык, төпле, елгыр карашлы бер егет басып тора иде.

— Миңа Сергей кирәк иде, — диде ул.

— Сергей?! Нинди Сергей? — Розаның кашлары маңгаена менде. Ул гаҗәпләнгән кыяфәт ясады. — Иремме? Әле эштән кайтмаган.

— Миңа Хорошев кирәк.
— Сезне кем дип белергә?
— Сул кулының уң кулы.
— О... Хәтта сул кулларның уң кулы да буламыни? Гаҗәп! Кызганычка каршы, андый тутый кош монда тормый!
Роза ачу белән ишекне япмакчы иде, әмма егет аның кулыннан эләктереп алды.
— Үскәнем, әллә очасың килдеме? — Роза усал итеп егеткә текәлде: — Ал кулыңны!
— Әллә чебен даруы эчтеңме, абыстай?! — дип хихылдап куйды егет. Шулвакыт Роза, ишекне ача төшеп, кискен генә хәрәкәт ясап, егетне үзенә тартып, аның күкрәк астына китереп сукты. Тегесе моны сизми дә калды, бөгелеп төште. Роза, ишекне ябып, Хорошев янына керде. Башта ул, тешләрен кысып, ачу белән аңа карап торды, аннан янына барып утырды.
— Кем иде анда?
— Синең чүбек башлардан башка кем булсын.
— Ой, обижаешь, начальник, — Хорошев торып утырды. — Әллә үпкәләттеме?
— Ишек төбендә ятып тора. Сине дә әйтер идем инде, үз хәлеңне үзең белеп, артыңны кысып кына утырсаң, шәбрәк булыр иде! Чамасын белергә кирәк, Сергей.
— Синең шул булыр инде.
— Башы эшләгән кеше дус чакырамыни монда? Кемгә ышанасың? Аларгамы? Җыен кеше калдыкларынамы? Күпме әйтергә кирәк? Әгәр берәрсен каптырсалар, ыһ та итми сатачаклар бит. Синең белән бергә башкалар да китәчәк. Безнең эштә дә бер генә ялгышалар. Маңгаеңа язып куй. Ник кирәк егет актыгы сиңа?
— Ул түгел, сәмән кирәк миңа. Беләсеңме, сәмән...
— Күпме?
— Илле мең.
— Нигә?
— Минем сиңа кирәкмәгән сораулар биргәнем бармы?
— Юк, дип фараз итик. Шулай да?
— Сорама, бир генә.
— Шакал!
— Роза, давай ычкыныйк моннан берәр кая! Хет җәһәннәм тишегенә. Домексен барысы бергә. Беткәнмени тынычрак, җылырак җирләр, ә?! Күтәреп кенә йөртәчәкмен. Имандыр!..
Роза, әллә нидән айнып киткәндәй, Хорошевның нәрсә уйлаганын белергә теләгәндәй төбәлеп карап торды. Әмма хәйләкәр көлемсерәп елмаюдан башка берни күрмәде.
— Түзәрлегең калса — көт, кирәк икән йөз илле дә, өч йөз меңен дә үзем бирермен, — диде ул җитди итеп.
Хорошев, исе китми генә, Розага сынаулы караш ташлады:
— Шаяртасыңмы?
— Башка сүзең юкмы?
— Аңла сине...
— Хатын-кызны аңлап бетерсәң, аның кызыгы бетә, дустым, — дип Роза аның борын очына чиертте. — Җил-давыллар узгач, мин сине бер кеше белән таныштырам.
— Тагын обкомнанмы?
— Суфый булып утырган буш куыкларны яратмаганны беләсең.
— Ну.
— Белгәч, ни пычагыма лыгырдыйсың.
— Ә Сальников?
— Ул сәрхүшләр белән санлашмый да булмый. Аларда — власть, бездә — акча.

— Әйтер идем властеңны, фахишәләрдән дә тегеләйрәкләр,— дип, Хорошев әшәке сүз әйтте.— Аларны да кандала урынына сытарга кирәк. Теге-бу була калса — аларның куллары чиста, ә синең белән минем кебекләрне, муеннан пычракка чумырачаклар.

— Тик пычракка чумганнар без түгел, дустым. Аның өчен маймыч балык та җитәрлек. Кыйммәтле ташларны, киресенчә, югалмасын, дип, кадерләп саклыйлар. Әллә алар үзләренең өч йөз, биш йөз сумнарына яши алачакларммы? Зур шәһәрдә типтереп яшәр өчен калын кесә кирәк. Ул иллешәр меңлек дачалар, аларның ярым дебильный балаларына «Жигули»ләр, «Волга»лар окладка алына дип беләсеңме? Тот капчыгыңны. Демократия уйнауларыннан гына тормыш үзгәрми. Алар лыгырдый, ә безнең эше акыл иясре үзләренекен эшли. «Ну, погоди!» мультигы ничә серия әле?

— Шайтан белсенме аны! — диде Хорошев, ваемсыз гына.— Санап утыраммыни мин аны?!

— Һәрхәлдә, анда бүре куянны ашамый, хәтта үзара дуслашып та киткәлиләр. Ә бүре куянга ни дип кычкыра: «Куян, син мине ишетәсеңме?» — ди. Ә тегесе: «Ишетәм, ишетәм!» — дип китеп бара. Бүре: «Ну, погоди, заяц!» — дип кычкыра да, шуның белән бетә. Бездә дә шулай, өстән: «Ну, погоди!» — дип яныйлар да, вәссәлам. Шулай булгач, куркып утырырга ничу!

— Кем белән таныштырасыңны тәки әйтмәдең бит.

— Вакыты җиткәч, белерсең. Сиңа, бәлки, бер-ике елга чит илгә, йә Польшага, йә немецларга барып кайтыргадыр, ә?

Хорошевның йөзе агарып китте, күзләре үҗәтләнде.

— Нәрсә, әллә табутка минем башны тыгып, кокаин кайтартырга ниятлисезме? Менә сезгә! — Хорошев Розаның борын төбендә «кәҗә тоягы» уйнатып алды.— Тавык мие эчкән фраерларны башка җирдән эзләгез.

— Әгәр дә теге Мәскәү мүкләге тагын койрыкка басса?

— Нишләп соң әле ул Хорошевны эзләп табарга тиеш? Үзебезнекеләрдән башка кем белә мине?

— Алла сакланганны саклармын, дигән. Ә син дус-ишләреңне чакыргансың. Дошманны читтән эзләмиләр, ул бүрек астында була. Әлеге тын гына өйдә ятарсың. Гөнаһлы юл, башта киң булса да, соңыннан тарая.

— Шул Мәскәү килмешәгенең арт сабагын укыта алмыйсыңмыни? «Али баба»ны күргән булсам, без аңардан бик тиз котыла идек.

— Кирәкмәгәнгә борыныңны тыкма. Синнән башка шөгыльләнүчеләр дә юк түгелдер әле.

— Шулай дисеңме? Кем? — Хорошев, сынаулы итеп, Розага карап алды.

— Белмәгәннең башы авыртмый, башыңны кирәк җиргә сакла.

— Димәк, ышанычны югалтканмын...

— Кысыр хәсрәт белән чирләмә. Ул ышанычның булуы белән булмавы шул кадәрле генә. Синдәге товарлар исән булсын, таба күрмәсеннәр. Тапсалар, эшләр хөрти.

Хорошевның йөзе агарып китте:

— Нәрсә, тентү белән барырга мөмкиннәр, дисеңме?

Ишектән ачкыч шалтырады. Розаның әнисе кайта иде, ахрысы.

* * *

Төш вакыты авышып, көн бераз сүрәнләнә төшкән булса да, кояш астында утырырлык түгел, кыздыра иде. Капка төбендәге ике милиция машинасын бала-чага, карт-корылар уратып алган. Кепка кигән ак сакаллы карт белән урта яшьләрдәге бер абзый, башларын чайкый-

чайкый, нәрсәдер турында гәпләшәләр, бәхәсләшәләр. Малай-шалай, койма башына менеп, йорттагыларны күзәтә.

Хорошевлар йортында өченче сәгать инде тентү бара. Пүнәтәйләрнең икесе, эсседән өй ышыгына яшеренеп, җиргә сыза-сыза нәрсәдер хәл итәләр. Ишек алдындагы туфракта тавыклар тибенә. Гайрәтле әтәч, горур басып, тавыклар тирәсендә йөри.

Озерцов болдыр янындагы эскәмиягә утырган. Койма артында өеп куелган тиресне милиция хезмәткәрләре тимер таяк белән тишкәлиләр. Бераздан болдырга Варвара Степановна да чыгып басты. Тентү ясау карчыкның зиһенен тәмам тараткан, борчылуы йөзенә-торышына бәреп чыккан.

— Варвара Степановна, утырыгыз әле, аңлашылып бетмәгән кайбер нәрсәләрне ачыклыйк,— диде Озерцов.

Карчык фикерләрен туплый алмый торды.

— Варвара Степановна, сүзем әлеге дә баягы Овсянников турында. Ул үзе нинди рәк кеше иде?

Карчык, тоник күзләре белән ялварган сыман, Озерцовка карады:

— Үлгәннәр турында начар сүз әйтү дә гөнаһ. Сөйләми дә хәл юк. Шупы өстәсәм генә: сугыштан мал белән, баеп кайткан, дип тә сөйләүчеләр булды. Үзе гомер буе ярлылыкка зарланды. Үлгәч, күпме алтын сәгать таптылар үзеннән.

Карчык, сөйләгән җиреннән тукталып, карашын тентүчеләргә таба юнәлтте.

— Коры куллы, кырыс кеше, дия торган иде хатыны. Бервакыт шул җүнсез балта белән хатынының башын чабып өзәм дигәндә, олы кызы балтага ябышып алып калган. Сугышта кеше атып яткан бәндә кисәгеннән нинди мәрхәмәт көтәсең?

— Ул Сергейны ярата идеме?

— Сергей Ибукны гел дә өнәп бетермәде. Яратсаң-яратмасаң да — карендәш. Килгән кешене борып җибәреп булмый. Сугышта булганнар бит, алар барысы да нервынныйлар.

Варвара Степановна улының качкынлыкта йөргәнен белергә-тиеш түгел иде. Шуңа күрә Озерцов та үзе кызыксынган сорауларны бик сак, читләтеп кенә бирде.

— Варвара Степановна, читтә кызыгыздан башка тагын кемнәрегез бар? Туган-тумачалардан дип әйтүем.

— Карендәшләргә ярлы булдык без. Чаллыда туганнан туганыбыз бар. Петр кызы Мария — районда. Башка туганнар юк. Участковыйга инде барысын да бәйнә-бәйнә сөйләгән идем.

— Нинди участковыйга? Кайчан?

— Мәүлетовка. Сергей качкач та килде. Бер генә түгел, берничә тапкыр килеп, капшамаган җире калмады. Нәрсә эзлисең дигәч, малаең качкан, өйдә яшеренеп ятмый микән, дип җавап бирде.

Озерцов янына Булатов килде:

— Александр Сергеевич, анда, сарай идәне астыннан целлофан төргәк табылды,— диде ул.

Пүнәтәйләр белән бергә Варвара Степановнаны алып сарайга кергәндә, тентүчеләр кара-каршы утырып сөйләшәләр иде. Озерцов белән Булатов кергәч, алар торып бастылар.

Варвара Степановна, зур целлофан төргәкне күреп, аптырап калды.

— Бу сезнекеме?— диде Озерцов.

— Беренче тапкыр күрәм.— Карчык ни әйтергә дә белми иде.

— Йорт алдына алып чыгыгыз,— дип боерды Озерцов.

Төргәкне чирәм өстенә куеп, ачкач, түгәрәкләп баскан пүнәтәйләр белән милиция хезмәткәрләре бер мизгелгә «аһ» итеп алдылар да телсез калдылар.

Капчык эчендә кап-кап йөзлек, иллелек, егерме бишлек акчалар ята иде. Варвара Степановна күзләрен тутырып карап торды-торды да елап җибәрде.

— Алланың каһәре суккыры! Кара инде аны, кеше ышанмаслык бит, кеше ышанмаслык!

— Бу сезнең акчалармы? — дип сорады Булатов.

Карчык бермәл дәшмәде.

— Бу кадәр акчаны гомеремдә беренче тапкыр күрәм, — диде аннары, башын аска иеп.

Өч йөз җитмеш биш мең сум акчаны, санап, документларны рәсмиләштереп бетергәндә өй түбәсеннән алып төшкән табыш Озерцовның үзен дә шаккатырды. Аның алдында иң кимендә бер миллион сумлык гашиш, марихуана ята иде. Кечкенә генә шушы авыл өенең түбәсеннән бу кадәрле наркотик табылыр дип кем уйлар? Павел Наримановтан башланган вакыйга акча, наркотикларга килеп бәйләнде. Бәлки, Павел, Хорошевтагы акчаларга гына түгел, шушы агуга да шаһит булгандыр? Бәлки, Павелның үлеме белән наркотиклар арасында берәр төрле бәйләнеш бардыр? Булса, хикмәт нәрсәдә? Әгәр Павел, Хорошевта бер сумка акча күрдем, дип ычкындырса, ышанырлар идеме? Ай-һай! Ул чагында яшь-яшь егетне үтерер өчен тагын нинди сәбәп булырга мөмкин! Димәк, Павелның үтерелү сәбәбен башка җирдән эзләргә. Тик каян? Нәрсәдән? Озерцов, тентүләр тәмамлангач, үзенең авыр уйларыннан арыла алмыйча, Наримановларга керде.

Габдрахман абзый иңбашына солге салган да, веранда бусагасына утырып, яшел чәйнектән су салып аякларын юарга җыена иде. Озерцовны күргәч, торып, яланаяк хәлдә аңа каршы атлады. Хәл-әхвәлләр сорашкач, сөйләшүнең мөһим өлешенә күчтеләр.

— Миңа ун минутка гына Павелның көндәлеген биреп тормассызмы? — диде ул, урындыкка утырып. — Тагын бер кат карап чыгасы килде.

— Әллә өйгә узабызмы? — диде карт.

— Юк, юк. Рәхмәт. Саф һавада рәхәтрәк.

— Һава бездә сихәтле.

— Шулай шул. Кала һавасы хәлне ала.

Карт, җәһәт кенә атлап, өйгә кереп китте. Ул үз улының көндәлеген алып чыккан арада, Озерцов ишек алдына күз салды. Ихата чиста итеп себерелгән. Коймa арасыннан кыяр сабагы чыгып, кычыткапга үрмәли башлаган.

Көндәлекне җентекләп укып чыкканнан соң, күзен йомып, барысын да кабат күз алдыннан уздырды Озерцов. Шикләнерлек бер генә деталь дә юк дисәң, «Ну, Хорошев — артист», — дигән сүзләр бераз уйга калдырды аны. Ни өчен артист соң әле ул? Нинди хикмәт ята бу сүзләрдә?

— Нигә уйга калдыгыз? — диде карт, аның фикерен бүлдереп.

— Юк, болай гына, Габдрахман Рәшидович. Павел шәһәргә еш бара идеме?

— Әллә инде. Баргалады.

— Барганда туганнарыгызга тукталасызмы?

— Минем анда ике брат. Берсе — Дачнаяда, икенчесе үз өе белән тора.

— Сез дә кунакта буласыздыр?

— Сирәк. Үз өе белән торганы бик тәкәббер. «Волга»сы, хан сарае сыман дачасы бар. Идел буенда.

— Зур җитәкчемени?

— Каян килсен, — диде карт, көлемсерәп. — Аның бит мәктәптә укыганда да «икеле»дән башы чыкмады. Хатыны гастроном директоры. Үзе — ниндидер министрлыкта тәэминат бүлеге начальнигы.

— Димәк, кешеләр әйтмешли, «яши» белә.

— Мин аның тормышына сокланмыйм да, кызыкмыйм да. Куркып яшәгән кебек яши ул. Бер барасың — кычкырып сөйләргә курка, икенче юлы күкрәк киереп шапырына. Ошамый ул миңа. Павелга да ошамый иде алар. Әти, йөрмә шул козгын оясына, аларның байлыгы кешеләрнең күз яшенә күмелгән, ди торган иде. Нигә шулай сөйләнгәндер. Кияве кайдадыр өлкә комитетында эшли. Павел үтерелгәч, хәтта кызыксынмады да.

— Габдрахман Рәшидович, андагы номенклатураның да төрлесе төрле сорттан.

— Павел турында хат язып, анда да булдым. Берничә тапкыр. Гафу итегез, Александр Сергеевич, үзем коммунист булсам да, әйтер идем... Анда тычкан тотарга иренгән ата мәчеләр утыра. Җан әрнемәсә, әйтмәс тә идем.

— Киявенең исеме ничек соң?

— Виктор Николаевич Сальников. Үз-үзенә гашыйк бер бәндә шунда. Чәчләрен бөдрәләтә дә, тик йөри күркә сыман.

Озерцов, хушлашып, капкага таба юнәлде.

* * *

Ә өлкәдә аны сюрприз көтә иде: Хорошевның үле гәүдәсе табылу турында хәбәр чигәләренә кан дулкыны китереп бәрде. Бер мәлгә зиһене таралып, фикерләрен туплый алмый торды. Хорошевка бәйләнгән җинаять тамырларының еракка, бик тирәнгә киткәнен ул тәмам аңлады. Экспертиза нәтиҗәләрен ул башта, кәнәфи кырыена таянган килеш, күзләре белән тиз-тиз йөгертеп чыкты. Аннан соң, җайлап утырып, кабат, җентекләп, игътибар белән укырга керешге. Укып чыккач, ни әйтергә дә белми, беравык өнсез-тынсыз утырды. Өстәлдәге телефонның шалтыравы аны уйларыннан арындырса да ул ваемсыз калды, әкрен генә торып, тәрәзә янына килде. Аннан соң гына телефон трубкасын алды.

— Ә, Марсель Айдарович, Хорошевның үтерелүе турында үзегез нинди фикердә?

— Нәрсә әйтергә дә аптыраган, — диде шалтыратучы. — Мондый хәлдә, гадәттә, җинаятьче үз корбанын мөмкин кадәр табалмаслык итеп яшерә. Корбанның йә башын кисеп ыргыталар, йә тураклап ташлыйлар, ә монда кырмыска оясына салганнар. Сәер күренеш.

— Мәет табылган урын шәһәрдән еракмы?

— Якында гына, авыл хуҗалыгы институтының дачалары янында. Аста күл. Ул урында безнең милли бәйрәмне — сабан туен уздыралар. Хикмәт шунда: башта Хорошевны коткаралар, ә аннары үтереп ташлыйлар.

— Алдан юрамыйк әле, — диде Озерцов, телефон трубкасын куеп, яңа номер җыя башлады.

— Шакирҗановны мөмкинме?

— Шакирҗанов тыңлый. Кем әле бу?.. Ә-ә-ә, Александр Сергеевич, сез икән. Мин сезне күптән инде Мәскәүдә дип торам. Күрешергә телисезме?

— Әйе.

— Каршы килмәссең, университет янындагы бакчада күрешик...

Озерцов Хорошевның ничегрәк үтерелүен кыскача гына сөйләп бирде.

— Менә шунда туктагыз, — диде Шакирҗанов, бармагын күккә текәп. — Үтерү ысулы ничек?

— Атып. Машинаны кемнәрдер туктата һәм икесен дә, тәрәп диярлек, Вест-Виссон пистолетыннан теге дөньяга озаталар.

— Могҗиза!

— Бусы әле кереш сүз генә. Кичә, Хорошевларда тентү ясау вакытында, өч йөз җитмеш биш мең сум акча һәм миллион сумлык наркотик табыла.

— Бәрәкалла, бәрәкалла. Италия мафиозы диярсең.— Шакирҗанов, гаҗәпләнүеннән, куллары белән ботына чабып куйды.— Әкият. Валлаһи әкият!

— Әкият булса, бик шәп булыр иде дә, кызганыч, әмма чынбарлык, коллега. Берничә ел элек Себердә, зур бер леспромхозга хезмәт хакы алып кайтканда, кешеләрен атып үтереп, акчаларын алып качалар да, шуның белән — бетте китте. Ниһаять, акчаның бер өлеше Хорошевтан табыла. Нәкъ шундый ук вакыйга — монда, сезнең «Кызыл йолдыз» районында. Үтерү алымы бер үк.

— Бер Хорошевка артык күп булмасмы икән, ә, Сергеевич? — дип бүлдерде Шакирҗанов.

— Күпме-азмы — Хорошевның хәзер исеме генә калды. Аның артында кем тора? Менә хикмәт нәрсәдә.

— Кем генә торса да, монда яхшы оештырылган төркем эш итә. Яки шуларның синдикаты.

— Карап-карап торам да, сез үзегез — фантазиягә бай кеше, ә төркемнәрнең нинди синдикаты булсын ди?! Хулиган малайларга синдикат, трест тагын!

— Ә сез, нәрсә, төркем дигәч тә, анда ун-унбиш хулиган дисәме? «Тяп-ляп»ны да төркем генә диярга маташканнар иде, ә алар яхшы оештырылган банда булып чыкты. Өч ел буе шәһәрне дер калтыратып тоттылар. Менә сиңа группировка. Без бит демократия, гласность уйнасак та, күзгә кереп кычкырып торган дөреслектән куркабыз. Үзегез уйлап карагыз, шәһәрдә МВД, прокуратура, комсомол, партия һәм беркем берни эшли алмый. Сталин заманында тота белгәнне, хәзер җиңә алмыйлар, имеш. Теләмиләр. Ә кемнәрдер шуны оештыра да, бик оста гына дилбегәләрдән тартып утыра. Бәлки, аларның башлыклары да Хорошев кебек кешеләрдер. Ә монда күпме чиновниклар берниндн гамәл кыла алмыйлар. Бу беraз сәеррәк түгелме?

— Битарафлык.

— Әйдә, чукынсын барысы бергә. Әллә Хорошевка кайтабызмы? Синең фикереңчә, ул бер әр төрле төркемнең короле булырга мөмкинме?

— Алла белсен аның кем булганлыгын. Ни өчен аны, бер тапкыр коткарып, аннары кырмыска оясына ташларга? Пономаревтан беразинформация чыкты. Аның сөйләве буенча, ул Хорошевны, әллә ничә тапкыр чибәр бер хатын-кыз белән күргән. Шул ук хатын-кыз милиция формасыннан Хорошевның Себердә эшләгән леспромхозында булган, имеш. Ә Хорошев леспромхоздан киткәч, банктан эшчеләргә зарплата алып кайтучыларны үтереп акчаларын алалар. Акчаларның бер өлеше Хорошевтан табылды, ә калганы кайда — шайтан белсен.

— Гаҗәп. Сез монда МВД хезмәткәрләренең катнашы бар диярга ниятлисезме?

— Мин фикер генә йөртәм. Кем булган ул хатын-кыз? Милиция работнигымы, рецидивистмы? Әллә Пономарев кына шыттырамы? Миңа кирәкле хакыйкать — җиде кат җир астында.

— Сез, Александр Сергеевич, гаять җитди җинаять гамәлләренә чыккансыз. Наркотикларга бәйләнешле җирдә куркыныч бер. Анда иманлы кешеләр юк.

— Искәртүегез өчен рәхмәт, әлбәттә. Әллә инде бер-ике көнгә кайтып килергәме?

— Белмим, ничек түзәсездер?

— Түзми нишлисең.

— Чәйгә бармыйм дисәгез, минем ремонттан туфлине алып чыгасы бар иде,— дип, Шакирҗанов хушлашырга кул сузды.

Кунакханәгә кайтып, исле сабын, сөлге алып, тагын нәрсә алырга икән дип уйланып торганда, телефон шалтырады.

— Тыңлыйм,— диде Озерцов ваемсыз гына.

— Озерцовмы?

— Нәкъ үзе.

— Озерцов, хәзер мине тыңлагыз. Сез тәҗрибәле, акыллы кеше,— диде телефонда таләпчән ир-ат тавышы.— Эшлисе эшегезне эшләдегез. Тотарга тиешле кешеләрне кулга алдыгыз, шунда тукталыгыз. Сез хәтәр сукмакка чыктыгыз. Тауга менәргә тырышмагыз, хәлегез җитмәс.

— Кем ул тау, сез түгелдер ич?— дип бүлдерде Озерцов.

— Юк, мин сезнең юлда — кыя гына. Сез иртәгә-берсекөнгә кайтып китәчәксез. Анда кайтып, буран күтәрмәскә киңәш итәр идем. Сез кыю кеше, сүз дә юк. Тавыш күтәрмәс өчен, утыз мең тәкъдим итәм.

Озерцов эндәшмәде.

— Нәрсә, азмы? Илле мең, шуннан да артык тормыйсыз.

— Акыллы кеше тәкъдим итми, «күпме» дип сорый, тинтәк баш!

— Не дурак... Ставкагызны әйтегез.

— Акчага ихтыяҗлык юк,— диде Озерцов.

— Пешканың бәясе миллион булмый!

— Миңа сезнең такса батып бетми, мистер Икс. Сез тәкъдим иткән сумма кәҗә тәкәсе алырга гына җитә.

— Кәҗә тәкәсе пүчтәккә дә сатыла, Озерцов. Күп сүз — юк сүз, җавап көтәм!

— Карале, син, әкәм-төкәм, сатыла торганнарны башка җирдән эзлә!

— Сез — яшь. Хатыныгыз чибәр. Кызыгыз матур гына үсеп килә. Шундый матур тормыш туйдырдымыни? Туйдырмаса — уйлагыз, бер тәүлек вакытыгыз бар. Безнең шартка килешсәгез, тәрәзәгезгә тумбочкагызда яткан сары кәгазьне ябыштырырсыз. Килешмәсәгез — мин сезне кызганам.

Телефон трубкасын тоткан килеш, ул беравык басып торды да, җәһәт кенә атлап, тумпочкасының тартмасын ачты. Чыннан да, анда сап-сары кәгазь ята иде. Озерцовның тәненнән, бала йоннарын торгызып, салкын дулкын узды. Кайдадыр якында гына үлем сагалап йөргәнен йөрәге белән тоеп, бер мизгелгә үкереп җибәрәсе килсә дә, тешләрен кысып тыелып калды. Ләкин бу халәте озакка сузылмады, кинәт күңелендә нинди дер ачу тышка бәреп чыкты.

— Аһ, шакаллар, кандала урынына сытарга кирәк сезне!— дип котырынды ул. Шулай инде ул, мәче юк җирдә — тычканнар хуҗа. Карарбыз — кем кемне җиңәр. Үз гомерендә телефон аша да, хат аша да янаучылар булмады түгел, булды.

Урамда халык, машиналар. Әнә, ике чегән хатыны узган-барганнардан нидер теләнә. Шикләнергә бернәрсә юк сыман. Ул, махсус заказ белән ясаткан җайланмага шәхси таныклыгын тыгып, кесәсенә беркетте дә, коенырга китте. Кичке як булуга карамастан, пляж шыгрым тулы иде. Чишенеп, киемнәрен сумкага салды да, билдән суга кереп басты. Су җылы, йомшак. Кояшның кызарып баеп килгән чагы, елга өстенә алсу нур сибелгән. Еракта балыкчылар балык тота...

Берәр чакрым чамасы узгач, талчыкканлыгын сизеп, чалкан ятып, кире борылды.

Елга кырыена чыккач, җылы комга яткан килеш, күзләрен йомып ял итәргә тырышса да, телефоннан шалтыратып янау, Хорошевтан табылган акча, наркотиклар уеннан китмәде. Кечкенә генә авыл

җирендә булган вакыйга әнә нинди кыяга китереп терәде! Озерцов, үзенең нинди авыр хәлдә икәнлеген яхшы аңласа да, бирешәсе килмәде. Аптыраган минутларда ул үзен җинаятьче урынына куеп карый торган иде. Хәзер дә шулай эшләде. Хорошев урынында булса, сүз дә юк, тынычрак, кеше аз йөри торган берәр почмакта, тавышгауга басылганчы көтәр иде. Яшь, таза ир-ат хатын-кыз булган җирдә генә озак яшеренеп ятарга мөмкин. «Әйе,— диде ул, үз-үзенең фикерен раслап.— Бәлки кырмыска оясындагы кеше ул булмагандыр? Хорошевның дусларын аның белән интим тормышта булган хатын-кызлар аша эзләсәң генә. Пономарев та, Чихирев та, Горелов та берни белми». Озерцов, аягына кемдер кагылып китүен тоеп, башын күтәрде. Аның аяк очында, кулына күлмәген тотып, коену костюмыннан гына Светлана басып тора иде.

— Исәнмесез, Александр Сергеевич, әллә танымыйсызмы?— диде ул, мөлаем елмаеп.

— Сине, Светлана, Аллаһы тәгалә үзе җибәрәдер миңа. Укулар барамы?

— Барсаң — бара, бармасаң йокланып калына. Мондый эссе көннәрдә кемнең әкият тыңлап утырасы килсен. Ә сезнең хәлләр ничек? Тотып буламы соң әле Хорошевны?

— Син каян беләсең аның качканын?

— Участковый әйтте. «Теге бандит тагын качкан»,— диде.

— Кайсы участковый?

— Фамилиясен оныттым.

— Мәүлетовмы?

— Шул.

— Мәүлетов та, Мәүлетов диләр, нинди̇рәк кеше соң ул? Картмы, яшьме дигәндәй?

— Утыз яшьләр тирәсе. Чегәннәрнеке кебек кара бөдрә чәч, яһүдләрнекенә охшаш борын.

— Алай икән. Күптән эшлиме?

— Өч ел тирәсе.

— Сезнең якныкымы?

— Хатыны гына безнең районныкы. Алар әлек кайдадыр Урта Азиядә яшәгәннәр. Ул ниндидер заставада прапорщик булып хезмәт иткән, ди.

— Кузгалабызмы, Света.

— Боерсагыз?

— Боермыйм, чакырам.

Киенеп, тротуарга чыккач, алар артыннан тагын өч егет иярде. Светлана, нидер сизенгән сыман, «Әллә троллейбуска гына утырабызмы?» — диде.

— Каршы килмәсәң, җәяү генә кайтыйк. Ял да булыр.

— Кунакханәдә торасызмы?

— Әйе. Ә син?

— Тулай торакта. Бер бухгалтер кыз белән тора идек тә, кичә укуын бетереп кайтып китте. Аулакта калдым.

— Димәк, без икебез дә аулак өйдә икәнбез.

Светлана, Озерцовка елыша төшеп: «Әнә, теге өч егет безнең арттан килмиләрме?» — диде.

— Кемгә кирәк без? Син — авылдан, мин — Мәскәүдән.

Бераз сөйләшеп баргач, аулаграк урынга җиткәндә, Озерцов үзенә эндәшкән тавышка борылды.

— Әй, мужик, туктале, сөйләшәсе бар!

Егетләрнең уртадагысы Озерцовка якын ук килде. «Кайда күрдем бу егетне,— дип күз алдына китерергә тырышты Озерцов.— Нәкъ шул, кунакханәдән чыкканда ботинкасының шнурын бәйләп тора иде. Нәрсә бу? Эзәрлекләүме? Әллә очраклы хәлме?»

— Тыңлыйм,—диде ул тыныч кына.
— Сигаретың бармы?
— Тартмыйм.
Егетләрнең өчесе дә, якын ук килеп, ике яктан бастылар.
— У-һ-у, нинди чибәр кыз, өчебезгә дә җитә. Ничек, егетләр, алып китәбезме?
— Йә, бирәсеңме кызыңны?
— Йә, кайсыгызга бирим?!—Озерцов, берсенең кулыннан эләктереп, кискен генә үзенә таба тартты да, кул кыры белән муен тамырына сукты һәм, яшен тизлеге белән, икенче егетнең аягыннан эләктереп алып, махсус ысул белән борды. Ләкин өченче егетнең арттан сугуы аны аяктан екты. Озерцов, мәтәлчек атып китеп, сикереп торды. Муен тамырына сугылган егет селкенми дә ята иде. Егетләрнең берсендә пычак ялтырап китте. Озерцов, үзенең шунда мәңгегә ятып калачагын аңлап, каратэ ысулы белән пычакны сугып очырды, иң соңгы чиктә генә кулланырга рөхсәт ителгән чара белән сугып, егетне җиргә сеңдерде.
Җирдә яткан егетләрне милиция машинасына утыртып җибәргәндә Озерцов, үзенең кем икәнлеген аңлатып, хулиганнарны иртәнгә кадәр җибәрмәскә боерды.
— Алар миңа тикшерү эше буенча кирәк,—диде ул машинадагы өлкән лейтенантка.
Машина киткәч, Светлана Озерцовның муенына сарылды да сулкылдап-сулкылдап елый башлады.
— Бу нәрсә инде?! Менә сиңа, мә!—диде Озерцов, кызның чәченнән сыйпап.—Йә, йә, ела. Була ул кайчак, курыкканнан...
Калган юлны кунакханәгә кадәр такси белән кайттылар.
Нидәндер куркып, тынып калган кызны Озерцов кофе белән сыйларга уйлады:
— Бераз ял алыйк, стрессны бетерә ул,—диде.
— Шулай шул. Стресс белән Хорошевны тоталмассыз.
— Аны тотасы калмады инде, Светочка. Ул күптән теге дөньяда, диделәр милициядә.
— Ничек?
— Үтергәннәр аны.
— Абау, алла. Әллә ничек, кызганыч булып китте. Ә кем үтергән?
— Их, белсәк икән дә бит. Белмибез.
— Розасы елар инде.
— Нинди Розасы?
— Бар иде аның ирдән кайткан бер хатыны. Үзеннән алты-җиде яшькә олымы шунда.
— Каян беләсең аның андый кешесе барын?
— Хатын-кыз ни белмәс...
— Шулай да?
Озерцов, табын әзерләвеннән бүленеп, Светлана янына килеп утырды.
— Йә, сөйлә инде, Светочка, интектермә. Минем өчен бик мөһим яңалык бу.
— Ике ел элек, кышкы сессиягә килгәч, бер кыз белән танышкан идем. Әтисе каядыр обкомда эшли иде. Кунакка чакырды. Дүртенче катта торалар. Без, шәһәрне карарга дип, балконга чыгып баскан идек. Карыйм, бер хатын белән култыклашып, безнең Сергей чыгып бара. Хатын-кыз белән булгач, эндәшергә яхшысынмадым. Аннары теге кыз сөйләп бирде. Әнә, Роза тагын үзенең сөяркәсе белән чыгып китте, диде. Ул подъездда Розаның әнисе тора икән. Берүзенә өч бүлмәле квартирасы, ди. Розасы, иреннән аерылган, икенче бер җирдә тора, имеш.

— Розасының кайда эшләгәнен әйтмәдеме?
— Мин кызыксынмадым, Оля әйтмәде.
— Квартирасын хәтерләмисеңме?
— Оля җиденче катта дигән кебек хәтерлим. Алтмыш бишенче квартирадан, диде бугай. Мин әле үземнең туган ел белән чагыштырдым.
— Урамы белән йорт санын да әйтсәң, мин — сиңа мәңге бурычлы.
— Күрсәтүен күрсәтә алам, болай белмим.
Озерцов, сәгатенә карап алды да, кызның иңбашыннан кочты.
— Хәзер, такси алабыз да, син миңа ул йортны күрсәтерсең, яме?

* * *

Ишекне урта яшьләрдәге, мөлаем йөзле сылу хатын ачты.
— Сезгә кем кирәк? — диде ул ишекне ярты лаш ачып.
Озерцовның артында басып торучы милиция лейтенанты алга таба атлады:
— Мин яңа участковый, үтәргә рөхсәтме? — диде.
— Рәхим итегез.
— Мөмкин булса, сезнең белән якыннан танышу йөзеннән, бу фатирда кемнәр торганын ачыклар идем, — диде лейтенант.
— Без икәү генә. Мин дә ирем. Иптәшем әле эштән кайтмаган. Сабировлар без. Мин Румия Гайнетдиновна, врач, ирем — трест управляющие Наил Зарипович, — диде квартира хуҗасы.
— Тирә-як күршеләрегез яшәргә комачауламыймы? Тавышланмыйлармы, дигәндәй?..
— Ул яктан зарланган юк, аллага шөкер, күршеләрдән уңдык. Егерме дүртенче квартирада — замминистр. Бик әдәпле, бик яхшы кешеләр. Егерме бишенче квартирада — пенсионерка, Мария Афанасьевна. Ул, гомумән, ялгызы.
— Бөтенләй ялгызмыни? — дип сорады лейтенант.
— Ирдән аерылган кызы бар, тик ул монда килеп кенә йөри.
— Аларның да квартирасы ике бүлмәлеме?
— Өч.
— Мул яши икән. Күпме кеше квартирага тинтерәп йөри, квартирант тотса, бераерсенә файда булыр иде бит.
— Ниндидер буйдак кертте кебек, инженер, диделәр шунда.
— Квартирантын күргәнегез бармы?
— Берничә тапкыр күрдем болай. — Хуҗа хатын, нидер сизенгәндәй, бер Озерцовка, бер лейтенантка карап алды.
— Менә шул түгелме? — диде лейтенант, хатынга фоторәсем сузып.
Хуҗа хатын, текәлеп карап торгач, «ул», — диде.
— Румия Гайнетдиновна, сез, берәр төрле сәбәп табып, ул әбине монда чакырмассызмы икән?
— Хәзер була ул. Без еш кына икәү бергә чәй эчәбез. Әле бүген генә лимон да алып кайткан идем, — дип, хатын күршеләренә кереп тә китте.
Күрше әби, милиция киемендәге кешене күреп, тукталып калды:
— Батюшки, синдә кунаклар бар икән, күрше, исәнмесез, — диде ул.
— Мария Афанасьевна, рәхим итегез, утырыгыз, — дип, Озерцов урын күрсәтте. — Сез безне, зинһар, гафу итегез, чакырттырып керткән өчен. Мәҗбүр булдык. Сездә квартирант егет тора икән.
— Әйе.
— Аның исем-фамилиясен әйтсәгез икән?

— Исеме — Сергей, фамилиясе — Волков. Инженер. Нефть трассасында эшли. Бик тәртипле, әдәпле, эчеп борчымый. Янына беркем дә килми дисәң дә була. Ә ни булган? Прпискасы бар.

— Пропискасы сездәме?

— Башка җирдә. Мин прописка бирергә шикләндем, хәзерге яшьләргә ышан.

— Күптән торамы?

— Бер ел чамасы.

— Волков сезгә танышлык буенча килдеме, әллә берәр туганыгыз-фәләнме?

— Кызым алып кайткан иде.

— Волковның сезгә элек килгәне булмадымы?

— Юк...

«Светлананың әйтүе буенча, аның Хорошевны бу йортта күргәненә ике елдан артык вакыт узган. Карчык белмиме, әллә ялганлыймы?» — дип уйлап алды Озерцов. Аннары, кесәсеннән фоторәсем алып, карчыкка сузды.

— Бу улмы?

Карчык, фоторәсемне әйләндереп-әйләндереп карады да, авыр сулап: «Ул», — диде.

— Волков өйләнгәнме?

— Кем белсен инде, буйдак, ди...

— Кызыгыз сезнең белән торамы?

— Розаның үз фатиры. Ирдән аерылды, балалары булмаганга.

— Кызыгызның эш урыны кайда? — дип сүзгә кушылды лейтенант.

— МВДыда, майор.

Озерцов белән лейтенант үзара күзгә-күз карашып алдылар. Һәрберсенең карашында аптыраш иде.

— Квартирантыгызның бүлмәсендә бик бармы?

— Аллам сакласын...

— Кергәч тә ул кайсы яктагы бүлмәдә?

— Аның бүлмәсе — сул якта.

— Мария Афанасьевна, хәзер сезнең монда калып торуыгыз кирәк. Без сезгә керәбез. Сезнең квартирантыгыз куркыныч җинаятьтә гаепләнә, — дип, урыныннан кузгалып, Озерцов лейтенантка ишарә ясады. — Аннары, Мария Афанасьевна, сез беркая да чыкмаска, беркемгә дә шалтыратмаска тиеш буласыз.

Карчыкның өй ачкычын алып, Озерцов лейтенант белән коридорга чыкты.

— Лейтенант, хәзер бергә керәбез. Аңарда корал булырга мөмкин. Бусы — бер; икенчедән, өйне опергруппа чолгап алды дип хис итик. Әгәр мин уйлаганча булса, сез чыгып торырсыз.

Озерцов, ишекне ачып, сак кына өйгә узды. Керүгә — киң, зур коридор, идәндә — келәмнәр. Як-якта — бер-берсеннән аерым өч бүлмә. Мария Афанасьевнаның әйтүе буенча, Хорошев сул яктагы бүлмәдә булырга тиеш иде. Лейтенант ишек төбендә калып, Озерцов аяк очына басып бүлмәгә таба атлады. Иң элек ванна белән туалет ишекләрен тикшерде, аннары бүлмә ишеген ачты. Хорошев китап укып ята иде. Озерцовны күргәч, үз күзенә үзе ышанмагандай, ашыкмый гына торып утырды. Күзләре, исәрләнгән кешенеке сыман, як-якны айкап алды да, ни әйтергә белми, авызын ачып катып калды.

— Хорошев, тагын бер акылсызлык эшли күрмәгез! Өй опергруппа белән чолганган. Качарга юл юк. Яшисең килмәсә, тәрәзәдән сикерергә генә мөмкин. Балкон аша качарга ниятләсәң, Румия Гайнетдиновналарда безнең кеше утыра. Коралыңны өстәлгә чыгарып куй, — диде Озерцов, кулын кесәсеннән алмыйча.

— Сезгә нинди корал кирәк, автоматмы, пулеметмы? — дип. мәсхәрәле көлемсерәде Хорошев.— Тырыштыгыз, гражданин нәчәльник. Ерак китәрсез. Комиссар Каттанидан да уздырасыз хәтта.

— Эш хакын акларга тырышабыз.

— Бер окладка шул хәтле чүп казып чыгаргач, премия бирүләре дә бар.

— Бирерләр, бирерләр, минем өчен кайгырма. Кайсы миллионер өч йөз җитмеш биш мең сум акча бирде һәм ни өчен? Наркотиклар каян килде сиңа? Син аны кемгә бирергә тиеш? Кырмыска оясына үтереп ташланган егетне дә онытма!..

— Нинди кырмыска оясы?! Минем беркемне дә кырмыска оясына салганым булмады! — дип кычкырды Хорошев.

— Паспортың кемдә?

— «Борча»га бирдем.

— Кем ул «борча»?

— Мөдәррисов Рәфкать.

— Кайда эшли, нинди кеше ул? Нигә аңа паспорт?

— Озын буйлы, тәкәббер генә, алкашка охшаган бер бәндә, эчәргә дисәң — үлә. Кайдадыр замначальник булып эшли. Килде дә, шеф синең паспортны алырга кушты, ничу ике паспорт белән яшәргә, дип алып китте. Икенче көнне, шул ук Мөдәррисов шалтыратып, шеф сине, борчылмасын, өйдә генә ятсын диде, дип, Волков фамилиясе белән паспорт китерде.

— Кем ул «шеф»?

— Белмим, беркайчан да күргәнем булмады. Кемне, кайда үтергәннәр — белмим һәм беләсем дә килми. Башка берни дә сөйләргә җыенмыйм һәм теләмим дә. Акча белән наркотикларны вакытлыча куеп тордылар. Вакыты җиткәч, килеп алырбыз, диделәр. Вәт, бетте-китте...

Озерцов Хорошевның маңгаендагы яра эзенә карап торды:

— Павел Нариманов белән каравылчы карт, старшина Әгъзамов гонаһы. Акча һәм наркотиклар. Леспромхоз юлында үтерелгән бухгалтер һәм башкалар. Җинаять йөгең зур бит, Хорошев. Нәрсә коткәнне үзең дә яхшы сизәсеңдер. Уйла, Хорошев, уйла. Кемнәргәдер гомер буләк итеп, үзеңне кая тыгарга җыенасың?

Озерцов, уйларга вакыт калдырмыйча, сорауларны яудырды. Шул вакытта гына җинаять тулысынча ачылырга мөмкин иде.

Хорошев, терсәкләренә таянган килеш, куллары белән йөзен каплады да, йодрыгы белән кискен генә өстәлгә сугып, биш катлы итеп сүгенде. Яшькелт күзләре усалланып, ерткычларга хас бер караш чаткысы чагылып китте.

— Давай, нәчәлник, яз, даңгыр-дуңгырын, барысын да яз, сөйлим, яшерен-батырыннан түгел. Тик бер шартым бар, мине аерым камерада тотсыннар, югыйсә, үтерәчәкләр. Аларның кулы озын. Тик сез мине бүлдермәгез... Армиядән кайткач, төрле җирләрдә эшләп алдым. Соңрак алтынчы РСУда грузчик булып эшләдем. Яхшы эшли идем. План дисәң — план. Бригадир итеп куйдылар. Бераздан тагын күтәрелдем. Беркөнне трест управляющие чакыртты да: Хорошев, сине ЖККа начальнигы итеп куярга булдык, ди. Ярдәм итәрбез, ди. Ни дисәң дә — нәчәлник, машина үз кулыңда. Конторада йөз җитмеш адәм актыгы иде. Кая борылма — алкаш. Кыскасы, кон дә пакуй юк, тон да пакуй юк, ел ярым эчендә ЖККаны тәртипкә салып, эшләрне нык җайлап җибәрдем. Башта эндәшми йөрдем. Күрәм, эшче халык баласын күтәреп елап йөри. Торырга урыны юк, ә монда — горисполком аркылы — ахириләргә дә, сояркәләргә дә, дусларның сояркәләренә, сояркәләренең ахириләренә кадәр квартир биреп яталар. Өч ел теш кысып эшләдем. Бервакыт, туктале минәйтәм, миңа да җаван бирергә туры килмәсен, дип баш күтәрә башладым. Мин, баштарак,

квартираларны фальшивый ордер белән биргәннәрен белмәдем. Соңыннан гына сиздем. Аннары берәүләре чыгып китә, пропискага кергән кеше ике-өч бүлмәле квартирада кала. О... Андагы шухер-мухерны сөйләсәң, ахырына чыгарлык түгел. Кыскасы, горисполком белән милиция — кода белән кодачалар. Кәгазьләр — акчага, акча алтынга әверелә торган урын. Шул хакта горкомга яздым, мине эштән кудылар, ә горкомның бер кабахәте Сальников управляющий булып килде.

Хорошевның, гасабилануыннан, битендәге мускуллары тартыша башлады.

— Сальников белән элек таныш идеңме?

— Юк.

— Соңыннан кем икәнлеген белдеңме соң?

— Аңлап бетермәдем.

— Кыскасы, Сальников белән Наримановлар арасында нинди уртаклык бар?

— Ә... сез аны әйтәсезме? Безнең як кияве икәнен соңыннан гына белдем.

— Павелны үтергәндә аларның кияве икәнен белә идеңме?

— Әйе.

— Дәвам ит.

— Җыен әкәм-төкәм, хайваннарны фаш итә торган документларның нөсхәләрен әмәлләп, дөреслек эзләргә Мәскәүгә киттем. Ике тапкыр Үзәк Комитетта булдым. Документлар Мәскәүдән — обкомга, обкомнан — горкомга, яңадан шул ук Сальниковка кайтып төште. Аптырагач, теге кысык күзле Әмиров янына бардым, законның исе дә килми. Утыралар кәбестә сатучылар белән булышып.

— Кем ул Әмиров?

— Район прокуроры.

— Кайсы районныкы?

— Прокурорлар аунап ятмый, кирәксә — табарсыз. Ну, шуннан эчә башладым. Горком, обком әкәм-төкәмнәрен бәреп үтерердәй булып йөргәндә Гафиятулланы очраттым.

— Фамилиясе?

— Гиниятуллин. Барысы өчен дә ул — Гафиятулла. Пенсионер. Пенсионер булса да, бите шома, яшь этәчнеке кебек, кып-кызыл. Кыскасы, үзе янына эшкә чакырды. Безнең трестның агач эшкәртү комбинаты эчендә алма бакчасы бар. Алма бакчасында — теплица, теплица кырыенда — мунча. Ул — шул хуҗалыкның бердәнбер хуҗасы. Бакча түгел, оҗмах. Алма агачлары арасында умарта оялары. Мунчасында мәрмәрдән ясалган бассейн, сауна, чәй бүлмәсе. Икенче катта бильярдный, сөяркәләр белән ял итәргә, кәеф-сафа ачарга махсус бүлмәләр. Гафиятулла абзый мине шунда үзенә ярдәмче итеп алды. Дөреслек эзләп йөрисең, дөреслек ул — яши белмәгән җыен диваналар өчен генә, ди.

— Мунча турында конкретрак. Кайда? Нинди җирдә?

Хорошев, терсәгенә таянган килеш, борын очын тотып нидер исенә төшереп торды.

— Трестның агач эшкәртү комбинаты бер генә җирдә. Мунчадан йөз-йөз илле метр — елга. Яр кырыенда — катер, моторлы көймәләр. Нәчәлство,канишне, күпчелек вакытта «Волга»ларында килергә ярата. Машинада яшь, чибәр кызлар була. Берсендә Әмиров килде. Кәеф ача торгач, прокурор нык исерде. Мин дә югалып калмадым, тоттым да, тегенең гүзәл сөяркәсен үз бүлмәмә алып кереп, бөтен ачуны алдым.

— Ничек?

— Шәрә хатын белән нишлиләр? Вәт шуннан китте, шуннан китте минем эшләр җайга салынып.

— Кем иде ул?
— Роза Алексеевна.
— Мария Афанасьевнаның кызымы? Роза Алексеевнаның роле нидән гыйбарәт?
— Каян белим. Мин аңа эш кушмыйм бит.
— Каравылчы картны нигә батырып үтердегез?
Хорошевның күзләрендә үҗәтлек утлары кабынды:
— Сорасагыз — бер нәрсә генә сорагыз. Бер сорауны уйлап бетергәнче, икенчесен бирәсез. Мин алай җавап бирә алмыйм.
— Монда сорауны мин алам, Хорошев. Сезнең эш — җавап бирү. Аңлашылдымы? — диде Озерцов тавышын күтәрә төшеп.
— Кем батырсын аны. Пычагыма кирәк иде! Таеп, үзе егылып төште. Караңгыда шәлперәйгән карт артыннан суга кем сикерсен?! Яшәргә теләгәч, бушлай килгән аракыга тыгынмасын иде.
— Син аны көчләп эчердең, Хорошев. Шулай түгелмени? Павел үтерелгәннән соң кем белән киңәштең?
— Нәрсә турында?
Хорошев аңламыйрак торды, башына барып җиткәч:
— Ни пычагыма кирәк ул сезгә? Әһлиуллин иректә. Аның башын «санатория»гә тыгарга мин ярдәм иттеммени? Сезнең коллегалар. Алар ришвәтне аз тамызсаң гына борын җыералар, анда да кешесенә карап, — дип өстәде. — Сержантлар өч тәңкәдән дә чирканмый, һәрберсенең үз бәясе.
— Син минем сорауга җавап бирмәдең.
— Хәтерләмим дисәм, барыбер ышанмыйсыз.
— Милициядән куылып, Киров өлкәсенә шабашкага киткән өлкән лейтенант Быков белән таныш идеңме?
— Ой, начальник, үтереп коласе килә дә, көлеп булмый. Кем инде милициядән китеп урман кисәргә барсын. Аның беркая киткәне булмады. Җүләрме әллә ул шабашкада йөрергә... Ул хәзер нинди кооперативта персидәтел. Сезгә бит аны сүз булсын өчен генә шыттырдылар.
— Ничек шыттырдылар?
— Күзгә карап. Барысы да сезнең кебек ак та, пакъ та булалмый, начальник. Намус белән тамак туймый, ди Сальников. Дөньяны акча йөртә. Акчаң булса — син кеше, булмаса — тфү! Акчаң булса — кем белән дә сөйләшергә була. Акча ул — ходай, начальник. Бер миллион тәкъдим итсәләр, әллә син кире кагар идеңме? Ничә мең козгын арасында йөреп, әллә ак козгын булырга ниятлисеңме?
— Бөтен дөнья акчага тәрәлмәгән, Хорошев. Күңелеңдә бушлык, салкынлык җилләре уйнаса, җаныңны бернинди акча белән дә җылыта алмассың.
— Буш сүз бу, начальник. Акылга сайлар сүзен әбиегезгә сөйләгез. Мин бер директорны беләм, — король кебек яши, аңардан хәтта райкомның беренче секретаре шүрли. Нәрсә тели, шуны эшли. Берәр чибәррәк кызны чакырып ала да, институтта укыйсың киләме, ди. Укыйсың килсә — кич белән килерсең, көтәм, ди. Ә соңыннан, кәнизәкләре берәр егетне табалар да, әгәр зур квартир, телефон, гараж, машина аласың килсә, шундый-шундый кызга өйлән, диләр. Өйләнмәсәң үзеңә начар була, диләр. Бетте-китте, вәссәлам. Ә сез, имеш, акча ул пүчтәк, дияргә җыенасыз. Мин дә заманында, сезнең кебек, ипи белән бәрәңге ашасам, бәхеткә саный идем. Ә чынлыкта алай түгел икән.
— Димәк, — дип бүлдерде Озерцов, — Павелны машина таптаган итеп күрсәтүчеләрнең берсе Роза Алексеевна, икенчесе прокурор Әмиров булып чыга?
Хорошев әшәке итеп сүгенде.
— Бик кызыксынсагыз, үзләреннән сорарсыз, — диде.

— Мин бит, Хорошев, Павелны акчаңны күргән өчен генә үтерүегезгә ышанмыйм. Сәбәбе башкада, син әйтергә теләмисең.

— Ну, даешь, син, гастролер мәскәүский!..

— Күзләреңә курку чыкты, Хорошев, курку! Наримановка кагылмаган булсам, рәхәтләнеп яши идем әле дип үкенәсеңме?

Хорошев, күзләрен зур итеп ачып, Озерцовка карап торды:

— Сезгә фантаст кына булырга калган!

— Бу фантастика түгел, версия. Ә ул тәҗрибәгә килеп бәйләнә. Иртәме-соңмы чын сәбәбен әйтәчәксең. Синең абзаң Овсянников, беләсеңме, ни өчен акылдан шашып берничә көн эчендә үлде? Чонки сугыш вакытында кешеләр атып торган. Ә аларның күпмесе гаепле дә, күпмесе гаепсез булган. Менә, кешенең психикасы түзалмый. Юкка гына белмәмешкә салынып утырасың. Ну?

— Чүп өстенә чүмәлә өяр хәлем юк! Бигайбә.

— Павел тагын нәрсә күрде?

— Җир йотсын дип әйтәм, белмим.

— Гафиятулла ни өчен утырган? — дип сорады Озерцов, Хорошевны сынап карар өчен генә.

— Ул суфыйдан белерсең! Ниндидер зур махинацияләр аркасында утырган булган, дип кенә чалынган иде колакка. Ул бит ялангач тәннән йон кырка торган кеше.

— Хәзер леспромхоз эшчеләренең зарплатасы синең кесәгә ничек килеп кергәнен сөйлә.

— Мин белмим. «Шахмара»дан сорагыз.

— Шахмара? Кем ул?

— Роза.

— Алексеевнамы?

— Ул булмыйча, кем булсын. Минем эш — разведка, ә калганын, кемнәр нәрсә башкарганын — белмим һәм кызыксынмыйм да. Акчаны «Шахмара» алып кайтты, анысы факт.

— «Якты таң» совхозына акча алып кайтучыларны үтерүчеләр кемнәр?

— Анысын участковый белсә генә.

— Мәүлетовмы?

— Сез, гражданин нәчәлник, гел җүләр сораулар бирәсез.

— Мәүлетов ниндирәк кеше?

— Яшел алма, — дип көлде Хорошев. — Ничек ашасаң да ярый. Пешкән килеш тә, чи килеш тә.

— Минңа аның турында барысын да белү кирәк.

— Кирәк нәрсәләр күп, болай да күп сөйләдем. Аларда иман юк, бүре өерендә — бүре законы.

— Шулай да, Мәүлетов ниндирәк кеше?

— Алла белсен. Кем ул, жуликмы, коммунистмы? Баптистмы? Бергә эчеп утырган булмады. Сөйлисен сөйләдем, җитәр. Вакыт әрәм итмәгез, чакырыгыз кәҗә тәкәләрегезне. Мин әзер, — дип кулларын сузды Хорошев.

— Төрмә синнән качмас, ашыкма, өлгерерсең. Һәр җинаятьче үз җәзасын үзе алырга тиеш. Ә син үзеңне баткаклыкка төртеп керткән әшәке җаннарны саклап калырга ниятлисең. Сукыр йөрәк сукыр күздән яманрак.

— Калын бауның төене зур була, гражданин нәчәлник. Сез миннән шул төенне чиштерергә маташасыз. Сезнең рәшәне күргәнегез бармы?

— Бар дип фараз итик.

— Рәшәне кулга тотып буламы?

Озерцов, Хорошевның нәрсә уйлаганын белергә омтылгандай, күзләренә текәлеп торды. Куе чәчле тар маңгай, бүренеке кебек чыгынкы яңаклар, тик күзләрендә генә борчылу сизелә иде.

— Мин сезгә үземнең ЖЭКта эшләгәнемне сөйли башлаган идем. Ни өчен дип уйлыйсыз? Мин, Сальниковның чын йөзен ачып салыр өчен, Үзәк Комитетта ике тапкыр булдым, ә бу нәрсә бирде? Сальниковны тагын да зуррак эшкә, обкомга алдылар. Сальников хәзер — минем ахири. Университетта укучы улы бераүне кочләде, соңыннан кызның үзен гаепле итеп чыгардылар. Кызның әтисе төрле инстанцияләргә яза башлагач, психбольницага эләкте, әнисе асылынып үлде, ә кыз соңыннан югалды. Мунчага алып килгән унбиш-унҗиде яшьлек кызларга наркотиклар биреп рәхәтләнәләр иде, сволочлар. Аларда власть, акча. Акчаның каян килгәнен алар гына белә.

— Ә син?

Хорошев җилкәсен сикертте.

— Димәк, мунчаның хуҗасы Гафиятулла иде? Дөрес аңладыммы?

— Әйе.

— Менә син Гафиятулла янында эшли башладың. Синең вазифа нидән гыйбарәт булды?

— Килгән кешеләргә самавыр куярга, өстәл әзерләргә. Арка чабасың, каен миннегә белән, җитми калганда — аракыга йөгерәсең. Аннары миңе нинди-дер пакетлар, дипломнар белән йомышка йөртә башладылар. Роза белән йөри башлагач, доверие икеләтә артты.

— «Москва—Томск» поездыннан алган чемоданны кемгә бирдең?

Хорошев, күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп карап торды. Аннан соң әйтте: «Гафиятуллага!» — диде.

— Чемоданда нәрсә иде?

— Хрен белсен аны.

— Ну, син бит Пономаревка өлешен бирдең?

— Шулай кирәк булган, ызначится.

— Карбыз алып кайтканга рәхмәт белдергәннәрдер бит?

— Юк. Аннан соң үзем Урта Азиягә киттем.

— Наркотиклар алыргамы?

— Чемоданны ачып карамадым.

— Соңгы партия наркотикларның адресы?

— Каттакургаңнан.

— Посылканы кайда, ничек тапшыралар иде?

— Баргач та чәйханәгә керәсең. Анда Чәйханщик янына килеп чәй сорыйм. Ул: «Сезгә чәйне пыялада биримме, әллә татарчамы?» — ди. Мин аңа: «Икенче сортлы индийский чәй яратам, пыялада»,— дип җавап бирәм. Посылканы поезд киткәндә станциядә ала идем.

— Кемнән?

— Прапорщиктан, йә үзбәктән.

— Прапорщик белән ничә тапкыр очраштыгыз?

— Өч.

— Наркотикларга Мәүлетовның нинди катнашы бар?

— Соңгы очрашуда прапорщик: «Ничек анда безнең Мәүлетовның хәлләре?» — дип сорады. Алар бергә погранзаставкада хезмәт иткәннәр.

«Менә нәрсәдә хикмәт. Димәк, Хорошевны коткаруның сере дә наркотикларга бәйләнгән. Менә ни өчен Мәүлетов кыбырҗыган. Бәлки, Хорошевны да әллә кайчан йомдырган булырлар иде дә, кемнедер комсызлык тота», дип уйлады Озерцов.

— Соңгы партия наркотикларны нигә өендә яшердең?

— «Шахмара» шулай кушты. Минемчә, алар анда нәрсәдер бүлешә алмыйлар кебек.

— Кемнәр «алар»?

— Мин сезгә нәрсә, күрәзәчеме әллә? Һаман төпченәсез дә төпченәсез.

— Роза Алексеевна белән Мәүлетовның очрашканнары булдымы?

— Энә тишегеннән доя күрергә маташасыз, гражданин нәчәлник. Сез менә мине кызганасыз, ә мин — сезне. Үзегез әйтмешли, бу хәтле зур багаж белән Мәскәүгә кайтармаячаклар сезне. Алар сезне анда, Мәскәүдә дә табачаклар. Кирәксә.

— Җитәр, Хорошев! — диде Озерцов кискен генә. — Ахмак сүзләрдән болай да гарык. Овсянников әтиең калдырган нинди хат тапшырды?

— Ни пычагыма бәйләндегез әле шул хатка?! Ата кеше ни әйтеп калдырмас. Сезгә барыбер түгелмени?

— Барыбер булса, сорау да бирмәс иде.

— Әти колхоз сарыгын суеп ашагач, Мәүлетовның әтисе белән бергә зонада булганнар. Әти аны ничектер үлемнән коткарып калган. Авыр чагында аңа мөрәҗәгать ит, ярдәм күрсәтер, дигән язу калдырган.

— Соң ничек? Ярдәм иттеме?

— Сталин заманында төрмәдән кайтканнар озак яшәгәннәрме соң? Хәзер генә ул төрмәдә армиядән дә яхшырак. Эшләсәң-эшләмәсәң дә ашаталар.

— Мәүлетовның әтисе кайда яшәгән?

— Үзбәкстанның Иштихан районында.

— Мәүлетов үзе хәзер кайсы авылда тора?

— Чиялектә.

— Син миңа шуны әйт, Павел Наримановны кырда кыйнап калдыргач, ни өчен Пономарев белән кире борылып бардыгыз?

— Каян алдыгыз моны? Без кайттык та йокларга яттык. Кем әйтте шундый ялганны? Кая дәлилегез?

— Башны катырма, «Штирлец» әбиеңне белсәң, сорауга җавап бир.

— Дурак булганга бардык, алайса.

— Бүре каргышы сарыкка төшми, Хорошев. Менә сиңа кәгазь, авторучка. Монда сөйләп узган кешеләрнең эш урыннарын, адресларын яз. Кемнәр Гафиятулла йортында йөри? Мунча аша узган хатын-кызларның исем-фамилияләрен, эшләгән җирләрен төгәлрәк күрсәт. Наркотиклар турында энәсеннән җебенә кадәр яз.

— Ну, нәчәлник, кулыңны чылатмыйча бит юарга каян өйрәндең шул хәтле? — диде Хорошев, пләшләнә башлаган түбәсен кашып.

— Мин бит, Хорошев, сине кулга алмыйча да чыгып китә алам.

— Ничек?

— Иректә калдырам да китәм. Шәһәрдән качарга гына мөмкинлек бирмим.

Хорошевның кашлары маңгаена менде. Ул, уйлап торды-торды да, шашынып көлеп җибәрде:

— Сез, мине кулга алмыйча, домашний арест ясыйсызмы? — дип кул чабып көлгән җиреннән шып туктап тынып калды. Утырган урыныннан күтәрелә төшеп, кулына авторучка алды.

— Хәйләкәр кеше син, Озерцов.

— Хәзер генә барып җиттеме?

— Деннәрен өшкерим, беткән баш беткән! Баткан икән, барысы да чумсыннар.

Озерцов, барып, лейтенантка пышылдап кына, оператив группаны чакырырга кушты да, тәрәзә каршына баскан килеш, күз кырые белән генә Хорошевны күзәтте.

Тикшерү эше тагын да катлауланачак, авыраячак икәнен ул хәзер генә төшенә башлады. Димәк, телефоннан шалтыратып янаулары, ришвәт тәкъдим итүләре юкка гына булмаган. Аларның башларына, Хорошев табылыр, дигән уй килми дә. Хәйләкәрлек җиде катлы. Мәүлетов белән Хорошев турыдан-туры элемтәдә торалардыр дисәң, ни өчен ул, сорамаган да килеш, Мәүлетовны ачып салды? Мәүлетов

белән прапорщикны «бәйләп» погранзаставага китереп терәде. Гаҗәп, бауның иң четерекле төене менә кайда булырга мөмкин. Хорошев белән ачыктан-ачык сөйләшү шәп булды.

Шикле кешеләр күренми микән дигәндәй, ул урамга күз салды. Әнә, агач йорт капкасы төбендә кыз белән егет кочаклашкан. Йортны сала белгәннәр — урыны аулак, тыныч, трамвай, троллейбус, машиналар йөрми. Завод-фабрика морҗалары да күренми. Озерцов Хорошевка күз салды. Ул иренен чәйни. Маңгаена тир бөртекләре бәреп чыккан.

«Тырыш-тырыш, хәшәрәт, барысын да яз. Ничә кешенең башына җиттегез, кабахәтләр,— дип сүгенде Озерцов эченнән генә.— Иртәгә, Мәскәүгә шалтыратып, ярдәм сорарга кирәк. Берләшеп ауласаң, бүре түгел, арыслан да җиңелә».

Озерцовны уйларыннан арындырып, ишектән милиция лейтенанты тыгылып карады, ишарә белән генә нидер аңлатты. Бу аның, опергруппа килде, диюе иде.

Хорошев язып бетергәч, Озерцов җентекләп укып чыкты да: «Конвойдан ничек, кемнәр коткарганын язарга онытканский»,— дип, кире өстәлгә куйды.

— Төкерим сана мильтоннарыгызга. Шул сасы кәҗә тәкәләре булмасамы,— дип, Хорошев усал итеп сүгенде.

— Син яз, яз,— диде Озерцов.— Үз муеныңа салынган элмәкне алырга теләсәң, яз!

— Белмим мин ул фиргавеннәрне. Имандыр. Берсе капитан, икенчесе лейтенант киеменнән иделәр. Башта үзем дә курыктым. Мине дә расходка җибәрерләр дип.

— Нинди машина белән иделәр?

— «Нива».

— Номеры?

— Күзең-башың аларган чакта номер кайгысымы анда?

— «Нива» белән кая алып кайттылар?

— Сальников дачасына.

— Аннары?

— «Шахмара» килгәч, монда кайттым.

— Капитан белән лейтенантны элек күргәнең бар идеме?

— Юк.

— Күрсәң таныр идеңме?

— Сез нәрсә, мине томанага санайсызмы?

— Акыллы булгач, мә, яз, мине коткаручыларның берсе милиция капитаны, икенчесе өлкән лейтенант, дип яз.

— Кыскасы шул,— дип, язасы урынга сөйли башлады Хорошев.— Авылда әнинең ике кечкенә иконасы бар. Шуларның берсендә фотопленкалар яшерелгән. Аларның бәясе хисапсыз. Кайбер рәсемнәрне монда да саклыйм.

— Күрсәт.

Хорошев, карават астыннан чемоданын тартып чыгарды да, ачып, киемнәрен бер читкә ташлады. Җайлап кына чемоданның яшерен төбеннән фоторәсемнәр чыгарып, өстәлгә ыргытты.

— Классный порнография.

Озерцов, фоторәсемнәрне карап чыккач, арадан берсенә тукталып калды. Тәнен билдән түбән сөлге белән урап, яшь кенә чибәр ханым белән бокаллар чәкештереп утыручыны танып алды ул. Бу — Шакирҗанов иде.

— Бу кем? — диде ул, рәсемгә күрсәтеп. Хорошев, күзләрен түшәмгә төбәп, телен шартлатып куйды:

— Ялгышмасам, судья. Нигә сорыйсыз?

— Бу порнографияләрне хозурланып карар өчен генә бирмәгәнсеңдер, дип уйлыйм.

Хорошев, фоторәсемнәрне алып, кемнәр икәнен санап китте:

— Менә бусы — Сальников, үзенең себеркесе белән. Погорелов, Ходжаев. Менә бусы Сальниковның мединститутта укый торган кызы, минем ахири белән. Ботларын ничек күтәргән! Фахишә. Син аптырыйсыңдыр, нәчәлник, ни өчен төшердем диген? Үч. Үч алдым мин ул үләтләрдән. Алар миңа ышаналар. Миңа шул гына кирәк иде. Әгәр артларына су төшсә, алар бөтен пычракны, әшәкелекне минем өскә өеп куячаклар иде. Күзгә кереп торган дәлил булганда кемне дә кулда тотарга мөмкин. Кызганыч, үчләремне алып бетерә алмадым. Инде соң.

— Нәрсә соң?

— Күрәсең,, шурлаганмен, дурак,— дип сүкте Хорошев үзүзен.— Мунча кергәндә ул исерекләрнең сауна ташына тавык тизәге шикелле нәрсә ыргытсаңмы?!

Хорошев җанланып китте. Бит алмалары алланып чыкты. Усал күз карашында нәфрәт чаткылары уйный башлады. Аннары ул мышкылдап елап җибәрде. Һич көтелмәгәндә, Хорошевның җаны әрнеп, үкенеп балаларча елавыннан Озерцовның үзенең дә күңеле әллә ничек йомшарып китте. «Ихтимал, аның сүзендә дә хаклык бардыр! — дип уйлады ул.— Барыбыз да доньяга нәни, нарасый булып туганбыз. Тик кешеләрнең бер-берсенә карата гаделсезлеге аркасында килеп чыккан сәбәпләр кемнедер ялгыш юлга юнәлдереп җибәрәдер. Кем моңа гаепле, кайда хаклык? Дөреслек эзләп Үзәк Комитетка, обкомга, прокурорга барган вакытта таяныч тапкан булса, бәлки, чыннан да, бу хәлгә калмас иде бу егет».

Озерцов Хорошевка төбәлде. Ул, сыгылып төшкән дә, тавышсыз гына елый. «Әйдә, бераз тынычлансын,— дип уйлады Озерцов.— Бер яктан кызганыч та. Икенче яктан... Аның күңеленә начарлык хәзер генә килгәнмени? Юк, әлбәттә. Гаделсезлек бит ул, агу сыман, җанга җыела килә-килә дә, имансызлык оеренә әверелеп, башкаларның язмышын җимерә, сындыра, зәгыйфьләндерә башлый».

Хорошев, битендәге яшь бөртекләрен бармак очлары белән генә сөртеп алганнан соң, Озерцовка күтәрелеп карады.

— Син үч алу турында сөйләдең? Конкрет кемнән һәм ничек үч алдың?

— Мин әле хәзер генә үч ала башлыйм.

— Ничек?

— Сальниковның улы көчләгән кыз югалды дигән идемме? Ул кыз югалмады. Аның дачасында типтергәндә улына марихуана бирдем.

— Аңа кадәр кулланмый идеме?

— Тыгына иде. Бир генә. Теге үләксәгә, исергәч, «сөйли күрмә, мин бер кызны йомдырып, суга ташлаган идем, сизмәсәләр ярар иде»,— дип әйткән идем, мәхлук җан, ачылды да китте. Пүчтәк ул, кайгырма, ди... Минеке дә кыяр түтәле астында ята, ди.

— Димәк, Сальников үзәк фигура?

— Әйттем же белмим дип. Бәлки, ул үзегезнең Мәскәвегездә үк утырадыр.

— Ихтимал, Вашингтонда, дип җибәрерсең?

— Шыр ахмакларны үзегездән эзләгез. Эткә сөяк ыргытсаң, орудән туктый ул. Шулай да, бер сүз әйтәм — баш ватар очен. Узган ел булды бу. Сирәк-мирәк кенә безнең мунчага ниндидер кешеләр җыелалар. Андый чакларда минем борынны да тыгылдырмыйлар.

— Хатын-кызлар була идеме? — дип бүлдерде Озерцов.

— Юк. Бервакыт качып тыңладым. Тик бернәрсә дә аңламадым. Берсе әйтә: доньясын хаоска китерергә, ди. Икенчесе: дөрес, ыгы-зыгы, тавыш-гауга күп булган саен яхшырак, ди. Кыскасы, сүз шәһәрне кулда тоту турында барды. Ә бер тавыш гел дә сирәк тыгылды. Вәт

шунысы: әйдә, чәйнәшсеннәр, үтерешсеннәр, сез күрмәгез, белмәгез, акчасын кызганмагыз, цыган дорожит ходом, ди.

— Бу мәсьәләгә әле кабат кайтып туктарбыз. Әлегә җитәр. Онытканнарыңны исеңә төшерә тор, Хорошев. Безнең сөйләшү озын булыр дип уйлыйм. Тик бер киңәш сиңа. Допросны киләчәктә фәкать мин генә алачакмын. Бүтән беркемгә бернәрсә дә сөйләмә. Бу синең иминлегең өчен кирәк.

— Турысын әйтегез, мине нәрсә көтә?

Озерцов, урыныннан торып, бүлмә буйлап узды:

— Барысы да үзеңнән тора,— диде ул кискен итеп.— Әгәр бүген сөйләгәннәрең хак булса, безнең арада да гадел кешеләр аз түгел. Җинаятьне ачыкларга ярдәм итсәң, бу искә алыныр.

* * *

Бераздан Хорошевны алып киттеләр.

Озерцов документларын, магнитофонын дипломатына салып китәргә җыенганда ишектә кыңгырау шалтырады.

— Лейтенант, могаен, әбидер. Ач әле.

Ишек төбендә хатын-кыз, милиция майоры басып тора иде. Лейтенант артындагы Озерцовны күреп, майорның йөзе сизелеп агарынды. Моны Александр Сергеевич та күрми калмады түгел.

— Сезгә кем кирәк иде? — дип, узарга дәшеп ишарә ясады.

— Әни янына,— диде майор кырыс кына.— Гафу итегез, ә сезне кем дип белергә?

Озерцов, таныклыкларын алып, майорга сузды.

Майор таныклыкны кире кайтарды да, уйларга вакытны сузар өчен, чәчләрен төзәткәләде:

— Сезне әни кунаклары дип аңларгамы? — дип, кухня ишеген ачып карады.

— Мария Афанасьевна күршеләрегезгә кергән иде. Сез Роза Алексеевнамы?

— Нәкъ үзе.

— Әнигез әйткән иде шул.

— Әни кунаклары да булмагач, нишләп йөрисез соң бу өйдә? Бик үк аңлашылып бетми.

Роза Алексеевнаның йөзендә елмаю чагылып китте. Ул үз-үзен кулга алып өлгергән иде инде.

— Без сезнең квартирантыгыз янына килдек.

— Әллә алиментлан качып йөриме?

— Прокуратураның аеруча махсус эшләр тикшерүчесенең алимент түләмәүчеләр белән шөгыльләнмәгәнен белергә тиешсез, Роза Алексеевна,— диде Озерцов.

Майор, иреннәрен бүлтәйтеп, гаҗәпләнгәндәй итте.

— Сер булмаса, нинди әшәкелек кылган соң ул?

— Әллә утырып сөйләшәбезме? — диде Озерцов.

— Чыннан да, нишләп аягүрә басып торабыз әле? Әйдәгез залга,— диде Роза Алексеевна.

Залның стеналарында һәм идәндә — затлы, кыйммәтле келәмнәр. Күзгедәй ялтырап торган җиһаз, матур-матур кытай фарфорыннан төрле сурәтләр, алтын йогерткән зиннәтле савыт-саба.

— Александр Сергеевич, нинди начар эш кылган соң әнинең квартиранты?

— Ничек дип әйтим икән сезгә.— Озерцов сынап майорга карады.— Хорошев узган ел үз авылларында унҗиде яшьлек егетне үтерүдә катнашкан. Дуслары белән бергә, әлбәттә.

— Нинди Хорошев турында сөйлисез сез?

— Аның чын фамилиясе Хорошев. Ялган паспортта ул — Волков.

— Абау! — диде хатын, гаҗәпләнеп. — Кара инде син аны. Елан. Менә җәлләп керт син аларны. Нинди оят, нинди гарьлек. Ни өчен үтергәннәр шул япь-яшь малайны?

— Тикшерү тәмамланмыйча кистереп әйтүе кыен.

Озерцов күз кыры белән генә майорның йөз-кыяфәтен күзәтте. Ләкин Роза берни дә булмагандай тыныч иде. Гафу үтенеп, бүлмәдән чыкты. Бераздан, өстендәге милиция киемен салып, бик матур бизәкле халат киеп керде. Озерцов елмаеп куйды.

Роза аның елмаюын үзенчә, хатын-кызларча кабул итте. Ләкин елмаюның сәбәбе башкада иде. Роза Алексеевнаның үзе һәм әнисе дә Хорошевны Волков дип баралар. Нәрсә бу? Алдан ук уйланылган хәлме? Әллә карчык белмичә буташтырамы? Светлананың әйтүе буенча, Хорошевны ул монда ике ел элек күргән, ә Волков исеменә паспорт ел ярым элек кенә алынган. Әгәр ул уйлаганча булса, карчык белән Розаның ялганы тотылачак.

— Роза Алексеевна, коллега буларак әйтегез әле, нинди рәк кеше ул Хорошев? Һичшиксез, дуслары да булгандыр.

Роза, дулкынлануыннан, сигарет алып кабызды. Хорошевның шундый кеше булып чыгуына гаҗәпләнгән, ачуланган төс алды ул.

— Кем уйлаган бит кабахәт кеше булыр дип, оятсызны, — диде ул сигаретын сүндереп. — Нәрсә әйтәсең инде. Миңа бит монда сирәк булырга туры килә. Үзегез беләсез, ОБХССта вакыт чикләнгән. Кыяфәтенә карап, тәртипле, итәгатьле егет дип белә идек. Килгән вакытта пальтоны салдырып, игътибарлы иде. Ни дисәң дә, инженер.

— Инженер икәнен үзе әйттеме, әллә?.. — дип капыл гына күтәрелеп туры карады Озерцов.

— Әни әйткән кебек хәтерлим... Мин әнине ачуланып та караган идем. Ялгызым кыен, иптәш булыр дигәч, бик каршы да килмәдем. Карт кешеләрнең сырхаулый торган гадәтләре дә бар бит. Уйлап-уйлап куям да, шаккатам. Кемне кыйнап үтергәннәр дидегез әле?

— Павел Наримановны.

— Кызлар аркасындадыр инде.

— Юк, Роза Алексеевна, җинаятьнең сәбәбе башкада, — дип, Озерцов урыныннан торды. «Шахмара»ның кем икәнлеген күрәсе килгәнгә генә тоткарланган булса да, сөйләшүнең файдасын күрде ул. Ни өчен «Шахмара»? Ни өчен еланнар патшасы?

— Ярый, йокыгызны калдырмыйм, вакыт соң. Тикшерү барышында кирәгегез чыкса, күрешербез, — дип, Озерцов саубуллашып чыгып китте.

* * *

Озерцовны подъезд ишеге төбендә милиция лейтенанты каршы алды. Ул, нәрсәдәндер куркынган сыман, агач төбенә сыена төшкән.

— Йә, лейтенант, киттекме? — диде Озерцов күтәренке кәеф белән.

— Кая?

— Һәрхәлдә, ресторанга түгел. Бүре оясы янына аучы якынлашса, бүреләр нишли?

— Бүреләрнең запас оялары булса?

Озерцов, икеләнеп, туктальп калды.

— Әлеге очракта да булырга мөмкин дисезме? — дип, лейтенантка таба борылды.

— Сез сорадыгыз, мин җавап бирдем. Минемчә, бүре оясы янына кеше заты килсә, бүреләр качу ягын карый, әлбәттә.

— Бусы шәп фикер. Димәк, безгә синең белән моннан ерак китәргә ярамый. Әллә бераз сабыр итәбезме? Сабыр төбе сары алтын, диләр. Әйдә, әнә, балалар бакчасы кырыендагы куаклар эченә посабыз.

— Александр Сергеевич, бер туп-туры сорау бирим әле: сезгә куркыныч түгелме?

Озерцов уйланып торды.

— Ахмак кеше генә бернәрсәдән дә курыкмыйдыр. Ләкин гел куркып яшәп тә булмый. Алар бездән курыксыннар.

— Аңлыйм,— диде лейтенант, як-ягына каранып.— Әллә менә монда кереп утырабызмы? Безгә кирәкле балкон да күренеп тора.

Нәкъ шул вакытта балконда хатын-кыз гәүдәсе күренде. Ул, аяк астына урындык куеп, кер элә торган җепкә ак җәймә, аның өстенә кызыл сөлге элеп куйды.

— Александр Сергеевич, карагыз әле, ничек итеп элделәр,— диде лейтенант.

— Гаҗәп? Берәр төрле искәртү билгесе түгел микән, дисеңме? Мөмкин.

— Алла белсен,— лейтенант җилкәсен сикертте...

Роза Алексеевна, җәймәне элеп кергәч, күршеләргә шалтыратып, әнисен чакырып чыгарды.

Сөмсере коелган Мария Афанасьевна, кызына дәшми-нитми, кухняга узып, чәй куярга кереште. Ул, эчендә дулаган ачу давылын басарга тырышып, табак-савытларны шалтырата. Кулыннан шуып төшеп, ярты литрлы банка ватылды.

Роза үз эшләре белән мәшгуль булганга, әнисенең ни эшләгәнен әллә ишетмәде, әллә игътибар итмәде. Ул, гасабиланып, ашыга-ашыга, стенкадан нидер эзләде. Аннары, телефонны алып тезенә куйды да, номер җыярга кереште. Бераздан телефоннан иренеп кенә дәшкән басынкы ир-ат тавышы ишетелде.

— Нәрсә, матурым, йокы симертәбезме? — диде Роза Алексеевна.

— Әллә корт чактымы, төн уртасында шалтыратмасаң?

— Ашыкма, хәзер син дә уянырсың.

— Кыскарак тотып булмыймы? — диде телефондагы тавыш.

— Башкаладан килгән тинтәк безнең җирән алашаны конюшныйга ябып куйды, шылдымы?

— Нәрсә?!. Каян шалтыратасың?

— Әнидән. Алып киткәннәренә ярты сәгать тә юк.

— Көт, хәзер килеп җитәм.

— «Бөдрә чәч»кә үзең шалтыратасыңмы, әллә минме?

— Ашыкма. Икәү килербез.

Роза, телефон трубкасы белән чигәсен ышкып торды да кабат номер җыярга кереште. Йокысыннан уянып бетмәгән нечкә тавыш ишетелде.

— Эдик, срочно син кирәк!

— Янгынга ашыкмыйсыңдыр бит? Хәл-әхвәлне сора башта...— диде нечкә тавыш.

— Соңыннан, Эдик, соңыннан. Вакыты ул түгел. Теге «Ябалак» ауга чыга.

— Такса нинди?

— Иң югарысы...

— Оһо!..

— Машинаңны өй янына куй, сигнал биргәч керерсең.

Бераздан Роза Алексеевналарга Гафиятулла, Сальников, тагын бер ир-ат килеп керделәр. Мария Афанасьевна кухнядан үз бүлмәсенә чыкты.

Сальников, килеп кергәч тә, уфылдап диванга барып утырды. Гафиятулла, яше шактый олы булуына карамастан, егетләрчә тоз,

чандыр булганга, җәһәт кенә атлап, Сальников янына барып утырды да галстугын бушайтты. Кунакларның өченчесе, урта яшьләрдәге, нык бәдәнлесе, ишек яңагына сөялеп, тын гына басып торды. Роза, тәгәрмәчле кечкенә өстәлне Сальников каршына куеп, француз коньягы янына дүрт рюмка, берничә кисәк лимон, кара икра, колбаса китерде дә, утырган килеш, аягын аякка куеп, ашыкмый гына рюмкаларга коньяк салып, эчәргә тәкъдим итте.

— Нәрсә өчен була инде бу? — дип сорады Гафиятулла.

— Безнең күктәге болытлар тизрәк таралсын өчен, — диде Сальников, елмаеп.

— Лә-хәүлә, — дип Гафиятулла һәм, җәһәт кенә рюмкасын бушатып, Роза Алексеевнага төбәлде. — Инде сөйлә, ничек Сергейны тапкан соң ул?

— Алла белсен, кулыннан тотып китермәдем.

— Гаҗәп! — диде Сальников, як-ягына каранып. — Нинди нәтиҗә ясыйбыз?

— Нәтиҗә — бер, — диде әлегә кадәр сүзсез торучы өченче кунак, — телсез шаһиттан да яхшы нәрсә юк. Телгә килсә, йомгакның тәгәрәп китүе бар.

— Кем-кем, әмма Мәскәү этләре йомгак артыннан чаба беләләр, — диде Сальников.

Роза Алексеевна тәрәзә каршына килде. Алдан сөйләшкәнчә, «Ябалак»ның ак төстәге «Волга»сы шартлы урында тора иде. Ул, кабат урынына утырып, рюмкаларны тутырды.

— Минем уйлавымча, Озерцов кая да булса якында, сезне сагалап торадыр. Ул — профессионал.

— Белә торып, безне монда китерттеңме? — диде Сальников.

— Мин чакырдыммыни сезне? Үзегезнең күзегез-башыгыз тонып килеп җиттегез бит. Профессиональ тикшерүче генә түгел, хәтта гади милиционер да мондый чакта, һичшиксез, сагалап торыр иде.

— Иштең ишәк чумарын, — Гафиятулла урыныннан тору нияте белән талпынып куйды да кире утырды.

— Кыбырҗыма, Гафиятулла абзый, табарбыз җаен, — диде Сальников. — Иң соңгы чиктә психбольницада урын бетмәгән. Бер атна тотып чыгарып җибәргәндә дә куркыныч булмаячак.

— Әмиров минем өстә, — диде өченче кунак. — Сценариясен язып тору кирәкмәс, үзе белә.

— Рәсим нәрсә сөйли? — дип сүзгә кушылды Роза.

— Ул хәйләкәр төлкене аңламассың, бәһасен белә. Без генә ул, ахмаклар, көне-төне чабабыз, — диде Сальников.

Өченче кунак җитди итеп карап куйды да:

— Виктор Николаевич, син партҗыелышта түгел, нәрсәгә болай күп сүз? Рәсим — безнең барометр.

— Күп сүз — юк сүз, нинди нәтиҗәгә тукталабыз? — диде Гафиятулла.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Роза, телефонны алып, Озерцов торган кунакханәгә шалтыратты.

— Сания, матурым, синме? — диде ул, телефондагы ягымлы тавышны ишетеп.

— Әйе.

— Безнең дус күренмәдеме әле?

— Юк.

— Ялгышмыйсыңмы?

— Минем глаз — алмаз, Розочка, шикләнмә.

Роза Алексеевна телефонны куйды.

— Әгәр кунакханәгә кайтмаган икән, димәк, ул кайдадыр якында.

— Күпме тәкъдим иттегез ул типка? — Нык бәдәнле ир чәнечкеле карашын Розага төбәде.

— Соңгы тапкыр — йөз мең. Ә ул ярты миллион сорады.
— Ы...ы... җыен комсыз, сараннар. Шул комсызлык аркасында бетәрсез дә әле.
— Мин аның акча аласына ышанмыйм. Ул безнең белән уйный гына кебек,— диде Виктор Николаевич.
— Үлем белән шаярмыйлар да, уйнамыйлар да.— Нык гәүдәле ир үзенә дип салган рюмкасын эчеп куйды.— Теге мүкләгегезне кая алып киттеләр?
— Безгә,— диде Роза.
— Ул күкәйле таракан күп белә, нәрсәдер кылырга кирәк. Озерцовта — йомгакның төене. Төенне чишсә, авыр булыр.
— Мәскәү кәҗә тәкәләре чишәрлек төен булса, лыгырдап утыруның файдасы да юк,— диде гәүдәле ир.— Роза, Хорошевны үз карамагыңа ал, кайгысыннан камерада асылынып үлә күрмәсен.
Утыручылар үзара елмаешып куйдылар.
— Башка мәсьәләләргә килгәндә, Ходай саклаганны саклармын, дигән. Мәскәүле — минем остә, калганнарын үзегез чамалагыз,— дип, нык бәдәнле ир урыныннан кузгалды.— Дөресен әйткәндә, үзәктә Озерцов кебек егетләр булуы зыян итмәс иде, әлбәттә.
— Булганнары да җитәрлек,— диде Сальников.— Аларны печән белән туйдырып торып булмый!
— Каян килгән сиңа шул кадәрле комсызлык?! Әллә үзеңнекен бирәсеңме?
Сальниковның елмайган күзләре кинәт усалланды, кашлары җимерелде.
— Аны бит акыллы итеп аласы да бар әле! Күктән яңгыр гына ява.
— Хәер, сез фәлсәфә сатарга мастерлар, ә миңа вакыт,— дип нык бәдәнле ир чыгып китте. Ул киткәч, бүлмәдә бер-ике минут тынлык торды. Сальников янә коньяк эчеп куйгач, Роза Алексеевнага карап әйтте:
— Җитәр булмаса — күп шаярдык, уйнадык... Үзенең махсус эшләрне тикшерүче икәнлеген күрсәтте бит. Акча да кирәкмәгәч, башка берни тәкъдим итәлмыйбыз. Мәскәүләр дә борчыла башладылар. Аларга ямьсез мәгълүматлар кирәкми.
— Акчадан баш тартты дип кем әйтте? — Гафиятулла учына йөткереп алды.— Мәскәүләр үз бояларен белә алар.
Роза Алексеевна, кабат телефоннан шалтыратып, Озерцовның кунакханәгә кайтуы-кайтмавы турында белеште.
— Һаман кайтмаган.
— Шәт, безне сагалап утырадыр, каһәрең,— дип сүгенде Гафиятулла.
— Утырасы килсә — утыра бирсен, безнең өчен ул нуль,— диде Сальников.
Розаның борчылудан бит алмалары кызарып чыкты, нечкә иреннәре тагын да тартыла төшеп, күзләрендә үҗәтлек чаткысы чагылып китте. Гафиятулла белән Сальников, аның ачуы килүенә пошмыйча, сорауларын яудырдылар: Сергейдан нәрсә сорашканнар? Сергей берәр нәрсә әйткәнме? Роза, теш арасыннан гына сыгып:
— Мин дә, сезнең кебек үк, тыңлап утырмадым, каян белим,— диде.
— Ә син, Розочка, белер өчен куелган. Җитмәсә, бүген-иртәгә подполковник булырга торасың. Мин булмасам, бәлки, һаман зона тирәсендә уралыр идең.
— Узган эшкә салават, диләр,— дип ысылдады Роза.— Киләчәк турында уйларга кирәк.
— Анысы өчен бимазаланма, Розочка. Сергей синең остә. Калганын хәл итәрләр. Ә сорауга җавап бирмәдең?

Гафиятулланың тавышын күтәрмичә, һәр сүзгә басым ясап сөйләвеннән Розаның ачуы басыла төште. Ул елмаеп сөйләшсә — яхшылык көтмә. Роза моны үзе өчен гомерлеккә сеңдергән иде. Гафиятулланың фин мунчасыннан кайберәүләрнең тимер мичкә эченә цементлаган килеш су төбенә тәгәрәп төшкәннәрен исенә төшереп, Роза тынып калды.

— Бер нәрсә дә аңлата алмыйм, Гафиятулла абый,— диде ул.— Үзем өчен дә кояшлы көнне күк күкрәгәндәй булды.

— Теге атнада Мәскәүдән бик мөхтәрәм дустыбыз киләчәк. Чалбарлары белән урам себерә торган хайваннарыңа җиткер, Роза, шәһәр майлаган кебек тып-тын булырга тиеш. Бернинди өерелеп сугышулар, тәртипсезлекләр ишетмик,— дип, Сальников кара бөдрә чәчләрен сыйпап алды.

— Сер булмаса, кем килә?

— Газеталардан укып белерсең. Син дә,— дип, Гафиятуллага борыла төште Сальников.— Резервтагы кызларны әзерлә, «кыздырып» тор!

— Безнең янып үлгән Мүкләк урынына ышанычлы егетләр күренәме дигәндәй?

— Барын бар да... Әллә бераз сабыр итикме, дим.

— Кем ул?

— Самаркин. Бездә старшина булып эшләгән иде.

— Ниндирәк егет?

— Дүрт ел минем кул астында эшләде. Башта — ГАИда, аннары уголовный розыскта селкенеп йөрде.

— Нигә китте?

— Биргәнне ала белмәгәнгә, бирмәгәнне талап алганга.

— Хуҗасын тешләрдәй эт булмасын тагы. Тиздән бик җаваплы посылка булачак. Бер-ике егетегез белән Самаркинны Таллинга әзерләргә кирәк булыр.

Сальников сәгатенә күз салды:

— Ярар, булды, без Останкинодагы түгәрәк өстәл артында утырмыйбыз.

Гафиятулла белән Сальников чыгып китүгә, шартлы сигнал биреп, Роза Алексеевна урамда көтеп торган башкисәр Эдикны чакырды. Буйга шәп, таза гәүдәле, спортсменнарга охшаган Эдик үзен озак көттермәде. Авызында сагызын чәйни-чәйни ул әмер көтте.

— Ул каядыр якын тирәдә. Ике тапкыр кунакханәгә шалтыраттым.— Кайтмаган, димәк, минем өйне сагалый. Син машинаң белән әкрен генә урамнарны әйлән. Әгәр очратсаң, җайлы моментта якыннан уз...

Лейтенант Саматовтан аерылгач, кунакханәгә тикле Озерцов җәяү кайтты. Төнге һава сулышка иркен. Урам тып-тын. Бер кеше заты күренми. Тиздән таң ата башлаячак. Ул сәгатенә карап алды да уйларына бирелде: «Иртәгә үк Тихон Анисимовичка шалтыратып сөйләшергә булыр. Монда, мөгаен, дәүләт иминлеге комитетына да мөрәҗәгать итәргә туры килер. Наркотиклар, һичшиксез, Мәүлетовның чиктә хезмәт итүенә бәйләнешле. Ләкин ничек? Юк, монда төптән кисәргә ярамый. Барысын да ачыклар өчен, озын-озак юл үтәргә кирәк. Бердәнбер юл — Хорошевтан сорау алуларны сузып, күзәтү оештырырга. Җинаять юллары кая илтер?»

Озерцов, тротуарда үсеп утырган юкәнең яфрагын өзеп алып, авызына капты.

Өченче көн кичен коенып кайтканда һөҗүм иткән хулиганнарны, гаепсезгә санап, милициядән чыгарып җибәрүләре аны, һичшиксез, шөбһәгә калдырды. Әлегә кадәр тикшерү эшләренә аяк чалуларына икеләнсә, хәзер инде тәмам инанды. Димәк, кемнәрнеңдер тынычлыгы җуелган. «Их, беләсе иде»,— дип куйды Озерцов һәм, тавыш ише-

теп, нидер сизенгәндәй, электр баганасы артына яшеренде. Янәшәдән генә, тротуар өстеннән выжылдап, «Волга» узып китте. Озерцовның тәне эсселе-суыклы булып, калтыранып куйды. Маңгаена салкын тир бөртекләре бәреп чыкты. Ярый әле, бәхетенә — электр баганасы саклап калды, юкса шунда ятып каласы иде.

Кунакханәгә кайткач, ул иң элек ваннада юынып чыкты. Йокларга ятарга җыенганда, кинәт телефон шалтырады.

— Александр Сергеевич, хәерле кич! — диде телефондагы тавыш.

Озерцов тавышны шунда ук таныды:

— Хорошевны кулга алгач, әллә такса арттымы? — диде ул киная белән.

— Юлбарыс арт аякларына чүксә, сәлам бирә, дип шатланмагыз. Чебешләрне көз көне саныйлар бездә, чубек баш.

— Бетми торган бәйрәм булмый. Көзе дә җитәр, чебешләре дә саналыр, яңачарак бәйрәм дә булыр.

— Балтаның кечкенәсе дә зур агачны екканын беләсезме? Тантана итәргә иртәрәк әле.

«Әллә соң, акчаны алырга ризалашып, нинди бәндә икәнен күреп, күзәтү оештырыргамы? Ул вакытта, тиз генә Мәскәүгә кайтып, киңәшеп килергә кирәк булачак», — дип уйлады Озерцов. Шулай уйлап:

— Сез нинди телефоннан сөйләшәсез? — диде.

— Нигә сорыйсыз?

— Безне тыңлап торулары мөмкин.

— Автоматтан.

— Минем сүз шул: 500 мең.

— Күп.

— Мин бирүзем генә түгел, — дип, хәйләгә салышты Озерцов.

— Ярар. Җавап алырсыз, көтегез.

— Һәм соңгы киңәш, — диде Озерцов, басым ясап. — Эзәрлекләвегезне туктатмасагыз, тавык мие эчкән бирәр егетегезнең маңгаена тишек ясыйм!

Урамда инде яктырган иде. Озерцов, урынына ятып, күзен йомды. Әллә арыганлыктан, әллә йөрәге кысканга — тәнендә калтырау тойды.

«Бүген үк Тихон Анисимовичка шалтыратып сөйләшергә кирәк. Һич тә сузарга ярамый. Уйламаганда гына хәнҗәр китереп тыгарга күп сорамаслар, кабахәт җаннар. Сатып алырга ниятлисезме?» — дип үзалдына сөйләнде ул.

Озерцов, уйланып яткан җиреннән торды да, чиста кассета алып, магнитофонына куйды һәм кнопкага басып җибәрде:

«Тихон Анисимович, бу мин — Александр Сергеевич. Сез, тыңлый башлагач та, аптырап калырсыз. Сез — бердәнбер ышанган кешем. Тикшерү эше шундый дәрәҗәгә җитте: мине, бер ерткычны эзәрләкләгән кебек, аулый башладылар...» — дип сөйләп китте...

* * *

Иртән торып, салкын су белән юынгач, кичтән алып куйган бер шешә кефирны эчеп, Озерцов өлкә прокуратурасына юнәлде. Прокуратурада аны сүлпән, караңгы йөз белән каршыладылар. Прокурор урынбасары, башын күтәрми генә, урын тәкъдим итте. Озерцов телефонны үзенә таба борып: «Шалтыратырга мөмкинме? — диде. — Тихон Анисимовичка шалтыратасы иде».

— Ашыкмагыз әле, коллега, сөйләшәсе сүзләр монда да җитәрлек. Тихон Анисимович үзе дә яңа гына шалтыраткан иде. Төнлә Хорошевны кулга алган булгансыз икән.

— Әллә тагын качканмы? — диде Озерцов, урынбасарны кисәк бүлдереп.
— Камерасында асылынган.
— Үлгәнме?
— Асылынгач, үлми нишләсен.
Озерцов коточкыч хәбәрдән сикереп үк торды:
— Мөмкин түгел! Ышанмыйм! Беләсезме бу нәрсә? Бардак!
— Күңелегезгә якын алмагыз. Бер эт беткәннән ни булган?
— Сезнең өчен эт булса, минем өчен ул кеше иде! — диде Озерцов, прокурор урынбасарына нәфрәт белән карап. — Бәлки, ул эттән дә әшәкерәк булгандыр, ләкин ул — бердәнбер шаһит. Беләсезме, ул мафия белән бәйләнгән бердәнбер шаһит иде.
— Нинди мафия турында сөйлисез, Александр Сергеевич?! Аллам сакласын. Бу бит Италия түгел.
Озерцов телефоннан Мәскәүне җыйды. Телефоннан, коттереп кенә, кор тавыш ишетелде.
— Тихон Анисимович, сезме бу? Исәнмесез!
— Ә... Сашок, туганкай, хәлләр ничек?
— Яхшы да түгел, начар да түгел.
— Нейтральный, димәк. Мин, киресенчә, синең хәлләр мөшкелрәк дип уйлаган идем.
— Һәрхәлдә, төзәргә була.
— Шулай гынамы?..
Прокурор урынбасары, болар иркенләбрәк сөйләшсен дипме, чыгып китте.
— Тихон Анисимович, миңа бер-ике сәгатькә генә булса да, кайтып килергә кирәк. Телефоннан гына сөйләшә торган сүз түгел. Бу — бик мөһим.
— Нигә бер-ике сәгатькә генә? Начальство, эшне урындагыларга тапшырып, бөтенләй кайтырга боерды, туганкай. Шатлан.
Бу хәбәрдән Озерцов, теле көрмәкләнеп, эндәшә алмый торды.
— Конкрет әйткәндә, кемнең боеруы буенча кайтырга тиешмен?
— Бала-чага булма, Саша. Барыбер түгелмени? Мин әйттем ни, башка ни...
— Барыбер булса, сорап та тормас идем. Сорыйм икән, димәк, мөһим. Ярар, әйтергә теләмәсәгез — кирәкми. Мин шулай булачагын берничә көн элек үк белә идем.
— Әллә телепатка әверелдеңме?
— Телепатка түгел, әллә кемгә, әллә нәрсәгә әверелерсең монда! Тик, кайтуга ук, үз теләгем белән эштән китәргә гариза язам.
— Шаяртуың балаларча беркатлы, Александр Сергеевич.
— Мин шаярмыйм һәм шаярырга теләгем дә юк. Эшне кемгә тапшырырга?
— Нинди корт чакты соң сине?
— Минем соравыма җавап бирмичә торып, мин башка сезнең белән сөйләшергә теләмим.
— Ахмак баш, бездә кем боера соң? Әлбәттә, мин түгел. Хәзер бөгештерми генә сөйлә.
Озерцов җиңел генә сулап куйды.
— Берничә көн элек, кунакханәгә шалтыратып, төшкә дә кермәгән сумма тәкъдим иттеләр.
— Нәрсә өчен?
— Күп сөйләмәс өчен.
— Тукта әле, тукта, пулеметтан атма. Күрәм, эш шаярудан узган.
— Күптән, Тихон Анисимович. Инде берничә тапкыр юлдан алып ташларга тырышып карадылар.
— Шулаймы, — дип гаҗәпләнде Тихон Анисимович. — Син әлегә бөтен дөньяга ярып салма. Кайткач, барысын да сөйләшербез. Аңла-

дыңмы? Ә мин, син кайтканчы, өермә җиленең каян килгәнен ачыкларга тырышырмын. Элекке заманнар түгел.

Озерцов, эшне тапшырып, кайтыр юлга җыенды. Аны аэропортка озату өчен машинаны бик теләп бирделәр...

* * *

Прокурор, тәрәзә янагына сөялеп, урамга төбәлгән. Ул, кем кергәнен белсә дә, борылып карамады. Була бит шундый мизгел, бер ноктага карап уйга каласың да, карашны тиз генә алалмый торасың. Ул, уйларыннан арынып, урынына килеп утырды да, секретарена: «Шалтыратсалар, мин юк»,— дип искәртте.

— Менә шундый хәлләр,— диде ул, Тихон Анисомовичның елтырап торган пләшенә игътибар итеп.

— Гаять кызганыч,— диде Тихон Анисомович.

— Гаиләсе ничек?

— Кара кайгыда.

— Әтисе шалтыраткан иде. Саша ришвәт ала торган кеше түгел. Без — дворяннар токымыннан, кеше буларак үтенәм, гаепләләрне табыгыз, ди. Ә монда кемне гаеплисең?

— Нигә алай дисез?

— Шоферның хәле ничек икән?

— Аңа берни дә булмаган, ике кабыргасы да, аягы гына сынган. Минем сезгә бер соравым бар иде дә, күму мәшәкатьләрен уйлап, яхшысынмадым...

— Берегез, берегез соравыгызны.

— Сашаны ни өчен кире чакырткан идегез? Нәрсәгә кирәк булды ул монда чакыртып кайтару? Шул анонимка өчен генәме?

— Сорауны аңламадым, Тихон Анисомович. Чакырту-чакыртмауның монда берәр төрле роле булса икән. Чакыртмаган булсак, ихтимал, мондый фаҗига килеп тә чыкмаган булыр иде, дип, мин дә үзүземне җәберлим. Күрәсең, язмыштан узмыш юк.

— Сез минем сорауга җавап бирмәдегез,— Тихон Анисомовичның йөзе кырысланды, күзләре усалланды. Маңгаендагы, күз кырыйларындагы җыерчыклар әллә ничек тартылып китте. Картның усал, җитди карашын прокурор да күрде.

— Чакыртырга уйламаган да идем, өстән шалтыраттылар,— диде ул.

— Ничек өстән?

— Гафу ит, Тихон Анисомович, ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме?

— Зарланган юк, аллага шөкер,— дип, карт магнитофон кассетасы белән фоторәсемнәрне һәм башка документларны өстәлгә куйды.— Бу материаллар өчен Саша гомере белән түләде.

Прокурор, сулыш алырга курыккандай, күзләрен мелт-мелт иттереп Тихон Анисомовичка текәлде.

Прокурор, фоторәсемнәрне җентекләп карагач, адрес, эш урыннарын күрсәтеп язган кәгазьгә күз салды. Укып чыкканнан соң, маңгаен ышкый-ышкый нидер уйлады.

— Бу документлар ничек синдә әле? — диде ул.

— Кайткан көнне үк иртән, аэропорттан шалтыратып, самолет экипажы командиры аша җиборде.

— Кассетаны тыңладыгызмы?

— Сорап торасыз...

— Самолет экипажы аркылы җибәрердәй булгач, күрәсең, безгә билгесез вакыйгалар булган. Шулай да, ике сүз белән генә: Сашаның үлеме турында син нинди фикердә?

— Нәтиҗә ясарга иртәрәк, әлбәттә. Саша аэропортка милиция машинасы белән китә. Анысы аңлашыла, үзе сораган булырга да мөмкин. Ләкин бернәрсә мине аптырата: илле мең сум акча аның костюм кесәсенә кайсы вакытта салганнар? Монысы — табышмак. «КамАЗ» белән бәрелгәнчегә кадәр аның кесәсендә акча булмаганлыгы көн кебек ачык. Бусы — бәхәссез мәсьәлә. Кем һәм кайчан ул акчаны кесәгә салган? Бөтен хикмәт шунда булырга тиеш. Авария булуга ук, әллә каян ГАИ да килеп чыга, «Скорая помощь» та табыла.

Бүлмәдә тынлык урнашты.

— Катлаулы хәл бу, — диде прокурор, авыр сулап.

— Скорыйга салганда Саша, бәлки, исән дә булгандыр. Әгәр шулай булмаса, нигә тизрәк скорыйда озатырга? Бәлки, аңа юлда «ярдәм иткәннәрдер»? Бу фәкать минем шик кенә.

— Алдан уйланып куелган спектакльгә охшаган бу, Тихон Анисомович. Дөресен әйткәндә, ышанасы да килми, ләкин...

— Мафия...

— Бездә аны башкача, ведомственность, дип атыйлар, — диде прокурор маңгаен җыерып. — Бәлки алай да түгелдер.

— Сашаның эшен кем дәвам итәчәк?

— Син мине стенага терәмә. Уйларга вакыт калдыр. Ятьмәгә вак балыклар түгел, акулалар эләккән булса кирәк. Акулалар артында китлары йөзсә, нишләрсең? Беләсеңме, монда эш нинди тузлар белән бәйләнешле? Хәзер кулга ала башласаңмы — давыл кубачак! Һәр ведомство үз карагын коткарырга тырышачак.

Прокурор, чыраен сытып, йөрәген тотты.

— Ярар, сөйләштек, булды, — диде ул, урыныннан торып. — Әгәр каршы килмәсәң, гаиләсе янына барып киләсе иде. Кассетаны калдыр, калганнарын алсаң да ярый.

Тихон Анисомович ишеккә таба борылды.

— Тихон Анисомович, — дип туктатты прокурор. — Әкрен генә, детальләп уйла... Ашыгырга кирәкмәс. Эре балык тирәндә йөзә. Аны ычкындырмаслык итеп тота да белергә кирәк.

---

Роман тулысынча килеш быел Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак. *(Редакция искәрмәсе).*

# ШИГЪРИЯТ

## Шамил Маннап

### КЫШЫМ БЕЛӘН ЯЗЫМ КҮРЕШКӘН МӘЛ

### Рәнҗү катыш хәер-дога

Бәла җиле башым идергәндә
искә алам сине, әнием.
Киңәшеңне әллә тотмаганга
төштә микән, димен, рәнҗүең?
«Канатыңнан, бәйләп куеп булмый,
хәерле юл, балам...» — дисәң дә,
күзләреңдә рәнҗү күрдем сыман
төп нигездән чыгып киткәндә.

Тик белмәдем:
авылыңнан китү —
тамырыңнан кубу икәнне,
чит-ят җирдә янә тамырлану,
җимеш бирү кыен икәнне.
Нигезеңнән китү —
динеңнән дә,
телеңнән дә китү икәнне,
мирасыңнан китү —
үзеңне дә
мирасчысыз итү икәнне
белмәдем шул...

Уртак коридорда узды гомер,
эшләсәм дә күндәм ат кебек.
Инде — аерым фатир...
Ә шулай да,
үз өемдә үзем ят кебек.

Телләребез төрле, гаиләмнең
учагына яңгыр явамы?
Балам күзләрендә чагыла, әни,
синең рәнҗүеңнең дәвамы...
Хәер-дога катыш рәнҗүләрең
салганмы соң шундый бәлагә?

---

Шамил МАННАП (1938) — *шагыйрь. «Хәят көндәлеге», «Кайту», «Әти урманы», «Җиргә сыенам» һ. б. татар, рус телләрендә нәшер ителгән дистәгә якын китап авторы. Проза әсәрләре дә яза, әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Казанда яши.*

Куркам, әни:
мин дә бер көн килеп,
рәнҗемәсәм иде балама...

Күктән иңгән вәхи сыман, әни,
ишетелә сабыр тавышың:
«Рәнҗүләрем салса бәлаләргә,
Изге догам йолып алышыр...

## Сабырлык

*Алла сабырлар беләндер.*
Коръәннән.

Бу дөньяда яшәү өчен
кирәк шундый сабырлык:
кайгы-хәсрәт дәрьяларын
кичеп чыга алырлык.

Көрәшләргә Ил дәшкәндә
нигә, димсез, сабырлык?—
Сабырлыкта көч вә кодрәт,
җиңеп чыга алырлык.

Йомшаклык түгел, олпатлык
билгесе ул сабырлык;
«Сабыр төбе — сары алтын»,—
дип юкка әйтми халык.

Сабырсызланулар булды...—
Инде гыйбрәт алырлык.
Халкымны асыл сыйфаты —
сабырлыктан танырлык.

Халык иркен буучылар
инде гыйбрәт алырлык:
Дөньяда куба гарасат,
шартлап сынса сабырлык!

* * *

Кыш белән яз көрешә февральдә,
бу сүзләрдә, димсең, нинди мәгънә?—
Әнә яшь кыз язны өйгә дәшеп,
җырлый-җырлый юа тәрәзәсен.
Кыш белән яз көрешкән бу мәлдә.

Кыш белән яз көрешкән бу мәлдә
ничек күрми узыйм кызның йөзен?
Аһ, тәрәзә чагылдыра минем
йөземдәге картлык пәрәвезен!
Кыш белән яз көрешкән бу мәлдә...

* * *

Гаҗәп инде, турысын әйтмибез ник,
начар бәндәләргә: «Бәдбәхет!» — дип?

Янып сөйгәннәргә: «Яратам...» — дип,
бик еш әйталмыйбыз, йөрәк җитеп.

Яшь вакытта сөйләшәсе килә,
өлкәнәйгәч, аз сүзле без нигә?

Өйрәнәбез башта сөйләшергә,
Аннан — ирек бирмәү җаен телгә.

Яхшымы бу йә начармы икән?
Ышанырсыз микән: «Белмим» — дисәм?..

* * *

Ераклардан хәбәр биреп,
Китмәссеңме, дисең, килеп,
Бармагач, үпкәлисең.
Табигатьнең законы бар:
Мәгълүм бер орбитада
Әйләнә һәрбер җисем.

Һәр нәрсәнең үз вакыты,
Һәр фасылның үз чираты:
Язлардан соң килә көз...
Безгә бирелгән язларны,
Яратыр вакыт, форсатны
Кулдан ычкындырдык без.

Кайчандыр ашкынган егет,
Син диеп шашынган егет —
Ул — мин идем микәнни?
Юлда очрап азга гына,
Еракларга китеп барган —
Ул — син идең микәнни?

Поезд киткән... Гомер үткән...
Син дә бүтән, мин дә бүтән,
Телебездә — ят исем.

Табигатьнең законы бар:
Үзенә язган орбитада
Әйләнә һәрбер җисем.

Поезд дигән тормыш икән,
Беребез калган, беребез киткән,
Асрым кердек көзләргә.
Йөгерек сулар үргә акмас,
Узган гомер кире кайтмас,
Нигә көрешү эзләргә?!

Һәр нәрсәнең үз вакыты,
Һәр фасылның үз чираты:
Язлардан соң килә көз.
Безгә тиешле язларны,
Булачак уртак назларны
Кулдан ычкындырдык без.

Никадәрле тартылсак та,
Якынаймас, ерагаймас
Язмыш куйган арабыз.
Без Җир белән Ай шикелле...
Читтән торып, бер-беребезне
Сагына гына алабыз.

## Улым китә солдатка

Яшьлегемне гүя кабатлап,
улым китә бүген солдатка.
«Еллар тыныч, борчылма», — диеп,
якыннарым минс юата.

Ничек борчылмыйсың, туганнар,
күрдек ласа, тыныч вакытта

кемнәрнеңдер газиз улларын
кайтардылар цинк табутта.

Бәйнәлмиләл бурыч дигәннән,
күпме тамыр-бәгырь киселде.
Кеше каны акты таулардан,
таудай кайгы җанга ишелде...

Инде күпме корбан бирмәдек,
(недоимка гүя түләдек).
Кемнән калган тагын ул бурыч,
яшь гомерләр биреп түләрлек?!.

Командирда — солдат язмышы,
ә солдатта — халык язмышы.
Кем булсаң да, улым, сынатма,
ул язмышлар белән сак бул син!

Гаделлеккә аткан солдаттан
көтмәк кирәк нинди игелек?
Танкларга төяп, ирексез
китереләмени чын ирек?!

Аеруы актан караны
беләм, улым, җиңел булмасын.—
Кыйблаң булсын халкың догасы,
Хозыр Ильяс булсын юлдашың...

## Соңгы чара

Чая җаннар Ирек мәйданында
Ирек даулап ачлык белдерә.
Уразаның әҗерен ходай белә,
Ач торуның әҗерен кем белә?

Ач торуның әҗерен халык белә:
Яман була ачның ачуы.
Заманында алтын сарайларны
Каерып ачкан ачлар ташкыны.

Ач кадерен туклар гына белми,—
Яман була ачның ачуы.
Аннан яманрак,
Сабыры бетеп,
Ачыгучы инсан шаукымы.

Шушы шаукым җыя бар халыкны.
Юк, зарланмый халык ачлыктан,—
Ул кайчандыр канын түгеп алган
Азатлыгы өчен зарыккан.

Соңгы чара:
Ирек мәйданына
Ирек таләп итеп Ил килә.
Уразаның әҗере — кыяматтә,

Ач торуның — кайчан?
Кем белә?!

Изге теләкләрне кабул кылу
Кемнәргәдер кыен, ахрысы.
Тик белсеннәр:
Халык нәфрәте ул —
Башка төшәр Ләгънәт камыты!..

## Өзелмәгән өмет

*Ак күгәрченне кулымнан алдылар, козгын биреп...*

Г. Тукай

Ак күгәрчен дигәнебез һаман,
козгын булып,
бавырыбыз чукып торганга,
рухи богауларын өзгән халык
Мәйданнарга агыла, урамга.

«Азатлык!» дип, күгәрченен даулый,
козгын җәбереннән туйгандыр.
Ак күгәрчен кайтып кунмасмы дип,
манарага аен куйгандыр...

Юк, бу бер-бер уенчыктан туеп,
башка тәти таләп итүче
сабый кәефсезләнүе түгел,
халык ниятләре — икенче.

Яшел төскә манган байрагында
«Уян, татар!» дигән өн яна.
Юк, инде ул уйнап кына түгел,
чынлап яшәмәкче дөньяда.

Чынлап яшәмәкче үз җирендә
күгәрченнәр кебек гөрләшеп.
Ләкин язмыш аңа бу юлы да,
күгәрчен дип,
козгын гына бирә күрмәсен...

## Солтан Йосыпов

# ӘСИР ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

*Солтан Йосыпов (1920—1989) Татарстанның Буа районындагы Кул Черкене авылында туып үсә. Сәламәтлеге какшаган булу сәбәпле, аны башта сугышка алмыйча торалар. Сугышка 1942 елда китә. Шул ук елда, яралы хәлендә, әсирлеккә эләгә. Концлагерьда Солтан Йосыпов Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән бергә була. Бу истәлекләрдә ул лагерь хәлләре, легионның ничек оештырылуы, шагыйрь белән очрашулары турында яза. Истәлекләр Муса Җәлилнең әсирлектәге тормышын, көрәшен күз алдына тулырак китерергә мөмкинлек бирә.*

*Авторга бәйле бер вакыйганы искә алу кызыклы булыр. Солтан фронтта энесе Зәки дивизиясенә туры килә. Һәм алар, икесе ике вакытта — энесе фронтка элгрәк китә — сугышка алынып, Калуга өлкәсендә очрашалар. Абыйсы эзләп таба. Күпмедер вакыт хәл белешә алмыйлар.*

*— Абыйны эзләдем, ләкин язмышын белүче юк иде,— дип сөйли Зәки әфәнде.— Рота политругыннан сораштым. Хәзер дә хәтеремдә, ул бездән өлкән, утыздан узган кеше иде. Мәскәүдән иде, фамилиясе дә истә — Лаврушков, безнең туганнар икәнлегебезне белә иде ул. Соңгы сугыштан соң, мин абыегызны күрмәдем, һәлак булган, дисәң, гәүдәсе табылмады, бәлки, исәндер дә, дигән иде политрук. Исәндер, дигәнен мине юату өчен әйтте инде...*

*Солтан Йосыповның истәлекләрен, матбугатта бастыру өчен, бертуган энесе Зәки ЙОСЫПОВ һәм журналист Ләлә САБИРОВА әзерләде.*

Вагон ишегеп тышкы яктан шалтыр-шолтыр бикләделәр. Кырыклап кеше безнең вагонда. Поезд тәгәрмәчләренең тигезле-тигезсез шакылдавын тыңлап бара торгач, көн исәбен дә югалттык. Берәвебез: «Унбиш тәүлек булды инде»,— диде, икенчебез: «Унҗиденче китте»,— дип төзәтте.

Вагонда бәләкәй генә дүрт тәрәзә бар, алар кат-кат тимер рәшәткәләр белән капланган, яктылык аз төшә. Һава начар. Ишек төбендәге парашадан сасы ис күтәрелә. Әле лагерьда чакта яшелчә шулпасы белән әз генә баллы үлән чәе эчә идек. Юлга чыкканнан бирле эрзац икмәк белән кайнаган судан башка нәрсә капкан юк. Баштарак кайбер әсирләрнең тәмәкесе бар иде. Ул уртактан тартылып бетте.

Биш тәүлектән соң, Демблинга җиттек. Хәрби әсирләр лагере шундагы крепостьта икән. Вагонны ачып җибәргәч, ни күзебез белән күрик — безне полицайлар һәм немецлар этләр белән каршылый. Машиналары да шактый күренә. Җиргә төшеп басуга, сгылып-сгылып китәбез. Хәл юк, баш әйләнә, өстәвенә, аяклар оешып каткан. Көч-хәл белән сафка тезелдек. Кат-кат санагач, көчле сак астында лагерьга таба алып киттеләр. Кызу барырлык чама юк, алай да немецлар ашыктыралар, сгылганнарыбызны камчылап торгызалар.

Ниһаять, ерактан крепость стеналары күренә башлады. Якынайган саен, аларны уратып алган чәнечкеле тимер чыбыклар ачыграк күренә.

Тимер капка шыгырдап ачылды. Санап керттеләр. Безне эшчеләр зонасы коменданты Атай кабул итте. Полицай. Немецларга сатылып, бик күп әсирләрнең башына җиткән. Аягында хром итекләр, башында кара мехтан тегелгән бүрек, чалбары да, өстендәге казакие дә кара сукнодан, шәп пирчәткә кигән, камчысы еландай. Күтәрелеп карарга куркыныч, ерткычлыгы йөзенә чыккан.

— Бишәрләп тезелегез, ашарга барасыз,— дип боерды ул.

Тамак ялганды. Бүгенгә ял итәсез, диделәр. Мин зона эчендә йөренгәләргә тотындым. Бер төркем әсирләр янына якынлашкач, таныш тавыш ишеткәндәй булдым. Ялгышмаганмын икән, күрше авыл егете Зиннәт Садыйков булып чыкты. Без аның белән җиденче классны бергә тәмамладык, бергә комсомолга кердек. Зиннәтнең әтисе һәм туганнары колхоз оештырып йөргән активистлар иде. Садыйковның өстендә Кызыл Армия командирлары кия торган шинель, башында фуражка. Янындагы иптәше дә әйбәт кенә киенгән. Кем алар хәзер минем өчен? Дусмы, дошманмы? Миңа Зиннәт мица таба килә башлады. Эндәшергәме, юкмы? Шулай икеләнеп басып торганда, Садыйков, дип эндәшкәнемне үзем дә сизмичә калдым. Ул да мине таныды, кочаклап күреште. Бераз тынычлангач:

— Солтан, син бик бетәшкәнсең. Нишләргә соң синең белән?— диде. Уйланып торды да:— Кухнядагы өлкән пешекче Зыятдинов абый белән сөйләшеп карыйм әле, үз янына алмасмы,— диде. — Кухняда да җиңел түгел анысы, шулай да салкында авыр эштәге кебек булмас.

Зиннәт үзе киемнәр складында эшли, шуңа да өс-башы бөтен икән. Ул мине кухня янындагы эскәмиягә утыртты да:

— Хәзер мин бер җиргә барып киләм. Шушыннан кузгалма,— диде.

Утыра торгач, туңып беттем. Инде өметем кисеслә башлаган иде, кемнедер ияртеп, Зиннәт килеп чыкты.

— Хәсән, игътибар беләнрәк карап кал бу егетне,— диде ул үзе белән килгән кешегә.— Минем якын дустым-сабакташым ул. Мин әйткәннәрне эшли күр.

— Йөзе-кыяфәте истә калырлык икән, күргәч, танырмын,— диде Хәсән.— Кайда яшисең? Юкса, меңәрләгән халык арасыннан ничек эзләп тапмак кирәк.

— Койма ягыннан икенче блокта.

Моны ишеткәч, Хәсән:

— Бәхете бар икән дустыңның, Зиннәт,— диде.— Җылы җирдә икән. Бүген ике йөзләп әсир вафат булды, шулардан бушаган урыннарның берсенә эләккән якташың. Башкаларга ачык һавада кунарга туры киләчәк.

Зиннәт миңа бераз икмәк, маргарин, тәмәке алып килгән иде.

— Хәсән — сез яши торган зонаның өлкән полицае. Фамилиясе Акчурин. Ул да, Атай да минем үтенечне аяк астына салмаслар. Нигә, дисәң, азык һәм киемнәр складының хуҗасы — бер немец офицеры. Ул мине нигәдер якын итә. Аңладыңмы инде, Солтан, минем кем икәнлекне?

Икенче көнне Акчурин белән кухня янында очраштык. Эчкә кердек.

— Әнә, күрәсеңме теге кешене?— дип ымлады ул озын буйлы таза гына берәүгә таба.— Зыятдинов шул була.

Зыятдинов миңа усал күзләре белән карады, Акчуринны читкә алып китте. Шулай да кайбер сүзләре колагыма чалынып калды.

— Зиннәтне тыңламыйча ярамый, кирәкле кеше...

— Карап торырга ук үләксә бит.

— Ярар инде, сынап кара, күз күрер.

Мине курку алды. Зыятдинов абыйның күрсәтмәләре коры булды:

— Чәй кайнатырсың. Эш урының чиста булсын. Урлашмаска. Эшкә вакытында килергә. Җиренә җиткереп эшли алмасаң, Зиннәтнең якташы, дип тормам, куармын!

Эш белән таныштым. Казан тирәләрен акка буядым. Бетон идәнне тимер кисәге белән кырып чистарттым. Ял да итмичә эшлим дә эшлим. Зыятдинов абый үтеп барышлый күз салгалый, сүз дәшми.

Кичен туйганчы яшелчә шулпасы эчтем. Корсагым күпсә дә, тәнем җиңеләйгәндәй булды.

* * *

Иртән учакны тергезеп җибәрә алмыйча азапландым. Коры агач юк иде. Аш пешерү бүлегенә барып, утын аралый башлаган идем, берәү бик ачуланып кычкырды:

— Ычкын, моннан, үләксә! Синең өчен әзерләмәдем мин аны!

— Гафу ит. Кайдан алырга соң коры утынны?

— Эзлә, табарсың!—дип кырт кисте теге.

Безне тыңлап торган бер әсир:

— Нигә тамак ярып кычкырасың аңа? Яңа кеше бит, белмәгәндер,—диде. Аннары мине үзе белән ияртте.—Әйдә, кайдан алырга икәнен күрсәтәм.

Барганда минем кемлегемне сорашты. Үзен, Гайнан Кормаш, дип таныштырды. Ул кухняда аш пешерү бүлегендә эшли икән.

Моңланып, җырлап та алды.

Утын күтәреп кайтканда, зона эченә ныклабрак күз салдым. Күңелне хәсрәт басты. Монда китерелгәнче күп лагерьларда булырга туры килде миңа. Үзебезнең илдәгеләре дә ток җибәрелгән тимер чыбыклар белән уратылып алынган иде. Дүрт почмагында дүрт вышка булып, сакчылар безне этләр белән каравыллыйлар иде. Әмма лагерьдан ерак түгел картлар, балачагалар үтеп-сүтеп йөри, алар безгә фронт хәлләрен кычкырып китәләр, кайчакта сакчылар аша ашамлык һәм тәмәке бирәләр иде.

Биредә боларның берсе дә юк.

Крепость стеналарының калынлыгы метрдан ким түгел. Ике яктагы ике катлы тимер капкаларга авыр йозаклар эленгән. Капкалар өстендә — вышкалар, анда — пулеметлар. Шуның өстәвенә, крепость өч рәт чәнечкеле тимер чыбык белән уратылган...

Утынны кертеп аудардым да, бераз хәл җыйгач, янә бер юлга барып кайттым. Кухняга җитәрәк, йөгемне җиргә куеп, ял итеп алмакчы булдым.

Миннән ерак түгел ике кеше басып тора. Берсе кыскарак буйлы, аныңсы иңенә санитар сумкасы элгән. Көлешеп алдылар. Кыскарак буйлысын кайдадыр күргәнем бар кебек, әмма хәтеремә төшерә алмыйм.

Утынны күтәрдем дә, тегеләргә карый-карый, кухняга керә башладым. Шулчак нәрсәгәдер абындым, утыннарым бер якка, агач башмакларым икенче якка очты. Атай белән бер немец солдатының чыгып барышлары булган икән, тотындылар егылган килешемә кая туры килсә шунда типкәләргә... Ярый әле, каяндыр Зиннәт килеп чыкты.

— Чү, Атай, нишләвегез бу?!—дип кычкырды ул.

Атай белән немец солдаты эндәшмичә китеп бардылар. Зиннәт мине торгызырга азапланганда, безнең янга теге ике кеше килеп басты.

— Харап иттеләр бу бичараны!—диде кыскарак буйлысы.

Аның тавышы да таныш кебек тоелды. Һәм соңыннан мин аның кемлеген хәтеремә төшердем: бу бит шагыйрь Муса Җәлил абый иде!

Зиннәт мине кухняга алып кереп юындырды. Киемнәр алып килгән икән, өс-башымны алыштырды.

— Карагыз әле, Зыятдинов абый, минем якташка! Бөтенләй икенче кешегә әйләнде бит,—диде ул өлкән пешекчегә.—Хәзер тәненә ит кундырасы калды.

— Мин аңа ашны кызганмыйм,—диде Зыятдинов.—Туйганчы ашасын. Әлегә тырышып эшли.

Ул киткәч, Зиннәт озак килә алмавының сәбәбен аңлатты:

— Алар минем сине монда урнаштыру турындагы үтенечне тыңладылар. Инде аларның таләбен үтәргә кирәк иде. Ә моның өчен урлашмыйча булмады. Азык мәсьәләсе бер хәл — складта бар анысы. Исерткеч юнәтү кыенрак.— Аннары миңа бер төргәк сузды.— Менә сиңа бераз ризык һәм тәмәке. Бусында ике йөз грамм эчемлек, иптәшләрең белән бүлешерсең. Тизрәк җыеп куй.

Ул чыгып китте, рәхмәт әйтергә дә өлгермәдем.

Мине уй басты. Муса абый белән кабат ничек очрашырга? Аның сугышка кадәр эшләгән изгелегенә ничек игелек кылырга?

Кичен эштән кайткач, бүгенге вакыйгалар турында Мәхмүт абый белән Ибраһимга сөйләп бирдем.

* * *

Кухня ишегенә немец, татар һәм рус телләрендә белдерү элделәр:

*«Кухняга керергә рөхсәт ителә:*

*1. Немец офицерларына һәм солдатларына.*

*2. Зона комендантына һәм өлкән полицайга.*

*3. Махсус пропускы булган полякларга, әсирләргә.*

*Кухня мөдире фельдфебель Функ.»*

Казанга су салып, ут кабызып җибәрдем дә, читкәрәк китеп утырдым. Кичә булган хәлләр тагын күз алдыма килеп басты. Муса абыйны кайда очратырга? Очрашкан тәкъдирдә дә, аны белүемне ничек аңлатырга? Мин сине күргәнем юк, дияр дә китеп барыр. Теге белдерүдән соң кухня эченә дә керә йөрмәс инде ул...

Кинәттән ишетелгән таныш тавышка сискәнеп киттем:

— Кем монда чәй кайнатучы?

Муса абый бит бу! Шатлыгымнан: «Исәнмесез, Муса абый!» — дип кычкырып җибәрә яздым.

— Абый, мин булам чәй кайнатучы.

— Әллә көн саен алмашынып торасыз инде? Берничә көн элек кенә башка берәү иде. Менә пропускам. Мин зонада санитар булып эшлим.

Шулчак ул монтерны күреп алды, барып, кул биреп исәнләште, аннары икәүләп бер бүлмәгә кереп киттеләр. Мин берни дә аңламыйча калдым.

Муса абый күрешкән кеше — поляк, монтер. Ике араларында нинди уртаклык булырга мөмкин? Нинди телдә сөйләшә икән алар?

Әз генә сүз алышкан арада да мин Муса абыйны җентекләп күзәтеп өлгердем. Ут кебек янып торган күзләре эчкә баткан, йөзе саргайган, битен сакал-мыек баскан, чәчләренә чал керә башлаган, бик ябыккан. Өстендәге киемнәре иске. Шундый хәленә дә карамастан, үзен гаҗәп тыныч тота.

Менә ул бүлмәдән чыкты.

— Озак торырга туры килде, чәең суынып беткәндер инде,— диде.— Медикаментларны аерып-аерып куярга кирәк иде. Мин аларны монтер бүлмәсендә саклыйм.

— Суынды шул,— дидем мин, сүз башлау өчен җае табылуга шатландым.— Хәзер, тиз генә җылытам мин чәйне. Аңарчы бераз сөйләшеп тә алырбыз.

— Нәрсә турында сөйләшербез икән?

— Сүз табылыр, абый.

— Әйе шул, менә үзегез турында сөйләгез. Ничек җиңел эшкә урнаша алдыгыз? Бу киемнәрне кем бирде?

Мин аңа Зиннәт ярдәм итүен әйттем. Соңыннан:

— Сез бит Муса абый! — дип кычкырып ук җибәрдем.

Ул ике бармагын авызына куйды да:

— Чү! — дип пышылдады.— Нәрсәгә таянып, шулай дисез?

— Муса абый, беренче генә күрүем түгел минем сезне. Сугышка чаклы сөйләшеп утырганыбыз да булды. Казанда, Матбугат йортында, Язучылар союзында.

— Сез белгән Мусаның фамилиясе ничек иде соң?

— Шагыйрь Муса Җәлил.

— Мин дә Муса, әмма фамилиям туры килми. Гомәров мин. Хәтерегездә тотыгыз: Гомәров! Аңладыгызмы?

— Аңлавын аңладым, әмма буй-сыныгыз, тавышыгыз, кул хәрәкәтләрегез күз алдымнан да, күңелемнән дә һич китми шул...

Ул мине эчкә баткан күзләре белән елмаеп тыңлап торды да:

— Энем, мине шагыйрь Муса Җәлилгә охшатып, көлкегә калмагыз,— диде. Шулай да чыгып китәр алдыннан:— Ярый, энем, бер утырып сөйләшербез әле,— дип өстәде.

Минем күңелем булды. Ачылып җитмәсә дә, кабат очрашудан да баш тартмый, димәк. Ул киткәч, ашыгып кына Зиннәт керде.

— Эшебез тыгыз, үтеп барышлый гына сугылдым. Менә сиңа тартырыңа һәм бераз икмәк белән колбаса. Вагоннар бушатабыз, азык-төлек шактый килгән. Синең хакта Атай белән сөйләштем. Моннан ары сиңа кул күтәрмәс.

* * *

Лагерьда үлүчеләр саны кимеми. Әсирләр ачлыктан, ялангачлыктан интегә. Мәхмүт абый белән Ибраһим «Капут командасы»нда эшлиләр. Кичләрен бик арып кайталар. Шулай да авыр эштә булуларына бик борчылмыйлар, чөнки көненә өчәр мәртәбә икешәр өлеш баланда ашыйлар, эрзац икмәкне бүтәннәр кебек, биш кешегә түгел, ә өч кешегә бүләләр. Өстәвенә, аларга пешкән бәрәңге йә чөгендер һәм өчәр сигарет бирәләр.

...Кичләрен, туган якларны сагынып, моңаешып утырабыз. Кемдер җыр көйли, Тукай, Такташ шигырьләре искә төшә...

Көн артыннан көн үтә. Муса абый сөйләшеп утыру турындагы вәгъдәсен онытты бугай. Чәй алырга килгәндә, исәнләшә дә, саубуллашып чыгып та китә.

* * *

Әсирләр арасында җанлылык сизелә башлады. Төркем-төркем җыелып сөйләшүләр ешайды. Бу бигрәк тә «Кичке базар» вакытында була.

Бер кичне Мәхмүт абый белән Ибраһим мине кухня ишек төбендә көтеп торалар иде.

— Солтан алып чык әле шуннан бер-ике әрҗә,— диде Мәхмүт абый.

Әрҗәләрне алып чыгу минем өчен куркыныч түгел, аларны ут тергезер өчен вата торган идем.

Мәхмүт абый алдан китте. Без аның артыннан. Халык җыелган урынга җитеп туктадык. Әсирләр арасында мин Муса абыйны күреп алдым. Беркөн күргән озын буйлы кеше белән сөйләшеп тора. Кинәт ул күздән югалды. Озын буйлы әсир без алып килгән әрҗә өстенә менеп басты.

— Иптәшләр!— диде ул.— Сезнең белән киңәшәсе иде... Монда бик якын килмәгез, бераз ара калдырыгыз.

Тынлык урнашты.

— Мин дә сезнең кебек үк әсир. Авыр эштә эшлим, ачмын, ялангачмын. Әлегә үз аягымда, әмма, кем белә, блокка кайтып җитә алмавым да ихтимал. Үзегез күреп торасыз, көн саен күп әсирләр вафат була. Сәбәпләрен беләсез. Шулай да, шөкер, арада җиңелрәк эштә эшләүчеләр, азыкка да, киемгә дә артык интекмичә яшәүчеләр дә бар. Дөрес әйтәмме?

— Дөрес, дөрес,— дип хуплады кемдер.

— «Кичке базар»— безнең ял итү урыны. Әмма шуннан явызларча файдаланучылар туганнарыбызның вафатын якынайталар. Ничек итепме? Әле кайчан гына илебез азатлыгы өчен кулга корал тотып уртак дошманга каршы сугышкан адәмнәр үз иптәшләрен алдыйлар. Бер тартырлык тәмәкене биш кешегә бүлеп бирелгән икмәккә талап диярлек алышалар. Иске киемнәрен яңаракка алыштыралар. Бер-беребезне болай мыскыл итүләргә чик куярга кирәк!

— Дөрес, дөрес!— диешә әйләнә-тирәдәгеләр, кул чапкан тавышлар да ишетелгәләде.

— Без һәммәбез дә кушылабыз сиңа, шулай бит, туганнар?— диде өлкәнрәк яшьтәге әсир.

Шулчак яхшырак киенгән таза гына гәүдәле берәү алга чыгып басты.

— Синең әйткәннәрең безгә закон түгел!— диде ул.— Кем ничек булдыра, шулай яшәргә тиеш.— Аннары тагын да гайрәтләнде:— Менә сиңа ике юл — йә сүзләреңне кире аласың, йә башыңнан колак кагасың!

Һәм, йодрыкларын уйнатып, озын буйлы әсир янына килеп тә басты, аның якасына ябышырга ук омтылды. Шөкер, әзмәвер гәүдәле Мәхмүт абый:

— Кулыңны тидерәсе булма!— дип кычкырып өлгерде.— Үзеңнең муеның борылмагае!

Тегесе ансат кына басылмады, йодрыкланган кулы белән Мәхмүт абыйга тондырды.

— Әле син шулаймы?! Мә, алайса!— дип, Мәхмүт абый кизәнеп үк сукты...

* * *

Теге көнне танышкан Гайнан исемле сөйкемле егет белән якыннан аралашып киттек. Еш күрешәбез. Бүген аны озаткан гына идем, ишектә Муса абый күренде. Башка көннәрдәгегә караганда күңеле шатрак, йөзе ачыграк. Кул биреп күреште.

— Энем, бүген менә сезнең белән сөйләшергә вакыт табылды,— диде ул.

Шатлыгымнан нишләргә дә белмәдем. Утын өстәп, учактагы утны көчәйтеп җибәргәч кенә, Муса абыйга утыргыч тәкъдим иттем. Сүзне ул башлады.

— Нинди шартларда күрештегез сез шагыйрь Муса Җәлил белән?— дип сорады.

Мин ашыкмыйча гына сөйләргә керештем.

— Муса абый белән беренче очрашуым кырыгынчы елда Казанда булды. Аны эзләп Язучылар союзына барган идем. Сәбәбе мондый. Безнең авылда Бари Хәлиуллин дигән кеше бар иде. Үзе фирка әгъзасы, колхоз рәисе булып эшли иде. Соңгы елларда явызлыкка бирелеп китте. Колхоз ашлыгын урлаудан да хурланмады. Амбар мөдире белән икәүләшеп ашлык урлаганда, аларны каравылчы Садыйк абый тота. Әмма ялгызы берни дә эшләтә алмый. Ул чакта мин, укытучы булып эшләү өстенә, авылда комсомол оешмасы секретаре да идем. Садыйк абый бу хәлләрне миңа сөйләде, язып та бирде. Авылда фирка оешмасы юк иде, шуңа күрә Бари абыйның эшен комсомол җыелышында тикшердек. Бари абый җыелышка килүдән баш тартты. Без, аны фирка әгъзалыгыннан чыгарырга, колхоз рәислегеннән азат итәргә, дигән карар кабул иттек. Әмма партия райкомыннан килеп колхоз җыелышы ясадылар да, безнең теге карарны юкка чыгардылар. Якланып калган Хәлиуллин үзенә каршы кешеләрдән үч ала башлады. Колхозчылар тагын миңа мөрәҗәгать иттеләр. Шуннан мин бу хакта очерк яздым. Шуны күтәреп, Казанга, «Кызыл Татарстан» газетасына киттем. Анда безнең районда эшләгән Ислам Рәхмиев дигән кеше бар

иде. Очеркымны укыгач, ул миңа, моны газетада бастыру кыенрак, бик озын. Әйдә, Җәлилгә керик әле, бәлки, ул берәр киңәш бирер, диде. Менә шунда күрдем мин Муса Җәлилне. Ул, без кергәч, урыныннан торып, каршыбызга килде, кул биреп күреште. Аның белән минем өчен Рәхим абый сөйләште. Мин исә Җәлилдән бер минутка да күземне алмадым. Соңыннан ул миңа, сез язмагызда колхоз рәисен генә түгел, партия райкомын да гаеплисез, шуңа күрә сезгә, партия өлкә комитетына барып, хәлне сөйләп бирергә кирәк, дип киңәш итте. Ул әйткәнчә эшләдем. Партия өлкә комитетында мине, Хәлиуллин җәзасын алачак, дип ышандырдылар. Аннан канатланып чыктым, туп-туры Муса Җәлил янына киттем. Рәхмәт әйтергә иде ниятем. Әмма очрата алмадым. Озак та үтмәде, Хәлиуллинны, фирка әгъзалыгыннан чыгарып, колхоз рәислегеннән төшерделәр. Шуннан соң барлык колхозчылар исеменнән Муса абыйга рәхмәт хаты язып салдым...

Әңгәмәдәшем мине игътибар белән тыңлады. Соңыннан тирән итеп уфылдады. Аннары:

— Сез фирка әгъзасымы?— дип сорады.

— Әйе.

— Якын иптәшләрең бармы?

Мин Мәхмүт абый белән Ибраһим исемнәрен атадым, аларның кем икәнлекләрен әйттем. Муса абый минем күзләремә озак карап торды.

— Әйе, мин Муса Җәлил булам,— диде, шактый вакыт узгач. — Әмма бу хакта берәүгә дә белгертмәгез. Әйткәнгә карап, сезгә җиңеллек килмәячәк.

— Аңладым, Муса абый. Билетым үзем белән булса, шуны тотып ант итәр идем. Ышаныгыз!

Мин аны Зиннәт алып килгән ризыклар һәм ширбәтле чәй белән сыйладым.

— Якташым сүзендә торса, мин һәрвакытта да сезгә өлеш чыгарырмын,— дидем.

— Әй, энем, бер мин генә мени шушындый көнгә калган!— дип ачынды ул.— Көн дә күпме әсир вафат була... Күпме хатын-кыз тол, балалар атасыз, әти-әниләр баласыз кала... Башка сыймаслык хәлләр...

Муса абый саубуллашып чыгып китте. Аның кызуланып атлавын тәрәзәдән карап калдым.

* * *

Бу юлы кергәндә йөзе ямансу иде аның. Авырганга да охшамаган, ниндидер уйга калган кеше сыман. Чәй кайнамаган иде әле, мин аңа тиз генә электән калган салкын чәйне салып бирдем.

— Рәхмәт, энем. Буыннарым калтырый, туңдыра.

Муса абый учак каршысына утырды, кулларын җылытты.

— Мин үзем юк-барга ышанмыйм. Шулай да бүген күргән төшем никтер шөбһәләндерә. Төне буе юньләп йокы күрмәдем, таң алдыннан гына оеп киткәнмен. Тиргә батып уяндым. Торып утырсам, блок эчендә берәү дә юк. Янымда котелок белән баланда тора. Иптәшләр алып килеп калдырганнардыр. Баланданы зона тазартучы бер әсиргә бирдем. Эчәсем килә иде. Рәхмәт.

— Муса абый, хәзер ашарыгызга бирәм.

— Юк, энем, миңа монда авыз күтәреп ашап утырырга ярамас. Әле кухня хуҗасы фельдфебель, әле зона коменданты, әле өлкән полицай керер-чыгып йөриләр. Ашап утырганымны күрсәләр, сиңа да, якташыңа да эләгер. Инде үзегездән артса, теге монтер полякка кертеп бирерсез, шуннан алырмын.

Аннары Муса абый төнлә күргән төшен сөйләде.

— Казанда, Матбугат йортыннан чыгып килəм, имеш. Урамның каршы ягында басып торучы ханым белəн кыз балага күзем төште. «Əнием, кара əле, тегендə əтием басып тора бит»— ди кызчык. «Юк, кызым, ялгыш күрəсеңдер,— ди ханым.— Əтиең һəрчак кырынып, чəчен алга тарап, пөхтə киенеп йөри. Моның өстендə иске шинель, башында каешланып беткəн пилотка, аягында агач башмаклар, йөзе дə саргайган, үзе шыр сөяк. Ул тере кешегə дə охшамаган бит». «Бу — мин, мин!»— дип дəшəм аларга. «Чык бу якка, əтием!— ди Чулпан, кулларын чəбəклəп. — Мунча керерсең, күп ризыклар əзерлəп куйдык, сыйланырсың».

Муса абыйның тыны кысылды, күзлəрендə яшь бөртеклəре җемелдəде. Тирəн сулыш алды да дəвам итте.

— Урам аша атлаган гына идем, алдыма зур кара эт килеп басты. Өрми дə, тешлəми дə, бара башласам, авызын зур итеп ача да алгы аякларын күтəрə. «Əтием,— ди Чулпан,— əнə, Кремльгə таба кит!» Этне алдап, тиз генə теге якка чыкмакчы булам. Əле тегелəйгə, əле болайга барам, ə эт һич тə миннəн калмый. Шулай йөри торгач, тəмам хəлдəн тайдым. Шыбыр тиргə батып уянып киттем... Борынгылар, төштə эт күрсəң, дошман булыр, дигəннəр. Дөрескə килмəгəе. Əсирлектə булуыбызга өстəп, арабызда сатлык җаннар да булуын да онытмыйк...

Сүзсез утырдык.

— Их-х, гаилə сагындыра! Кызым белəн хатынымны күреп, туйганчы сөйлəшəсе килə...— дип моңсуланды Муса абый.— Хыялымда озын-озын итеп хат язам. Очып барган кошны чакырам да, хатымны аның аягына бəйлим. Хатымны гаилəмə тапшырыр кебек кошкай... Əй-й, бу коточкыч крепость өстеннəн нинди кош очсын соң... «Кошчык»дигəн шигыремне дə шулай хыялланып йөргəндə яздым... Əминə иркəм белəн Чулпан кызымны, төштə генə булса да, туйганчы сөеп тə булмады...

Муса абыйның күзлəреннəн яшьлəр тама иде...

Урам яктан берəүнең җырлаганы ишетелде. Гайнан Кормашның моңлы тавышы иде бу:

— Кара да гынай, кара урман...

Тəрəзə кактылар. Мəхмүт абый белəн Ибраһим икəн.

— Кайнар чəй белəн тартырга чыгармассыңмы?— диде Мəхмүт абый.

Муса абыйга аларның кемнəр икəнлеген əйткəч:

— Син, энем, чыгып йөрмə, миңа бир дə, мин тапшырырмын. Минем арттан барырга əйт үзлəренə,— диде.

Кичен мин кайтканда, Мəхмүт абый белəн Ибраһим ятканнар иде инде. Муса абый белəн ни сөйлəшкəннəрен мин дə сорамадым, үзлəре дə əйтмəде. Аларны да кисəтеп куйгандыр, күрəсең, Муса абый.

* * *

Иртəн Гайнан килеп керде дə:

— Муса абыйдан сəлам сиңа,— диде.— Ул авырып китте. Аякка баскач, өчегезне дə күреп сөйлəшергə тели.

Димəк, Муса абый безне юньле кешелəргə саный.

— Якташың күренгəлиме?— дип сорады Гайнан.

— Бик кирəкмени?

— Кирəк. Чиркəү артындагы бер катлы йортта яшəүче полковник хəзер дə шунда микəн, якташың килсə, шуны белеш əле.

...Көннең икенче яртысында бик ашыгып кына Зиннəт кереп чыкты.

— Хəлеңне белим, дидем. Тартырыңа килəсе юлы калдырырмын. Əле үтеп барышлый гына керүем.

Мин аңа Гайнанның үтенечен əйттем.

— Кая китсен ул?! Полковник бит үз иркендә яшәми. Иртәгә һәм берсекөнгә аны русча белүче немец карты саклый. Шундый көннәрдә генә аңа әйбер тапшырып була. Кәгазь сораган иде.

Соңыннан Гайнанга Зиннәт белән сөйләшүемне җиткердем.

Муса абый минем аша Зиннәткә ниндидер йомыш кушарга исәпли, ахрысы. Башкаларны түгел, нәкъ менә безне, фирка әгъзаларын сөйләшүгә чакыра. Ниндидер план кора, күрәсең...

Мәхмүт абый белән Ибраһим, йөзтүбән яткан килеш, ни турындадыр гәпләшәләр иде. Мине күргәч, торып утырдылар, бүгенге вакыйгаларны сораштылар. Муса абыйның безне чакырачагы турында ишеткәч, алар да шатланды.

Гайнан кухняга көләч йөз белән килеп керде. Уйланып торды да, йомшак тавыш белән сөйләп китте.

— Бу хатны полковникка кем аша тапшыру хакында без күп уйлаштык, Солтан,— диде:— Якташыңның хыянәт итмәячәгенә ышанасыңмы?— дип сорады.

— Аңладым, Гайнан,— дидем.— Әгәр берәр хәл була калса, минем белән теләсә нәрсә эшләрсез. Мин Зиннәткә ышанам, хыянәт итмәс.

Зиннәт сүзендә торды, әйткән вакытында килде.

— Полковникка кәгазьләр илтә барышым. Менә сиңа сигаретлар.

Куенымда Гайнан биргән хат иде, йомышымны әйттем.

— Әллә полковник белән хат алышасыз инде,— дип көлде Зиннәт.

Шуннан соң мин аңа Муса абый турында сөйләп бирдем.

— Син аны күреп сөйләштеңме?— дип кызыксынды ул.

— Зинһар өчен, тапшыр шушы хатны полковникка, җавабын да алып кайт,— дидем мин.

— Бала чактан бергә үстек, бергә укыдык. Сиңа хыянәт иткәнем булдымы берәр вакыт?— диде ул, ышанычлы итеп.— Шулай булгач, җиткер Муса абыйга, җавабын иртәгә менә сиңа китерермен.

Мин аңа хәерле юл теләп калдым. Аннары аш пешерү бүлегенә кердем, Гайнанга ярым пышылдап:

— Хатны бирдем, җавабы иртәгә булыр,— дидем.

— Кайткач, Муса абыйны шатландырыйм әле,— дип елмайды Гайнан.

* * *

Иртәнге аштан соң ял итәргә генә утырган идем, монтер поляк килеп керде. Баш иеп исәнләште. Ике бармагын ирененә куеп, «пуф-пуф», дип тартырга сорады. Мин биргән сигаретны йотылып тарткач:

— Мутса!— диде.

Шуннан исемә төште: мин аңа Муса абый өчен ризык бирергә тиеш бит! Төргәкне алгач, монтер аны түшенә яшерде.

Ибраһим һәм Мәхмүт абый кичен Муса абый белән очрашканнар. Озак тордылар алар. Инде «Кечке базар» да тарала башлады. Ниһаять, кайтып керделәр. Йокламыйча ятуымны күргәч:

— Бар тизрәк, синең үзеңне дә Муса абый чакырды,— диде Ибраһим.— Күрше блок янында көтә.

Муса абый бик тә җитди иде.

— Нинди яңалыкларың бар?

Мин аңа Зиннәт белән очрашуымны әйттем. Муса абыйның тагын йомышы бар икән.

— Якташың миңа кәгазь белән каләм табып бирә алмасмы, сораштырсаңчы,— диде ул.— Тагын менә нәрсә: өлкән полицай минем белән кызыксына икән. Кемдер минем шагыйрь Муса икәнлегемне җиткергән. Дөресме бу — якташыңнан монысын да белеш әле. Мине очрата алмасаң, җавабын Гайнанга әйтерсең.

— Ярар, Муса абый...

* * *

Ышандыруын ышандырдым да, әмма Зиннәттән ничегрәк белешергә икән, дип уйга калдым. Бәхетемә каршы, Зиннәт, очрашкач, бу хакта үзе үк сөйләп бирде.

— Бер хәбәр әйтим әле үзеңә,— дип башлады ул.— Акчурин, Атайның кушуы буенча, шагыйрь Муса Җәлилне эзли икән. Сезнең зонада Муса исемлеләр бишәү, ди. Тик берсенең дә фамилияләре туры килми икән. Синең янга чәй алырга йөрүче санитар абыйдан шикләнәләр. Акчуринга, аның чын фамилиясе — Гомәров, дигәннәр. Җәлилне табып бирүчегә зур бүләкләр вәгъдә итәләр икән немецлар. Акчуринның әйтүенчә, гаиләсе белән дә кызыксыналар икән.

— Әгәр тапсалар, нишләтерләр аны?

— Берни дә эшләтмәячәкләрдер. Полковникны җәберләмиләр бит әнә. Агитация алып бармасын, дип, сак астында гына тоталар,— дип тынычландырды Зиннәт.— Гаиләсе ни өчен кирәк булганлыгын гына аңламадым. Бик нык эзләнәләр. Шулай да нинди кешенең намусы җитәр икән аны сатарга? Иреккә чыгарабыз, дип вәгъдә итсәләр дә, мин мондый әшәкелеккә бармаячакмын!.. Менә шундый яңалык алып килдем сиңа, Солтан. Ашарыңа, тартырыңа бардыр бит әле?

— Рәхмәт, Зиннәт дус, әлегә җитәрлек. Бераз кәгазь белән каләм кирәк иде...

— Нигә элегрәк әйтмәдең аны?! Хәзер, Акчуринга барам да, алып та киләм,— диде, ашыгып кухнядан чыгып та китте һәм, озак та үтмичә, төргәк күтәреп тә керде.

...Муса абыйга Зиннәт керткән кәгазь-каләмне бирдем. Аны эзләүләре хак икәнлеген әйттем. Ул дикъкать белән тыңлады. Уйланып утыргач:

— Төшем рас килә...— диде.

Шушы сөйләшүдән соң озак вакытлар очраша алмадык. Үзе кермәде, миңа аның янына барырга ярамый иде.

* * *

Муса абыйның үз иркендә икәнлеген (әкәмәт, әй, әсир кешене дә кулга алырлар, дип куркабыз бит!) Гайнан һәр көнне диярлек җиткереп тора. Шөкер!

Мәхмүт абый белән Ибраһим, Муса абый белән очрашканнан соң, эштән бик арып кайтуларына карамастан, «Кичке базар»дан бик соң керә башладылар. Беркөнне шул базарда полицай Акчурин Мәхмүт абыйга әйткән:

— Син, егет, «Капут командасы»нда эшлисең. Үзең яхшы кешегә охшагансың. Эшең авыр, күреп торам. Муса Җәлил дигән шагыйрьне табып бирә алсаң, авыр эштән котыласың. Тамагың да туяр.

Аның сүзенә каршы Мәхмүт абый кистереп болай дип җавап биргән:

— Сезгә кирәк икән, үзегез табыгыз. Мин андый шагыйрьне белмим дә, белергә дә теләмим. Аягым-кулым исән, тәнем сәламәт. Ачлыктан интекмим, баланданы ике порция ашыйм, ипине өч кешегә бербөтен бирәләр...

Бу хакта мин Гайнанга әйттем. Ул Муса абыйга җиткергән. Муса абый Мәхмүт абыйга рәхмәт әйтергә кушкан.

Муса абыйның язмышы мине бик тә борчый башлады. Тавышы колагымнан, гәүдәсе күз алдымнан китми. Казанга су салып, учакны тергезеп җибәрдем дә, тәмәке кабызып, тәрәзә каршына килеп бастым. Күзләрем — Муса абый яшәгән блок ишегендә. Менә ул, иңенә санитар сумкасын асып, кулына котелок тотып, авыр башмакларын сөйри-сөйри кухняга чәй алырга чыгар кебек.

Зиннәт керде.

— Күңелсез хәбәр китердем,— диде ул, учак каршына утыргач. Күмер болгата торган тимер таякны тотып, бер кавым уйланып утырды. Уфылдап куйды да, дәвам итте:— Эзенә төшкәннәр шагыйрь Муса Җәлилнең. Теге санитар абый булып чыккан ул.

— Кем әйтте?— дидем мин кабаланып.

— Бүлдермә. Кичә кич Акчурин берәүне тимер капкага озата барды. Читтән генә күзәтеп тордым. Аларны гражданский киемдәге икенче берәү каршы алды. Сүзләрен ишетә алмадым, ара ерак иде. Кайтышлый, Акчуринның каршысына төшеп, боларның кем икәнлеген сорадым. Каршы алучының кем икәнлеген белмим, үзем озаткан кешене беләм, шагыйрь Муса Җәлил ул, диде. Аны табып бирүче үзебезнең арада яшәүче бер сатлыкҗан икән.

— Болай булгач, аны бөтенләй югалтып куюлары мөмкин бит,— дидем.

— Немецларның нәрсә уйлаганнарын кем белә? Бу хакта складта эшләүчеләргә дә сөйләгән идем. Алар да бик кайгырды. Мин сиңа әйткән идем бит, азык һәм кием склады хуҗасы лагерь комендантының туганы, дип. Ул безнең белән дус яши, чөнки үзе бик урлаша, ә без аңа булышабыз. Җәлилне нишләтергә уйлауларын аның аша белешеп карарбыз әле.

Тукталып торгач, ул тагын яңа хәбәр әйтте:

— Бүген складка өс һәм баш киемнәре китерделәр. Өс киемнәренең сул җиңнәрендә «Идел-Урал легионы» дигән эмблема тегелгән. Склад хуҗасыннан моның ни икәнлеген сораган идек, ул көлеп кенә куйды, бу көннәрдә нәрсә генә эшләнми, көн дә бер яңалык, ди.

Китәргә кузгалгач, мин аны туктатып:

— Зиннәт, болай булгач, мин Акчурин янына азык алырга керә алмам. Җирәнәм мин аңардан!— дидем.

— Син аның белән сөйләшеп тормыйсың бит, Солтан. Мин китергән ризык аныкы түгел...

Үзем генә калдым. Кем белән уртаклашыйм бу хәсрәтләремне? Мәхмүт абый белән Ибраһим эштә. Гайнан янына керсәм, анда ят кешеләр күп. Хәер, бу хәбәр аңа барып ирешкәндер инде. Уйлый-уйлый башым катып бетте. Елар идем, яшь чыкмый.

Әсирләр «Кичке базар»га җыйнала башлады. Мин кайтып ятканда, Мәхмүт абый белән Ибраһим юк иде әле. Соң гына кайттылар. Сөйләшүебез тагын да Муса абый хакында булды.

— Аны сатучылар берәү генә түгел, өчәү булырга тиеш,— диде Мәхмүт абый.— Исемнәре дә билгеле: Хаҗи, Шәрип, Нигъмәт. Аларның Атайга, комендант әфәнде, сезгә әйтәсе сүзебез бар, дигәннәрен ишетеп калганнар. Атай аларны үзе яши торган блокка алып кергән. Шуннан соң аларның аннан чыкканнарын да, блокларына кайтканнарын да күрмәгәннәр. Хәтереңдәме, «Кичке базар»да берәүне бәреп еккан идем? Үтергәнче сугасым калган икән...

Иртән эшкә килгәндә, кухняда ут юк иде. Өлкән полицайның кемгәдер җикеренүе, фельдфебельнең кемнедер ашыктыруы ишетелде. Мөгаен, монтер полякны тиргиләрдер. Югыйсә, эшен җиренә җиткереп башкара ул. Күрәсең, җил аркасында кайдадыр авария булган. Менә монтер атыла-бәрелә чәй кайнату бүлегенә килеп керде, электр үткәргечләрен тикшерә башлады. Күп тә үтмәде, ут кабынды. Ул да булмады, өлкән пешекче белән фельдфебель монтерны, идәнгә егып салып, типкәләп кыйнадылар да китеп бардылар. Монтер егылган җиреннән торды, киемнәрен какты. Битендәге җәрәхәттән аккан канын яулык белән сөртә башлады. Каны һаман туктамады. Моны өлкән пешекче үзе күреп алды, йода, пластырь алып, җәрәхәтен бәйләп куйды. «Каян килгән бу фашист ялчысына мәрхәмәтлелек?»— дип уйлап куйдым.

Монтер миннән тәмәке сорады. Үзе:

— Мутса, Мутса,— дип кабатлады.

Мин үземчә аңлатырга тырыштым. Ишарәмә төшендеме, юкмы, күңелсез генә сөйләнеп чыгып китте. Менә бит, үзенең хәле авыр булуга карамастан, ул да шагыйрь турында кайгырта.

Зиннәт Муса абый хакында җылы хәбәр китермәсме, дип көтәм. Зона капкасын ачып керүен ерактан ук күреп алдым. Ашыгып килүен күргәч, йөрәгем жу итеп китте. Кухняга җитәрәк, Зиннәт, туктап, кем беләндер сөйләшә башлады. Мин түземсезлек белән көтәм, ә ул ашыкмый, сөйләнеп тора бирә. Йөгереп чыгып, икесен дә сугып егардай булдым. Зиннәт тәрәзәдән каравымны күреп алды, көлеп җибәрде. Бераз тынычлангандай булдым.

— Үзебезнең хуҗадан сораштык Муса абый турында,— диде Зиннәт ашыкмыйча гына.— Ул әйтте, хәзер сезне җәзалап үтерү түгел, кыйнау да катгый тыела, диде. Гитлерның шундый әмере бар икән. Җәлилне каядыр озатачаклар, диде.

Димәк, Муса абый исән. Мең шөкер! Тик, кызганыч, янында таяныр кешеләре юк. Кая гына озатсалар да, ышанычлы иптәшләр табу өчен, озак вакыт кирәк булачак әле аңа. Әнә, Гайнан әйтүенчә, күп әсирләр кайгыра аның югалуына. Шигырьләре белән күңелләрне юата иде, дөрес киңәшләр бирә иде, ди. Бүген, «Кечке базар»га чыгар алдыннан, Мәхмүт абый:

— Таба алмабызмы теге сатлык җаннарны! — дип, кулларын йодрыклап, тешләрен шыгырдатып куйды.— Буып үтерер идем мин аларны! Эзләсеннәр иде караңгыда кем эшләгәнне...

— Мәхмүт абый, миндә сындәгедәй көч юк,— диде Ибраһим. — Алай да, кирәк булса, читтә калмам...

Чәй кайнату бүлегенә Гайнан ачык йөз белән керде. Учак янына тезләнде, таяк алып, күмерләрне болгатты, аннары гына хәбәрен әйтте:

— Безнең белән аш пешерү бүлегендә эшләүче Хәйдәр абыйны беләсеңме? Блогына кайтып килгән иде, Муса абыйны очраткан. Башта танымаган, чөнки өс-башын алыштырган, сакал-мыеклары кырылган. Хәйдәр абыйның соравына каршы, кунактан кайтышым, әмма хәлем бик начар, дип кенә әйткән.

Димәк, Муса абый кабат безнең арада. Тик менә авырып китүе генә...

— Бүгенгә аның янына кереп йөрмәгез,— диде Гайнан.— Яңалык әйтсә, иртәгә үзем сезгә җиткерермен.

Уйланып калдым. Кайда, кем янында булды икән ул кунакта? Авыруы каты микән? Кулга алынган булгач, ничек кабат безнең арага җибәргәннәр икән?

Икенче көнне, Гайнанның ымлавы буенча, бер кат эшемне бетергәч, аш пешерү бүлегенә кердем. Миңа кадәр үк монда берничә әсир җыелган иде. Тик үзара сүз алышырга өлгермәдек, берәү (ул Гайнан әйткән теге Хәйдәр абый булып чыкты):

— Сабыр ит, Гайнан, теге палач — Атай болайга таба килә, — диде.

Нишләргә, дип аптырашып торганда, шул ук Хәйдәр абый хәйләсен тапты.

— Безгә җырлау тыелмаган бит,— диде.

Немец фельдфебеле, Атай һәм өлкән пешекче безнең янга килеп басканда, тырышып-тырышып татарча җыр суза идек:

Су буена төшкән идем,
Яфрак яра тал-тирәк...

Тегеләр җырга колак салып тордылар.

— Нинди шатлыгыгыз бар болай утырырлык?— дип сорады Зыятдинов.

— Тамагыбыз тук, өстебез дә ялангач түгел, эш урыныбыз да җылы,— диде Хәйдәр абый.— Ә күңел ачарга урын юк. Туган якларны, гаиләбезне сагынабыз. Шулай җырлап, хәсрәтебезне басабыз...

Алар киткәч, Гайнан Муса абыйдан ишеткәннәрен сөйли башлады.

— Аны кунакка ак эмигрант доктор Әхмәт Тимер дигән кеше дәшкән. Әүвәл юындырганнар, кырындырганнар, өс-башын алыштырганнар. Әңгәмә ашлы-сулы өстәл янында барган. Алар янына бер ханым белән Муса абый-

ның Чулпаны яшендәге кызчык керeп-чыгып йөргән. Боларны күргәч, ул үзенекеләрне искә төшергән, күңеле моңланган. Шулай да үзен кулга ала алган. Монда чакыртуларының сәбәбен сораган.

— Мин тиздән төзеләчәк «Идел-Урал» дәүләтенең президенты итеп билгеләнгән кеше,— дигән Әхмәт Тимер.— Безгә сезнең ярдәмегез кирәк. Гаскәрсез дәүләт булмый, ә ул гаскәрне әсирләрдән оештырырга мөмкин. Аларны сез ышандыра аласыз...

Мәсьәләне аңлагач, Муса абый әңгәмәне дәвам иттерүдән баш тарткан.

— Мин моңа барачак түгел, хәзер үк атсагыз да була,— дигән.

Әхмәт Тимер, бу сүзләрне ишеткәч, елмаеп куйган, аннары йомшак кына итеп:

— Сез мине аңлап җиткермәдегез бугай,— дигән.

— Аңладым, президент әфәнде,— дигән Муса абый тыныч кына.— «Идел-Урал» дәүләте сезнең кәгазьдә барлыкка килгән бит инде. Сез аңа ярдәмне Гитлердан сорагыз.

Әхмәт Тимер дә тиз генә бирешергә теләмәгән.

— Кызыл Армия полковнигы да башта сезнең кебек каршы килеп маташкан иде,— дигән.— Соңыннан риза булды.

Муса абый ул полковник белән очрашырга теләвен әйткән.

Әмма Әхмәт Тимер моның мөмкин түгеллеген белдергән. Ул хәзергә китте, дигән.

Ак эмигрант ягына авышмыйча, үз сүзен итәргә кыюлык һәм ихтыяр көче туплый алган Муса абыйга сокланып утырдык. Әмма сүзебезне дәвам итәргә өлгермәдек, Атай белән өлкән пешекче кабат кухняга килеп керделәр. Без җәһәт кенә таралыштык.

Үзем эшлим, башымда исә — төрледән төрле уйлар. Муса абыйның төш юрап утыруы хәтеремә килде. Теге кара эт Әхмәт Тимер булып чыга инде алайса. Ул аны таламаган бит, урам аша гына җибәрмәгән.

Яшереп куйган азыкларым бар иде, яңадан Гайнан янына кереп, шуларны Муса абыйга дип биреп җибәрдем.

Блокка кайткач, Муса абый турындагы хәбәрне мондагыларга да ирештердем. Үз чиратында Мәхмүт абый «Кичке базар»да ишеткәннәрен җиткерде.

— Берәүдән Муса турында яман сүз ишеттем,— диде.— Монда Советлар Союзы дип уйлагандыр ул, шигырьләр язып, безне котыртып ятарга, паразит, дип сүгенде. Икенчесе, менә бер кирәген биреп кайтаргач, безнең янга чыгарга да курка, дип тегенең сүзен хуплады. Шуннан тотындылар төрле яктан боларны тукмарга! Полицайлар килеп җитмәсә, белмим, ни белән беткән булыр иде бу.

— Күрсәң, бу икәүне таныйсыңмы?— дип сорады арабыздан берәү.

— Таныйм, сезгә дә күрсәтермен,— диде Мәхмүт абый.— Мондый сатлык җаннар болар гына да түгелдер әле. Көрәшергә кирәк. Тик саклык белән генә...

* * *

— Шөкер, Муса абый аякка басты,— диде Гайнан, сөенеп. — Сиңа сәлам әйтергә кушты. Үзе монда килеп йөри алмый, эше дә күп.

Рәхмәт үзенә, мине дә онытмаган икән. Әле йомыш та кушкан. «Акчурин янына ешрак кереп йөрсен, берәр яңалык ишетмәсме»,— дигән. Куандым. Димәк, миңа ышаналар икән. Шик тудырмас өчен, көн дә кереп йөрергә кирәк Акчурин янына, дигән фикергә килдем.

Ә бер кергәндә, Акчурин үзе юк, аның бүлмәсендә ят кеше утыра иде. Немец солдаты киемендә үзе. Сул җиңендә «Идел-Урал легионы» дип язылган. Егет бераз кызмача иде.

— Әйдәгез, шикләнмичә керегез,— диде ул миңа.

Сөйләшеп киттек.

— Сез дә язылырга килдегезме?

Моны нәрсә турында соравын, билгеле, төшенмәдем. Шулай да нидер әйтергә кирәк иде, сүз җаеннан соравының мәгънәсе аңлашылуы мөмкин иде.

— Әүвәл танышыйк. Сез кем атлы буласыз соң? — дип сорадым.

Самат исемле икән.

— Ә мин Солтан булам. Миңа сез кайда һәм кемгә язылырга икәнлеген аңлатып бирегез әле башта.

Саматтан байтак нәрсә ишеттем.

— Атай мине үзенең бүлмәсенә чакырган иде,— диде ул.— Анда сыйланып, ни турындадыр киңәшеп утыралар иде. Арадан берсе булачак «Идел-Урал» легионының президенты икән. Үзебезнең татар кешесе. Мине дә сыйладылар, өстемә менә шушы киемнәрне бирделәр. Белсәгез иде, нинди яхшы кешеләр алар! Аркамнан сыйпап мактадылар.

— Хәзер сез нәрсә эшләргә тиеш буласыз инде?

— «Идел-Урал» легионына башта үзем язылам. Озакламыйча митинг булырга тиеш. Шунда башкаларны да язылырга өндәячәкмен.

— Ә Атай алдында ничек итеп ышаныч казана алдыгыз соң? Тикмәгә генә шундый нәрсәне беренче булып сезгә тәкъдим итмәгәндер бит?

— Баш эшли синең, агайне! Дөрес, хикмәте бар. Мин аңа большевикларны яклаучыларны табышам.

— Ничек итеп?

— Атай әфәнде үзе әйтә кемнәрне эзләргә. Син дә языл, оттырмассың. Кыюлыгың җитмәсә, үзем кереп әйтәм.

Ничек җавап бирергә, дип аптырап торганда, Самат үзе ярдәмгә килде:

— Кая югалды соң бу Акчурин? Аның янына сугылырга кушканнар иде.

— Миңа миңа да аны күрергә кирәк шул. Эзләп керим әле,— дидем дә чыгып киттем, кире әйләнеп кермәдем.

Бу яңалыкны Муса абыйның үзенә турыдан-туры сөйләп булмады. Гайнанга җиткердем.

Соңгы көннәрдә баланданың сыйфаты бераз яхшырды. Ярма, ит консервасы, маргарин сала башладылар. Эрзац икмәк тә биш кешегә түгел, дүрт кешегә бер бөтен бирелә. Чәйгә дә шикәр күбрәк салына. Ни булды икән бу немецларга?

«Кичке базар»да мондый фикергә килделәр: бу — фашистларның чираттагы алдаулары. Балыкны да, ятьмә салганчы, суга ярма сибеп, бер төшкә туплыйлар бит...

* * *

«Татарларга, башкортларга, татарча аңлый һәм сөйләшә белгән башка әсирләргә! — дип башланган иде кухня стенасына эленгән белдерү.— Иртәгә «Идел-Урал» дәүләтенең президенты Әхмәт Тимер әфәнде митинг үткәрәчәк. Барыгыз да митингка! Комендант.»

Әсирләр белдерүне укыйлар да, нинди дәүләт ул, кем икән ул Әхмәт Тимер, диешә-диешә, китеп баралар. Фикер алышырга мөмкинчелек юк, игъланнар тактасы янында полицайлар басып тора.

Безнең блоктагы әсирләр, Мәхмүт абый тирәсенә җыелышканнар да, нидер киңәшәләр иде. Урыныма барып утырдым да сүзләренә колак салдым. «Адаш! — диде берсе.— Син тормышны бездән әйбәтрәк аңлыйсың. Шул белдерүнең мәгънәсен аңлатып бир әле».

Мәхмүт абый тәмәке кабызды. Әсирләргә карап елмайды да ашыкмыйча гына:

— «Идел-Урал» дәүләте — вәхши илбасарлар идеясе — диде.

— Алар бездән армия төзеп, кулларга корал тоттырып, Кызыл Армиягә каршы сугыштырырга ниятлиләр. Немецларга ак эмигрантлар ярдәм итә. Әхмәт Тимер — шундыйларның берсе. Митингта ул безне легионга язылырга өндәячәк. Без язылмаска тиешбез. Төрле сәбәбен табып. Бәлки, арабызда корбаннар да булыр...

Башкалар аның фикерен куәтләде:

— Канга — кан! Җанга — җан!

— Алайса, әйдәгез, «Кечке базар»га чыгыйк та, башкаларга да бу хакта аңлатыйк. Тик бик сак булыйк, туганнар. Үзегез дә күрәсез, полицайлар өерләре белән йөриләр.

Мин дә кузгалмакчы идем, Мәхмүт абый:

— Синең анда күренмәвең хәер, — дип туктатты. — Бу эштә тәҗрибәң чамасыз.

«Кечке базар»да озак булып керделәр. Мәхмүт абыйның адашы куанычлы хәбәр әйтте:

— Без генә түгел икән немецларның хәйләсенә төшенүчеләр. Шома егетләр бар! Әсирләр арасына кереп, алданмагыз, язылмагыз, диләр дә китеп югалалар. Полицайлар берсен дә тота алмады.

«Муса абыйның ышанычлы кешеләре эшле икән», — дип куанып уйладым.

Икенче көнне кухняга мин барып кергәндә, фельдфебель белән Зыятдинов анда иде инде. Нидәндер йөзләре ачык, күңелләре шат күренде.

Бераздан әсирләр, дүртәрләп сафка басып, ашка, чәйгә килә башладылар. Аларны бүген башка көннәрдәгечә ашыктырмадылар. Атайның полицайларга боерык биргәне ишетелде:

— Барча әсирләрне сафка тезәргә!

Ниһаять, әсирләр тезелешеп бетте, зона эчендә бераз тынлык урнашты. Ноябрь ае бит, хәйран салкынча. Җиле дә бар, кары да төшә. Әсирләр баскан урыннарында сикергәлиләр. Каршыга лагерь коменданты, берничә немец офицеры, гражданский киемдәге күзлекле берәү чыгып басты. Нидер киңәшләшеп алгач, гражданский киемдәгесе биек кенә тартма өстенә менде.

Зыятдинов ашны тизрәк өлгертергә кушты. Кухнядан чыгып китеп булмый, тышта ни сөйләгәннәре ишетелми. Теге кешенең кулларын хәрәкәтләндереп нидер аңлатырга азаплануы тәрәзә аша күренә. Тавышлар бер көчәя, бер басыла. Вакыт-вакыт көлешеп тә алалар.

Эшне бетереп, без дә чыгып бастык.

— Мөселман кардәшләр, татарча аңлаучы әсир әфәнделәр, тагын кем нәрсә әйтергә тели? — дип сорады Әхмәт Тимер. Граждан киемдәге кеше ул икән.

Читтәрәк бер кул күтәрелде. Аны Әхмәт Тимер тиз күреп алды, үзе янына килергә кушты. Бу әсирне ерактан ук танып алдым — Муса абый белән бер блокта яшәүче Сәйфетдинов. Ул, әкрен генә атлап, Әхмәт Тимер янына килеп басты.

— Әсир әфәнде, башта исем-фамилиягезне әйтегез!

— Минемчә, — диде Сәйфетдинов, аермачык ишетелерлек итеп, — исем-фамилияне әйтүнең кирәге юк. Менә сез «Идел-Урал» дәүләте озаклямыйча барлыкка киләчәк, дидегез, легионга язылырга өндәдегез. Сугыш техникасы, кием-салым һәм азык белән Гитлер хәзрәтләре тәэмин итәчәген әйттегез. Минем туган авылым Советлар Союзында. Сез анда кадәр барып җитә алмаячаксыз, чөнки аны кызылармеецлар саклый. Аларны хәзер беркем дә җиңә алмаячак. Минем тагын бер сүзем бар. Бу митингны сез үзегез генә дә үткәрә ала идегез бит, немец офицерлары нигә кирәк булды соң?

Әхмәт Тимер, тартма өстеннән төшеп, немецлар белән сөйләшеп алды. Тегеләр читкә китте. Алар урынына полицайлар килеп басты. «Президент», күзлеген киеп, саф арасыннан кемнедер эзли башлады.

— Солтан,— дип дәште янәшәмдәге Хәйдәр абый,— җентекләбрәк кара әле, күзлекле адәм Мусаны эзли бугай.

Муса абый тыныч кына басып тора иде.

— Таләбегезне үтәдем — хәзер үзебез генә калдык. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик,— диде Әхмәт Тимер.

Бер әсир, кул да күтәреп тормыйча, салмак атлап «Президент» каршына килде.

— Минем берничә соравым бар. Мөмкинме? — дип сорады ул.

— Рәхим итегез, әсир әфәнде.

— «Идел-Урал» дәүләте төзелгәч, безгә сүз иреге биреләчәкме? Башкаласы кайсы шәһәр була? Дәүләтнең армиясе дә, хәрби заводлары да булырга тиештер. Уртак тел кайсы милләтнеке булачак?

Болар Әхмәт Тимер өчен көтелмәгәнрәк сораулар иде, ахры. Көн салкынча булуга карамастан, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарды да, эшләпәсен күтәреп, башын, маңгаен, күзлеген сөртте. Тамагын кырды, йөткереп куйды. Әсирләр тын калып аның җавабын көттеләр.

— Мин бит ачык әйттем,— дип сөйләп китте Әхмәт Тимер.— Әлегә «Идел-Урал» дәүләте төзелмәгән. Легионга язылган кешеләр немец солдатларына бирелгән хокуклардан файдаланачак. Аерым хөкүмәт булып оешкач, сүз иреге дә, матбугат ирege дә биреләчәк. Газит-журналлар да, китаплар да чыгачак. Башкала да булачак. Ә инде армия мәсьәләсенә килсәк, без шул армияне төзәргә җыелдык бит инде. «Идел-Урал» дәүләте җирләрендә казылма байлыклар күп. Димәк, хәрби заводлар турында баш ватарга да кирәкми. Ә уртак тел, билгеле, татар теле булачак. Татар күп санлы халык, мәдәнияте дә алга киткән аның. Менә минем җаваплар шундый, әфәнделәр.

Әсирләр арасыннан берәү тавыш бирде:

— Президент әфәнде, бу җаваплар гына безне канәгатьләндерми. Дөрес бит, иптәшләр?

— Дөрес, бик дөрес! — дип башкалар да тавышланды, әмма полицайлар аларны тиз тынычландырды.

Әхмәт Тимер тартма өстенә бер менде, бер төште. Ниһаять:

— Мөселман кардәшләр, тагын кем сөйләргә тели? — дип сорады.

Әсирләр арыганнар иде, туңа да башладылар. Эндәшүче булмады.

— Кем үз ирке белән легионга язылырга тели? — дип кабат мөрәҗәгать итте «президент».

Күтәрелгән куллар күренмәде.

Әхмәт Тимер Атай белән ни хакындадыр киңәште. Шуннан соң ике полицайны, ашыктырып, каядыр җибәрделәр. Кире борылып килгәндә, алар белән немец солдаты киеменнән берәү бар иде. Сул кулы белән яңагын тоткан, бармак араларыннан кан саркый. Мин аның берничә көн элек Акчурин янына килгәч танышкан Самат икәнлеген таныдым.

— Самат әфәнде, кайда болай җәрәхәтләндегез? — дип сорады Әхмәт Тимер.

— Монда килгәндә берәү нәрсәдер ыргытты,— диде Самат.

Аны кухняда юындырып, битенә пластырь ябыштырып алып чыктылар. Әхмәт Тимер тагын тартма өстенә менде.

— Хәзер сүз мөселман кардәшебез Самат әфәндегә бирелә,— дип белдерде ул.

— Хөрмәтле әсир әфәнделәр! — дип Самат як-ягына каранды.— Ни өчен бу митингка җыелганыгызны доктор Әхмәт Тимер әфәнде әйткәндер. Мин үзем дә, сезнең кебек әсир төшеп, лагерьда ярым ач яшәдем. Минем дә, сезнең кебек үк, туган илдә гаиләм бар. Мин дә туганнарымны бик сагынам. Әмма кайтырга мөмкинлек юк. Сугыш беткән тәгъдирдә дә безгә туган илгә кайту юллары бикле. Чөнки илдә безне хыянәтчеләр дип саныйлар, кайтсак, үлемгә хөкем итәчәкләр. Гаиләләребезне дә хөкемгә тартачаклар. Сугышның тиздән бетәчәгенә ышанам мин. Бөек Германиянең җиңүе белән бетәчәк. Легионга язылсак, кулга корал тотып, без җиңүне

якынайтырбыз. Кызыл большевикларга каршы Германия солдатлары белән бергә сугышсак, үзебезнең «Идел-Урал» дәүләтенә җиңүчеләр булып кайтачакбыз. Гаиләләребез янына. Якта дөньядан китәргә иртә әле, нигә безгә, ачлыктан интегеп, сәламәтлегебезне какшатырга? Германия ярдәм кулы суза икән, моннан файдаланып калырга кирәк. Мин легионга беренче булып язылам, сезне дә шуңа чакырам.

Самат тартма өстеннән төште. Әхмәт Тимер, Атай, аларга ияреп, полицайлар кул чапты. Әсирләрнең: «Сатлыкҗан!» «Эт калдыгы!» «Туган илең, гаиләң, халкың турында уйла!» — дигән ачулы сүзләре ишетелде. Әхмәт Тимер, Саматны кочаклап, аңа рәхмәт әйтте. Аннары, әсирләргә борылып:

— Йә, тагын кем язылырга тели? Кем? — дип кабатлады.

Өстәл, урындык чыгарып куйдылар. Ул да булмады, берәм-берәм килеп язылучылар да табылды. «Президент», шатлыгыннан, әрле-бирле йөренде. Легиончылар шактый җыелды, шулай да язылу озакка бармады.

— Сүз сөйләргә теләүче бармы? — дип сорады Әхмәт Тимер.

Берәү кул күтәрде, аннары, сафтан чыгып, командирга рапорт бирергә барган кебек, каты-каты басып өстәл янына килде. Сердәш дустым Ибраһим булып чыкты ул. Ашыга торган кеше түгел Ибраһим, фикерен дә уйлап, ачык итеп әйтә.

— Президент әфәнде, әлегә мин язылырга ашыкмыйм, тора-бара күз күрер. Сезгә соравым да юк. Мин иптәшләр белән фикерләремне уртаклашырга гына телим.

Әхмәт Тимер сагая калды.

— Минем уйлавымча, «Идел-Урал» зур дәүләт булачак, — дип дәвам итте Ибраһим. — Аның белән бер президент кына идарә итә алмаячак бит. Сез бу хакта әйтмәдегез. Димәк, бу дәүләт кәгазьдә генә барлыкка килгән әлегә.

— Әсир әфәнде, болай булса, мин сезгә сөйләвегезне дәвам итәргә ирек бирмим!

Төрле яктан төрле сүзләр ява башлады:

— Сөйләсен! Үзегез сүз ирке бирдегез түгелме соң?

— Алайса, нигә безнең белән киңәшләшеп торасыз!

Әхмәт Тимер уңга-сулга, алга-артка борылгалап карады. Атайдан бүтән таянырдай кешесе юк иде бугай. Атай, баскан җиреннән кузгалмыйча гына:

— Ярый, сүзегезне дәвам итегез, әсир әфәнде, тик артык озакка сузмагыз! — дип кычкырды.

— Менә берничә көн инде ашауның сыйфаты яхшырды, — диде, Ибраһим. — Бу әсирләрне легионга алдап кертү өчен генә түгелме соң? Дөрес, бүген үк язылучылар булды, әмма алар әсирләрнең чама белән уннан бер өлеше дә юктыр. Аларның да кемнәр икәнлеген без яхшы беләбез...

Әсирләр көлешеп алды.

Әхмәт Тимер, ашыга-ашыга, Саматка:

— Хәзергә легионга язылучыларның командиры сез буласыз, — диде. — Башта мунча керсеннәр. Әйбәтләп юынсыннар. Аннары әнә теге каршыдагы зонага алып барыгыз. Анда аларны көтеп торалар. Йөзәр грамм аракы белән сыйфатлы аш бирәчәкләр. Тартучыларга сигарет өләшәчәкләр. Блоклар эче чиста итеп җыештырылган, йомшак урыннар җәелгән. — Шуннан соң, Ибраһимга таба борылды. — Менә, күрәсезме, легионерларны нинди әйбәт тормыш көтә. Алар — хәзер иректә кешеләр. Нәрсә телиләр, шуны эшлиләр. Яннарында тик хур кызлары гына юк. Озакламыйча, кем белә, алары да булыр, бәлки...

Ибраһим да аңа карап көлеп тора иде.

— Президент әфәнде, беләсезме, бер агай яшь чагында йорт салып кергән, имеш. Бер ел да тора алмаганнар, ишелеп төшкән йорт. Ярый әле, үзләре өй эчендә булмаганнар. Нигә ишелгән? Чөнки нигезе нык булмаган икән.

— Моның белән ни әйтергә телисез, әсир әфәнде?

— Менә сез безнең сорауларга төпле җавап бирә алмадыгыз. Үзегез белмәгәч, башта галимнәребез белән киңәшләшим, аннары әйтермен, дигә иде. Димәк, сезнең таяныр кешеләрегез юк. Нигезе булмагач, ул «Идел-Урал» дәүләте мәңге оешачак түгел. Безнең башны катырып, үзегезнең вакытыгызны әрәм итеп йөрмәгез монда.

Әхмәт Тимер, кызып китеп:

— Әх, син, эт калдыгы, кызыл большевик! — дип Ибраһимга таба килә башлады.

Әмма Атай өлгеррәк булып чыкты, арттан килеп, Ибраһимның башына нәрсә беләндер сукты. Ибраһим, ах, дип, чайкала-чайкала җиргә егылды... Кемдер, каты итеп:

— Нәрсә карап торасыз, бирик кирәкләрен! — дип кычкырды.

— Канга-кан, җанга-җан! — дип шаулаша-шаулаша, әсирләр полицайларга ташландылар.

Бәрелеш китте. Бу хәлне күреп, крепость түбәсеннән сакчылар пулеметтан атып җибәрделәр. Озак та үтмәде, автомат тоткан немецлар, этләр ияртеп, зона эченә йөгерешеп керделәр. Шулай да кул сугышы шактый дәвам итте. Һавага ата-ата, немецлар этләре ярдәмендә әсирләрне тарката алдылар. Без кухняда яшерендек. Ниһаять, зонада тынлык урнашты.

Кухняга лагерь коменданты белән немец офицерлары һәм солдатлары атылып керде. Мөдир бүлмәсеннән Әхмәт Тимер белән Атай чыкты. Йөзләре агарган, үзләре калтырана. «Президент» зонадан немецлар сагы астында китәргә мәҗбүр булды.

Тәрәзәдән урамга күз салдым. Унлап әсир килә. Якыная башлагач, араларыннан Мәхмүт абыйны танып алдым. «Капут команда»сында эшләүчеләр, димәк. Мәетләрне рәткә салырга тотындылар. Мәхмүт абый берсен икенче урынга аерым салды. Озаклап карап торды. Аннары җиң очлары белән күзләрен сөртте.

«Ибраһим мәетедер», — дип уйладым мин. Күзләремнән кайнар яшьләрем тама иде...

Зыятдинов безне җыйнады да:

— Бүген әсирләргә аш та, чәй дә булмаячак, — диде. — Эш урыннарыгызны җыештырыгыз да, иртәнгә чаклы ял итегез.

Кайтышлый мәетләр янына тукталдым. Ибраһимның гәүдәсенә озак карап тора алмадым, күзләремнән тагын яшь ага башлады... Блокта, Мәхмүт абыйны кочаклап, үкереп елап җибәрдем.

— Энем кебек иде, — диде Мәхмүт абый да үкси-үкси.

— Гел бергә идек...

— Мәхмүт абый, нигә аларны бүген күммәдегез?

— Иртәгә иртән дә күмәргә кушмадылар. Кем каршы килә, аларны да үлем көтүен белеп торсыннар, диделәр.

— Болай булгач, бу вәхшиләр бездән үч алачаклар икән, — диде кемдер.

— Безне зур көрәшләр көтә, — диде Мәхмүт абый. — Ибраһимны онытмыйк...

Югалтулар зур иде легионга беренче язылу көнендә. Шулай да әсирләрнең, коралсыз килеш, Муса абыйның яшертен җитәкчелегендә ирешкән беренче җиңүе дә иде бу вакыйга.

* * *

Болай да ярым ач әсирләрнең ашамыйча калып төн үткәрәчәкләре берәү өчен дә яңалык булмады. Немецларның бу чираттагы явызлыгы Әхмәт Тимернең җиңелүе өчен үч алу иде. Әсирләрнең, үз блокларында гына җыелышып, зар-моңнарын уртаклашудан бүтән чаралары юк иде.

Без, кухня эшчеләре, хезмәткә таң алдыннан ук китәбез. Башкалар йоклап кала әле. Бүген исә аларның күбесе урамда иде инде, митинг вакытында һәлак булган иптәшләре белән саубуллашалар, фашистларга, Әхмәт Тимергә чиксез нәфрәтләрен белдерәләр.

Кухня тәрәзәсеннән тышка күз салдым. Өлкән полицай Акчурин «Капут командасы»ннан берничә әсирне ияртеп килә. Мәхмүт абый да шунда. Элек Ибраһим белән икесенә бер носилка тоталар иде. Бүген Илдар исемле егет белән парлашканнар. Илдар да яшь, сөйкемле егет. Мәхмүт абый минем карап торуымны шәйләде, ахры, кухня ягына борылды да ике кулын күрештереп куйды. Дустың белән хушлаш, дию инде...

— Синең янга ашыгуым әле, Солтан,— дип сөйләнә-сөйләнә керде Гайнан. Күрешкәндә үтә дә якын итеп карады.— Муса абый Мәхмүт абый белән сиңа сәлам әйтергә кушты. Без икебез дә сезнең кайгыгызны уртаклашабыз. Шәп егет иде Ибраһим...— дип чыгып та китте.

...Ачлык, ялангачлык тагын элекке дәрәҗәсенә әйләнеп кайтты. Вафат булучылар күбәйде. Башкаларга сабак булсын, диптер инде, легионга язылучыларны әйбәтрәк ашаталар. Алар каршыдагы иркенрәк зонада яшиләр, тышкы кыяфәтләреннән, сөйләшүләреннән канәгать булулары сизелеп тора. Безгә алар белән якыннан аралашырга рөхсәт итмиләр.

...Гайнанның төсе үзгәргән, каушый, тотлыга.

— Муса абыйны... алып киттеләр...

— Кемнәр? Кая алып киттеләр?

— Немецлар инде... Кая алып киткәннәрен... кем белсен...

— Шунысы да бар бит әле,— дип тынычлана төште, Гайнан. —Бу хакта ишеткәч, әсирләр тавыш куптармасалар, ярар иде. Муса абыйны бик яраталар бит. Тавышлансак, легионга язылу митингысындагы кебек хәл кабатланасын көт тә тор. Эзләнү башланса, аның якыннарын да алып китәчәкләр. Муса абый гауга чыгармаска кушты. Шахтер Мәхмүт агайның әсирләргә сүзе дә үтә, диде, тыныч булырга әсирләрне берүк үгетли күрсен, диде. Кич кайткач, мин әйткәннәрне аңа җиткер.

Кинәт кенә күз алдым караңгыланды, башым әйләнде. Көнне көч-хәл белән уздырып җибәрдем. Борчылуымны Мәхмүт абый кайтуга ук сизеп алды.

— Ни булды?—дип сорады, ул, әсирләр белән сөйләшеп утырган җиреннән кузгалып.

Муса абый турындагы хәбәрне һәм аның Мәхмүт абыйга үтенечен әйттем.

«Кичке базар» вакыты җитеп килә иде, Мәхмүт абый:

— Әйдәгез, шунда башкалар белән дә киңәшик,— диде.

«Кичке базар»да тавыш купмаган, Мәхмүт абыйны тыңлаганнар. Гайнан да күпләрне алдан үгетләп өлгергән булган. Яңа хәбәр дә таралган «Кичке базар»да.

— Легионерлар яши торган зона янындагы беренче блок — төрмә икән,— дип сөйләде Мәхмүт абый.— «Кичке базар»да, алдашуны бетерик, дигән хәтерлисезме? Аларның икесен дә шул төрмәгә япканнар. Муса белән бер блокта яшәгән булган алар. Митингның хурлыклы төстә таралуын Мусадан күрәләр икән...

Гайнан белән күптән күрешкән юк. Авырып киткәндер, дип уйладым. Шуны белергә дип, аның белән эшләүче Хәйдәр абый янына сугылдым.

— Ишетмәдеңмени?— диде ул минем соравыма каршы.— Аны да алып киткәннәр бит...

Кайгы өстенә — кайгы. Серләшер кешеләрем дә бетеп бара.

Зонада яңа хәбәрләр күбәя башлады.

— Төрмәгә ябылган теге ике әсирне чыгарганнар,— диде Мәхмүт абый.— Сөйләшеп тордым. Бик ябыкканнар. Муса хакында бик эзләнәләр, чакыра калсалар, «белмим»нән башка сүз әйтмәгез, дип кисәттеләр.

Икенче көнне тагын бер яңалык — Гайнан кайткан. Өстәвенә, яңадан кухняда эшләргә рөхсәт иткәннәр. Төшке аштан соң үзе минем янга керде. Өстендә — Белгия солдаты киеме. Кочаклашып күрештек.

— Мәхмүт абыйга да, сиңа да Муса абыйдан сәлам, — дигәч, бөтенләй сүзсез калдым.

Гайнанның кайтуы хәлләрнең әйбәтрәк үзгәрүенә әсирләр арасында ышаныч уятты. Ашның сыйфаты кабат яхшырды. Мунча кертеп, өс-башларны алыштырдылар. Агач башмаклар урынына күн ботинкалар бирделәр. Боларның сәбәбен берәү дә аңлатып бирә алмады. Тиздән минс тиф бәреп екты. Ике айдан артык лазаретта ятарга туры килде.

* * *

Ничә тәүлек аңсыз ятканымны белмим. Исемә килгәч, көч-хәл белән күтәрелдем дә, як-ягыма күз салдым. Тирә-юньдәгеләр ыңгыраша, саташып сөйләшә. Кайда ятуымны аңламыйча тордым. Шул чакта ак халатлы берәү, яныма килде дә, җайлап кына урыныма кире яткырды. Кан тибешемне тикшерде, култык астыма градусник куйды. Аны алып карагач:

— Хәлең ярыйсылана инде, лазаретка кергәндә, температураң кырык бер дә биш иде, — диде. Мин:

— Иптәш доктор, — дип дәшә башлаган идем, ул миңа якын ук иелде дә, елмаеп:

— Биредә «иптәш» дигән сүз юк, — диде. — Аннары, доктор да түгел мин, фельдшер. Исем-фамилиям дә юк минем. Йомышың булса, доктор әфәнде, диген.

Янымда ятучы бер агай, миңа гаҗәпләнеп карап:

— Кайда ятканыңны белмисеңме әллә син? Без бит лазаретта, фашистлар кулында, — диде.

Хәлләр бераз уңайлангач, өзелеп-өзелеп ашыйсы килә башлады. Дүрт кешегә бер эрзац икмәк, көнгә өч мәртәбә баланда бирәләр. Шул чакта медицина хезмәткәрләренең изгелекләренә тагын бер мәртәбә таң калдым. Хәл эчендә ятканда, без ашаудан язганбыз. Әмма безгә тиешле икмәкне җыеп барып, сохари киптергәннәр, хәзер шуны чәй эчкәндә әз-әзләп бирәләр иде. Аякка баскач, безне урамга чыгарып бастырдылар. Хәзер үзегезнең зона полицайлары алып китәрләр, диделәр.

«Безнең» полицайлар башта лазаретка кереп ниндидер кәгазь алдылар. Үз зонабызда комендант Атай яши торган блок янында туктаттылар. Берсе блок эченә кереп китте. Ерак түгел эшләп йөрүче әсирләр арасыннан Мәхмүт абыйны эзләдем, тик ул күренмәде. Гомумән, монда халык гадәттәгедән азрак булып тоелды. Әллә легионга язылучы сатлык җаннар күбәйде микән?

Менә блок эченнән Атай белән теге полицай чыкты. Лазареттан алган кәгазь хәзер Атай кулында иде. Мин аңа чиксез нәфрәт белән карап тордым. Аны әсир дип берәү дә әйтмәс, чып-чын фашист иде ул. Ибраһим дустымны ул сугып үтерде бит.

Атай, кулындагы кәгазьгә күз йөртеп чыкты да, аптыраулы кыяфәт белән:

— Ун кешегә җиңел эш ничек табыйм ди мин? — диде. — Үтәмичә дә ярамый — врачлар кушкан. Нишләргә соң? — Аннары һәрберебездән аерымаерым сораша башлады: — Лазаретка киткәнче кайда, нинди эштә идең?

Чират миңа җитте.

— Мин, комендант әфәнде, кухняда чәй кайнаттым.

Атай миңа күзләрен акайтып карап торды. Безне алып кайткан полицайга борылып, ачулы тавыш белән:

— Бу йолкышны кухняга илт, — диде. — Үз урынында эшләсен. Калганнарын, Акчурин савыгып чыкканчы, блоклар эчен чистартырга куй.

Атайлар блогы безнеке белән янәшә иде. Ишеккә күз төшереп, анданиләр бар икән, дип уйларга өлгермәдем, аннан Мәхмүт абый килеп чыкты. Мине шунда ук таныды.

— Солтан, син исән икәнсең бит! — дип кочаклап күреште.

Икебезнең дә күзләр яшьләнде. Бер-беребезгә карашып, ни әйтергә дә белмичә торганда, полицай тупас кына:

— Әйдә, киттек, вакытым юк,囚 эштән соң сөйләшерсез,— диде дә кухняга әйдәкләде.

Анда мине Зыятдинов үзе каршылады.

— Савыктыңмы? — диде.— Ярар, бүгенгә кайтып ял ит, иртәгә килерсең.

Мәхмүт абый мине зонадагы яңалыклар белән таныштырды.

— Хәзер вафат булучылар саны кимеде, элек «Капут командасы»нда йөзләп кеше идек. Сигез калдык. Күптән түгел зонага яңа әсирләр китерделәр. Сафка тезделәр дә лагерь тәртипләре белән таныштырдылар. Шунда ук теге легионнан Саматны дәшеп китерделәр, сөйләргә куштылар. «Мин сезгә «Идел-Урал» дәүләте исеменнән мөрәҗәгать итәм,— диде ул.— Без әнә каршыдагы зонада яшибез. Андагы тормыш белән мондагысының аермасы — җир белән күк аермасы. Мондагылар авыр эштә, ә без ял итәбез. Монда эченә йомычка тутырылган мендәргә ятып йоклыйлар. Безнең урын-җир яхшы. Радио тыңлыйбыз. Ашау-эчү дә күпкә яхшырак. Атна саен мунча керәбез, эчке киемнәребезне атна саен алыштырабыз. Күптән түгел генә Мәскәү радиосын тыңладык. Анда безне, туган илен сатучылар, дип атыйлар икән. Әсирләрнең гаиләләрен дә хөкемгә тартачаклар икән. Әсир әфәнделәр, Кызыл Армиянең хәле бик начар, немецлар Уралга якынлашып киләләр. Димәк, тиздән сугыш бетәчәк. Бөек Германиянең җиңүе белән бетәчәк. Берлиннан килгән вәкил безгә менә мондый шатлыклы хәбәр җиткерде: легионга үзләре теләп язылучылар озакламыйча Идел-Урал дәүләтенә — туган якларына, гаиләләре янына кайтып китәчәкләр. Җиңүчеләр булып. Андыйларга зур хокуклар биреләчәк. Җирнең иң яхшы өлешен алар бүлеп алачак». Шулай дип сөйләде Самат. Аннары легионга язылырга теләүчеләрне барлый башлады. Өнди торгач, чыгып басучылар булды үзе, алай да күп түгел. Аларны шунда ук каршы зонага алып киттеләр...

* * *

Мәхмүт абый зонада күбрәк йөри, шуңа күрә ул яңалыкларны алданрак ишетә. Ә безнең юл — блок белән кухня арасы. Кухняга керүчеләрдән генә яңа хәбәр ишетеп була. Кухняга исә һәркемгә керергә ярамый.

Истәлекләремдә «керү-чыгу»ларны еш искә алырга мәҗбүрмен. Бу, беренчедән, әсирлек хәлләренең төгәллеге өчен кирәк булса, икенчедән, зонаның сахра түгеллеген онытмыйк — анда аралашу да чикләнгән...

— Чиркәү янындагы мәйданда сәхнә ясап маташалар,— диде Мәхмүт абый, кич эштән кайткач.— Эскәмияләр дә куйганнар. Тагын митинг уздырырга җыеналар бугай.

— Бу кабахәтләргә ирек бирелгән, ни теләсәләр, шуны эшлиләр,— диде кемдер.

...Лагерьда бер төрле, легиондагылар өчен икенче төрле тормыш дәвам итә. Легионерларны иртән крепостьтан алып чыгып китәләр дә, немец техникасын өйрәтәләр. Җырлап баралар, җырлап кайталар...

Игъланнар тактасына белдерү эленгән:

«Әсир әфәнделәр!

Зур җыелыш булачак.

Көн тәртибендә:

1. «Идел-Урал» дәүләтенең яңа президенты Шәфи Алмас әфәнде белән әңгәмә.

2. Зур концерт».
Әсирләр, игъланны укыйлар да, үзара фикерләшәләр, яңа президент дигәннәрс нинди асыл кош икән тагын, диләр. Шунда Мәхмүт абый без һич тә көтмәгән яңалык әйтте:
— Эштән кайтканда, легионерлар зонасында Мусаны күрдем. Өстендә — яңа костюм, башында — эшләпә. Тазарып киткән. Теге сатлык җан Самат белән сөйләшеп тора иде. Концертны да Муса оештырмыймы икән әле...

* * *

1943 елның беренче июль иртәсе. Башта легионерларны сафка тезеп алып киттеләр. Аннары — безне. Чиркәү янындагы мәйданга җиткәндә, легионерлар алдагы урыннарга утырышкан иде. Безнең күбебезгә басып торырга калды. Әсирләр күп, шулай да тынлык монда. Сәхнәгә гражданский киемдәге таныш түгел кешеләр дә чыгып утырды. Муса Җәлил белән Гайнан Кормашны тиз танып алдык. Атай урыныннан торды да:
— «Идел-Урал» дәүләтенең яңа президенты Шәфи Алмас әфәндегә сүз бирелә! — диде.

— Сүз җаеннан шуны әйтәм — без беренче «президент» Әхмәт Тимернең ни өчен алыштырылуы сәбәбен төшенмәдек. Бәлки, ул тыңлаусызрак булгандыр да, немецларга Шәфи Алмас кебек карусызрак кеше кирәк булгандыр...
Шәфи Алмас сәхнә алдына басты. Легионерлар, полицайлар һәм сәхнәдәгеләр кул чапты. Алкышлар тукталгач, Шәфи Алмас сөйли башлады:
— Хөрмәтле легионерлар һәм әсир әфәнделәр! Мин «Идел-Урал» комитеты әгъзалары тарафыннан сайланып куелган президент булам. Әрләшергә, куркытырга, өркетергә килмәдем. Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә телим. Әле Берлинда чакта ук ишеткән идем: монда әсирләр ачлыктан күпләп һәлак булалар икән. Мин менә алдагы рәттә утыручыларга карап торам — алар да шыр сөяккә калган булганнардыр. Хәзер исә алар егетләр кебек. Сәхнәдәгеләргә карагыз әле, алары — артистларыбыз. Мин озак сөйләп тормыйм, хәзер сезгә «Идел-Урал» гәҗите таратырлар...
Гайнан Кормаш, көләч йөзен балкытып, сәхнә уртасына чыкты. Башын түбән иде. Концертны башлап, Муса абыйга сүз бирде. Сәхнәдә без күреп белгән, өстенә касшланып беткән гимнастерка, аягына авыр агач башмаклар кигән, күзләре эчкә баткан, битләрен сакал-мыек баскан Муса түгел, бөтенләй бүтән кыяфәтле Муса басып тора иде. Өстендә костюм, ак күлмәк кигән галстук таккан, чиста итеп кырынган.
Әсирләр тын утыралар. Бу концертның асылына, Муса Җәлилнең үзгәрүе серенә төшенмибез әле...
— Хәзер, дуслар, мин сезгә шигырьләр укыйм. Башта Чулпан кызыма багышлап язылган шигыремне тыңлагыз.

...Киткән чакта, кызым, нигә шулай,
Күзләремә әрнеп карадың?
Сиздеңмени откан йөрәгенең
Синең янда өзелеп калганын?..

Муса абый шигырьләрен дулкынланып укыды. Аның мондый халәте безгә дә күчте. Әсирләр шагыйрьне урыннарыннан торып алкышладылар.
Концерт озак дәвам итте. Ул безнең күңелләрдә халык моңнарын уятты. Соңыннан сәхнәгә Шәфи Алмас, тагын берничә билгесез кеше һәм зона коменданты Атай менде.

— Хөрмәтле әфәнделәр, без өләшкән гәҗитләрне укыдыгызмы? — дип мөрәҗәгать итте әсирләргә «президент».

— Укыдык.

— Таныштык.

— Ә концерт ошадымы?

— Ошады. Рәхмәт егетләргә, кайгыларыбызны тараттылар, гаиләләребез искә төште...

— Әфәнделәр, легионерларның сезгә әйтер сүзләре бар.

Әлеге дә баягы Самат элекке сүзләрен кабатлады, легионерлар тормышын мактады.

— Хәзер без ике йөзгә якын. Беребез дә тормышыннан зарланмый. Өстебез бөтен, тамагыбыз тук, ятагыбыз чиста. Хәзер немец армиясе коралларын өйрәнәбез. Немецның сугыш кораллары һәм техникасы шәп. Шуңа күрә бөек Германия, Кызыл Армияне тар-мар итеп, алга бара. Зур рәхмәт Гитлер хәзрәтләренә! Сезгә дә рәхмәт, президент әфәнде, бөтен көчегезне биреп, безнең бәхетебез өчен тырышасыз...

Әмма ул сүзен йомгакларга өлгермәде, Шәфи Алмас аны сорау биреп бүлде:

— Сез үзегез кызыл большевикларга каршы көрәшергә әзерме соң?

— Әлбәттә, әзер, президент әфәнде!

— Рәхмәт. Самат әфәнде, тагын да әйтер сүзегез бармы?

— Мин барлык әсирләрне дә легионга язылырга чакырам!

Әсирләр шаулашып алдылар. Шәфи Алмас аларны ишетмәмешкә салышты.

— Хөрмәтле әсир әфәнделәр, кемнәр легионга язылырга тели? Яисә чыгып сөйләүчеләр бармы? — дип кат-кат сораса да, әсирләр авызларына су капкандай утыра бирделәр.

Ниһаять, берәү кул күтәрде.

— Берничә сүз әйтергә телим, — диде ул. — Мин «Идел-Урал» газетасын укып чыктым. Концертны ошаттым. Сез сөйләгәннәрне игътибар белән тыңладым. Мин бу крепость эчендә күптәннән яшим. Ачлык-ялангачлыкны да күп күрдем. Туган илгә исән-сау кайтырга өметләнәм. Әмма сугыш тиз бетәрме соң, президент әфәнде?

— Сугышны тизрәк бетерер өчен кызыл большевикларны тизрәк юк итәргә кирәк.

— Минем әйтәсе фикерем башка. Күз алдыбызда көн саен дистәләрчә, йөзләрчә әсирләр вафат булды. Ул чакта сез кайда идегез, ни өчен алданрак чарасын күрмәдегез? Шул хакта уйлагач, сезнең легионга языласы килми. Һәм мин язылмыйм!

Ул сөйләп бетергәч, әсирләр хәйран гөрләшеп алдылар.

Шәфи Алмас кызып китмәде, тыныч кына тыңлап утырды.

Икенче бер әсир урыныннан сикереп торды.

— Президент әфәнде, — диде ул, — менә безнең гаиләдән биш кеше сугышка киткән, ә инде әти белән әни ягыннан туганнарны санасаң, утыз биш булабыз. Сезнең легионга язылсам, мин утыз дүрт туганыма каршы сугышам була бит...

Моңа охшашлы сөйләүләр шактый булды. Шәфи Алмас аларга туры гына җавап бирә алмады. Әмма:

— Хөрмәтле әсир әфәнделәр, без күп кенә лагерьларда булдык инде. Башкаларда мондагы кебек каршылык күрсәтмәделәр, — дип шактый саллы дәлил китерде ул. — Уйланыгыз әле...

— Мин язылам, — диде берәү.

— Монда килегез, әсир әфәнде. Фамилиягез ничек?

— Сәйфетдинов.

— Хәрби дәрәҗәгез?

— Өлкән лейтенант.

— Рәхмәт, котлыйм сезне, Сәйфетдинов әфәнде. Тагын теләүчеләр бармы?

— Мин. Фамилиям — Гыйззәтуллин, хәрби дәрәҗәм — лейтенант.

...Муса абый, Шәфи Алмас янына килеп, нәрсәдер әйтте. Шәфи Алмас елмаеп куйды, бераз уйланып торгач:

— Хөрмәтле легионер әфәнделәр, «Идел-Урал» дәүләтенең президенты буларак, Сәйфетдинов белән Гыйззәтуллин әфәнделәрне рота командирлары итеп билгелим, — диде.

Легионга хәтсез кеше язылды. Ахырдан Шәфи Алмас әсирләргә мөрәҗәгать итәргә онытмады.

— Тагын теләүчеләр булса, комендант Атай әфәндегә килеп язылырсыз. Бүгенгә сөйләшүне туктатып торабыз, — дип тәмамлады ул.

Таралыштык.

* * *

Иртәгесен Муса абый белән йөзгә-йөз очраштык. Бер-беребезнең күзләренә карашып озак тордык. Сөйләшер сүзләр күп тә, юк та кебек. Ниһаять:

— Гайнаннан ишеттем синең хәлләреңне, — дип башлады Муса абый. — Каты авырып алгансың икән. Чыдарга язган безгә. Бирешмә, тиздән ныгып та җитәрсең. Хәзер тормыш алай начар булмаска тиеш. Теге митинг бүгенгедәй күз алдымда. Дустыгыз Ибраһимның вәхшиләрчә үтерелүе һич күз алдымнан китми... — Аннары сүзен башкага борды. — Шулай да без хәзер икенче төрлерәк эш итәргә тиешбез. Шахтер Мәхмүтнең хәлләре ничек?

— Һаман да «Капут командасы»нда эшләп йөри.

— Легионга язылмадымы?

— Юк. Язылучыларга да нәфрәтләнә.

— Шулайдыр, җентекләп аңлап җиткермичә, бер эшкә дә капылт кына алынмас ул.

Муса абый, түш кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь алып, аны миңа сузды.

— Моны тиз генә яшереп куй. Мәхмүт агайга бирерсең. Ярый, мин киттем.

Кичен Мәхмүт абыйга теге кәгазьне бирдем. Анда болай дип язылган иде: «Кадерле иптәш! Легионга язылу туган илебезгә һәм халкыбызга хыянәт итү түгел. Киресенчә, без шундый юл белән генә Кызыл Армиягә ярдәм итә алачакбыз. Комитет».

Легионга бик күпләр язылды. Мәхмүт абый да. Мин, Муса абыйның кушуы буенча, шушы эшемнән китмәскә тиеш идем.

Алда көрәшнең тагын да зурысы, җаваплысы, куркынычы көтә иде безне...

# Фәйрүзә Мөслимова

## Коръән арасында сакланган борынгы хат-шигырь

Хәзер инде могҗизаны күрдегезме?
Бездән өстен язмышларга күндегезме?
Хыял кала хыял килеш — белдегезме?
Гамәлләргә тик бер Алла хуҗа булыр.

Учак булып күп тапкырлар яндыгызмы?
Очкыннарга сулыш өреп ардыгызмы?
Яна-яна кайнар көлгә калдыгызмы?
Яңа уттан тик бер Алла саклап торыр.

Язмыш саклый ялгышлардан — тойдыгызмы?
Хәтерегезгә гомерлеккә уйдыгызмы?
Гөнаһлы уй, буш хыялны куйдыгызмы?
Сездән мине тик бер Аллам яклап торыр.

Бәхет юрап йолдызнамә ачтыгызмы?
Усгызда үткәннәрдән качтыгызмы?
Былбыл булып, һаваларга аштыгызмы?
...Раббем Аллам! Ярлыкагыл, ярлыкагыл...

## Бәлки...

Җилләр безгә гел-гел каршы исә,
Йолдызнамә бәхет юрамый...
Борынгыдан килә: беркем әле
Язмышларны кире боралмый.

Капма-каршы тарафларга аккан
Елгалардай яши бирәбез.
Кушылдыклар, койган күлләр башка,
Ике полюс — синең белән без.

Җәйге таңда җирдән күтәрелгән
Томан булып икәү берләшсәк,—

---

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА — *шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта, шул исәптән журналыбызда да һәм күмәк җыентыкларда да басылды. Казанда яши.*

Бәлки әле, күлләр-кушылдыклар
Мизгелләрне санап көнләшмәс?

Гасырлардан бирле ике якка
Язмыш-ярдан узмый акканга —
Мәхрүм итмәс, бәлки, каршы җилләр
Биеклеккә ашкан чаклардан?

Яр буенда ак томаннан оеп,
Йокласыннар иркә таллыклар...
Мәңгелектән мизгел генә бит бу —
Язмыш безне, бәлки, ярлыкар?

## Гамь

Күзләремне иңләп кошлар оча,
Шәүләләре төшә тәрәзәгә.
Кош канаты сыйпап үткән саен
Тәрәзәмдә күкләр зәңгәрләнә.

Кош канаты сыйпап үткән саен
Күзләр белән офык араларын —
Гамьнәремне киң галәмгә биреп,
Йөрәгемә җыям яңаларын.

Бу галәмдә мин дә бер кош бугай,
Дөнья гамен канатыма салыйм!
Күкләр генә зәңгәрләнсен иде
Канатларым сыйпап үткән саен.

## И табигать!..

Чәчәк атмый быел минем гөлләр,
Минем халәт күчкән аларга.
Булса булыр: чәчәк бөресеннән
Бер-бер артлы яфрак ярала.

Кысыр яфрак — чәчәк бөресеннән! —
Өметләрне кисә берьюлы.
Нинди чәчәк? Хәтта яфраклар да
Күзләремә керми коелды.

Чәчәк атмый быел минем гөлләр.
Тик табигать — үзе могҗиза:
Чәчәк сыман сулган чакларында
Әфсен өреп, тартып торгыза.

Мин гөл түгел, кысыр яфрак түгел...
Кеше булу күпкә кыен ла.
Өмет исән: минем гөлләр дә бер
Чәчәк атар сыман тоела.

Чәчәк атар әле минем гөлләр,
Минем кәеф күчәр аларга.
И табигать! Бу хыялый җанны
Кайгылардан, берүк, арала!

## Таң

Туңган җанга җылы өмет итеп,
Мин күкләрдән якты таң сорыйм.
Тик нурларның бары күләгәсен
Кояш итеп таңда каршылыйм.

Күрше йортның каршы тәрәзеннән
Кояш төшеп, мине уята:
Көнбатыштан, гүя, таңнар ата,
Юрганыма сынык нур ята.

Тәрәзәмә нурлар сынып керә
Каршы йорттан төшеп чагылгач.
Уяныргa шул да җитә икән
Таң вакытын чынлап сагынгач.

Көннәрсмне шулай башлыйм иртән:
Сынык нурлар — минем юл башым.
...Көнбатышка таба авышыр да,
Тәрәзәмнән керер кояшым.

Тәрәзәмә кояш туры карар,
Каршы йорттан гына чагылмас.
Әмма инде таңнарыннан киткән
Иләс җаным анда табылмас.



# Иделбикә

## Идеалыма

Сихерле пәрәвез алып
Чолгар идем башыңны:
Күр, дип, күз пәрдәңне ачып,
Кыйгачлыгын кашымның.
Әйтмәсәм дә аңларсың, дим
Яшергән сүзләремне;
Күрерсең ягымлылыгын
Сөрмәле күзләремнең;
Белерсең чайкалуларын
Күңелем иделендә;
Наз-хәзинә саклануын
Хыялымның телендә,
Табарсың гади йөземдә
Сылуларның сылуын,
Кер төшермәү йөрәгемә —
Синең өчен булуын.
Шул чагында, үзем күзләп;
Пәрәвезне ачармын.
«Тап хәзер, сихерсез, эзләп», —
Диярмен дә... качармын.

## Салган гөлләр

Яу чорында җиткән кызлар — гөлләр!
Сезгә атыйм җырым — бәетне,
Наз татымый сүнгән күңел, күзләр,
Кичерегез минем бәхетне...

Сезнең өзелеп-өзелеп көткән тиңнәр
Сезне тиңләр тиңнәр кабердә.
Хәтер җыры булып исә җилләр
Рәхмәт укып минем кадергә.

Балам көлгән саен уела җан
Сез күрмәүгә ана бәхетен.
Шик шомлата: яшьлек биләгәндер
Бәлки башка бер җан тәхетен...

Һәр килгән май сезне борчый — һаман
Кайгы катламнарын сугарып.
Ата сыман — сарыгылган каннан
Май мәкләре янып, кызарып.

Яу чорында җиткән кызлар-гөлләр!
Сезгә атыйм бу җыр-бәетне.
Наз күрмичә сүнгән күңел, күзләр,
Кичерегез минем бәхетне...

ИДЕЛБИКӘ (Лена Садыйкова) — *Ульяновск шәһәрендә яши. Шигырьләре көндәлек матбугатта басыла килә.*

«Калдырдыгыз. Көч түгелде
Җиде ят арасында.
Яшь күзгә иртә күренде
Агы да, карасы да».—
Димим, әткәй,— язган шулай,
Сызланмыйм, аңлыйм бусын:
Дөнья куюына кеше
Ничек гаепле булсын!
Юклыкка да күнегелгән,
Инде түзелде бик күп.
Мирас итеп саклый сезне
Җир үзе дә минем күк...
Шунысы тик: әти булып,
Исем туема индең;
Хәтерең моңына батып,
Миңа ят исем бирдең —
Лена, дидең... Үз исемнә
Гаепләме балалар? —
«Ник Лена» да «ник Лена» дип,
Җелекне корыталар...
Тик шунысына теләнә,
Сыкрана, әрнеп йөрәк...
Һәр адәмгә үз теленнән
Үзенә тиң ат кирәк.
...Идел. Идел. Иделбикә...
Шулай әйтә күк анам.
Күтәреләм биеклеккә.
Иделдә канатланам.
Иделбикә исемен алам,
Шуны көткән күңелем:
Гомерем дә, тармакланган
Ярларында Иделнең.
Иделем көч-дәрт индерә,
Иделем шатлык бирә...
Иделдәй дәгъва үземә —
Иделбикәгә күрә.

# Фирдәвес Әһлия

## Җанымны саклап

Нидер югалткан кешедәй,
Эзлисең-йөдисеңме?
Таш диварлар арасында
Каңгырып йөрисеңме?..
«Кызык иттең әле мине,
Янган утларга салдың,
Ә үзең, күп тә уйламый,
Еракка китеп бардың!..» —
Дисең микән? Битәрләмә:
Китмәдем сине ташлап.
Киттем, үз-үземне эзләп,
Киттем — җанымны саклап.

## Арада — упкын

Иксез-чиксез галәм киңлегендә
Йөри идем төсле адашып,
Үз урынын җуйган йолдыз сыман
Бәргәләнеп, йөдәп, саташып.

Әйтерсең лә бөтен галактика
Үги иде миңа, мин — ятим.
Бөтен галәм буйлап, өзгәләнеп,
Эзли идем гүя үземә тиң.

Һәм, ниһать, таптым: нәкъ үзем күк,
Икс тамчы судай охшаган.
Тик арада — космик упкын ята...
Шуны кичәрмен дип ышанам!

## Юк әмәл...

Дөньяның бер ягы китек була,
Бөтен ягы булмый мөкәммәл.
Яшәү белән әҗәл бергә йөри,
Бәхет белән бәла. Юк әмәл...

---

Фирдәвес ӘҺЛИЯ (Әһлиуллина) — *«Актриса», «Ак күгәрчен» исемле проза китаплары авторы. Казанда яши.*

## Төннең күз яше

Таң алдыннан ал Гөлчәчәк
Ник сискәнеп уянды?
... Аңа авыр чык бөртеге —
Төннең күз яше тамды.

## Каргыйсым килми

Баш өстемдә кара кайгы кошы
Армый-талмый канатын җилпи.
Ә шулай да хыянәтең өчен
Никтер сине каргыйсым килми.

* * *

Сине генә җаным тели,
Сине генә иш итә.
Сулыш алуыңа хәтле
Йөрәккәем ишетә.

## Нигә?....

Рәхмәт укыйм микән,
Ләгънәт орыйм микән?
Нигә соң син миннән
көчлерәк?!.

Дөньяга да сыймас
МәгъруР мәхәббәтем
Синең алда — гүя
кечкенә...

## Чәчмә әсәрләр

Рашат Низамиев

# БИЛГЕСЕЗ КЫЗ СУРӘТЕ

хикәя

Очраклы гына бер хәл кешенең тормышын шулкадәр үзгәртеп ташлый, соңыннан үзең үк кайта-кайта гаҗәпләнеп куясың. Күнеккән, искереп беткән, офыктан көн дә бер төсле чыга торган кояш зәңгәрсу дым белән өртелгән биек йортлар артыннан кинәт яшәреп, тагын да нурланып, тормышның әле берәү дә белмәгән серен сакларга тырышып кына илаһи тынлык, салмаклык белән күтәрелә башлый. Шушы тынлык аша шәһәрнең уянуын, төн буе ял иткән асфальт өстендә урам җыештыручы картның себеркесе кыштырдавын, трамвай рельслары чинавын, иртә кузгалучы сөт һәм икмәк машиналарыннан да ныграк гүләп узган самолет тавышын ишетәсең...

Очраклы хәл... Кырык яшенә җитеп килгән, шәһәр читендәге тугыз катлы йортның бер бүлмәсендә ялгыз яшәүче рәссам Фатих белән дә шулайрак булды. Суга төшермәс, утка пешермәс язмыш юк, диләр. Дөрес икән, шайтан алгыры!

Барысы да бер гаепсез телефон аркасында килеп чыкты. Пионерлар сараенда эшләп йөргән Фатих, төсле рәсемнәр белән бизәлгән чираттагы белдерүне ясап бетергәннән соң, бер танышының Мәскәүгә барасын хәтеренә төшерде. Бөтенләй онытылган: ул бит аңа, очрый-нитә калса, майлы буяулар алырга кушасы иде! Үч иткәндәй, танышының телефонын исенә төшерә алмый интекте. Аннары, ни булса шул булыр дип, хәтерендә калган саннарны җыя башлады. Язмыш, күрәсең, кайсыдыр санда ялгышкан иде ул. Телефондагы озын гудоклар кинәт өзелде дә Фатихны чыбыкның теге башына китереп ялгады. Хатын-кыз тавышы иде бу... Йа хода, кемнәргәдер шундый тавышны бирсәң дә бирерсең икән! Тамак төбеннән түгел, гүя табигатьнең камил бер тарафыннан күтәрелгән ефәк тавыш...

Фатихның мондый тавышны беренче тапкыр ишетүе булды, ахры, югыйса кемгә ни өчен шалтыратуын да онытып, әсәрләнеп утырмас иде ул бу минутларда.

— Сезгә кем кирәк? Алло!

— Миңа... ни...

Әнә шул ике сүздән соң Фатих тукталып калды, аннары гына теленә килгән беренче сүзләр белән тырышып-тырышып кемгә ни өчен шалтыратуын аңлатырга тотынды.

— Сез номерны ялгыш җыйгансыз, ахры...

Фатих, аның трубканы элеп куюыннан куркып, сүзне тизрәк ялгап җибәрергә ашыкты:

— Трубканы куймый торыгыз, зинһар...

— Безнең нинди сөйләшер сүзебез булырга мөмкин?

— Алай дияргә ашыкмагыз...— Бу урында Фатих хәйләгә керешүне кирәк тапты:— Миңа сезнең тавышыгыз ничектер таныш тоела. Бәлки, исемегезне әйтеп сөйләшерсез?

— Ялгышасыз, иптәш. Мин сезне бөтенләй белмим.

— Ихластан әйтәм. Тавышыгызны кайчандыр ишеткәнем бар кебек. Тавышыгыз искиткеч матур! Соклануым өчен гафу итегез, моңардан гына сезгә зыян тимәстер, дип уйлыйм.

— Юк, билгеле. Тик сез, тормышта шулай күпләргә сокланып, бу сүзләрегезнең дәрәҗәсен төшермисез микән?

— Бер белмәгән кешегә шундый зур гаеп ташларга җыенасыз, ә?

— Сезне белмәгәнгә күрә, аптыраганнан әйтүем. Бәлки, мин хаклыдыр?

— Гаепләвегезне кире алырга киңәш итәм. Кирәк икән, мин сүзләремне исбатларга әзер.

— Кирәкми. Мин ышандым инде... Сөйләшүне шуның белән туктатабыз, ярыймы?

Кызның бу сүзләреннән соң Фатих телефон трубкасын кысыбрак тотты. Шулай кызыклы гына башланып киткән әңгәмәне һич кенә дә өзәсе килми иде аның. Нәрсәдер әйтергә, акыллырак бер сүз табып, бәхәсне тагын да сузасы иде.

— Кызык бит, бер-беребезнең исемен дә белмибез, ә ничаклы сүз алмашып өлгердек!

— Исемнәрне белүнең кирәге бар микән? Мондый очраклы сөйләшүләр тиз онытыла ул.

— Әгәр мин онытырга теләмәсәм? Әйтәм ич, тавышыгызга гашыйк булдым.

— Ихтыярыгыз. Кухняда чәйнегем ташый бугай: трубканы куям...

— Тагын бер генә сүз әйтергә рөхсәт итегез! Сезнең тавышыгызны ишетәсе килеп, иртәгә дә шалтыратсам, зинһар, ачуланмагыз, ярыймы?..

Шул беренче сөйләшүдән соң Фатих яңа танышына көн дә шалтыратырга гадәтләнеп китте. Кызның сефәктәй тавышын ишетү рәхәт, гаҗәп рәхәт иде аңа. Икенче сөйләшүдә кызның исеме Миңлегөл икәнен белде. Урау-урау юллар белән сораша торгач, кияүдә түгеллеген дә ачыклады. Һәр сөйләшүдән соң, салават күпереннән дә югарырак ашып, хыялларның йөгереп, мәтәлчек атып уйный торган зәңгәр гөмбәзенә чаклы күтәрелә иде ул.

Фатих инде яшьлегендә мәхәббәтне кичергән кеше. Гаиләсе дә бар иде барын, әмма бала белән, максатлар һәм күңел берлеге белән ныгытылмаган гаилә, ком өстенә салынган йорт шикелле, көннәрнең берендә сүтелде дә төште. Ялгыз яшәвенә икенче ел китте менә. Аны иҗат эше, хакыйкать табу ләззәте, төрле күргәзмәләрдә катнашу мәшәкатьләре генә ялгызлыктан, эч пошудан, тайгак юллардан коткара. Юкса, ялгыз калудан кинәт сыны каткан булдыксыз ирләр сыман, ул да күптән инде эчүчелеккә сабышкан булыр иде, мөгаен.

Фатих — телсез-күзсез бөкән түгел, мүкләнеп беткән түмгәк хәленә дә төшкәне юк. Назга, югары хисләргә ласк күңелендә мәхәббәткә урын бар әле аның. Һәр талның үз сандугачы булган кебек, аңа да үз илһамчысы, йөрәген аңлардай сердәш, фикердәш кирәк. Төрле кешеләр газетадагы, игълан тактасындагы белдерүләр аша танышу эзләгән чакта, ул көтмәгәндә-уйламаганда телефон аша бирәү белән танышкан икән, моның ни гаебе бар? Шуңа да ул, «дипломатик» сөйләшүләр белән генә чикләнмичә, тора-бара Миңлегөлне очрашу-күрешүгә кыстый башлады. Тик кыз каты чикләвек булып чыкты, мондый чакыруларга карап кына авып китмәде, әле тегенди, әле мондый сәбәп белән Фатихның тәкъдимнәрен кире кага килде.

Дөньяны төсләр белән күрергә күнеккән Фатих кызның аккоштай сөйләшүен төсле тавыш дип кабул итте. Бу тавышка чынлап та гашыйк

иде ул. Төсле тавыш аның өчен төсле җыр шикелле иде. Әнә шул тәэсирләре нигезендә кызның рәсемен ясарга максат куйды һәм тынычлыгын югалтты. Миңлегөл үзенең тавышы, сөйләшүләре, тыйнак көлүләре белән Фатихның хыял күгендә тәмам урнашып өлгергән иде. Кызның рәсемен ясау теләге бар куәтенә әләктереп алды аны. Көтмәгән-уйламаганда уйлары җилкенеп, куллары кәгазь һәм каләмгә, мольберт тактасындагы буяуларга үрелде. Кеше сурәтен ясау дигәндә рәссамнар һәрвакыт натурадан карап эш итәләр. Ә менә Фатих аңлы рәвештә моңардан баш тартты, дөресрәге, андый мөмкинлектән качарга һәм үз хыялына гына таянырга булды. Александр Блок Билгесез ханымга атап менә шигырьләр язган ич әле, ә нигә Фатихка да үзе генә белгән Билгесез кызның рәсемен ясап карамаска? Сәнгать тәҗрибә ясауларны ярата ул. Тапталган, моңа кадәр билгеле эздән баруга караганда, яхшымы-начармы, үз сукмагыңны салу күпкә кызыклырак.

Фатих әнә шулайрак уйлады. Һәм менә беленер-беленмәс кенә төшә башлаган юка, йөгерек, сыгылмалы сызыклар артында кызның чәче, йөзе, кашы һәм күзләре пәйда булды. Каләмне ниндидер тылсымлы көч хәрәкәтләндерә, Фатихка аны кулыннан төшермичә дөрес юлдан йөртә белү генә кирәк иде шикелле. Сызыклар арта, өстәлә, кушыла барган саен сурәткә җан керә барды. Киндергә буяулар төшергәндә исә Фатих тәмам шашты, үз хыялларында үзе исерде, хәтта язмышының ярсып дулавын аңларга вакыты да калмады аның. Буяулардан алтын сарысын, көмеш агын яратканга күрә, пумаласын әлеге ояларга аеруча илһам белән манчый-манчый онытылып, канатланып эшләде, кузгалып китеп, төсләр-буяулар балкышын читтән карый-карый эченнән генә ләззәт, канәгатьлек кичерде. Әнә, кызның карасу-коңгырт чәчләре, ак нәфис муенын капламаска тырышып кына, җилкәсенә төшеп яткан. Карлыгач канатыдай кашлары уйларының очышта икәнлеген искәртә кебек. Зәңгәрсу-яшькелт күзләрдә моң һәм шатлык төсмерләре бергә кушылган. Килешле генә борын һәм чиядәй алсу иреннәр шушы карашны тагын да көчәйтеп, тулыландырып тора. Битнең сул ягына, йөзгә табигыйлек бирер өчен, сизелер-сизелмәс итеп кенә юка күләгә төшерергә кирәк иде. Гаҗәп: нәкъ менә шунысы бик авырдан килеп чыкты. Ак белән кара, иксез икс юлдан барганга күрә, аларны саркытып кушу, чиратлаштыру газапка әверелде. Ниндидер бер көч каршылык күрсәтә иде шикелле. Тегеләй салып карады Фатих буяуны, болай салып карады, шактый озак азапланганнан соң, таң шәүләсе белән баетып, күләгәнең чагылышын эзләп тапты.

Ниһаять, кызның алтынсу рамга беркетелгән сурәте әзер иде. Аны ясау байтак вакытны алды. Хәзер рәсем эш өстәле каршында эленеп тора. Фатих өчен киндердәге буяулар, барлык төсмерләр Миңлегөл тавышы белән сөйләшә, җырлый иде кебек. Тик нигә очрашуны кире кага ул? Горурлыкмы бу, Фатихны телефон чыбыгы тирәсендә күрәләтә бушка әйләндереп йөртүме, әллә бүтән сәбәпләр бармы — аңлау кыен иде. Адәм алманы алма булганы өчен түгел, тыелган булганы өчен өзгән... Миңлегөл очрашуны суза килгән саен, язгы сулар һаман көчәя, куәтләнә барган шикелле, Фатихның бу омтылышы да зурая, тирәнәя генә барды. Юк, алга таба да болай билгесезлектә яшәү мөмкин түгел иде. Җәя киерелгән икән, аңардагы ук атылырга тиеш...

Ниһаять, бүген алар очрашырга сүз куештылар. Миңлегөл бер бүлмәле фатирда биш яшьлек кызы белән генә яшәвен дә әйтеп өлгергән иде инде. Барырга һәм күрергә кирәк үзләрен, күзгә-күз танышырга кирәк. Кешеләр танышканнан дөньяга ни зыян? Фатихның уй-хисләрен, яшерен өметен һәм хыялларын әлегә кадәр телефоннан сиздергәне булмады ич, ул боларның барысын да күңелендә бикләп тотты. Менә шул серләр давылланып тышка чыгармы бүген? Хыялларына күләгә төшмәсме? Фатих бүген, унҗиде яшьлек үсмердәй дулкынланып, очрашуга әзерләнә! Тырышып, пөхтәләп кырынганнан соң ияк тирәләренә хуш исле одеколон сөртте, ак күлмәк өстеннән кешелеккә дигән әйбәт костюмын киде. Чыгып китәр ал-

дыннан ике каптырмалы портфеленә өч йолдызлы коньяк һәм стенадагы алтынсу рамлы рәсемне төреп тыкты.

Җәй иде, май аеның җылы, йомшак көне иде бу. Ул утырган «Икарус» автобусы күпер һәм урамнар аша шәһәр үзәгенә омтылды. Казансу елгасында кызыл-зәңгәр билге белән чуарланган ак җилкәннәр, аның такта көймәсенә аягүрә баскан каһарман кыяфәтле егетләр, җилне йөгәнләргә тырышып, Ослан ягына таба йөзә. Әнә яр буена һәвәскәр балыкчылар сибелгән. Күперне чыгар алдыннан тарихның җитмеш җиде катлы язмышын күтәреп торган ярымайлы Сөембикә манарасы игътибарны үзенә җәлеп итте. Манара очы тирәсендә элек әрсез каргалар, чикылдык чәүкәләр еш кайнаша иде, хәзер күренмиләр. Халык манара очына ай куйгач, килеп кунардай урын калмаганга күрә, чиркәү гөмбәзенә ияләштеләр, ахры...

Хәер, бу күренешләр Фатихның күз карашына элэгер-элэкмәс дәрәҗәдә генә чагылып узды. Күңел карашы исә бөтенләй бүтәндә иде.

Фатихның уйлары һаман саен Миңлегөлгә әйләнеп кайтты. Тукталыш саен кергән-чыккан кешеләр, автобус эчендәге ыгы-зыгы, өлкәннәрнең кибеттә әйбер юклыгыннан зарланулары аңа бөтенләй кагылмый иде шикелле. Ул ничек итеп очрашачакларын күзалларга тырышты. Звонок биргәч тә, Миңлегөл ишекне ачып җибәрер, синмени инде бу, дигәндәй, елмаеп куяр. Бер-берсенең хәлен сораша-сораша табын корып җибәрерләр, сүз арты сүз китәр. Фатихның хыялыннан күчереп ясалган рәсеме Миңлегөлгә бик тә, бик тә охшаган булыр. Әңгәмәнең иң кызып җиткән бер вакытында ул аны ашыкмыйча, кабаланмый гына портфеленнән тартып чыгарыр да Миңлегөлгә бүләк итәр. Тавышыңнан, сөйләшүләреңнән мин синең сурәтне әнә шулай итеп ясадым, дияр. Биш яшьлек кызына (көч-хәл юнәтеп!) «Пушкин әкиятләре» дигән шоколад алырга да онытмады ул. Кызның әтисе кем, кайда — Миңлегөл болар хакында да сөйләр, сөйләмичә калмас. Шулай итеп, күбесе бер-берсен белмичә яшәп яткан миллионлы шәһәрдә Фатих өчен өр-яңа кеше, өр-яңа дөнья ачылып китәр...

Әнә шулай үз уйларына чумып бара торгач, Фатих үзенә кирәк тукталышны да узып киткән икән. Ике тукталыш арасын җәяүләп кенә барды да, Миңлегөл әйткән адрес белән, почмакларын яңгыр суы юып саргайткан биш катлы кирпеч йорт каршына килеп туктады.

Нинди язмыш, нинди очрашу көтә сине, Фатих?

Бу соравының сүзләрен һәм барлык икеләнүләрен баскыч саен сибеп калдыра-калдыра, өченче катка күтәрелде. Кыңгырау, төймәсенә баскач та, оясыннан егылып төшкән сыерчык баласыныкыдай тавыш белән чырылдап алды... Көтү мизгелләре шулай бит ул: минут эчендә Фатихның уе аша тәүлеккә тиң вакыт узып китте кебек. Менә, ниһаять, ишек ачылды һәм аның артында кемнеңдер кайнашканы, ут яндырганы күзгә ташланды.

— Керергә мөмкинме? — дип Фатих эчкә узды һәм икесенең дә күзләре мизгел эчендә сүзсез генә танышып, исәнләшеп өлгерде. Менә нинди икәнсең син, Миңлегөл!? «Миң-ле-гөл...» Фатих гаҗәпләнеп калуын, ут белән суның буталуына охшаш тетрәнүле уйларын сиздермәде, йөзенә күләгә чыгармады, билгеле. Хикмәт шунда: егерме биш-утыз яшьләр тирәсендәге бу хатынның сул як бите каш тирәсеннән алып иягенә кадәр ямьсез миң — чия кагыдай кызгылт-карасу төс белән капланган иде. Бер урында хәтта тамырланып торган зәңгәрсу тап та шәйләнә шикелле. Кичерәйтелгән яшен, диярсең...

Фатих үзенең сизгерлегенә хәйран калды: Билгесез кыз сурәтенең сул як битенә күләгә төшергәндә төсләр менә ни өчен карышкан, хыялының ни дәрәҗәдә дөрес икәнлеген күрергә, чагыштырырга менә ни өчен шулай ашкынган икән ул...

Яшьлеге ташып торган Миңлегөл өчен, һичшиксез, фаҗигадер бу. Тавышында кайчак күз яшьләре аша елмаеп сөйләшү төсмерләре дә чагылып китә иде шул аның, тик хыялый Фатих моңа игътибар биреп җиткермәде бугай.

Миңлегөл исә аны-моны сиздермәде, берни булмагандай, табигыйлек һәм ихласлылык белән Фатихны эчкәре чакырды. Бүлмә эче хатын-кыз кулы белән матур һәм җыйнак итеп җыештырылган иде. Чәчәкле болынның ашъяулык кадәрле бер өлешен, келәм итеп кисеп алганнар да, стенага беркеткәннәр диярсең. Сервант эчендә савыт-саба балкышы төсмерләнә. Ялгыз карават өстендә челтәр ябылган пар мендәр. Сүзсез утырган урындыклар. Өстәлдә ак эскәтер. Фатих, юл уңаенда әләктергән чәчәкләрне бергәләп өстәлгә урнаштырган арада, өй эчен әнә шулай тиз генә күздән кичереп тә өлгергән иде.

— Тормышың матур икән, күз тимәсен,— дип, соклануын белдерүне кирәк тапты Фатих. Шул ук вакытта үкенеп тә куйды: бер күрүдә, бер селтәнүдә генә кешенең ничек яшәгәнен, бәхетлеме-юкмы икәнен кайдан беләсең ди, их син, юләр...

— Һәркемнең үз оясы, үз кояшы инде,— дип, Миңлегөл аның бу сүзләреннән үзенчә нәтиҗә ясап куйды.

Хыял һәм чынбарлык уртасында торып калган Фатих, әле һаман да үзенең төштәме, өндәме икәнлеген билгели алмыйчарак, шушы халәтенә ияләшеп кенә килә иде әле. Миңлегөл:

— Чәй артында сөйләшик, булмаса, шулай бит?— диде дә кухня якка кереп китте. Биленә җыйнак кына ак алъяпкыч бәйләргә дә өлгергән иде ул. Өстәлгә туралган ипи, колбаса, торт һәм конфетлар тезде. Очрашу хөрмәтенә, дип, үз чиратында Фатих та портфеленнән коньяк чыгарып утыртты. Шоколадны биргәндә:

— Менә монысы кызыгызга... Үзе кайда соң әле ул?— дип сораганын сизми дә калды.

— Бакчада. Аны алырга өч сәгать вакыт бар әле.— Миңлегөлнең тавышында баласына булган мәхәббәт очкыннары, шул ук вакытта нәрсәдәндер уңайсызлану чалымнары да сизелде кебек.— Бүген — төшкә кадәр эшләү көне минем.

— Очрашу өчен, икенче кат танышуыбыз хөрмәтенә,— дип кабатлады Фатих һәм, чәкештергәннән соң, рюмкасын төбенә кадәр эчеп куйды. Миңлегөл исә, томшыгы белән таң чыгына кагылган коштай, эчемлеккә иренен генә тидереп алды. Ул кунагына ничек тә уң як бите беләнрәк утырырга тырыша иде шикелле.

Бирегә килеп эләгүен Фатих гап-гади бер танышлык итеп кабул итәргә тырышты. Шуңа күрә аны ничә көннәр буе канатландырган хыял һәм романтика каядыр еракка чигенгән, сүрелеп калган иде. Икенче рюмка исә аның тәнен җиңеләйтеп, телен ачып җибәрде. Мавыгып китеп, сүз арасында хәтта балачагыннан күптәнге бер вакыйганы да сөйләп алды:

— Мин үзем авылда, табигать кочагында туып үскән кеше. Чирәмлектә күлмәкләр яшелләнгәнче ауный идек тә, буага төшеп су коена идек. Бервакыт, чирәм исенә кызыгыптыр инде, читән буенда калдырган күлмәкләребезне бозау чәйнәгән иде. Җиңнәрен тәмам мунчала иткән... Ачу килде. Тыкрык башында кечерәк кенә мунча бурасы тора иде. Шуны сүтеп, бозауны эчтә калдырдык та, бурәнәләрне кире өйдек. Бәдриҗамал карчык бозавын икенче көнне көчкә эзләп тапкан. Вәт хәйван, бура эченә ничек кердә икән ул, дип, кеше саен шаккатып сөйли икән теге...

Көлештеләр, кызык булып китте.

— Мин кызым йөргән бакчада тәрбияче булып эшлим,— диде Миңлегөл үзе турында сөйләгәндә.— Эшем ошый үземә. Балалар арасында кайнашу дөньямны онытгыра.

— Ә кызның... кызның әтисе турында сорарга мөмкинме?

Бу юлы инде Миңлегөл ачыктан-ачык уңайсызланып куйды. Ләкин үзен бик тиз кулга алды ул. Сөйләргәме-юкмы дигәндәй бер тын уйланып торды да кызына кагылышлы тарихның чын дөресен сөйләп бирде.

— Ялган тотыла ул, мин алдашырга яратмыйм,— диде сүзенең башында ук ихласлыкка чакырып.— Серемне сөйләргә дә күнекмәгән. Тик сезгә сөйлим... Сәнгать кешеләре кешене аңлый белә, диләр. Тик бер генә үте-

нечем — аны, зинһар, үзегездә генә саклагыз. Ничек башларга икән? Чөнки бу хакта берәүгә дә сөйләгәнем юк... Иптәш кызларым кияүгә чыгып беттеләр. Мин, уйладым-уйладым да, кияүгә чыкмаска карар иттем... Аңлыйсыздыр, табигатьнең мине рәнҗетүен башкалар язмышына күчерәсем килмәде. Аннары миңа... егетләр арасыннан сүз кушучы да булмады. Мин аларны гаепләмим, егетләрнең чибәрләргә омтылуын аңларга була, мин үзем өчен бердәнбер юл күрдем — үземне саклау, югалтмау. Кияүгә чыкмасам да, моның өчен миңа бала кирәк иде. Очраклы, ләкин тәртипле егет белән бәйләнешкә кердем... Рәхмәт аңа, ул мине аңлады, онытты һәм бүтән борчымады. Мин аның хәзер кайсы шәһәрдә яшәвен дә белмим. Йолдыздай атылды, югалды, сүнде ул минем өчен, әмма теләгемә ирештем... Менә шулай, мин балам өчен, кызым өчен яшим. Бөтен яшәвем — аның өчен. Бу тормышта миңа шуннан артыгы кирәкми. Таләп тә итмим... Язмышым белән инде әллә кайчан ризалаштым мин...

Миңлегөл боларны шулкадәр тыныч, дөньяга үпкәсез, үз-үзенә хөрмәт белән сөйләде ки, Фатих аны бер дә бүлдермичә, исе китеп, дулкынланып тыңлады. Миңлегөлнең әйткән сүзләре, фикерләре, кырыс язмышында әнә шулай берәүне дә кабатламас юл сайлавы — бу ап-ачык хакыйкать бернинди юату-хуплауларга мохтаҗ түгел иде шул.

— Мин сезне аңлыйм... Ихластан сөйләвегез өчен рәхмәт, — диде Фатих шулай да, озак дәшми утыруның килешеп бетмәслеген аңлап.

Фатихның күңел төпкелендә инде байтактан бирле посып яткан бер сорау тагын кыбырсынып куйды, үзенә юл эзләде. Ничә көннәр илһамланып, канатланып ясаган рәсемне Миңлегөлгә бирергә тиешме ул, юкмы? Кызның йөзен авырлык белән ясавын әйтмичә генә бирәсең икән, һавадагы бушлык сыман, моның бернинди мәгънәсе калмый. Рәсемне кулына биргәндә барысын да әйтеп салсаң, кешенең иң авырткан җиренә кагылуың ихтимал. Рәсем бер бите кояшлы якны, икенчесе болытлы-яшенле төнне хәтерләткән Миңлегөлнең күңелен тырнап, җәрәхәтләп кенә торачак. Ул инде, үзе әйткәнчә, язмышы белән күптән ризалашкан. Шулай булгач, аның тынычлыгын алу, инде болай да эчке фаҗига кичергән кешене, үзенең нindiлеген искәртеп, тагын да яңа газапларга дучар итү дөрес булырмы? Аннары, кайбер чалымнары туры килсә дә, рәсемдәге кыз Миңлегөлгә әллә ни охшамаган да. Әлеге рәсемен Фатих күргәзмә залына тәкъдим итәр, иң яхшысы шул булыр. Күргәзмәдән соң аны бөтенләйгә үзендә калдырыр...

Фатихның яшерен уйларын үтәли укыгандай, Миңлегөл кинәт әйтеп куйды:

— Бик теләгән идегез, менә очраштык та... Канәгать булдыгызмы инде?

Аның кинаяле бу сүзләрен Фатих: «Сез чибәр бер хатын күрергә өметләнеп килгән идегез. Ә мин андыйлар затыннан булып чыкмадым, өметегез акланмады. Сез шуңардан канәгатьме?» — дип аңлады, билгеле, бу кадәресе барып җитте аңа. Ул акыллы сүзләр эзләп тормады, әллә ничә төрле мәгънәгә урын калдырып, үзе дә сизмәстән:

— Канәгать... — диде бер сүз белән.

Фатих үзен эчтән генә: «Гап-гади бер очрашу булып чыкты бу», — дип ышандырырга бик теләсә дә, аның күңелендә тел белән аңлатып булмый торган ниндидер үзгәреш, әрнеш уянып килә иде. Шашты, янды, эзләнде, ничә көннәр шушы очрашуга талпынды һәм менә барысы да урынына кайтып төште түгелме? Ул инде әлеге шашкын хыялларын бер истәлек итеп хәтерендә саклар, бүтәнчә очрашуга омтылмас, ә бәлки әле телефоннан сирәк-мирәк булса да сөйләшкәләп торырлар. Иң мөһиме — икс арада әйбәт кенә аңлашу килеп чыкты, Миңлегөлнең үз-үзенә хөрмәт белән каравы кимсетелмәде. Ул шулай үзенчә бәхетле һәм үзенчә бәхетсез яши бирсен — тәкъдирдән кемнең әле качып китә алганы бар?

Чәйләр инде суына төшкән иде. Миңлегөл, чәйнекне яңартып килим, дисә дә, Фатих, рәхмәт әйтеп, кузгалырга вакыт җиткәнен сиздерде. Соңгы

минутларда гына ул үзенең ялгыз калырга тиешлеген чамалап алган иде. Портфеленнән чыкмый калган сурәткә онытылып, озаклап ялгызы гына карыйсы, сул як биттәге күләгәнең ничек чыкканлыгын өр-яңадан күрәсе, шуның белән бүгенге очрашуга нокта куясы килде аның.

Шуны аңлады: ялгызлык аңа үз-үзе белән сөйләшү, әрнешле уйларын тәртипкә китерү өчен кирәк иде.

Миңлегөл ишек төбенә кадәр озата килде. Аның нидер әйтәсе килә кебек. Күр әле: битенең кояшлы ягы белән торганда ул хыялдагы сурәткә ныграк охшый төшә, ахрысы... Миңлегөл телгә килгәнче, бу юлы ничектер Фатих алданрак сүз кушып өлгерде:

— Ничек уйлыйсыз, Миңлегөл, бүгенге очрашуны мин киләчәктә рәсем итеп ясасам...

— Ә мин бөтенләй башканы уйлап тора идем,— дип елмая төште Миңлегөл.— Быел җәй безнең бакчада бизәү-ремонт эшләре башланачак. Бүлмә һәм коридор стеналарына байтак кына рәсемнәр дә төшерәсе бар. Вакытыгыз булса, бәлки, сезгә мөрәҗәгать итәрбез.

— Кирәк дисез икән, тырышырбыз,— дип Фатих ризалык белдерде.

Ул урамга чыккач кына үзенең бераз кызмача икәнлеген сизде. Тукталышта автобус көткән чакта шунда басып торган кешеләрнең йөзеннән «кем бу, ни өчен яши» дигән мәгънәнең җавапларын укырга тырышты. Кешеләрнең һәркайсы — табышмак. Фатих әнә, рәссам буларак, төсләр һәм буяулар ярдәмендә әнә шул табышмакның җавабын табар өчен яши дә инде. Табарга һәм югалтмаска — тормыш тарафыннан аның талантына әнә шундый зур җаваплылык та салынган.

Кешеләрнең мең мәшәкать белән эштән кайткан чагы, автобуслар балык мичкәседәй шыплап тулган. Фатих, җилкәсе белән җай гына юл яраяра, бер читкәрәк кереп урнашты. Чү! Кинәт аның күз аллары әллә нишләп китте: янәшәсендә генә, үз уйларына чумып, таныш түгел бер кыз бара иде. Киндердәге ул ясаган рәсемгә охшаса да охшар икән! Гаҗәпнең аръягындагы хәл иде бу... Менә шунда, җайлабрак урнашам дигәндә, саксызлыгы аркасында Фатих ялгышлык белән кызның аягына китереп басты. Чибәркәй дигәнебез шундук кара коелып төште, күзләрендәге матурлык күз ачып йомганчы ямьсез нәфрәт белән алмашынды. Тагын да яманрагы, ул тәмәке ике аңкыган сулышы белән ысылдап:

— С-сыер!..— диде дә Фатихка арты белән борылды. Син минем өчен чүп, дигәнне аңлата иде аның бу тәкәббер кыланышы.

Әлеге хурлыкны күтәрә алмады Фатих, беренче тукталышта ук автобустан төшеп калды. Нәрсәдер эшлисе, ватасы, җимерәсе, кемнәндер үч аласы килә иде аның. «Тышкы матурлык эчке матурлык белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин...» — дигән уй гына сукыр нәфрәтеннән аралап алды аны. Дулап, өерелеп күңеленә төсле хыяллары әйләнеп кайтты. Гүяки офыктагы кызгылт-алсу болытлар артыннан, битенең кояшлы ягы белән елмаеп, кемдер аңа карап тора иде...

Менә шунда гына Фатих үзе өчен ачыш ясады: ул бит, тырыша-тырыша, Миңлегөлнең күңел сурәтен, күңел матурлыгын ясаган икән ләбаса! Кайчаннан бирле күңелендә бөргәләнеп тә, менә хәзер генә яшендәй сызылган бу ачышы бик тә кадерле иде аңа.

«Үз язмышын иңнәрендә тотып торыр өчен никадәр ныклык һәм сабырлык кирәктер Миңлегөлгә!..»

Фатих, портфелен кулына кысыбрак тотты да, каршы яктагы телефонавтоматка ашыкты...

*Март, 1991.*

# ШИГЪРИЯТ

## Гөлзада Әхтәмова

### Ташлар эзлим Алабугада

Ташлар юллыйм, ташбилгеләр карыйм,
Эзләр эзлим өзелеп үзәгем.
Кайда соң сез, кабер ташкайлары,
Ник аера алмый күзләрем?

Чиркәүләрне инде ничә гасыр
Күтәрүләр авырдыр сезгә.
Юллар түшәп, бозылып, шомарыплар
Чәрдәкләнеп, их, беткәнсез лә!..

Төшләремә керә манаралар,
Ялтырыйдыр көмеш айлары.
Телгә килеп бергә сөйләшәбез,
Ахры алар бабам җаннары:

«Ник онытып безне яшисез соң?
Ник кадерсез изге сөякләр?
Нигә вата потлы герләр белән
Кабер ташын кара йөрәкләр?»

Һәрбер бизәк, һәр гарәпчә хәреф
Кан дошманы һаман аларның.
Татар рухын, хәтта һәр авазын
Буа бара кәкре бармагы.

Булмаганнар, тормаганнар, диеп,
Бүген дә бит бармак яныйлар.
Ишетмисез мәллә, милләттәшләр?! —
Хәтерләрне безнең талыйлар.

Алабуга — урыс шәһәре дип,
Күпме инде җырлар язылды,
Ник йоклыйсыз, татар шагыйрьләре,
Тарихыбыз нигә сызылды?

Музыкантлар, кайда моңнарыбыз,
Җырчылар юк мәллә җырларга?!
Бәетләребез ник басылмый соң,
Кәгазь беткән мәллә аларга?

---

Гөлзада ӘХТӘМОВА — *Алабугада яши, укытучы; шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килде.*

Кайчан халкы өчен хезмәт итәр
Саф йөрәкле татар галиме?
Очсыз дан-шөһрәткә сатылмыйча,
Йөзен ачар гасыр белеме?

Кайда фидаилар, көчле ирләр,
Кайда югалдыгыз, кардәшләр?
Ташлар юллыйм, ташбилгеләр эзлим,
Мин ялгызмы? Эзлим юлдашлар!

## Алабуга корылмасы

Тау битендә җилләр нидер сөйли,
Уйный төнлә кемнең шәүләсе?
Дәверләрне бутап баскан мәллә
Алыпларның көчле гәүдәсе?

Юк, аларның җыры тынган инде,
Буыннарда бары сагышы.
Тик бер миңа ишетелә кебек
Калканнарның, чыңлап, тавышы.

Чәчелгән дә шушы калкулыкка,
Әйләнгән күк ташка бәгырьләр.
Җан өрәсем килә һәр ташына,
Кулларыма алам кадерләп.

Могҗизадай калган таш ныгытма
Эченә йоткан бөтен моң-зарын.
Җил-давылга вакыт бүләк иткән
Шатлыкларын, авыр газабын.

Чулман дулкыннарын, таш ныгытма
Моңсу уйда боегып күзәтә.
Алыпларның сынган сөңгеләре
Төшләренә керéп йөдәтә.

## Кем хужа туган туфракка?

Баш иелгән, бил бөгелгән,
Аркадан үтә ятлар.
Әйтерсең лә без курчаклар,
Әйтерсең кургаш атлар.

Җигелеп барын тартабыз,
Камчылар гына булсын,
Безгә әмер бирүченең
Мендәрне күпереп торсын.

Бу, дигәч, будык Чулманны —
Ни генә үтәлмәде?!
Акты-китте «кара алтын»,
Сарысы тәтемәде.

Хәзер дә кара АЭСлар,
ЕлАЗлар туып килә.
Эт өрә, бүре йөри, дип,
Түрәләр бездән көлә.

И халкым! Синең «сабырлык
Саф алтын» түгел бүген.
Юк сине, ахры, санлаучы:
Төтеннән ачы күгең.

Дөрләми әле, тик пыскый
Тел һәм дин учаклары.
Ни әйтеп уятырга соң
Күңеле чукракларны?

Шул хужа туган туфракка —
Кем аның суын эчә,
Кем сулый күкрәк тутырып,
Кем сөеп иген чәчә...
Тарихи җир-нигезендә
Татар нәселе үссә —
Язykмы шулай дисәк?

# Дилә Булгакова

* * *

Алдылар күңел күлемнән
Балыкларымны сөзеп.
Үттеләр инде, үттеләр
Камышларымны өзеп.

Киттеләр инде, киттеләр
Йөзгән кошымны атып.
Калды тик минем хыялда
Сынган камышлар ятып...

* * *

Яшь колыннар үсеп, тай, ат булгач,
Еллар әле тарар ялларын...
Үзем күрдем, колыннарын сагынып,
Ат күзеннән яшьләр тамганын.

Охшаганмы атлар кешеләргә,
Кешеләрме охшаш атларга?
...Яшен сөрткән әнкәемне күрәм,
Кайтсам уйда бала чакларга.

## Әйтче, язмыш

Яшь боланым үлән ярып китте,
Урман шомлы, урман караңгы.
Зөһрә йолдыз, син бит биегрәк,
Куркыныч юк микән, кара әле.

Зөһрә йолдыз — уртак йолдызыбыз,
Сукмакларын яктырт урманның.
Әйтче, язмыш, тормыш урманында
Адашмасын икән боланым?!

## Ят боланнар

Ят боланнар килер чыккан, диләр,
Боланнарның бармы ятлары?
Үлән утлап йөри ят боланнар,
Арасында юкмы агълары?

---

Дилә Булгакованың хикәяләре, шигырьләре Казан һәм Уфада чыга торган газета-журналларда даими басылып килә. Уфада яши.

Тоньяклардан килде микән алар,
Кайсы урман тартты җаннарын?
Калырлармы торып аланымда,
Үз итеп лә үлән тамнәрен?

...Урманнардан ят боланнар китә,
Кем өркеткән икән, ни булган?
Күңелемнең җырлы болынына
Үз паркаен чакыра ак болан.

## Куркам

Карамачы миңа,
Күзләреңнән куркам.
Әйтерсең лә алар
Атылырдай вулкан.

Кагылмачы миңа,
Кулларыңнан куркам.
Әйтерсең лә алар
Яралганнар уттан.

Якын килмә миңа,
Күкрәгемдә вулкан...
Синнән түгел, хәзер
Үз-үземнән куркам.

## Син ничек яшисең икән...

Син ничек яшисең икән?
Мин элеккечә яшим:
Яңгырлар да коеп үтә,
Элеккечә ут-яшен.

Элеккечә шәл бәйлимен,
Ялгышып кат-кат сүтәм.
Җил капкамның элгече юк,
Элеккечә бит көтәм.

Элеккечә ак болытлар,
Элеккечә ут-яшен...
Син ничек яшисең икән,
Мин һаман янып яшим.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Миркасыйм Госманов

# ЧӘЧЕЛГӘН ОРЛЫКЛАР

### Голҗа татарлары

*Очып, чүлләр кичеп, таулар ашып,*
*Килеп төшкән микән, башкай адашып?*

ДӘРДЕМӘНД

Вакыт-вакыт читтәге татар кешеләренең язмышы миңа көзге каенлыкта очкан яфракларны хәтерләтә. Берәм-берәм җилбердәгән, күче-күче белән бөтерелгән яфракларны, сибелгән орлыкларны искә төшерә.

Үзләренә җан биргән, санаулы гына җылы, якты көннәр бүләк иткән ак каүсәләр төбендә дә өелеп калып, ана агачның тамырларын ашлый ул яфраклар; басулар, кыр-үзәннәр буйлап та тузгып әллә кайларга очалар. Инеш-елгаларны юл итеп, дулкын-дулкын томырылып агалар... еракларга...

Ышыграк урыннарда тукталып калалсалар, җиргә ятып, әкрен генә туфрак булалар. Үзләре белән алып килгән орлыклардан яңа үсентеләр бирәләр.

Үсәләр. Чак кына шарты килсә, адашкан утрау булып, яңа каенлыклар бөдрәләнә. Аларның да яфраклары, орлык-тәлгәшләре тузгып оча башлый...

Җансыз чүлләргә, коры ташлыкларга да барып яталар алар. Сыек кына кар сулары, язгы тамчылар белән сугарылган орлыклар шытып та чыгалар. Тик... Көзгә таба алар барыбер корып бетәләр. Кайберләре, кыя ташларына сырышып булса да, үсеп маташалар. Кәкерәеп, бөкерәеп беткән хәлдә дә. Чын каеннарның истәлеге, ерак шәүләләре төсле...

Җил-язмышлар тагын яңа-яңа яфрак көтүләрен, орлык тәлгәшләрен, аерым-ялгыз бөртекләрне дә өзә тора, әллә кайларга куа тора...

Ботак-каүсәләрдән өзелеп каен яфраклары гына очмаган кебек, төрле-төрле якларга сибелгән халыклар да бер татар гына түгелдер, бәлкем, дөньяда.

Шулай да...

---

* Миркасыйм ГОСМАНОВ (1934) — *әдип, галим, тарих фәннәре докторы, профессор. «Каурый каләм эзеннән», «Үткәннән киләчәккә» һ. б. мәгълүм китаплар авторы. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Казанда яши.*

Советлар иленең барлык почмакларына диярлек таралып беткән татарларның төрле дәверләрдә төрле сәбәпләр белән чит илләргә һиҗрәт иткән — күченеп киткән өлешләре дә аз түгел. Һәрбер илдә булмаса да, Антарктидадан кала, һәрбер кыйтгада бар алар. Кайдадыр күпләп, күмәкләшеп гөрләп яшиләр, кайдадыр, берән-сәрән сибелгән хәлдә, дөнья көткән булалар. Кайберләре һаман юлда... Күзләре йомылганчы һәрберсе Казанны, Уфаны онытмас. Нәниләрен юатканда «йөрәк маем, багалмам» дип иркәлиләр. Телләрен онытып бетергәнче гел «Агыйделкәй алкын...» дип җырлар. Әмма, җае килсә, тагын сраккарак юл тотар. «Агыйделкәй...» дия-дия...

Бүген сүз шулай чит илләрдә яшәүче татарларның бер өлеше, дөресрәге, Кытай дәүләтенә барып чыккан, анда җирләшеп калган йәисә тагын күченеп киткән бер-ике уч кардәшләребез хакында.

Кытайдагы татарлар ике зур төркемнән гыйбарәт. Дәүләтнең көнчыгыш-төньяк территориясе булган Манҗуриядә яшәгәннәре һәм илнең көнбатыш өлкәләрен тәшкил итүче Шәркый Төркестан яки Уйгырстан җирләрендә таралып гомер кичергәннәре. Тамырлары бер булса да, оешу һәм яшәү шартлары, соңгы язмышлары аларның төрлечә. Шуңа күрә Манҗурия якларында бер җыелып, шау-гөр килеп яшәп алган, аннары тагын тузынып, таралып киткән татарлар хакында тәфсилләп сөйләүне икенче бер вакытка калдырыйк.

Хикәябез, шулай итеп, үзәк Азиядәге уйгыр җирләрендә яшәгән һәм өлешчә әле шунда яшәүче милләттәшләребез хакында.

Моңарчы Шәркый Төркестанда (һәм гомумән чит илләрдә) яшәгән яки әле дә анда яшәүче татарлар хакында, кайбер кыскача мәгълүматларны исәпкә алмаганда (карагыз: «Азат хатын», 1959, № 2; «Совет әдәбияты», 1961, № 1, 30—34 бб.; «Казан утлары», 1967, № 9, 112—113 бб.; 1978, № 11, 162—166 бб.), бөтенләй язылмады диярлек. Әмма аларның оешу һәм яшәү тарихларын, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен чагылдыра торган чыганаклар шактый. XIX йөзнең икенче яртысына һәм безнең гасырның башына караган Россия сәяхәтчеләреннән Ч. Вәлиханов, В. Радлов, Н. Пантусов, Н. Катанов һ. б. язмаларында теркәлеп калган фактлар, кыска һәм өзек-өзек булуларына карамастан, шактый зур әһәмияткә ияләр.

Татар авторларыннан тарихчы Корбангали Халидинең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә» (Биш шәрекъ иленең тарихлары) исемле фундаменталь китабы белән кайбер кульязмаларында да ул якларга караган мөһим фактлар теркәлгән. Атаклы мәгърифәтчебез Габдулла Бубиның уникаль кульязмаларында да безнең темага караган мәгълүматлар шактый. Әгәр болардан беренчесе озак еллар Чүгүчәк шәһәрендә имам вазифасын үтәп торган, Шәркый Төркестан буенча кызыклы сәяхәтләр ясаган кеше булса, 1913—15 елларда Голҗа шәһәрендә яшәгән Габдулла Буби да шул яктагы татарлар турында үз күзләре белән күргәннәрне, күңеленнән кичергәннәрне теркәп калдырган.

Әмма ул якларга барып чыккан, анда яшәгән татарлар хакындагы иң бай мәгълүматлар, һичшиксез, 1988 елда Өремче шәһәрендә уйгыр телендә нәшер ителгән «Татарларның кыскача тарихы» исемле китапта тупланган. Бу китап турында махсус сөйләүне, аның бәхәссез уңышларын, объектив җитешсезлекләрен бәяләүне башка урынга куеп (карагыз: «Шәһри Казан», 1991, 6 һәм 9 апрель), анда китерелгән фактлардан актив рәвештә файдаланачагыбызы махсус искәртү дөрес булыр. (Уңайлык өчен китап исемен алда ТКТ рәвешендә кыскартып алырбыз.)

Сөйләнәчәк вакыйгаларның бер өлеше күптән түгел узган хәлләр икәнлеген истә тотсак, шәхси истәлекләрдән файдалану да котылгысыз

хәл. Үзем дә Голҗа шәһәрендә туган, уйгыр һәм казакъ балалары белән уйнап үскән, шундагы татар һәм рус мәктәпләрендә укыган. 21 яшемә, ягъни 1955 елга кадәр шунда яшәгән, димәк, Голҗадагы төрле милләт халыкларының тормышыннан якыннан хәбәрдар кеше буларак, үз истәлекләрем белән дә, җаяләр эчендә дигәндәй, уртаклаша баруны кирәк табам. Күргәзмәлек өчен үз гаиләбез, дөресрәге, үз фамилиябез башыннан кичкән вакыйгаларга, истәлекләргә мөрәҗәгать итәләр. Мондый алым бер кадәре абстрактлык куркынычыннан коткарыр, хикәягә җанлылык бирер дип ышанам. Әмма башка фамилияләрнең гаилә истәлекләренә алай махсус тукталмам, чөнки, ялгышлар җибәреп, кайбер якташларымны рәнҗетеп куюым да ихтимал.

Хәтеремә ышанмаган чакларда, теге яки бу мәсьәлә буенча хәзер Алма-Ата һәм Ташкентта яшәүче якташларыма, туганнарыма хатлар белән мөрәҗәгать итүемне, шул рәвешчә «хәтер яңартуымны» да яшермим.

Кайбер вакыйгаларны, фактларны телгә алган чакта рәсми әдәбиятлардагы теге яки бу сәяси көчләрнең омтылышларыннан, ихтыярларыннан килеп туган тенденцияләргә иярмәскә, чынлыкта ничегрәк булган булса, шулайрак яктыртырга яки үзем аңлаганча язарга тырышырмын. Шул ук вакытта беркемнең дә теге яки бу иҗтимагый омтылышлардан читтә кала алмавын яхшы аңлыйм. Димәк, үземнең дә «хатадан хали» була алмаячагым табигый. Өстәвенә чын хакыйкать дигән «нәрсә» утыз үзәкле, кырык кырлы, шунысы белән гаҗәеп серле һәм катлаулы күренеш тә ул. Шуңа күрә бу язмаларымда очраган төгәлсезлекләрне, хаталарны төзәтүчеләргә алдан ук рәхмәтләремне белдерәм.

Ниһаять, тагын бер принципиаль мәсьәләне дә ачыклау зарур. Сүз Шәркый Төркестан һәм Голҗа татарлары хакында бара дигәч тә, минем максат аларның көнкүреш шартларын, гореф-гадәтләрен генә тасвирлауга кайтып калмый. Мондый этнографик, димәк, чагыштырмача таррак максатның да мөһимлеген мин кире какмыйм. Шулай да үз алдыма әлеге милләттәшләребезнең ничек, ни өчен, кайчан һәм кайлардан ул тарафларга барып чыгуларын, ягъни күпкә катлаулы һәм киңрәк мәсьәләләрне ачыклауны бурыч итеп куйдым. Чөнки этнографик үзенчәлекләр беренче чиратта аларның үз хосусиятларын гына чагылдырса, һиҗрәт сәбәпләрен, күченү юлларын ачыклап, җир-су алыштыруның чорларын билгеләү халкыбызның кырыс язмышын, гомум тарихын тирәнрәк, дөресрәк аңларга да ярдәм итә.

Язмаларым үзәгендә — укучы күрер — ватаннан һиҗрәт итү, чит җирләрдә төрле кәсепләр белән шөгыльләнеп ризык эстәү, баю, бөлү ише социаль-иҗтимагый мәсьәләләр, ниһаять, халык буларак яшәү, саклану, шул юлда сынаулар кичү, йәисә башкалар белән аралашу, алар арасында эреп бетү кебек катлаулы процесслар тора. Шуңа күрә мин, барлыкка килгән фактларны, күренешләрне теркәп бару белән генә чикләнмичә, андый мәсьәләләр һәм процессларның кайбер «технологик» үзенчәлекләрен дә чагылдырырга тырыштым. Чөнки тарихны белү генә җитми, аны аңларга, тоярга да кирәк. Хикәям тукымасына вак-вак ярдәмчел сюжетларның кереп китүләре, риваять-мәзәкләр белән бергә хосусый шәҗәрә материалларының, шәхси истәлек сәхифәләренең мул бирелүе шушы максатка бәйле. Истәлек дигәннән, үзем туып үскән, шуңа күрә яхшырак белгән Голҗа шәһәренә, аның хатирәләренә күбрәк игътибар иттем. Һәм бу табигый: күрмәгән җирләрең хакында «беләм» дип күкрәк сугу белән көлкегә калуың ихтимал.

Хикәя ителәчәк хәлләр укучыларымның һәммәсенә дә тигез дәрәҗәдә аңлашылсын өчен, вакыйгалар узган якларның ерак һәм якын тарихлары, географик шартлары буенча да кайбер мәгълүматлар бирүне кирәк табам.

Иң әлек Шәркый Төркестан, Уйгырстан дигән атамаларга махсус тукталыйк, уйгыр халкы белән дә кыскача танышып узыйк.

Күз алдыгызга Азия картасын китерегез.

Хәзерге Кытай халык республикасының көнбатышы. Һиндстан белән чиктәш Тибәт тауларын табыгыз. Шул олы тауларның төньягыннан алып, Үзбәкстан, Таҗикстан, Кыргызстан һәм Казагыстан республикаларының көнчыгыш чикләре буйлап, Монголиягә кадәр барыгыз да, көнчыгышка таба борылып, әлеге илнең көньяк чикләренә җитегез. Аннары көньякка таба кырт борылып, йәнә Тибәт тауларының көнчыгышына кайтыгыз. Сезнең алдагы кәкре-бөкре кырлы «дүртпочмакта» хәзерге Шенжаң-Уйгыр автоном районы булыр («район» сүзе бу очракта, дөресрәге хәзерге Кытайда, край, регион дигән мәгънәдә кулланылган).

Әллә ничә Франциялар белән тагын шуның хәтле Германияләрне бергә сыйдырырлык киң дөнья. Иксез-чиксез сахралар, бозлы кыялары күкләргә җиткән тау чылбырлары, дөньядагы иң түбән һәм иң зур иңкүлекләр, атналар буе гизәрлек каны кипкән ком чүлләре, дәрьялары алкын сулы, бәрәкәтле яшел үзәннәр иле.

Бу — Шәркый Төркестан яки Уйгырстан җирләре булыр.

Шәркый Төркестан үз нәүбәтендә географик һәм икътисадый, хәтта тарихи-этнографик җәһәттән дә җиде-сигез мөһим, үзенә күрә мөстәкыйль өлкә-регионнарга бүленә. Болардан безнең өчен әһәмиятлеләре түбәндәгеләр:

1. Алты шәһәр регионы. Уйгырстанның көньяк-көнбатыш өлкәләрендәге алты шәһәрдән (Кашгар, Яркәнд, Хутән, Өчторфан, Көчар, Аксу) чыгып шулай аталган. Үзәк Азиядәге иң борынгы цивилизацияләр туган, зур мәдәниятләр очрашкан тарихи җирләр. Яңа дәвер уйгыр халкы милләт булларак формалашкан төп өлкәләр болар.

2. Торфан-Хами (Кумул) төбәге. Шәркый Төркестанның көнчыгышындагы тарихи Кытай өлкәләренә иң якын регион. Бу яктагы уйгырлар электәэлектән кытайлар белән аралашып яшәгән.

3. Өремче һәм аның тирәләре. XVIII гасырның икенче яртысыннан алып Уйгырстанның, дөресрәге, Шенжаңның, ягъни Синьцзянның, административ үзәге. Өремче (русча карталарда: Урумчи) шәһәре хәзерге Шенжаң-Уйгыр автоном районының башкаласы. Халкы милли яктан шактый чуар.

4. Алтай вилаяте (өлкәсе). Алтай таулары системасы дүрткә бүленеп, аларның берсе хәзерге Казагыстанда, икенче — Россиядә, өченчесе — Монголиядә булса, дүртенче өлеше Шәркый Төркестанга карый. Җирле халыкның күпчелеге кирәй кабиләсе казакълары.

5. Тарбагатай вилаяте; төньяк-көнчыгыш Казагыстан белән чиктәш өлкә, үзәге Чүгүчәк шәһәре. Семипалатинск (Сими, Симәй) шәһәрен база иткән Россия сәүдәгәрләре Кытай дәүләте белән сату-алу эшләрен иң элек шул Чүгүчәк аркылы алып барган. Халкының төп өлешен казакълар, монголлар, уйгырлар һәм башка соңрак килүче кавемнәр тәшкил иткән.

6. Элә вилаяте. Бу өлкә Балхаш күленә коя торган Элә (картада: Или) дәрьясының бәрәкәтле киң үзәне тирәсендәге җирләрне — биек таулар һәм иркен сахраларны, алкын елгалы кечерәк үзәннәр белән уңдырышлы сыртларны эченә ала. Мәркәзе Голҗа шәһәре (картада: Кульджа, русча әдәбиятта «Кульджинский край» дип тә йөртәләр). Мондагы уйгырларны элек таранчылар дип атаганнар. Чөнки алар бу якларга XVII—XVIII йөзләрдә Алты шәһәр тарафларыннан китерелгәннәр һәм, күчмә монголлардан үзгә буларак, игенчелек белән шөгыльләнгән уйгырларның нәселләре («таранчы» сүзе монголча «игенче» дигәнне белдерә). Шәһәр халкының күпчелеген уйгырлар тәшкил итсә дә, районнарда, бигрәк тә тауларда, казакълар, монголлар, кыргызлар күбрәк иде.

Бу санап чыккан өлкә-регионнар бер-берсеннән биек таулар, зур чүлләр, киң сахралар белән аерылган. Элекке заманнарда алар арасындагы

барыш-килеш эшләре әллә ни җиңел булмаган. Шуңа күрә алар үзара этнографик җәһәттән дә бер-берсенә бик үк охшамаганнар. Әгәр илнең көньягында гел уйгырлар, үзәктәрәк аларга кытайлар, дөңгәннәр (мөселман динен алган «кытайлар») өстәлсә, төньякта монголлар белән казакълар да шактый. Памир таулары ягында кыргызлар, таҗиклар да бар. Элә вилаяте исә тагын да чуаррак. Анда, Уйгырстан һәм Урта Азиядәге халыкларның барысы да булган кебек, Манжуриядән күчерелгән шибә-соланнар да, ерак Европадан килүче руслар белән татарлар да шактый иде.

Менә шушы географик, демографик һәм тарихи шартлардан чыгып, Шәркый Төркестанны элегрәк ике зур регионга бүлеп, аның көньяктагы өлешен Кашгар ягы (русча әдәбиятта: Кашгария), ә төньягын исә Җөңгарстан (Джунгария) дип атаганнар. Көньякта халыкның абсолют зур өлешен уйгырлар тәшкил итсә, Җөңгар якларында XVIII йөзнең урталарына кадәр өстенлек монгол кабиләләре кулында булган.

Өлкәләре күп һәм төрле булган шикелле, Шәркый Төркестанның һава шартлары да бик үзенчәлекле. Күпчелек сахралары һәм үзәннәрендә җәйге эсселәр 40—50 градусларга җитсә, кышларын шунда ук 30—40 градуслы зәмһәрир суыклар да ят нәрсә түгел. Боз каплаган тау сыртларына җәй бөтенләй килмәгән кебек, кышның нәрсә икәнлеген белми торган иңкүлекләр дә бар.

Һава шартларына муафикъ рәвештә мондагы киң далаларда, сөзәк тау сыртларында һәртөрле ашлык үстерергә мөмкин. Бодай кырларында тана «күмелә язса», тары басуына кергән кабан дуңгызы күзгә күренмәс. «Күмүркунагының» (кукурузның) буе өчәр метрга җитәр. Бер үзәне иң тәмле кавыны, икенчесе искитәрлек карбызы белән дан тотса, өченчесе алмасы, йөземе белән мәшһүр. Ничә төрле өрек-абрикос, анар-гранат, инҗир... Йөз төрле яшелчә үсә бу шартларда. (Дөрес, Казан һәм Уфа татарларына арыш үсмәве, Самар-Пенза мишәрләренә «йир алмасының» ягъни бәрәңгенең уңмавы артык ошап бетми иде... Хәер, бу хакта сөйләп, мин бераз ашыктым бугай...)

* * *

Шәркый Төркестанның тарихы да гаҗәп бай. Борынгылыкта монда дистәләгән дәүләтләр яшәп узган. Бер цивилизацияләр урынына икенчеләре килгән. Ике-өч мәдәният кушылып, яңалары туган.

Төрки халыклар тарихында да бу җирләрнең әһәмияте гаять зур. Һуннар империясенең «алтын бишеге» дә шушы киңлекләрдә тирбәлгән дип әйтергә ярый. Борынгы Төрки каганлык VII—VIII гасырларда шушы иркен җирләрдә аякка басып, тарихтагы иң зур күчмә империяләрнең берсенә әверелгән. Аннары оешкан Уйгыр каганлыгы да (VIII—IX йөзләр) төрки дәүләт иде. Моннан соң регионның төньягында көнчыгыштан килгән мәҗүси киданнарның ханлыгы Каракытайлар дәүләте оешып, аерым уйгыр бәклекләре дә яшәсә, көньякта исә мөселман дәүләт — Караханыйлар патшалыгы (X—XIII гасырлар) күтәрелә башлаган иде.

Бу чорларда, төгәлрәк әйткәндә, безнең эраның беренче меңъеллыгы дәвамында, борынгы Уйгырстандагы төрки кабиләләр күршедәге мәдәни фарсы-таҗикларның, мөселман-гарәпләрнең, Тибәт һәм Һиндстан халыкларының телләре, диннәре, рухи һәм матди культуралары белән дә якыннан танышканнар. Шуңа күрә үзенчәлекле Урта гасыр төрки-уйгыр мәдәнияте зур казанышларга ирешкән.

Уйгырстан җирләрендә барлыкка килгән, безнең көннәргә кадәр сакланып калган күпсанлы юридик документлар, дин-фәлсәфә китаплары, әдәби әсәрләр, фәнни трактатлар, ниһаять, архитектура һәм сәнгать истәлекләре моны артыгы белән раслый. Үрнәк сыйфатында безгә кадәр килеп җиткән иң борынгы төркичә чын дөньяви әдәби әсәрләрдән Йосыф Хас Хаҗибның

«Котадгу билик» поэмасын (XI йөз), бөек телче Мәхмүд Кашгариның атаклы «Дивани лөгать-ит-төрек» сүзлеген (XI йөз) искә алу да җитә.

«Уйгыр язуы» дип аталган әлифба да кешелек тарихында зур урын тота. Уйгырлар ул язуны борынгы согдлардан алалар, һәм төрки телләргә яраклаштыргач, башка кардәш кавемнәргә дә бирәләр. Ул язуны, тагын бераз үзгәртеп-үзләштереп, монголлар һәм манжурлар да кабул итәләр. Монгол империясе чорында уйгыр язуының сферасы тагын да киңәя. Алтын Урда дәверендә ул Идел буенда да киң тарала. XIII—XIV гасырлардан безнең көннәргә кадәр килеп җиткән Идел буе истәлекләре арасында уйгырча язылганнары да шактый. Алтын Урда ханнарының битикләре (дипломатик хатлары) белән ул уйгыр хәрефләре Төркиягә дә, Польшага да, хәтта ерак Мисыр белән Италиягә дә барып җиткәннәр. Шуңа күрә хәзерге татар әдәби теленең нигезен тәшкил иткән Идел буе төркисе формалашуында да уйгыр теленең, уйгыр язма культурасының тәэсире мул чагылуы әллә ни гаҗәп түгел. (Кайбер тарихи чыганаклар күрсәтүенә караганда, элегрәк һәм XIII йөздә Идел буена килгән төрки кавемнәр арасында уйгыр ыруглары да булган икән.)

Әлбәттә, Монгол империясе оешу белән бөтен мәсьәлә бер уйгыр язуы таралуга гына кайтып калмый. Чыңгыз дәүләтенә үз ирекләре белән кушылган, шуңа күрә зур һәлакәтләрдән котылган уйгырлар аннары Чыгытай Улусы составына керәләр. Бу дәвердә алар «магул» исеме белән мәгълүм булып, Уйгырстан җире дә күбрәк Магулстан дип атала иде. Менә шул «уйгыр-магуллар» XVII—XVIII гасырларда гаять зур авырлыкларга дучар булалар. Урта Азия төрки ханлыклары зәгыйфьләнеп, феодаль таркаулыклар көчәюгә, уйгыр җирләрен сугышчан монгол кабиләләреннән уйрат-калмыклар басып ала. Шул рәвешчә, XVIII йөзнең урталарына хәтле алар Җоңгар дәүләтенә буйсынып яшиләр. Җоңгар ханлыгы таркалуга йөз токкач, Уйгырстанның төрле төбәкләрендә үзара ызгышып яши торган вак-төяк бәклекләр тернәкләнә башлый.

Күп заманнардан бирле уйгыр җирләренә каныгып яшәгән Кытай империясе дә бу форсаттан оста файдалана. Мәгълүм булганча, борынгы Кытай империясе илбасарлары безнең эрага кадәр беренче-икенче гасырларда ук, улҗа малы артыннан куа-куа, уйгыр җирләрен узып, Урта Азиядәге Фәрганә үзәненә кадәр килгәннәр иде. XVIII гасырда алар үзләренең шул борынгы казанышларын, димәк, «тарихи хокуклар»ың тагын искә төшерәләр. Шуңа күрә, бер яктан, тәхет өчен талашучы җоңгар ханнарының «чакырулары»на сылтап, икенче тарафтан, үзара ызгышучы уйгыр бәкләренең хаинлыкларыннан файдаланып, алар 1758 елны йөз меңлек армия белән тагын Шәркый Төркестанга басып керәләр, уйгыр халкын канга батыралар.

Ләкин җирле халыкның азатлык өчен көрәше дә туктамый. XIX йөзнең беренче яртысында барлыкка килгән эреле-ваклы баш күтәрүләр, бигрәк тә «уйгыр-дөңгән сугышлары» исеме астында канат җәйгән зур хәрәкәтләр (уйгырлар белән дөңгәннәрнең, ягъни мөселман динендәге кытайча сөйләшүче халыкларның үз автономияләре өчен баш күтәрүләре шуның мисалы иде. Шушы хәрәкәтләр нәтиҗәсендә яңа уйгыр бәклекләре оеша. Болар арасында тарихта сизелерлек эз калдырганнары йәисә безнең өчен әһәмиятлеләре сыйфатында Алты шәһәр якларында оешкан Якуббәк дәүләте белән Элә елгасы үзәнендә калкып чыккан Голҗа солтанлыгын махсус атарга кирәк.

Болардан Кытай хөкүмәтен дә, Рус империясен дә иң борчыганы Якуббәк хәрәкәте иде.

1840—1860 елларда Кытайда барган, хәзерге тарихи әдәбиятта Тайпин сугышлары дип исем алган киң колачлы халык баш күтәрүе нәтиҗәсендә империя бик нык көчсезләнгән, бигрәк тә Шәркый Төркестан кебек ерак өлкәләрдә үзәкнең тәэсире тәмам зәгыйфьләнгән иде. XIX гасырның 50—60 елларында Урта Азия ханлыклары берәм-берәм җиңелеп, Россиягә буйсына башлагач, «эшсез калган» үзбәк аксөякләреннән Якуб исемле бер

бәк (1820—1877) 500 сугышчысы белән 1864 елда Кашгарга килә. Бәхәссез батырлыгын да, оятсыз хәйләсе белән мәкерен дә эшкә җиккән Якуб Алты шәһәр вилаятьләрендәге эреле-ваклы «ханлыкларны», бәклекләрне бер-бер артлы кулга төшерә. Шул рәвешчә тиз арада, төгәлрәк әйткәндә, 1864—1877 еллар арасында Якубның биләмәсе зур гына дәүләткә әверелә яза.

Урга Азиядән соң Шәркый Төркестанны да «ялмап йоту» ниятеннән ерак тормаган патша хөкүмәте Якуббәк хәрәкәтен бик зур саклык белән күзәтә. XIX йөзнең 60 нчы елларында, ягъни Якуббәк пәйда булганчы ук, ул якларга бер-бер артлы рәсми делегацияләр, сәүдә кәрваннары күндерү (сәүдәгәрләрдән язма хәбәрләр җыю), гыйльми экспедицияләр оештыру, төрле кыяфәтләргә кергән разведчиклар җибәрү шуны раслый (мәсәлән, 1858—1859 елларда Әлимбай исемле сәүдәгәр кыяфәтендә Кашгарга барып кайткан Чокан Вәлихановны Шәркый Төркестан тарихын яхшы белүче чүгүчәкле галим Корбангали Халиди турыдан-туры «җасус» — шпион дип атый).

Патша Россиясен бигрәк тә Якуббәкнең Төркия хөкүмәте һәм Һиндстандагы Англия вәкилләре белән элемтәгә керүе, үз гаскәрен тәртипкә салуы, яңача кораллландыруы нык борчый. Һәм башлана шуннан рус әдәбиятындагы Якуббәк ул — «Төркия курчагы», «Англия шпионы» дигән раслаулар, каргаулар!... Әйтерсең лә, Кытай илбасарларына, Россия колонизаторларына каршы көрәшкән кеше боларның үзләреннән башка беркем белән дә элемтәгә кермәскә тиеш!...

Якуббәк «фетнәсе» җитмәгән кебек, Илә вилаятендәге уйгырлар да баш күтәреп, 1864—1871 еллар арасында яшәп калган Голҗа солтанлыгын игълан итәләр. Якуббәк хәрәкәтеннән дә саруы кайнап торган патша хөкүмәте тәмам чыгырдан чыга. Россия колонизаторларының эшлекле вәкилләреннән Җидесу вилаятенең хәрби губернаторы генерал-майор Г. А. Колпаковский инициативасы буенча «законлы Кытай хөкүмәтенә ярдәм итү», чик бозучы «каракларны» җәзалау дигән сылтау белән 1871 елның июнендә Голҗа солтанлыгына «вакытлыча» рус гаскәрләренең «чикләнгән контингенты» кертелә.

Өлкәне яулап алу генерал Колпаковскийның җирле халыкка махсус мөрәҗәгате игълан ителүдән башлана. Анда «мәгърифәтле» генерал җанаблары «төрле җенестәге» җирле халыкларны бер-берсенә каршы котырта. Ул, мәсәлән, XVIII йөздә үк дәүләт чиген саклау һәм жандармерия функциясен үтәү өчен Кытай императорлыгы тарафыннан Манжуриядән күчереп китерелгән, яңа урында төпләнеп калыр өчен иң яхшы җирләр белән тәэмин ителгән манжур-шибәләрне уйгырларга каршы өстерә. Шул рәвешчә, азатлык өчен көрәш чорында барлыкка килгән бер мөстәкыйль уйгыр дәүләтчелеге юкка чыгарыла. (Кайбер язма чыганаклар һәм халык риваятьләре күрсәткәнчә, Голҗа солтанлыгының дүртенче хөкемдары Әля солтан көчсез политик һәм начар оештыручы гына түгел, хәтта белем ягыннан да сай, садә кеше булганга охшый...)

Күп тә узмый, 1874 елдан башлап, көнчыгыш тарафтан кытай колонизаторлары да зур гаскәри көчләр белән Төркестан өстенә ябырылалар. Тагын бер-бер артлы мөстәкыйльлеккә омтылучы бәклекләр, «ханлыклар» туздырыла. 1877 елны, серле шартларда Якуббәк тә үтерелгәч, азатлык өчен көрәш сүрелеп кала.

Әмма, вак-төяк «явыз дошманнар» тәмам бастырылуга, ике дәү «тәкә»нең маңгайлары бәрелешә: Кытай императорлыгы белән Рус дәүләте арасында Голҗа вилаяте өчен талаш башлана. Чөнки руслар Голҗадан китәргә бер дә җыенмыйлар. Киресенчә, юллар салып, биналар төзеп ныгып калу ягын карыйлар. Кытай «хөкүмәтенә ярдәм», «вакытлыча керү» дигән сүзләр чираттагы миф кына иде. Моның шулай икәнлеген генерал Колпаковскийның Илә вилаятенә, Голҗа шәһәренә биргән бәясе дә күрсәтә: «Табигый байлыгы ягыннан Төркестандагы бер җирне дә Илә үзәне белән чагыштыру мөмкин түгел... Сәүдә өчен Голҗа шәһәре бик тә әһәми-

ятле. Чөнки ул бөтен Кытай чиге буенча үзәк нокталарның берсе исәпләнә. Хөкүмәт казнасын басту, сәүдә эшләрен җанландыру өчен дә (...), стратегик җәһәттән дә бик мөһим җир бу Элә өлкәсе...»

Мондый байлыктан җиңел генә баш тартыр өчен Кытай да җүләр түгел, әлбәттә. Һәм китә шуннан дипломатия көрәше! Башта килгән кытай илчеләренә генерал Колпаковский: «Элә өлкәсе мәңгегә патша хөкүмәтенеке булачак. Анда рус кешеләре хөкем сөрәчәк!» — дип җавап бирә. Кырыс генерал илчеләрне чик аркылы уздырмый. Әмма кытайлар да чигенмиләр — Европа аркылы Петербургка барып җитәләр. Ахырда беркадәре контрибуция исәбенә кайтарырга туры килә ул «майлы калҗаны»,1881 елгы «Санкт-Петербург шартнамәсе» буенча. Ул шартнамәдә көнбатыш чикләр ачыклана һәм кытай хакимиятенә каршы баш күтәреп, Элә солтанлыгын яклаган, шуңа күрә кытайлар тарафыннан эзәрлекләнүдән курыккан уйгырларга Рус дәүләтенә тиешле җирләргә һиҗрәт итү мөмкинлеге дә карала. (Гасырыбызның беренче яртысына кадәр Казагыстанда яшәгән уйгырлар — шул шартнамә буенча 1882—1883 елларда Элә вилаятеннән күченгән таранчыларның нәселләре.)

Рус хөкүмәте шулай ук башка җәһәттән дә үзе өчен кулай кайбер шартларга ирешә: Шәркый Төркестанның берничә шәһәре, җөмләдән, Өремче һәм Торфан, Голҗа һәм Чүгүчәк шәһәрләре Россия сәүдәгәрләре өчен «ачык зоналар» дип игълан ителә, аларның кайберләрендә рус консуллыклары булдыру хокукы таныла.

Шәркый Төркестанда, шулай итеп, яңадан Кытай империясе хакимияте урнаштырыла. Зур гаскәри көчләр ярдәмендә бу казанышларга ирешкән кытай полководецы Зу-Зоңтаң Уйгырстанда яңа административ структура төзи, һәм 1884 елда бөтен регионга кытайча рәсми исем бирелә: Шенҗаң — «Яңа чик». Йәнәсе, ике империя арасындагы яңа чикләрне ныгыткан җирләр! Шул рәвешчә, Уйгырстан дигән исем бары халык хәтерендә, ә Шәркый Төркестан исә, махсус атама буларак, гыйльми әдәбиятта саклана.

Кытай администрациясе көчәю белән бергә, Россия сәүдәгәрләренең мәнфәгатьләрен яклаган шартнамә гамәлгә керү нәтиҗәсендә Шәркый Төркестан җирләре ике яклап эксплуатацияләнә башлый. Кытай администрациясе җирле халыкны төрле салым-ясак җыю, ачыктан-ачык ришвәт алу юлы белән таласа, Россия сәүдә капиталы аның җелеген арзанлы чимал аркылы суыра.

* * *

XVIII—XIX йөзләрдә, башыннан кичкән әлеге канлы вакыйгалар нәтиҗәсендә, Шәркый Төркестанның халык составы да сизелеп үзгәрә башлый. Элек бу җирләрдә күпчелекне беренче чиратта уйгырлар тәшкил итеп, аннан соңгы урыннарда монголлар, казакълар торса, башка халыклар юк дәрәҗәсендә аз иделәр. Колонизация башлану белән, үзәктән җибәрелгән күпсанлы чиновникларга ияреп, җирсезлектән интеккән кытай һәм дөңгән игенчеләре дә агылалар.

Көнбатыш чикләрне саклау һәм җирле халык өстеннән күзәтеп тору өчен XVIII гасырда хөкүмәт манҗур кабиләләреннән сугышчан шибәләрне, соланнарны күчерә. XIX йөз урталарында көнбатыш яктан аздап-аздап үзбәк һәм татар сәүдәгәрләре, Россия консуллыклары ачылгач, руслар да килә башлыйлар.

Әмма читтән килүчеләрнең иң күбесен эчке Кытайның Гансу һәм башка өлкәләреннән агылган мөселман дөңгәннәр тәшкил итәләр. Шунысы да характерлы, саннары тиз ишәйгән дөңгәннәр үзләренә автономия яулау максатыннан еш-еш баш күтәреп, рәсми администрацияне дә борчыйлар, уйгыр бәкләкләре белән дә конфликтка керәләр. (Мондый «дөңгән сугышларының» иң соңгысы 1933—1934 елларда булган иде.)

Шулай да, XX йөзнең урталарына кадәр, Шәркый Төркестанда яшәүчеләрнең күпчелеге барыбер уйгырлар булып, җирле халыкларга нисбәтән кытайлар якынча биш-ун процентны тәшкил итә иде. 1950 еллардан алып, кем әйтмешли, «азатлыктан соң», кытайларның өлеше космик тизлек белән арта башлады.

Ниһаять, уйгырларның килеп чыгышы, телләре турында да берничә сүз.

Хәзерге уйгырлар — заманында үзенчәлекле язу тудырып, аны күп халыкларга биргән һәм Урта гасырларда Уйгыр каганлыгы исемле дәүләт төзегән борынгы төрки халыкларның нәселләре. Дөрес, кайбер тюркологлар, борынгы күчмән уйгырлар белән хәзерге утрак тормышлы уйгыр милләтенең телләре, көнкүреш шартлары һәм аерым гореф-гадәтләре арасында үзгәлекләр күреп, аларны башка халыклар рәвешендә тәкъдим итәргә тырышалар. Ләкин мондый омтылыш, минемчә, хәзерге төрки халыкларның мәдәниятләрен яшәртеп, кечерәйтеп күрсәтергә теләүдән йәисә халыкларның оешу, үсү закончалыкларын, милли культураларның тирән тамырларын яхшы белмәүдән килә торган бәла генә.

Чынлыкта бүгенге уйгырлар — борынгы күчмән уйгырлар белән кайчандыр Үзәк Азиядә яшәгән иран һәм башка телле утрак кабиләләр аралашуыннан, органик кушылуыннан барлыкка килгән төрки халык ул. Ассимиляция процессында хәрби яктан өстен, иҗтимагый җәһәттән яхшырак оешкан күчмәннәрнең теле өстенлек алган булса, матди көнкүрештә көньяк Үзәк Азия шартларына күптән күнеккән җирле утрак кавемнәрнең мөмкинлекләре җиңеп чыккан.

Уйгыр теле төрки телләр арасында «уйгыр-карлук» группасына керә, шунысы белән ул беркадәре үзбәк теленә якынрак тора. Әмма Урта гасырдагы гарәп язулы уйгыр әдәби теле белән чагатайча, ягъни иске үзбәкчә язма тел арасында якынлык тагын да көчлерәк. Кайбер Урта гасыр уйгыр авторларының әсәрләрен — үзбәкләргә йәисә, киресенчә, үзбәкләрнекен уйгырларга нисбәт итү фактлары шушы сыйфат белән бәйле. Шуңа күрә иске әдәби телебезне яхшы белгән, аның аркылы чагатайчадан да хәбәрдар булган татар кешесе өчен гарәп хәрефләре белән язылган элекке уйгырча текстларны укуы, аңлавы артык кыен түгел. Борынгы әдәби телләребездә, гомумтөрки уртак лексикадан тыш, гарәп-фарсы алынмаларының («мәдәни» сүзләрнең) күп булуы һәм аларның бер төсле язылуы бу аңлаешлылык дәрәҗәсен тагын да арттырган.

Дөрес, сөйләм телләре арасында аермалар күбрәк очрый. Традицион гарәп-фарсы алынмалары да халыкларыбыз телендә төрлечәрәк яңгырыйлар. Мәсәлән, татарлар «мәгариф» дисәләр, уйгырлар «мәарип» дип әйтәләр, татарларда «шәрәфенә» булса, уйгырларда — «шәрипигә», бездә «мөгаллим», аларда — «муәллим» һ. б.

Төркичә уртак сүзләрнең әйтелешләрендә дә кызыклы аермалар бар. Боларның берсе татарчада тотырыклы рәвештә а-ә белән әйтелә торган сүзләрнең уйгурчада-э-и (ы) авазларына күчү тенденциясе. Мәсәлән, татарча «йаңа» булса, уйгырчада — «йэңи» (өстәмә мисаллар: бәгъер — бэгъир, булмаса — булмиса, качып-къэчип һ. б.).

Бу тенденция кушымчалар алу исәбенә бер-ике иҗекле сүзләр күп иҗеклегә әверелгән чакта аерата көчәя. Әйтик, татарда: ат — аты, баш — башы — башыңны (ашыйм) булса, шул ук төрләнүләр уйгыр сөйләм телендә түбендәгечә үзгәрә: ат — эти, баш — бэши, бэшиңны (йәймән).

Шунысы да бар, кайбер очракларда мондый күчешләрнең бөтенләй киресен күзәтергә дә мөмкин. Әйтик, бездә «син, мин» булса, аларда «сән, мән» (ләкин: сэни, мэни); дип — дәп, биш — бәш, йир (җир) — йәр, мизгел — мәзгил һ. б.

Әлбәттә, мондый күчеш һәм үзгәлекләрнең билгеле бер кагыйдәсе, закончалыклары булырга тиеш. Тик аларны тотып алуы, кагыйдә рәвешендә куллануы артык җиңел түгел. Шуңа күрә уйгырлар арасында күптән түгел

яши башлаган татарлар кайбер хаталар да ясыйлар иде. Мәсәлән, 20 нче елларда Рәсәйнең үзәгеннән килгән бер абзый күрше уйгырга: «Тэвикъ сатасыңмы?» — дип эндәшкән. Уйгыр әкә бернәрсә дә аңламаган. Татар абзый: «Кыт-кытый», — дип кычкырып, куллары белән җилпенеп күрсәткән. Шуннан соң уйгырлар аңа «Тевикъ нугай» дигән кушамат биргәннәр, татарлар исә «Кыт-кытый Сәләхи» дип олылаганнар үзен. Чөнки уйгырлар тавыкны «тоху» дип атыйлар (борынгы төркичә «токаху» сүзенең үзгәртелгән рәвеше).

Шуңа күрә татар-уйгыр телләре арасындагы андый күчешләрне аңлар, үзләштерер өчен беркадәре вакыт, күнекмә, әмма иң мөһиме — игътибар һәм хәтер кирәк. Фикеребез аңлашыла төшсен өчен бер-ике «җанлы» мисал да китерик. Уйгыр халык җырларыннан күз яшьләре образын гәүдәләндергән үрнәк алыйк:

*Аh урармән, аh урармән,*
*Аhләрим туткай сәни;*
*Күз йәшим дәрья булуп,*
*Бәликъләри жуткай сәни.*

(Аh орырмын, аh орырмын, аhларым тотсын сине; Күз яшьләрем дәрья булып, балыклары йотсын сине).

Кыскасы, гадәти төрки тел икән бу уйгыр теле. Димәк, узган гасырларда ук Шәркый Төркестанга барып чыккан милләттәшләребез әллә нинди ят халыклар арасына эләкмәгәннәр икән. Өстәвенә, Уйгырстанга күченеп киткән татарларның бер өлеше андагы казакълар арасында да яшәгәннәр. Казакъ теле исә безнең өчен тагын да аңлаешлырак.

## Һиҗрәт дулкыннары

Көзге җилләрдә сөрелеп, төп-төз кәүсәле урманнарыннан, зифа буйлы ак аналарыннан аерылып, әллә-кайларга, еракларга киткән яфраклар, орлыклар төсле чит илләргә һиҗрәт иткән-күченгән татарлар хакында (башка милләт вәкилләре турында да) бездә моңарчы бер дә язылмады диярлек. Язылган хәлдә дә, аларны бер мескен җаннар итеп сурәтләргә тырыштык. Йәисә аларның күпчелеген «илен саткан хаиннар», туган халкы «мәнфәгатенә төкергән сатлык җаннар» сыйфатында тамгаладык.

Бездә моңарчы ажгырып торган рәсми идеология позициясеннән чыгып хөкем йөртсәң, чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның бер өлеше, чыннан да, әлеге идеологияне-большевизмны кирс кагучылар, хәтта ләгънәтләүчеләр иде. Ләкин бер өлеше генә. Калган күпчелегенең, ул идеология белән исәп-хисаплары, алыш-бирешләре генә түгел, хәтта гадәти танышлыклары да юк иде. Әмма безнең тоталь идеологиябез аларның барысын да бер калыпка куып кертеп, туласы белән читкә типте, каһәрләде, кешелек хокукларын таптады. Шунысы белән ул, тоталитарлык фәлсәфәсе, үзенең гуманисызлыгын ачып салды. Моның шулай икәнлеген татарларның Шәркый Төркестанга күченү фактлары да тулысынча раслый.

Милләттәшләребезнең бу якларда күренә башлауларын, гадәттә, Голҗа шәһәре һәм Голҗа солтанлыгы яшәп калган 1864—1871 елларга нисбәт итәләр иде. Мәсәлән, кайбер язма истәлекләр һәм элек үзем ишеткән риваятьләр шулайрак аңлаталар иде. Ләкин «Татарларның кыскача тарихы» (ТКТ) исемле уйгырча китапта бу миграциянең 1917 елга кадәрге беренче чоры шактый дөрес һәм төгәл яктыртылган. Анда, мәсәлән, татарларның Үзәк Азиягә һиҗрәт итү процессы дүрт дәвергә бүлеп каралган (ләкин Октябрь революциясеннән соң башланган икенче чор, аңлаешлы сәбәпләр аркасында, бу китапта юньләп яктыртылмаган).

Беренче дәвер XIX гасырның 30 елларыннан башланган икән.

Мәгълүм булганча, патша Россиясендә татарлар милли, дини хокукларның һәммәсеннән, хәтта кайбер экономик мөмкинлекләрдән дә мәхрүм

ителгән иде. Мәгәр алар гаскәргә алыну, ягъни егерме биш ел солдатлыкта баш чертү — империя мәнфәгате өчен чит-ят җирләрдә кан коюо, шинельле хәлдә «себер сөрелеп» урман кисү, шәһәр-кальгалар салу һ. б. шуның нше мәҗбүри эшләргә тартылу «хокукы»на бугаздан гарык иделәр.

Татарларны рус патшалыгының администрациясе, кодрәтле чиркәве алып барган көчләп чукындыру, руслаштыру сәясәтс дә туктаусыз эзәрлекләгән. Моңа еш-еш кабатланып торган ачлык, җир җитмәү, үз җирләреннән кысрыклану — ул җирләрне рус-христиан алпавытлары тартып алу казалары да өстәлгән.

Менә шушы сәбәпләр аркасында аларның күпчелеге башкорт җирләренә, Түмән-Тубыл якларына таралган. Ләкин ул якларда да, колонизация процессы киң җәелү нәтиҗәсендә, тормыш һаман авырая барган. Социаль изү көчәйгәннән көчәйгән. Мондый коллыкка риза булмаган татар кешеләренең бер өлеше үзләре теләп «себер качкannар», казакъ сахраларына барып, кайбер очракларда казакъ булып язылып, күчмәннәр арасына сеңгәннәр. Ләкин патша хөкүмәте монда да аларны эзләп тапкан, казакъ түгеллекләрен раслап, хөкемгә тарткан... Тагын шинель, йәисә Себер сөрелү...

1830 елларда Казан-Уфа якларыннан ук гаскәри хезмәттән качкан Исмәгыйль, Баһаветдин, Шәрәфи, Хисаметдин дигән егетләр, берәм-берәм дәүләт чикләрен узып, Кытайдагы Алтай тауларына барып чыгалар. Болардан Исмәгыйль исемлесе елгыррак булганга охшый. Ул башта җирле казакъларның кирәй кабиләсеннән «кара кас» ыругы байларының берсенә «бала була» — аның малларын көтә; 1840 елда ул Кадича (Хәдичә) исемле казакъ кызына өйләнә. Асраурга алган «атасы» үлгәч, Исмәгыйль әлеге Баһавстдин, Хисаметдин һәм Шәрәфиләрне эзләп таба, аларны үз янына күчереп ала; аерым бер кечкенә авыл булып, Балбагай дигән җирдә яши башлыйлар.

Шулай итеп, Алтай якларына беренче булып килгән татарларның, хатыннары казакъ кызларыннан булуга карамастан, бәләкәй генә үз җәмәгатьчелеге оеша. Соңрак вакытларда килгән татарлар исәбенә аларның саннары ишәя тора. Шуңа күрә, Балбагайдагы авылга җирле казакълар «Нугай авылы» дигән исем бирәләр. 1885 ел тирәсендә үлгән Исмәгыйльнең каберен казакълар хәзергә кадәр «Ысмайыл нугайның муласы» дип атыйлар икән (ТКТ, 12—13 б.; мула — кабер дигән сүз).

XIX гасырның урталарына таба 1718 елда салынган Сими, ягъни Семипалатинск шәһәре тиз үсеп, анда сәүдә эшләре җанлана төшкәч, Алтай якларына татар сәүдәгәрләренең үтеп керә башлавына да шартлар туа. Сәүдәгәрләр белән аларның йомышчы «малайлары» да бергә йөриләр (басым ясалган сүзне хәтерләп калыйк). 1880 еллардан соң, хатын-балалары белән күченгән сәүдәгәрләрдән тыш, руханилык, бала укыту белән шөгыльләнеп җан асраучы кешеләр дә күбәя башлыйлар.

Шул рәвешчә 50—60 ел дәвамында шактый ишәйгән, XX гасыр башында, Иртеш дәрьясында пароход йөри башлагач, сан ягыннан бермә-бер арткан Алтай татарлары Иртеш елгасының төньяк буендагы Чиркечә дигән җирдә күпләп урнашалар. Шуңа күрә аларны хәзер «Чиркечә татарлары» дип тә атыйлар (ТКТ, 15—17 б.).

Оешу, утраклашу һәм күбәю тарихлары шактый үзенчәлекле булган алтайлы татарларның көнкүрешләре, гореф-гадәтләре белән телләре дә гыйбрәтле эволюция кичерә. Хәер, бу хакта сүз алга таба булыр.

* * *

Икенче дәверне ТКТ авторлары хаклы рәвештә 1851 елдан башлыйлар (13—14 бб.). Чөнки шул елны Россия хөкүмәте белән Кытай императорлыгы арасында «Элә-Чүгүчәк сәүдә килешеме» төзелә. Бу килешем икс як өчен дә — коррупция сазлыгына батудан һаман акча җиткерә алмаган кы-

тай хөкемдарларына да, экономикасы капиталистик мөнәсәбәтләренә күчә башлаган Рус патшалыгына да файдалы була. Бигрәк тә соңгысы өчен, чөнки Төркестан киңлекләрендәге очсыз авыл хуҗалыгы, терлекчелек чималларына ачкыч табу аерата мөһим иде. Һәм нәкъ менә шушы юнәлештә татар сәүдәгәрләре өчен дә зур мөмкинлекләр ачыла.

Белгәнебезчә, Рәсәйнең үзәк өлкәләрендә мөмкинлекләре нык чикләнгән, патша администрациясенең ярдәменә таянган рус капиталистлары белән ярыша алмаган татар сәүдәгәрләре XVIII йөзнең башларында көнчыгышка таба йөз бора, шул гасырның урталарында казакъ сахраларына, Урта Азия ханлыкларына үтеп керә башлый. Җирле халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен тиз үзләштерү мөмкинлегенә ия, кирәге чыкса, урысча да сукалый алган татар кешеләренә, шартлар таләп итсә, алар арасында «чумып китү», аннары тагын «калкып чыгу» кыен түгел иде.

Мәсьәләнең бу ягын тоеп алган патша хөкүмәте булдыклы татар кешеләрен Россиянең тышкы сәүдәсенә активрак җәлеп итү чаралары күрә башлый. Мәсәлән, 1744 елда Оренбург шәһәре янына махсус татар бистәсен оештыруга рөхсәт бирү, 1745 елда Саба ягыннан Сәгыйть Хәялин җитәкчелегендә күченгән бер төркем татарларның Каргалы суы буенда зур гына авыл, хәтта соңрак Сәгыйть бистәсе йәисә Каргалы исемендә дан казанган кечкенә генә бер шәһәрчек төзеп җибәрүләре шуның нәтиҗәсе иде. Бу бистәдән чыккан кыю сәүдәгәрләрнең Иран һәм Әфганстан җирләренә, хәтта ерак Һиндстаннарга кадәр барып сату итү фактлары мәгълүм. Мәсәлән, XVIII йөзгә караган мәшһүр «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» шундый бер сәфәр нәтиҗәсендә туган истәлек. (1751 елны Сәгыйть Хәялин оештырган махсус сәүдә кәрваны белән биш татар кешесе Бохара аркылы, Әфганстанны узып, Һиндстанга җитәләр. Регионда зур сугышлар башланып, алар килгән юллары белән илләренә кайта алмыйлар. Диңгезләр кичеп, Гарәбстан, Төркия аркылы кайтырга булалар. Бер-бер артлы юлдашларын югалтып, ялгызы гына калган Исмәгыйль Бикмөхәммәт угылына сөекле Каргалысына кайтып җитәр өчен утыз ел чамасы вакыт кирәк була... Кайткач ул үзенең әлеге «Сәяхәтнамәсен» яза.)

Шул рәвешчә, XVIII гасырның икенче яртысында бик тиз тернәкләнеп, казакъ сахраларын, Урта Азия шәһәрләрен «үзләштерүдә» гаять зур активлык күрсәткән татар сәүдәгәрләре XIX гасыр башында Казагыстанның көнчыгыш чикләрендә, мәсәлән, административ үзәге элек Семипалатинск кальгасе булган Җидесу өлкәсендә дә күпләп тарала, урнаша башлыйлар. Семипалатинск — казакъча Сэмэй, үзбәкчә Шәмәй, татарча Сими — шәһәре шул регионның эре сәүдә үзәгенә әверелә. Монда Россия, Урта Азия һәм Кытай дәүләтенең сәүдәгәрләре, мал-товарлары очраша.

Татарлар, Сими шәһәреннән кала, Кытай чигеннән ерак булмаган Бахты, Аягуз, Өрҗар, Аксу, Капал, Ләпсе, Өч Арал, Талды Курган, Җаркәнт (хәзерге Панфилов) дигән җирләрдә дә күпләп урнашалар, аннары Верный — Алма-Ата ягына да елышалар.

Бу урында Сими шәһәреннән башлап, Алма-Ата (элекке Верный төбәкләренә кадәрге, Балхаш күленең көнчыгышындагы, киң дөньяны эченә алган Җидесу (русча әдәбиятта: Семиречье, шуннан — Семиречинская область, хәтта Семиречинский край) яклары турында да берничә сүз әйтергә кирәктер.

Көнчыгыш Алтай һәм Җоңгар таулары, көнбатышы бөек казакъ далалары һәм комлы чүлләр белән аерылып, Төньяктагы Себер киңлекләрен Урта Азиягә кушып торучы бу җирләр табигатенең байлыгы, төрлелеге җәһәтеннән кабатланмый торган бер дөньяны тәшкил итә. Бигрәк тә Өрҗар белән хәзерге Талды-Курган арасындагы сөзәк тау итәкләре үзләренең табигый байлыгы, күркәмлеге ягыннан аерылып тора. Алкын сулы үзәннәре аның шау чәчәкле болыннарга, төрле җиләк-җимешле үсемлекләргә бай. Арасына кереп киткән куй-кәҗәләр күренмәслек печәнлек-

ләрен әйтәсеңме, йодрык-йодрык кадәре булып үсә торган кыргый алмалары, өрекләре, карлыган-кура, сырганак куаклыклары белән җир җиләкләре дисеңме...

Җиләк-җимеш дигәннән, бер гыйбрәтле мәзәк искә төште. Кайчандыр Сембер якларыннан чыккан, азмы-күпме сәүдә белән шөгыльләнгән, аннары бөлгән бер агай үзенең күптән түгел килеп, игенчелек белән шөгыльләнә башлаган кардәшенә: «Әллә, быратым, туган якларга кәтеп китәбезме?» — дип эндәшкән, ди. Кибеп өлгергән алма какларын таслап утыручы туганы: «Што син, әллә мине дурак дип беләсең? Монда, ичмаса, йир алмасы булмаса да, ходай тәгалә биргән багалмасы йитәрлек!» — дип, тәкъдимне кире каккан ди.

Әйе, Рәсәй якларыннан каңгырып килгән руслар, татарлар бу якларда җиләк-җимеш җыю, киптерү, как кою, ашаганнан артканын сату белән дә шөгыльләнгәннәр.

Иртә килә торган яздан алып, озын җәйнең ахырынача шау чәчәктә утыра торган тау үзәннәрендә бал кортлары үрчетү, умартачылык белән шөгыльләнү өчен дә идеаль шартлар булган.

Бу якларның табигый муллыгын тиз бәяләп өлгергән читтән килмеш халыклар арасында шундый бер миф та туган. Имештер, ходай тәгалә җир йөзен яраткан чакта, бу Җидесу якларын онытып, бөтенләй буш калдырган. Аннары, үз хатасын төзәтер өчен, тегеннән-моннан йолку исәбенә дигәндәй, әлеге бушлыкны капларга тырышкан. Һималай һәм Кавказ якларыннан — таулар, Караком вә Урта Азиядән чүлләр белән бакчалар: Себердән исә күлләр, салкын сулы елгалар, урманнар китерә-китерә әлеге бушлыкны «ямап» бетергән...

Мондый иркен, табигате төрле һәм бай җирләргә килеп утыручылар игенчелек, терлекчелек, умартачылык белән шөгыльләнүдән тыш, сәүдә эшләренә дә зур игътибар бүлгәннәр. Җир сукаларга, урак урырга көчләре җитмәгән, сәүдәдән файда табарлык «хәйләли» алмаганнары аучылык, балыкчылык белән ризык аерган. Малга тигән бүредән, матур тиреле төлкедән гайре киекләргә казакъларның артык исләре китмәгән. Җирле халык балык тотып ашау белән дә мавыкмаган, ягъни көндәш-конкурентлар юк диярлек — беркайчан да ачтан үлмәскә тырышкан кеше. Ә инде боларын да эшли алмаган «булдыксызлары» (хатын-кызлар телендә: «җебегән»нәре) «мулдакәлек» иткән, бала укыткан — үзләренә җитмәгән белемнәрен сатып көнен күргән.

Казакъ арасында сәүдәдән табыш алу артык кыен булмаган. Шулай да аңа тотынган кешедән зур җитезлек, тапкырлык, әрсезлек соралган. Асылда татарлар, үзләре җитештергән мал-мөлкәтне сатудан бигрәк, зур капиталлы руслардан күтәргә алган товарларны, гадәттә, кызыл-малны һәм чәй-шикәрне казакълар арасында терлеккә, тире, йон, эчәге ише терлекчелек чималына алыштырганнар. Җыелган терлекне, зуррак базарларга илтеп сатканчы, беркадәре асрарга, чималны исә эшкәртергә — киптерергә, тозларга, тасларга, йөк-йөк итеп бәйләргә, аннары арбаларга төяп илтергә, сәүдәләшә-сәүдәләшә сатарга кирәк булган. Мондый «операция»ләрнең берсе очлануга, икенчеләре башланган — гел хәрәкәт, өлгерлек, җитезлек таләп ителгән.

Эшләре гөрләп алга киткән, баеган зур сәүдәгәрләр әллә кайлардагы Куянды, Каркаралы, хәтта ерак Уралдагы Эрбет йәрминкәләренә кадәр көтү-көтү мал кудырган, арба-арба йон-җабага, тире-тирсәк ташыткан. Кире кайтканда ул арбаларга кызыл мал, чәй-шикәр төялгән.

Бер ише сату-алу эшләре табыш китергән, икенчеләре зыян биргән. Табыш зыянны басса, откан татар агае; киресенчә булса, отылган-бөлгән, банкрот булган. Үзе садә күңел, бер бишмәтлек тукымага, күлмәклеккә, йәисә инә-җепкә мохтаҗ казакъның сарыгын, танасын арзанрак алып файда күрсә, аның үзен Симидә, Умбыда (Омскийда) зур корсагын сыйпап утыручы җирән сакаллы «кяфер пабрикант» төп башына утыртырга тырышкан.

Мондый өзлексез һәм тынгысыз хәрәкәткә — тизлек һәм тәвәккәллек, тәҗрибә һәм тапкырлык сорый торган бимазалы кәсепкә куплэр түзмәгән. Чөнки чын сәүдәгәрлек, кайберәүләр уйлаганча, эшләмичә генә керем алып ята торган гадәти спекуляция генә түгел, бәлки биниһая зур энергия, эзлекле хезмәт сорый торган катлаулы кәсеп тә ул. Шуңа күрә Җидесу якларында утраклашкан татарларның купчелеге һөнәрчелек, игенчелек белән дә шөгыльләнгәннәр. Мондый кәсепләр арасында умартачылык эше дә күренекле урын тоткан.

* * *

Умартачылыкка караган бер хосусый материалларга, дөресрәге, үземнең бабаларым тормышыннан кайбер фактларга мөрәҗәгать итүне кирәк табам.

Әтиебезнең әтисе Габделбари, аның атасы Габделмөэмин, аның атасы Әхмәр, аннары Гомәр, Госман, Ярмөхәммәд, Илмөхәммәд, Ильяс, Хәсән. Болардан Гомәр һәм аның балалары 1810—20 еллар тирәсендә җир азлыктан интегеп, Казан артындагы Олы Мәңгәр авылыннан Яңа Тазлар (хәзер Байкал авылы, Арча районында) ягына күченеп китәләр. Аннары, күп тә узмый, казакъ якларына, дөресрәге, Кызылъяр (хәзерге Пертопавловск) тирәсенә барып чыгалар.

1971 елда Олы Мәңгәрдә табылган шәҗәрәдә мондый юллар бар: «Бу Госманай бабаның балалары (шушы шәҗәрә белән безнең нәсел язуында олырак бабаларыбызның исемнәре абсолют тәңгәл — М. Г.) Яңа Тазларга, аннары Кызылъяр якларына киттеләр, дип ишеттек. Башка хәбәремез юк». Тик, монда да озак юанмыйлар алар — Симигә кадәр барып җитәләр. Симидә чакта Габделмөэмин баба сәүдә эшләрен көйләп җибәрә, бераз хәл алгач, көньяккарак елышып, хәзерге Талды-Курган өлкәсенә керә торган Өч Арал һәм Андреевка якларына килеп урнаша, шунда казакълар арасында сәүдә белән шөгыльләнә. Шул елларда салынган Ләпсе каласында кибет ача.

Габделмөэмин баба эшлекле, энергияле кеше булганга охшый, вак сәүдә белән генә чикләнми. Өч Аралдан ерак түгел тау эчендәге Җыланды дигән бер үзәндә руслардан арендага җир алып, умартачылык эшләрен дә башлап җибәрә. Бал кортлары үрчеп, оя башлары күбәйгән, хуҗасының үзе дә яхшы ук хәлләнгән елларның берсендә, балдан искитәрлек мул уңыш җыела. Бер кышта Сими шәһәренә өч-дүрт чана бал илтеп саткан Габделмөэмин шактый күп акчага ия, дөресрәге Симидән шул акча исәбенә алып кайткан дүрт-биш чана кызыл малга хуҗа кеше буларак язны каршылый.

Китә шуннан сәүдәләр гөрләп! Умарта эшләрен тагын да үстереп җибәрергә ниятләгән Габделмөэмин ага вакытлы арендага алган умарталык җирләрен үз милкенә күчерү чараларын эзли башлый. Һәм таба хәйләсен: җир хуҗасы булып исәпләнгән рус җәмәгатьчелеге белән сөйләшеп, аларга юл салдырып бирергә, шуның исәбенә умарталык җирләрен 99 елга арендага алу хакында килешүгә ирешә. Һәм шулай эшли дә ул. Моның хакта Корбангали Халиди язмаларында да мәгълүмат теркәлеп калган. Аны төгәле белән күчерик: «Габделмөэмин ага Ләпсәви. Бу зат Ләпсе билдәсенең (шәһәренең — М. Г.) ибтидасында (башлануында — М. Г.) 1855 нче елда сәүдә берлән килеп истикамәт итмеш. Мәзкүр (әлеге — М. Г.) шәһәрнең байларындан вә игътибарлы, нөфүзле (абруйлы — М. Г.) адәмләрендән иде. Шәһәрнең мәүкыйгы (торган җире — М. Г.) тагъ эчендә улмакла юллары гаять сәгъәб (кыен — М. Г.) вә агыр улдыкдан, бу зат шул кыен юлларны үз хәраҗәте берлә төзәттереп гаммәйә (күпчелеккә — М. Г.) бөек мәнфәгать килтердекечен ул шәһәр руслары бу затә (затка — М. Г.) умарталык йир виреп вә һәм губернатордан тәкъризнамә (мактау грамотасы — М. Г.) аттестат һәм алмыш иде».

Юл салу факты, әлбәттә, Жыландыдагы умартачылык эшләренең гөрләп алга китүенең нәтиҗәсе. Махсус рөхсәт белән җир бирү мәсьәләсенә килгәндә, аның гыйбрәтле тарихы бар. Ул казакъ җирләренә килеп урнашкан татарларга җир-су, йорт-бина кебек күзгалмый торган милек алу хөкүмәт тарафыннан тыелган булудан гыйбарәт. Үз җирләреннән кысрыкланып чыгарылган татарлар, шулай итеп, монда да тулы хокуктан мәхрүм иделәр... Шуңа күрә бу якларга килеп хәлләнгән татарлар үз йорт-җирләрен ришвәт бирү исәбенә бирәр «урыс яки хахул» кешесенең исеменә яздырып, аннан 99 еллык «арендага» ала торган булганнар. Габделмөәмин баба исә, китерелгән документтан күренгәнчә, җирне күп елларга үз милкенә алуның шактый оригинал юлын тапкан икән.

Габделмөәмин бабаның сәүдә эшләренә актив тотынуы 1840 елларның ахырларына туры килгән булса кирәк. Чөнки аның хәзер миндә саклана торган мөһер йөзегендә «Габделмөәмин бине Әхмәр. 1852» дип уелган язу бар. Йөзек кебек бармакка киеп йөртә торган мондый мөһер сәүдә вакытында эш кәгазьләренә шәхси имза рәвешендә сугылган. Кайбер хәбәрләргә (гаилә риваятьләренә) караганда, Габделмөәмин бабай һәм аның улы Габделбари ара-тирә сәүдә эшләре белән Кытай чигендәге Бахты шәһәрчегенә, аны узып Чүгүчәккә дә баргалаган...

Китерелгән шәҗәрә материалы — гаилә истәлеге — XIX йөзнең беренче яртысында Җидесу якларына барып урнашкан, шунда сәүдәгәрлек кәсебенә дә керешкән татарлар тормышыннан бер кызыклы мисал гына, әлбәттә. Шулай да мондый фактлар Җидесу өлкәсендә яшәүче татарларның XIX йөз уртасында ук Кытай империясе карамагындагы Шәркый Төркестан белән сәүдә мөнәсәбәтләренә катнашуына үрнәк була алалар.

* * *

Хәзер югарыда телгә алынган 1851 елгы «Элә-Чүгүчәк сәүдә килешемен» искә төшерик. Алда ул договорның буш җирлектә генә барлыкка килмәгәнен күрербез. Чөнки рәсми килешү гамәлгә кергәч, традицион сәүдә эшләре аерата җанланып китә. 60 нчы елларның башында Элә өлкәләренә сәяхәт ясаган атаклы тюрколог В. Радлов Җидесу өлкәсенең төрле җирләреннән Чүгүчәк һәм Голҗа шәһәрләренә барып кайтучы, ул яклардан төрле мал китерүче татар сәүдәгәрләрен еш очрата (В. Радлов. Из Сибири. М., 1889, 73—79 бб.). Һәм монда гаҗәпләнергә урын юк. Мәсәлән, шул ук Радловның сүзләренә караганда, бу вакытларда Аягуз (Сергиополь) шәһәрендә халыкның өчтән берен татарлар тәшкил иткән. Әгәр руслардан бер генә кеше алу-сату белән шөгыльләнсә, татарларның һәммәсе дә сәүдәгәрлек иткән (75—76 бб.). Шуны да өстәргә кирәк, халыкның шактый өлеше татарлардан торган андый яңа шәһәрләр Җидесуда унга якын иде.

1858 елда «әндиҗанлы» сәүдәгәр кыяфәтендә Кашкарга барып, разведка мәгълүматлары туплап кайткан Ч. Вәлиханов та, Алты шәһәр якларына сәфәр тотучы, андагы калаларның базарларында буй-буй җилән-чапаннар кигән, «әндиҗанлылар» сыйфатында алу-сату эшләре белән шөгыльләнгән татарларны очраткан (Чокан Валиханов. Избранные произведения. Алма-Ата, 1958, 445, 447, 450, 460, 493 бб.).

«Элә-Чүгүчәк сәүдә килешеме»ннән соң азмы-күпме җанланып киткән һиҗрәт процессы югарыда телгә алынган 1881 елгы «Санкт-Петербург шартнамәсе» төзелгәч тагын да көчәя, хәтта рәсми төс ала. Шәркый Төркестанның күп кенә шәһәрләрендә, иң элек Чүгүчәк һәм Голҗаларда рус консуллыклары ачылу шуның нәтиҗәсе иде.

Һәрхәлдә, XIX йөзнең 90 нчы елларында Алтайдагы Чиркчe төбәгендә генә түгел, Чүгүчәк һәм Голҗа шәһәрләрендә махсус мәхәллә-кавем рәвешендәге татар җәмәгатьчелекләре барлыкка килә. Һәм мондый процесс гасырыбыз башында аерата көчәйгән булырга охшый. Мәсәлән, шул еллар

да Жаркәнттән (Панфиловтан) Голҗага шактый хәлле кешеләрдән Фазылҗан Юнич, Сабирҗан Аллаһъяри гаиләләре күчеп килү шуны раслый. (Болардан Фазылҗан Юничны хәтерләп калыйк. Аның атасы Хәйрулла узган гасыр урталарында Петербургта яши, аннары, нииндидер бер эш белән, Фәрганәгә килеп урнаша. Рәсәйдә чакта Юнусов фамилиясен йөрткән кеше үзбәкләр арасында, ни өчендер, Юничкә әверелә. Хәйрулла Юничнең олы улы Жаркәнткә килеп, байларга яллана. Шул байларның эше белән Голҗага күчә, шунда урнашып кала. Тиздән Фазылҗан Юничны җирле татар җәмәгатьчелегенең башлыгы — аксакалы итеп билгелиләр. Һәрхәлдә, Голҗага Габдулла Буби килгән чакта Фазылҗан аксакал татарлар арасындагы иң йогынтылы кешеләрнең берсе була.)

Шулай бергә җыелган, күбәйгән халыкның үзләренә аерым мәчет-мәдрәсә, димәк, имам һәм хәлфә-мөдәррисләр булдыру ихтыяҗлары да туа башлый. Теге «мулдакәлек» итә-итә монда кадәр килеп чыгучылар гына җитми монда. Татарның үзенә мулла́ның чын «бохарые», хәлфә-мөгаллименең исә, Истанбул булмаса, иң кимe, Казанда укыганы кирәк! Шул ихтыяҗларны үтәр өчен иң элек Чүгүчәк һәм Голҗа җәмәгатьчелеге... Ярар, бу хакта үз урынында тәфсиллебрәк сөйләрбез әле.

* * *

Өченче дәвер. ТКТда «Өченче һәм дүртенче» дәверләр сыйфатында 1905 һәм 1914 еллардагы соңгы һиҗрәт дулкыннары күрсәтелә (14 б.). Минемчә, боларның икесен берләштереп, өченче дәвернең кысаларын 1905—1917 еллар белән чикләргә һәм Шәркый Төркестанга татар һиҗрәтенең беренче чорын шунда тәмамларга кирәк.

Бу дәвернең иң характерлы сыйфаты рәвешендә, элеккечә эреле-ваклы сәүдәгәрләрнең, бәхет эзләүче ярлы-ябагайлар белән һөнәрчеләрнең, малайлыкка ялланган яшьләрнең килүләре дәвам итүдән тыш, интеллектуаль шәхесләрнең дә күренгәләвен атарга кирәк. Алар үзләре белән 1905 ел революциясеннән соң күпләп чыга башлаган татарча гәзит-журналларны, дөньяви китапларны да, азатлык өчен көрәш идеяләре белән милли уяну хисләрен дә мул итеп алып киләләр. Араларында каләм осталары да, фикер ияләре дә була. Аларга ияреп, җәдитчелек белән кадимчелек көрәшләре дә килә Шәркый Төркестанга. Бигрәк тә Чүгүчәк һәм Голҗа шәһәрләрендәге татар җәмәгатьчелекләре күзгә күренеп үзгәрә, яңара башлый.

Бу дәвернең тагын бер характерлы ягы итеп, иң элек Голҗа, Чүгүчәк кебек нисбәтән зуррак шәһәрләргә җыелган татарлардан яңа «үрентеләр» үсеп, Өремче, Дөрбеҗен, Торфан, Кашгарише башка төбәкләргә дә күченә, тарала башлавын күрсәтергә кирәк.

Беренче чорның соңгы дәверенә хас сыйфат итеп, тагын аннан калган татарча язма истәлекләрнең дә шактый муллыгын күрсәтергә мөмкин. Әйтик, озак еллар Чүгүчәктә яшәгән Корбангали Хәлидинең «Тәварихы җәридәи җәдидә», «Тәварихы хәмсәи шаркыйә» исемле басылып чыккан китапларыннан тыш, Казагыстандагы Җидесу өлкәсе татарлары, Чүгүчәк һәм Голҗаларда яшәүче милләттәшләре хакындагы бай эчтәлекле кульязмасын да махсус атарга кирәк.

Шул елларда Казанда, Оренбургта татарча чыккан гәзитә-журналларда «Голҗадан» йәисә «Чүгүчәктән» дип басылган кыскача хәбәрләр, хатлар да шактый. Шәркый Төркестанның күп өлешен, бигрәк тә Кашгар якларын гизгән сәяхәтчебез Нәүширван Яушевнең күп санлы мәкаләләре, «Шура» журналы белән «Вакыт» гәзитәсеннән тыш, Урта Азиядәге төркичә вакытлы матбугатта да дөнья күргән. Шушы елларда Голҗа шәһәрендә булып кайткан Габделгазиз Монасыйпов «Таранчы кызы Җинәстәхан» исемле матур повесть яза.

1913—1917 елларда Голҗада яшәгән олы мәгърифәтчебез Габдулла Бубиның язмалары үз алдына бер байлык...

Ниһаять, революциягә кадәрге елларда Голҗа һәм Чүгүчәк шәһәрләрендә рус халкының саны да шактый ишәюне билгеләп үтү зарур. Әгәр элек рус милләтенең вәкилләре консуллыктагы чиновниклардан, йәисә Россиядәге рәсми дини политикага протест күрсәтүче баптист һәм староверлардан гына гыйбарәт булган булса, гасыр башында алар сан ягыннан кечерәк мәхәллә кыяфәтен ала язганнар иде.

70—80 еллык төгәл бер чорның йомгагы булган шушы дәвер хакында сүзне махсус искәрмә белән очлыйсы килә. Билгеле булганча, Совет хөкүмәте бөтен гомер буена диярлек чит илләрдәге ватандашларыбызның һәммәсе турында, җөмләдән Шәркый Төркестанда яшәүче милләттәшләребез хакында да, белүне булдырмаска омтылды, аларга бәйле истәлекләрне халкыбыз хәтереннән куып чыгарырга тырышты. (Сүз уңаенда бер кечкенә истәлек. 1959 елда «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре Рәшат Гайнанов тәкъдиме буенча «Голҗа татарлары» дигән бер кечкенә мәкалә язган идем. Рәшат абый аны шактый тарап, «сөннәтләп» бетергәч кенә бастырды. 80 нче елларның урталарында журналның элекке баш редакторы Асия ханым Хәсәнова бер очрашуда, инде картая да башлаган «авторы» белән узган елларны искә төшерде: «Беренче мәкалә бастыруыгызны да хәтерлим. Ул чыгуга ук өлкә комитетында: «Башка материаллар тапмадыңмы?» — дип, өстәл сугуларын әле дә хәтерлим...» Әйе, бар иде андый чаклар.) Әмма, моңа карап кына 1917 елга кадәр үк ул якларда җыелган милләттәшләребез, киресенчә, ватандарлык хисләрен бер дә җуймадылар. Чөнки алар һәрвакытта да үзләрен Россия дәүләтенең гражданнары дип хис иттеләр. Моны раслый торган бер документка мөрәҗәгать итик. Мәсәлән, 1917 елда, патша тәхеттән бәреп төшерелгәч, Голҗадагы татарлар, үзбәкләр һәм казакълар җыелышып, Дәүләт Думасына мондый телеграмма күндерделәр:

*«Председателю Государственной Думы Родзянко, Председателю Мусульманской фракции Тевкелеву.*

*Получив известие о перемене правительства дорогой нам родины, мы, русские мусульмане, волею судьбы (заброшенные) в далекий Китай, были безгранично обрадованы. Веря отныне в светлую будущность дорогого отечества, спешим выразить свою готовность пожертвовать всем, что имеем, для блага родины и молим Всевышнего благословить столь великое начинание избранников народа, истинных сынов матушки России и борцов за ее светлое будущее и свободы ее сынов.*

*Уполномоченные: имам Фатхутдинов, Касымджон Юлдашев, Низамутдин Фаткуллин, Ситдик Ювашев, Кенесбай Ушбетбаев «(ЦГИАЛ СССР, фонд 1278, оп. 5, № 1338, л. 17).»*

Документка кул куйган биш кешенең өчесе татар, берәрдән үзбәк һәм казакъ булулары да игътибарга лаек: телеграмма аерым шәхесләрнең генә инициативасы белән тумаган икән.

Шулай ук соңгырак дәверләрдә Шәркый Төркестан җирләрендә революцион фикер таралуга да анда яшәүче Россияле кешеләрнең, җөмләдән татарларның да, өлеш кертүләре бәхәссез. Һәм болар ул якларга шул беренче чорда һиҗрәт иткән кешеләр иде. Шулай итеп алар дөрес эшләгәннәрме, ялгыш ясаганнармы — монысы бөтенләй башка мәсьәлә. Сүз бирсдә факт турында гына бара.

Ул яктагы татарларның совет тәртипләренә, коммунистик фәлсәфә белән большевизмга тискәре мөнәсәбәттә торучылары да бар иде, әлбәттә. Алар, нигездә икенче чор һиҗрәт дулкыннарының вәкилләре иделәр.

* * *

Бу икенче чор хакында ТКТда бөтенләй әйтелми диярлек. 1914 елдан башланды дип күрсәтелгән «дүртенче» дәвер хакында язылган бер җөмләнең икенче өлешендә генә түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «вә үктәбер инкыйлабы гъәләбә казанганнан соң йәнә бер төркем вак милек ияләре, һөнәрчеләр, сугыш буталчыклыклары сәбәбеннән Шенҗаңга күчеп килде» (14 б.). Мондый «аңлатма»ны аклап булмаса да, аңлап була, әлбәттә. 1988 елдагы Кытай шартларында башкача язып та булмас иде. Чөнки анда да, коммунистик идеология хөкем сөргән барлык илләрдәге кебек, «кешелек тарихындагы иң бәхетле җәмгыятьне төзүче» дәүләтләрдән качучы булмаска тиеш. Ә «булмаганны», билгеле, язып та булмый.

Трагик эчтәлеккә ия икенче чор һиҗрәте үз нәүбәтендә ике зур дулкыннан гыйбарәт.

Беренче дулкын 1917—1919 елларга туры килә. Бу елларда, мәгълүм булганча, Казагыстанда революцион көрәшләргә Гражданнар сугышы да ялганып киткән иде. Авыл-шәһәрләрне бер көн кызыллар алса, икенче көнне аклар яулый. Кайбер торак пунктлары дүрт-биш мәртәбә йә тегеләр, йә болар кулына күчә. Алары да, болары да ашамыйча, эчмичә торд алмыйлар, билгеле. Мәшһүр «Чапаев» киносындагы зур сакаллы Урал казагының: «Белые приходят — грабят, красные приходят — грабят...» дип сукранганы шикелле. Гомер буе тырышып җыйган мал-мөлкәтнең талануы, хатын-кызларының көчләүне «киләчәк буыннарның бәхете өчен» икәнлеген аңламаучы «аңсызлар» да була, табигый...

Чик буена якын яшәүче халыкларның, җөмләдән татарларның да бер өлеше, дөньялар тынычланганчы, яңадан тәртипләр урнашканчы дип, чикнең теге ягына чыгып, шау-шулар басылганны көтеп тору ягын чамалый. Бигрәк тә хәлле кешеләр — милек ияләре... Нәкъ шушы төштә тагын гаилә истәлекләренә мөрәҗәгать итү зарур булыр.

* * *

Әйткәнемчә, Габделмөэмин бабай XIX гасырның икенче яртысына шактый зур умарталык хуҗасы, өстәвенә эшләрен уңышлы гына җайлап җибәргән хәлле сәүдәгәр буларак кирә. Ләкин күп тә узмый, ул тәмам бөлә яза. Эшләр көйле чакта кырдагы сәүдәләрне алып барган улы Габделбари байбәтчә дә соңгы вакытларда үзенә тапшырылган хуҗалыкка җитәрлек күңел бирми, бәлки яхшы ат менеп, кулына думбыра алып, казакъ авылларында ил кыдыру, җыр-үләң, кымыз мәҗлесләрендә гомер уздыру белән мавыга. Казакъның ул яклардагы акыннары, мәшһүр үләңчеләре белән аралаша, аерата Әсәт акын белән дуслаша. Хатыны үлеп, ике баласы ятим калгач кына Габделбари байбәтчә яңадан җиң сызганып эшкә тотына. Вакытында чит-ятларда сибелеп калган бурычларын җыя, умартасын яңарта, әлеге рус исеменә язылган йортын, кура-каралтыларын төзәтә.

Монда, бәлкем, яшь хатыны Бибизаһидәнең дә (Ләпселәге Хөсәен хәзрәт кызы) өлеше зур булгандыр, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, ике балалы тол иргә кияүгә чыккан, аннары үзе дә бер-бер артлы сигез-тугыз бәби тапкан, шулардан алтысын, элекке анадан калганнары белән исәпләсәң, сигезен зур үстергән бу әбиебезне — Өлкән әнине мин яхшы хәтерлим (миңа унбиш яшьләр вакытында машина авариясеннән үлгән иде ул). Теләсә кемне үз ихтыярына буйсындыра ала торган шушы Заһидәгә өйләнгәч, дүрт-биш мәртәбә Симигә дә чана-чана бал ташыгач, болай да көчле, кырыс характерлы Габделбари бабайның эшләре йәнә гөрләп алга китә. Гасыр башында инде ул зур-зур кибетләргә, көтү-көтү җанлы малга ия бай сәүдәгәр — икенче гильдия купец була. Элеккедән (теге думбыралы еллардан) килә торган җилбәзәк «байбәтчә» титулын үзгәртү ниятеннән ул хаҗ-

га барып кайта — Габделбари (казакълар арасында: Апарый) байбәтчәдән шул рәвешчә Габделбари хаҗига — Апарый каҗыга әверелә.

1917—18 еллардагы әлеге «бер аклар, бер кызыллар» вакытында, айлар буе тәрәзәләрен мендәр белән томалап, кибет малларын яшереп, буй җиткән кызларын, яшь киленнәрен идән астына качырып гомер уздырудан туеп беткән. Апарый хаҗи да бер карарга килә. Сугышлар тынып торган арада ике чанага сигез-тугыз баласын, орчык кадәре карчыгын, тагын икеөч чанага кисм-салым, түшәк-урыннарын төяп, йорт-җирен яхшылап бикләп, Бахты аркылы Чүгүчәккә чыга. «Дөньялар рәтләнгәнче» андагы танышларында торып тору нияте белән.

Тик, айлар-елллар үтүгә, дәүләт чиге генә «тынычлана», ягъни тәмам ябыла. Шул рәвешчә, кайбер өй җиһазлары белән терлек малларын гына чыгарып өлгергән Габделбарый хаҗи Госманов гаиләсе, илгә кайта алу мөмкинлегеннән бөтенләй өмет өзеп, Чүгүчәктән тормыш өчен җайлырак дип исәпләгән Голҗа якларына күченеп китә...

* * *

Әлбәттә, 1917—18, хәтта 1919 елларда шул рәвешчә Җидесу өлкәсенең Сими, Аягүз, Капал, Җаркәнт (хәзерге Панфилов), Верный (Алма-Ата) иште шәһәрләреннән, бигрәк тә чик буендагы күпләгән авылларыннан вакытлыча, «бәлшәүик бәласе үткәнче» генә дип, тегге якка чыгып калучылар бер Апарый хаҗи гаиләсе генә булмый. Сөйләнгән истәлек бер мисал — иллюстрация генә. Җидесу якларындагы татар байларының шактый өлеше менә шушы елларда үзләре өчен ят булмаган Шәркый Төркестан якларына барып эләгәләр. Бу дулкында ярлы-ябагайларның, хәтта урта хәллеләрнең качып чыгулары бөтенләй күзәтелми диярлек.

Дулкынны кызыллардан тәмам җиңелгән акларның күпләп, полк-полклары, төгәл дивизияләре белән качып чыгулары тәмамлый. Мәсәлән, атаман Анненков, атаман Дутов армияләренең өлешләре. Боларның күпчелеге гаиләләрен дә алып чыгалар. Нәкъ шушы дәвердән Чүгүчәк, Алтай һәм Голҗа якларында рус халкының саны күзгә күренеп ишәя. Араларында берән-сәрән, вак-төяк татар офицерлары да, Казан-Уфа якларында патша армиясенә хезмәткә алынган татар солдатлары да булган. Ләкин күп түгел.

Минемчә, Шәркый Төркестан җирләренә 1917 елдан соң бәреп чыккан шушы беренче дулкынның икенче өлешен генә чын-чынлап ак эмиграция дип атап була (беренче өлеше җан тынычлыгы, милек иминлеге эзләүче, сәясәт-мазарны тәмам аңлап бетермәүче гади качаклар гына иде).

Голҗа, Чүгүчәк якларына килеп чыккан ак эмиграция дулкыны өч-дүрт ел эчендә бөтенләй диярлек «эреп» бетә, хәрби көч булудан туктый. Вак-төяк халкы сәясәт-мазарга кул селтәп, авыл хуҗалыгы, һөнәр эшләренә тотына, «эрерәк кошлары» эчке Кытайга, ак эмиграциянең зур көчләре тупланган Манҗурия якларына китеп бетә. Әтинең сүзләрен һаман хәтерлим: «Алтын погоннары искереп, хәрби кительләре тузып беткәнче йөрделәр монда ул генераллар, полковниклар. Урам чатларында җыелышып, гел Рәсәйгә кайтачаклары турында сөйләшәләр иде. Аннары, никтер, юкка чыгып беттеләр».

Шуны да истә тотарга кирәк. Шушы ак эмиграция дулкыны белән ул якларга Дзержинский мәктәбен узган, ахыргача шул иманнарына тугрылыклы булып калган егетләр дә чыгып калалар. Әйтик Голҗа тирәләрендә бер мунчада ак генерал атаман Дутовны суючы кешене мишәр морзалары нәселеннән Касыймхан Чанышев була. Большевиклардан качып чыккан эмигрант сыйфатында Дутовка якынлаша. Эшен бетергәч, кире кайтып китә, әлбәттә. (Касыймхан Чанышев хакында Казакъфильм студиясе «Атаманның бетүе» исемле кинофильм да чыгарган иде. Анда баш геройның исем-фамилиясе Касыймхан Чарыяров рәвешендә бирелгән...) Башкалары исә үз эшләрен гасырыбызның 50—60 нчы елларына кадәр дәвам итәләр. Моның кайбер фактларын алга таба шәйләрбез.

* * *

Икенче дулкын 1922 елдан алып, 30 нчы еллардагы зур ачлык вакыйгаларына кадәргә аралыкка туры килә.

Дөреслектә бу дулкын 1922 елны Ленин күрсәтүе буенча яңа тәртипләрне, бигрәк тә большевизм идеологиясен кабул итмәгән зур интеллектуаль көчләрне (мәсәлән, Н. А. Бердяев һ. б.) күпләп илдән сөрү белән башланган иде. Дөрес, ул вакытларда әле андыйларга диссидент дигән тамга тагылмаган, шуңа күрә аларның барысы да «илдән качкан ак эмигрантлар» төркеменә кертелә иде. Татар зыялыларыннан Чүгүчәк һәм Кашгар якларына сөрелгән дөнья күләм мәшһүр дин галимнәре, философлардан Муса Биги Җарулла, Закир әл-Кадыйри шундыйлардан иде.

1921—22 елгы Идел-Урал буйларындагы ачлыктан качып котыла алучыларның да берничә төркеме чик аркылы чыгып сыгылалар. Боларга Казагыстан якларындагы кытлыктан интегүчеләр дә кушыла.

Күп тә узмый, Голҗа якларына «мулла малас» булганы өчен Казан-Уфа якларында мәктәпләрдән, рабфаклардан, хәтта институтлардан сөрелгән, бер җирдә дә эшкә урнаша алмыйча эзәрлекләнгән — кешелек дәрәҗәләре тапталган яшь-яшь ир-егетләр дә килә башлый. Аннары кулак дип, туган җирләреннән сөрелгәннәре...

Әмма иң куркынычы 20 нче елларның ахырына һәм 30 нчы елларның башына туры килә. Бөтен илдә диярлек, бигрәк тә Украина һәм Казагыстан киңлекләрендә ажгырган ачлык — Сталин хөкүмәте тарафыннан махсус оештырылган Олы ачлык елларында Кытай җирләренә йөзәрләп-йөзәрләп качалар. Хәлсезлектән аякларында көчкә генә торган, хәтта озак ачыгудан шешенә башлаган адәм балалары. Казакълар да, руслар да, татарлар да, үзбәкләр дә.

Аларның чик буйларында ятып калучылары да шактый булган — дәүләт чикләрендә чын-чынлап «совет тәртипләре» керә башлаган заман... Күзгә элəкмичә чыга алганнары исә туганнарына, танышларына һәм, гомумән, якташларына килеп сыенганнар. Якташлар дигәннән, беренче вакытларда таныш рус кешеләренә казакълар ярдәм кулын сузу, ач татарларны уйгырлар тәрбиягә алу, татар гаиләләренә казакълар килеп ышык табу очраклары да шактый иде. Бик ачыгучыларны бер кадәре вакыт азлап-азлап ашатып кына аякка бастырганнар. Бу төркемнән яңа җирләрдәге тормышларын хәер теләнү белән башлап җибәрүчеләре дә аз булмаган. Ярый әле хәер бирер кешеләр табылган...

Гомумән алганда, соңгы дулкын белән Шәркый Төркестан җирләренә килеп сыгылучыларның һәммәсе дә диярлек ач-ялангачлардан, гел ярлылардан гыйбарәт була.

Элекке дәверләрдә, икенче чорның беренче дулкыннарында ат арбаларда кирәк- яракларын төяп, кайда барасыларын, нәрсә эшлиселәрен белеп килүчеләр белән чагыштырганда, болар сүзнең чын мәгънәсендәге ярлы кардәшләр иде. Якты дөньядагы санаулы көннәрен ике-өч сулышка гына булса да озайтырга теләгән, шуңа күрә кулга-кул тотышып җәяүләп дәүләт чикләрен кичкән ач-ялангач шешенгән мескеннәр иде. Хәтта аларны сугыша-сугыша чигенгән ак эмиграция белән дә чагыштырып булмый. Чөнки болар элекке урыннарыннан кузгалмаучылар, яңа тәртипләр урнашкан яңа шартларда да яшәргә әзер, димәк, совет властен кабул иткән гадәти бәндәләр иде. Аларны җылы урыннарыннан ач үлем куркусы гына сөрә — большевизм «җәннәте» куа.

Араларында колхоз ипиенең тәмен татып өлгергәннәре белән, ГПУ подвалларының исен иснәүчеләр, укытучылар, бухгалтерлар, «мин восмилетканы кончать иткән»,— дип, маржаланучылар белән эчкечелекне тәмам кәсеп кылган «бизбужниклар» да бар иде. Әмма дөресен әйткәндә, болар хакында тәфсилләп сөйләве дә кыен. Күпчелеге кеше бусагасында хезмәтче, башкаларның хаҗәтләрен үтәүче хәлендә булдылар. Бәрәкәтле Төркестан шартларында да аякка рәтләп баса ал-

мыйча дөньядан үттеләр. Бары икенче буында гына бераз исләрен җыя алдылар...

Шушы ач-ялангачлар белән икенче чорның соңгы дулкыны тәмамлана. 30 нчы елларның урталарыннан алып, чик бозып Кытай якларына чыгу бөтенләй туктый диярлек. Чөнки бөтен илне төрмәләр системасына — ГУЛАГка әверелдереп өлгергән сталинчыл Система чик саклау сәнгатен дә камил рәвештә үзләштереп өлгергән иде.

Мәгәр күп тә узмый, дәүләт чиген икенче яктан килеп узу — илгә кайту процессы башланды. Әмма моның хакта махсус сөйләүне язмаларыбызның соңгы өлешләренә калдырыйк.

## Сибелгән ризыкны чүпләп

Төрле елларда төрле юллар һәм төрле сәбәпләр аркасында Шәркый Төркестан җирләренә һиҗрәт иткән, шунда төпләнеп яшәгән илдәшләребезнең һөнәр-кәсепләре, көндәлек шөгыльләре — ризык чыганаклары да төрлечә иде. Шулай да аларны өч-дүрт зур төркемгә бүлеп карарга була: сәүдә-хуҗалык, һөнәрчелек, хезмәтчелек, мәктәп-мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендәге эшчәнлек.

* * *

Сәүдәгәрлек кәсебе бу якларда, һичшиксез, беренче урында тора иде...

Ризык турында сүз башлап, шунда ук сәүдәгәрлек хакында сөйләргә тотынудан гаҗәпләнмик: һәрбер «товар алмашу», теләсә нинди «сату-алу» эше ахыр чиктә (һәм тәү башта!) бер кабым ризык табу, киләчәктә дә ачтан үлмәү омтылышына барып тоташа. Ә аннары...

Сәүдәгәрләрнең дә нинди генә юк иде монда!

Җыен вак-төяк белән сату итүчедән башлап, зур кибет тотучылары, меңәрләп-меңәрләп җанлы мал — куй-сыер, елкы көтүләрен бер алып, бер сатып ятучылары, хәтта чит илләр белән алыш-биреш ясаучыларына кадәр. Мондый зур «чуртаннар», әлбәттә, шул килеш кенә яралмаганнар дөньяга. Шуңа күрә купчелекне вак-төяктән башлаучылар, йәисә шундыйларыннан үсеп чыгучылар тәшкил иткән.

Татар кешеләренең ерак бабаларыннан мирас итеп алган бу хосусыятен — сәүдәгә һәвәслеген, сату-алу эшләренә маһирлыгын коммерсантлыкта «төшеп калмаган» уйгырлар үзләре дә икърар итәләр, хәтта бер вакыйганы мәзәк-риваять рәвешендә дә сөйлиләр иде.

* * *

Картаймышрак көннәрендә Голҗа якларына килеп чыккан Гәләви дигән бер татар кешесе шактый вакыт үзенә лаеклы эш таба алмыйча интегеп йөри. Малайлыкка ялланыр иде дә бит, йөгерә-йөгерә эшләве җиңел булмас. Аннары карт кешене малайлыкка бик үк теләп алмыйлар да. Аптыраган Гәләви бер көнне шәһәрдән чыгып, ерак-еракка китә. Бер җирдә күзләрне туфрак өстен каплап яткан ак элпәгә төшә. Бу — шурлак, ягъни җир өстенә чыгып кипкән тоз-тозлак була. Гәләви карап-карап тора да, әлеге тозлак элпәсен пычак белән кырып, бер капчык тутырып җыя. Иртәгесен шәһәр базары гөрләп торган бер җиргә килеп, җәелгән чүпрәк өстенә әлеге җир тозын өеп, төреп бирер өчен янына иске китап битләре куеп, сабыр гына утыра башлый. Ары-бире узган базар кешеләре зәңгәр күзле «нугай әбзидән» сорыйлар:

— Әбзи, бу нимә?

— Тычкан даруы,— ди Галәви тыныч кына.

— Аны ничек кулланалар?— дип кызыксыналар гел җир идәнле өйләрдә яшәп, йорт тычканнарыннан иза чигеп беткән кешеләр.

— Тычкан йөри торган юлга сибеп куясыз индс,— ди Галәветдин, бик гади итеп.

Алалар базардагылар тозлакны мул-мул итеп, азык-төлек әрҗәләрен тишеп, кап-капчык төпләрен ярып бетерүче сыерчыктай тычканнарның күрмәгәннәрен күрсәтер өчен. Яхшы хәбәр тиз тарала. Әмма иртәгесен Галәви күренми. Бер-ике көн узгач, җиргә җәелгән чүпрәгенә мул итеп тозлак өеп куеп, Галәви әлеге җирдә тагын утыра. Тагын алалар «тычкан даруын», әбзи аны ике-өч көн буе өйдә ясап яткандыр дип, чират торып алалар.

Галәви шулай атна-ун көн чамасы сәүдә итә. Ләкин тычканнарның кимемәвен сизгән уйгырлар да сагаеп калалар:

— Әбзи, бу дурудин чычканлар үлмәйде-гу?!— диләр.

— Сез аны ничек кулланасыз соң?— дип, Галәви үз нәүбәтендә Голҗа халкыннан сорый.

Тегеләр даруны ул кушканча сибеп куюларын әйтәләр.

— Алай дөрес түгел!— ди Галәви, кырт кистереп.

— Ә ничек дөрес соң?

— Элек тычканны тоталар, муенын кысып авызын ачалар, шуннан бу дарудан авызына ике-өч чеметсм салалар.

— Әй әбзи!— диләр базардагылар, бот чабып.— Тычканны тоткач, аны җиргә бәрү дә җитә бит!

— Алай да була...— ди Галәви базар халкы белән килешеп,— ләкин болай әйбәтрәк: оясына кереп үлә.

Бу вакыйга дөрестермс, ялгандырмы, Галәви дигән кеше чыннан да тозлак сатудан башлагандырмы Голҗадагы үз эшен — аларын төгәл белмим. Әмма әлеге риваятьнс төрле вариантларда уйгырлардан үзем кат-кат ишеткән идем. Һәрхәлдә, зур сәүдәнең кечкенәләрдән башлануын, һәрбер алып-сатуда алдашу, ялганлау элементы да булуын бу хикәя шактый дөрес яктырта.

* * *

Югарыда малайлыкка яллану мөмкинлеген дә искә төшергән идек. Әйе, 1917 елга кадәр бу якларга бәхет эзләп килгән татар яшьләренең бер өлеше үзләренең мондагы тормышларын бай сәүдәгәргә, бигрәк тә кибетчеләр белән ашханә һәм чәйханә тотучыларга йомышчы, самавырчы малай булып яллануда башлаганнар. Мал-мөлкәт белән килүче татар сәүдәгәрләре дә шундый малайларын үзләре белән ала килгәннәр.

Соңгырак дәвер хәлле татарларның өйдәге, ишек алдындагы вак-төяк хуҗалык ихтыяҗларын, мәсәлән, кура-ишегалды себерү, кар көрәү, ат-сыер карау ише йорт эшләрен башкаручы ялчылары, чал сакаллы олы яшьтәге кешеләр булуларына карамастан, барыбер «малай» дип аталалар иде. Алар, гадәттә, кырдан, ерак авыллардан эш эзләп килгән ярлы казакълар була иде.

Малай сүзенең таралышы һәм эчтәлеге үзгәрүгә болай махсус тукталуның сәбәбе бар. Чөнки гасырыбызның беренче яртысында, 50 нче елларның урталарына кадәр, Голҗа-Чүгүчәкләрдә «дөнья селкетеп» яшәгән татар байларының кайберләре үз вакытында эшчәнлекләрен шулай малайлыктан башлаган, тора-бара приказчик булып аякка баскан, аннары тәмам хәлләнеп, баеп киткән кешеләр икәнлеге мәгълүм.

Малайлыктан башлап, аннары зур хезмәткәр, хәтта ил-мәмләкәт күләм дәүләт эшлеклесе югарылыгына күтәрелгән кешеләр дә юк түгел иде. Мәсәлән, Татарстанның Буа ягындагы Кишер Аксуы авылында туып үскән, малайлык мәктәбен узгач, Голҗадагы сәүдәгәрләрдә хезмәткәр, зур

ширкәтләргә җитәкче булган Борһан әфәнде Шәһидине алыйк. Уйгыр байларына завод-фабрикалар алыр өчен Германияләргә дә барып кайта ул. 30 нчы елларда төрмәләргә эләккәч тә, тик утырмыйча, кытай телен төпченеп өйрәнә, соңра «Уйгырча-кытайча-русча лөгать» — сүзлек китабы бастырып чыгара (Пекин, 1953, 827 биттән). 40 нчы еллар ахырында җәмәгать, аннары дәүләт эшләрендә дә — ул. 50 нче еллар башында, Шенҗаң-Уйгыр җирләренең «мөстәкыйль хөкүмәте» төзелгән чакта, аның рәисе итеп, Алты шәһәрдәге, ягъни бернинди кишер-мишергә мөнәсәбәте булмаган «Аксу каласында туган, милләте буенча уйгыр Борһан Шәһиди» билгеләнә. Пекин-Өремчеләрдә иҗат ителгән мондый мифтан Голҗа халкының авызы ерылды, әлбәттә.

Кишер-мишер дигәннән, 1971 елның җәендә, археографик экспедиция вакытында, миңа Кишер Аксуында булырга, анда Борһан әфәнденең бертуган апасының кызын үз күзләрем белән күрергә туры килгән иде. Голҗадан кайткан кеше икәнлегемне белгәч, ул минем белән бик озак сөйләшеп, андагы туганнары хакында сорашып утырган иде. Әмма бу елларны Борһан Шәһиди тагын да югары менгән — Мао-цзедунның уналты урынбасарларыннан берсе дәрәҗәсенә күтәрелеп, Пекинның үзендә утыра иде...

Вәт сиңа, мишәр әйтмешли, малайка!...

* * *

Малайлык өлешеннән котыла алмыйча, гел ялчылыкта гомер уздырган татарлар да булган шикелле, сату-алу эшләре дә вак-төяктән узмаган сәүдәгәр кисәкләре дә шактый иде. Әйтик, гәзитә-журнал киоскысы шикелле кечкенә генә такта куышында инәҗеп, кыздырган көнбагыш, сагыз сатып утыра торган бәләкәй буйлы Ниматәй (Нигъмәт) абзыйны әле дә хәтерлим. Кесәбездә 10—15 тиен әтәч булып кычкыра башласа, сагызсымәнкә өчен шунда чаба идек. Аның кибетеннән «мал» алучылар арасында безнеңише җиде-сигез яшьлек балалардан гайре беркемне дә хәтерләмим.

«Бет базары» дип атала торган иске-моски базарында гомер уздыручы «татар сәүдәгәрләре» дә юк түгел иде. Дүрт-биш көн шунда иске чүпрәк-чапрак, тимер-томыр белән сәүдә итүче, аннары тапкан файдасына бер рәхәтләнеп «гуләйт» кылып алучы Каюм да истә калган. Олылар белән картларча, яшьләр белән егетләрчә сөйләшә белә торган кеше иде, мәрхүм. Аның хакта чыккан шаян җырның ике юлы һаман хәтердә: Каюм абзый — камфара, сатадыр шара-бара... (Әлеге «Бет базары»ның минем өчен әллә нинди үкенечле бер истәлеге дә бар. 50 нче елларның башында «кибете» лапас астындагы җиңел машина кадәрле бер лардан — зур агач әрҗәдән генә торган «китапчы» уйгыр карты белән әшнәләштем. Чөнки аның тегө дәү ящигы тулы иске китаплар арасында әллә нәрсәләрне очратырга мөмкин иде. Үземә ошаган дүрт-биш китапны сатып алам да, укып бетергәч, аларны кимрәк бәягә үзенә кайтарып, шул акчага тагын өч-дүрт китап сайлап алам. Аннары, чак кына акча кушып, тагын дүрт-биш китап белән кайта идем. Менә шул ящикта әллә нинди «әкәмәт» рәсемле кулдан гына язылган иске китаплар да очрый иде. Бәясе дә юк кына... Хәзер, борынгы китаплар буенча белгеч булгач кына, әлеге «әкәмәт» рәсемле китапларның миниатюралы кулъязмалар икәнлеген белдем. Әгәр ул вакытларда аларның кадерен, кыйммәтен аңлаган булсам!..)

Берише татарлар башка сатучы һәм алучылар арасында дәллалык — маклерлык итү белән көннәрен күрәләр иде. Алар кайда нәрсә вә күпмегә сатыласын, кемгә нәрсә кирәклеген, аның күпме акчасы барлыгын яхшы беләләр. Шундый мал һәм акча ияләрен табыштырып, килештерәләр, кулга-кул суктырып, «нәкъ сәүдә — хак сәүдә» дип эшне бетерәләр. Әлбәттә, ике кулдан да өченчегә бераз тамып кала.

Шулай, «Кытайдагы татарлар, нигездә, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр» дигәч тә, анда чыккан һәрбер татар да мәкәрҗә әһелләренә әверелеп беткән икән, дип уйланылмасын.

* * *

Зур сәүдәгәрләргә, аларның да иң кәттәләренә килсәк, андыйлары, билгеле, бармак белән генә санарлык. Шундыйлардан иң элек чүгүчәкле Рамазан бай Чанышевны, өремчеле сәүдәгәр Насыйрбай Бурнашевны атарга мөмкин. Болардан беренчесе, революциягә кадәр чәй белән сәүдә итүче рус байларының вәкиле буларак Кытайга килеп, шунда төпләнеп калган. Соңрак ул, Н. Бурнашев белән зур сәүдә ширкәте төзеп, көчле монополистларның берсенә әверелгән шәхес. Эчке Кытайдан чәй китерү, Төркестан җирләрендә исә тире, йон, эчәге кебек терлекчелек чималын сатып алу, аларны патша Россиясенә чыгара тору хокукы беренче нәүбәттә болар төзегән «Җишаңйүән ширкәте»нең карамагында булган. Тора-бара бу ширкәт терлек үрчетү, мамык эшкәртү, җанлы мал белән авыл хуҗалыгы чималларын Россиягә чыгару белән дә актив шөгыльләнгән (ТКТ, 18—19 бб.).

Рамазан хаҗи Чанышевның байлыгы хакында риваятьләр йөргән. Имештер, аның капиталы Николай акчасы белән ун миллионнан артык булган, диеп. Әмма Рамазан байның өйләнмәгән булуы һәм әлеге малны үз гомерендә җыйганлыгы бәхәссез факт иде. Үзе үлгәч, ул капиталның агасы уллары Хәсән һәм Хөсәенгә күчүе, боларның 1938 елда кытай төрмәсендә үлүе гыйбрәт рәвешендә телдә йөргән...

Бертуган Исхак, Ибрай, Гариф байлар төзегән куптармаклы «Тьяншаң ширкәте» Россиядән тимер, чуен әйберләре, төсле металлардан эшләнгән эш кораллары, шырпы, керосин, тукыма һ. б. алып каршыга Төркестанның төрле почмакларыннан җыелган тире-тирсәк, йон, эшкәртелгән мамык чыгарган. Кайбер елларны Россиягә күндерелгән мондый чималның гомум авырлыгы 16 мең тоннага җиткән (ТКТ, 20 б.).

Голҗада да берничә зур сәүдә ширкәтләре булып, шуның берсе татар байлары төзегән «Алтай ширкәте» иде. Аны асылда алты бай — Фатыйх, Закирҗан, Ситдыйк исемле, Аллаһъярый фамилияле өч бертуган һәм Фазылҗан Юнич (Юнусов), Галиәхмәт Садри һәм Низаметдин Шәмсетдиневләр төзегән. (Болардан иң хәллеләре Аллаһъярыйлар, аларның да — Фатыйхы иде; бу фамилияне «Алдагаров» рәвешендә казакълаштырып әйтү гадәте дә бар иде). Шуңа күрә ширкәт исемен башта «Алты бай ширкәте» дип атаганнар, аннары «Алтай...» рәвешендә кыскартканнар. Турыдан-туры СССР белән сәүдә итү хокукына ия булган ширкәт Шәркый Төркестаннан ашлык, терлек, төрле чимал чыгарып, Советлар Союзыннан исә тукыма, кием-салым һәм башка көндәлек кулланылыш товарлары китереп саткан.

* * *

«Алтай ширкәте» әллә ни озак яшәмәсә дә, Голҗа татарлары хәтерендә, җөмләдән безнең зур гаиләбез тормышында да, эз калдырган иде. Шуңа күрә тагын гаилә истәлекләреннән бер-ике сәхифә күчерик.

20 нче еллар башында Габделбари хаҗи Госмановның Чүгүчәктән Голҗага күчеп килүен әйткән идем инде. Терлек малларының күпчелеген исән-имин Чүгүчәккә качыра алса да, аның йорт-җире һәм кибет-амбарларындагы милкенең зур өлеше «бикләнгән килеш» илдә калуын да исегезгә төшерәм. Һәрхәлдә, икенче гильдияле Рәсәй купецының дәүләтеннән, дүрттән өче булмаса да, яртысыннан артыгы «җилгә очканлыгы» бәхәссез иде.

Яңа җирләрдә хуҗалык эшләрен тиз генә җайлап җибәрә алмау, аннары меңәр чакрымга якын юллар узып күченү, тагын яңа шартларга килеп керү нәтиҗәсендә әлеге «алла насыйп иткән» милекнең йәнә бер өлеше эреп бетә. Аннары җир сатып алып, тыштан ка̄рап торуга гадирәк булса да, күп бүлмәле итеп зур йорт салдыру, элгәрәк өйләнгән ике улын йорт-кура белән аерып чыгару, кызларын кияүгә бирү... Кыскасы, гильдия-мильдияләренең истәлек кенә булып кала. Шулай да тәмам бөлми Габделбари хаҗи Госманов. Зур байлардан ярыйсы гына аста торса да, урта хәллеләрдән өстәрәк була. Элеккедән килгән абруе да саклана. Бигрәк тә революция елларында Россиядән кабилә-ырулары белән «өркеп чыккан» казакълар арасында. Ел саен җәйләрен тау җәйләүләрендә уздырганга күрә, җирле казакълардан кызай кабиләле кешеләре белән дә якыннан аралаша, алар каршында да Апарый каҗы дип мәгълүм була.

Шундый җәйләрнең берсендә яшьлек чорындагы танышы, атаклы казакъ җырчысы Әсәт акын килеп егыла аның өенә. Илдән сөрелеп, каңгырап йөргән мәшһүр акын каты сырхау була — тамагыннан ризык үтми, үңәч рагы... Кайчаннардыр казылыклы кымыз мәҗлесләрендә үләң әйтешеп, кыз-киленчәкләрне ярыштырып хозур уртаклашкан якташын Апарый каҗы үз өеннән чыгарып җирли, Кытай җирендәге Күгәрчен исемле тауның Оланбура дигән җәйләвендә, 1923 елның 23 июнендә...

Картайган, актив хуҗалык эшләреннән читләшеп, мәчет картына әверелгән, әмма эссе җәй көннәрендә гомерен гел тау җәйләүләрендә уздырырга ярата торган кырыс холыклы, үз сүзеннән кайтмаучан Габделбари хаҗи барыбер гаилә тезгенен кулдан ычкындырмый. Утыз-кырыктан уза башлаган уллары, кичке мәҗлесләрдә кыза төшеп, артык шаулаша башласалар, хаҗи абзаң ишектән таягын болгаган — оныталып китүчеләр шунда ук тынганнар. Менә шул карт терлек малларның бер өлешен сатып, сәүдә хәрәкәтенә тотынырга теләгән улларына ирек бирми, кем белә, отуыннан отылуың тизрәк, ә терлек мал болай да үсем биреп тора. Тәвәккәллек итәргә Жыланды тавындагы бал кортлары юк монда! Шуңа күрә аның Локман, Габдерәүф, Габделәхәт, Габделмәтин исемле уллары төрле сәүдә ширкәтләренә хезмәткә керәләр. (Приказчик, мөдир, хәтта тулы хокуклы вәкил (доверенный) булып.) Шуңа күрә алар 20 нче елларның икенче яртысы белән 30 нчы елларның башларында СССРга да килеп киткәлиләр. Әлбәттә, Кытай дәүләтенең кешеләре сыйфатында.

Бу елларда картның өченче угылы Габделәхәт, безнең әтиебез, бая телгә алынган «Алтай ширкәте»ндә эшләгән. 1933 елның ахырларында аның хуҗалары бер ат йөге кадәре акча белән Кашгар якларына җибәрәләр. Кәгазь акчаларны металлга, ягъни алтынга әйләндереп кайту өчен. Әмма, ул юлга чыгуга, Шәркый Төркестан җирләрен сугыш ялкыннары каплый: Дөңгән сугышы дип мәшһүр булган болганчык сугышлар, төрле характердагы баш күтәрүләр, канлы ыгы-зыгылар башлана...

* * *

Сәүдәгәрләр хакында сүз башлап, мондый ширкәт хезмәткәрләренә кечүсем очраклы түгел. Чөнки Голҗадагы татарларның шактый зур өлеше, үзләре капитал хуҗалары булмаганы хәлдә, төрле зур сәүдәгәрләрнең эш башкаручылары, кибет-магазин мөдирләре, чит илләр белән сәүдә эшләрен алып баручы ышанычлы вәкилләре булып эшлиләр иде. Шул рәвешчә, хөрәкәттәге милеккә иялек ягыннан гап-гади хезмәтче, кәсеп җәһәтеннән профессиональ сәүдәгәр-коммерсантлар катламы да барлыкка килгән иде. Шуңа күрә җирле бай уйгыр сәүдәгәрләре дә, бигрәк тә аларның «кара байлары», уку-язу һәм исәп-хисап белгән, русча да яхшы сөйләшә алган татар егетләрен СССР белән сәүдә эшләрендә бик актив файдаланганнар.

Шунысын да күрсәтергә кирәк, байлар сәүдәсен алып баручы мондый профессионаллардан күп нәрсә торган. Байны тагын да баетып көлдергән

дә, милкен комга сеңдереп бөлдергән дә, гадәттә, шулар булган. Дөресрәге, аларның сәләте, тырышлыгы йәисә булдыксызлыгы... Әмма, булдыксызларына караганда, уңганнары, хәтта артык шомалары күбрәк иде боларның. Идел-Урал буйларыннан алып, бу якларга кадәрс килеп җиткәнче күпме юл узган, әллә ничә сынауларны күреп, хәвеф-хәтәрләрне җиңгән, кем әйтмешли, уттан — янмыйча, судан коры чыккан, «энә күзеннән» үткән ир-егетләрдән кемнәр җитлекмәс!

Мондый профессионал хезмәтче-сәүдәгәрләр җирле хөкүмәтнең сәүдә эшләрендә дә, катнаш ширкәтләрдә дә күп эшлиләр иде.

• • •

Шундый катнаш ширкәтләрнең берсе 30 нчы елларның урталарында оешкан халыкара «Совсинторг» ширкәте иде. «Советско-Синьцзянская торговля» иде бугай аның тулырак исеме. Әмма безнең гаиләдә ул гел «Сәвсимтурыг» дип әйтелеп, «со всеми торгует» мәгънәсендәрәк хәтергә сеңеп калган. Чөнки мин тугач ярты елдан соң гына, 1934 елның көзендә, Кашгар якларыннан көч-хәлгә кайткан әти, алып кайткан малларын тапшырып, әлеге «Алтай ширкәте»ннән китеп, энесе Габделмәтин белән шул «Сәвсимтурыг»ка урнаша.

1936 елны, мәрхүмә әниебез гел искә төшергәнчә, миңа ике яшь тулып җитмәгән көннәрдә, бөтен Габделбари хаҗи гаиләсенең бер өлеше, дөресрәге, өченче улы Габделәхәт үз хатын-баласы белән арбага төянеп, Голҗадан өч йөз чакрым чамасы читтәге Дахыяңзы дигән бер уйгыр кышлагына күченеп килә. Максат шул җирдә әлеге ширкәтнең сәүдә бүлеген ачу. Голҗада калган Габделмәтин абзый Советлар Союзыннан (гадәттә «Союздан» гына дип әйтелә) китерелгән төрле көндәлек тормыш хаҗәтләренә кирәкле товарларны, кызыл малны шул Дахыяңзыга җибәреп торачак. Әти исә ул малларны уйгырлардан, казакълардан, монголлардан гыйбарәт җирле халыкка сатып, сатылган мал хакына төрле чимал — йон, төрле тире-тирсәк, эчәге, хәтта терлек һ. б. алырга, җыелган хәтлесен Голҗага җибәреп торырга тиеш.

Шулай итеп, әллә кайларда тузанга күмелеп яткан, җәен гаҗәеп эссе, кышларын зәмһәрир салкын уйгыр кышлагында, бер генә бөртек булып яши башлый безнең кечкенә гаиләбез (1952 елда анда булгач, Дахыяңзының сәләмәлегеннән, ямьсезлегеннән котларым очкан иде...).

Ике-өч ел эчендә эшләр гөрләп киткәнгә охшый. Элек кеше өйләрендә фатирда торган гаиләбез өчен, миңа 5—6 яшь тулган елларда, бик иркен кура-ихаталары, әллә ничә амбар һәм сарайлары булган, зур гына йорт салдырганнар иде. Ул кура-ихатадагы ыгы-зыгылар әле дә күз алдында. Кырдан, ерак авыллардан ат-үгез сыртларына, ике тәгәрмәчле арбаларга йон, тире төяп килгән уйгырларның, казакъларның берсе кереп, икенчесе чыгып торалар.

Бер җирдә кабул итүче егетләр кап-кап йонны үлчәп алалар, йонның бик дымлы, су сипкәнсең, дип бәйләнәләр, сәүдәләшәләр. Икенче урында куй-кәҗә, сыер-елкы тиреләрен кагып-селкеп, җентекләп карый-карый алалар, төрле сортларга бүләләр. Ертык-тишекләрен, үзеңә тун тегеп киярсең, дип кире ыргыталар. Өченчеләре китерелгән тиреләрне, йоннарны таслап бәйләү, амбарларга илтеп ябу белән мәшгуль... Аларны китереп сатучылар өч-дүрт урамлы Дахыяңзының үзәгендәге кибеттән кисмәлек өчен төрле тукыма, чәй-шикәр, итек-читек, балта-пычак, урак-чалгы, кәрәсин, дары һәм капкын, көзге-сабын, инә-җеп кебек ише әйберләр алып китәләр. Җәйнең эссе көннәрендә шыбыр тиргә баткан калын гәүдәле әтинең, зур сөлге белән пеләшен сөртә-сөртә, мал җибәрүе, берсе белән сәүдәләшеп, икенчеләре белән шаяра-шаяра акча санауларын әле дә хәтерлим. Ни өчендер әлеге зур кибеттә, ярдәмче тотмыйча, берүзе генә тыз-быз чаба иде...

Кышларын киск җәнлекләрнең тиреләре агыла башлый. Дистәләп-дистәләп таслап бәйләнгән куян тиреләре бер кулдан икенчесенә күчә торалар. Кайчакларын тау-тау булып өеләләр (хәзер уйласам, исләрем китә: миллионлап үрчеделәр микән ул озын колаклар!). Куян, бурсык, суар тиреләрен ярдәмчеләр генә кабул итә. Ә төлке, бүре ише кыйммәтлерәк җәнлек тиреләрен әти үзе карый, үзе бәяли иде; аларның саклана торган урыннары да башка.

Вакыт-вакыт җыелган әлеге чималны арбаларга, ара-тирә машиналарга төяп, Голҗага озаталар. Аннары алар Союзга китәчәк. Аннан исә тагын төрле товар килергә тиеш.

Кайвакытлар шәп киенгән руслар килеп чыгалар иде, әлеге Совсинторг кешеләре бугай. Эчәләр төннәр буе (Кытайның дөгедән куылган сасы аракысын). Эчү ягына әти көчле булганга охшый, уйгырларның аңардан «мәс булмайдуган (исерми торган) нугай» дип көлүләре истә калган. Кайчакларын әлеге руслар белән кыр кәҗәләренә, тау тәкәләренә ауга да баралар иде.

Шундый зур кешеләр белән аралашучы, килеп-китүчеләрнең берәүләре белән көлә-көлә шаяртучы, икенчеләрен теттереп сүгүче әти миңа, табигый, дөньядагы иң акыллы, иң белемле, иң көчле кеше булып тоела иде. (Чыннан да, ул физик яктан бик таза иде: кайберәүләр белән бәхәсләшеп, ике потлы герне кырык мәртәбә күтәрүен, йәисә казакълар сатар өчен китергән йоннан ишелгән ат арканын өзүләрен, әрптәшләрен шулай җиңүләрен күргәнем бар.) Көндезләрен гел ир-атлар, әллә нинди ят кешеләр белән ыгы-зыгы килә торган, кичләрен бик арып йокыга тала торган әтинең игътибарын җәлеп итә алу шактый сирәк насыйп була иде шикелле. Бигрәк тә җәйге эссе көннәрдә. Шундый бер тынчу җәйге кичтә аның белән сөйләшүем хәтердә уелып калган. Тезләренә утыртып минем баштан сыпырды ул:

— Быел көзен, Алла боерса, Голҗага барып мәктәпкә керерсең. Анда Өлкән әниеңдә торырсың... Укып чыгып, зур үскәч, кем булырсың икән соң?

— Сәүдәгәр!—дидем мин уйлап та тормыйча.

—Юк,—диде әти кырт кисеп.—Сәүдәгәрлек ул яман эш: ялганы күп. Ә син укы, зур укып, духтыр бул, инжинир бул.

— Ә син нигә сәүдәгәр? Яман булса, нигә эшлисең?

— Мин... укымаган. Сугышлар булган иде. Мин үз малым белән сәүдә итмим. Кешенекен сатам, аңа алып бирәм. Башка эшкә ярамагач, эшлим шул. Ашарга кирәк, киенергә кирәк. Син сәүдәгәр булма, улым. Духтыр бул, инжинир бул!

Колагымнан аккан чакта анда казынган, тагын арт саныма инә кадап авырттырган духтырны беркадәрле белгәнгә, аның хакта сөйләшүне артык санап, инженерның нәрсә эшләвен сорадым.

— Улмы,—диде әти, мәгънәле итеп,—ул җир асты байлыгын эзләп таба. Әйтик, тимер, күмер, алтын-көмеш шикелле асыл мәгъдәннәрне җирдән чыгара.

— Ә ничек таба?

— Белеме булгач таба инде. Әйтик, бер җиргә килеп, үкчәләре белән җиргә тибеп-тибеп карый да, анда нәрсә барлыгын белә. Зур укыгын кеше белә, балам. Син дә укы...

Моннан соң мин малайлар белән шактый вакытлар җиргә тибә-тибә «инжинир уйнап», алтын-көмеш эзләп йөрдем. Әти үзе исә чынлап укымаган, нибары, Рәсәйдә чакта, ике кыш «карый абзыйдан» укый-язарга өйрәнгән, аннары бер кыш учительгә йөреп караган, шуңа күрә, ихтимал, Өч Арал авылындагы «хахул малайлары» белән уйнап ыштан туздырганга да, беркадәр русчаны сукалый торган кеше иде. Әмма аның уку кирәк-ярагы, китап-мазар алу, гәзитә-журналга язылу өчен акча кызгануын бер дә хәтерләмим.

Совсинторг эшләре шулай гөрли-гөрли 40 нчы елларга кергән вакытларда зурларның чыш-пыш сөйләшүләре, колакка «сәвит-гирман сугышы» хакындагы шомлы хәбәрләр дә ишетелә башлады. Кичләрен әтием кәрәсин лампа янында, Дахыяңзыга өч-дүрт көнгә соңгарып килә торган гәзитәләрне карый, сугыш хәбәрләре хакындагы аерым урыннарын кычкырып укый. Өйдәге туганнар йәисә кунаклар арасында нәрсәләр хакындадыр бик борчылып сөйләшүләр бара. Мондый борчылуларның асыл сәбәбен соң гына аңладым: сугышлар озак дәвам итсә йәисә сәвит хөкүмәтенә ул-бу була калса, әлеге Сәвсимтурыгның да очу куркынычы ихтимал икән.

Чыннан да, тиздән Шәркый Төркестандагы Кытай хөкүмәте белән Советлар Союзы арасындагы дуслык җепләре өзелә, ширкәт-миркәтләр дә таркала. Ләкин бу вакытлардагы Дахыяңзыны мин яхшы хәтерләмим — Голҗадагы татар мәктәбендә укый идем.

Күп тә узмый, хөкүмәткә каршы әллә нинди сәяси эшләргә катнашканы өчен әтине кулга алырга булалар. Ул бер атка атланып, икенче атны запаска алып, тауга кача. Иртәгесен, 1944 елның көзге бер көнендә, йөзләгән кытай гаскәрләре килеп, йорт-кураны уратып алалар, өйдә тентү, аннары барлык мал-мөлкәтне, өй җиһазларын талау башлана. Әнине ике баласы белән кулга алалар, төрмә урынына бер мөгътәбәр уйгырның өендә әсир итеп тоталар.

Әтинең сәүдәгәр-хезмәткәрлек дәверенең бер өлеше шулай инә-җепкә кадәр талану, җиде-сигез ел дәвамында җыйган йорттагы барлык мал-мөлкәтеннән аерылу белән очлана...

* * *

Хезмәткәр булып эшләүче татарлар бу төр «ярым коммерсантлар» белән генә чикләнмәделәр. Байларның сәүдә ширкәтләрендә генә түгел, бәлки хөкүмәт идарәләрендә дә эш башкаручылар, мөдирләр, бухгалтерлар, техниклар шактый иде алардан.

Хезмәткәр катламының зур өлешен төрле мәктәпләрдә, педагогик училищелар ише чак кына югарырак уку йортларында эшләүче мөгаллим һәм мөгаллимәләр тәшкил итә иде. Ләкин, болары хакында тәфсилләбрәк сөйләүне икенче урынга калдырып, хезмәткәрләр хакындагы бер нәтиҗәгә махсус тукталасы килә. Бай сәүдәгәрләр никадәре кодрәтле, абруйлы булмасын, әмма халык арасында иң тәэсирле, әйткән сүзләре үтемле, җәмәгатьчелектә кирәк фикер тудыра ала торган кешеләр, гадәттә, шул хезмәткәрләр, зыялылар арасыннан чыга иде. Татар җәмәгатьчелегенең милли йөзен, рухи бердәмлеген тәэмин итеп, аның уй-фикерен хәрәкәттә, билгеле бер омтылышта тотучылар да, кагыйдә буларак, шулар — хезмәткәрләр арасыннан чыгалар иде.

* * *

Хезмәткәрләр кадәре күп булмасалар да, татарларның шактый өлешен төрле һөнәрчеләр, вак кәсепчеләр тәшкил итә иде. Әйтик, тимерчеләр, кием тегүчеләр, итекчеләр, чигү чигеп сатучылар, алтынчылар, тире-күн эшкәртүчеләр, арба-чана ясаучылар, сәгать төзәтүчеләр, сабын кайнатучылар, тегермән тотучылар, киез итек басучылар, йорттан йортка йөреп, туй-мәҗлесләр өчен татарча аш-су пешерүче осталар h. б. h. б. Кайберләре үзләренә күрә бердәнбер осталар иде. Мәсәлән, фотоательe тоту буенча бу эшне Голҗада беренче булып Әкмәл Сәмитев дигән кеше башлап җибәргән.

30 нчы елларга кадәр уйгырларда «күтәк арба» дип атала торган ике тәгәрмәчле тупас арбалар гына булган. Голҗада дүрт тәгәрмәчле «хадук»

дигән җиңел арбаларны, махсус йөк арбаларын ясап сатучы беренче кеше Симидән килгән Зариф Гафуров дигән оста була.

Киез итек басу һөнәре дә Голҗага 20 нче елларда гына килә. Киез итекне ул якларда Себердәге атама буенча «пима» дип атый идек. Голҗа тирәләрендәге иң атаклы киез итек җитештерүчеләрдән Вәли пимакат мәшһүр иде.

«Союзныкы» шикелле әйбәт аяк киеме тектерергә теләсәк, Сафи абзыйга юнәлә идек. Аның туфлиләрен эләктергән хатын-кыз биеп кенә йөри иде.

Җирле халык кер сабынының төрлесен ясый белә иде. Әмма исле сабын Советлар Союзыннан килә йәисә татарлар, руслар тарафыннан кайнатыла иде. Голҗадагы Кашшаф абзый чыгара торган «Гөлҗиһан» сабыны 40 нчы елларда шактый популярлык казанды.

Хәтта кармак ясау буенча да Шахмаев дигән берәү мәшһүр иде. Аның кармакларын эләктергән малай-шалай шунда ук Элә дәрьясына йөгерә иде. Әйтерсең лә балык бары «шахмайский»га гына каба!...

* * *

Дөрес, Кытайдагы татарларның гел авыл җирләрендә яшәп, үзләре терлек үстереп, игенчелек белән шөгыльләнүчеләре дә булган. Тик алар, Алтай ягындагыларын исәпләмәгәндә, безнең тарафларда артык күп түгел иде. Андый сакал-мыегын сирәк кыручы, учлары сөялләнеп беткән чын игенче таза агайларның үзләре сирәк күренсәләр дә, аларның уку ягына чамалы, ләкин беләк-йодрыклары нык малайлары, яңа пешкән пәрәмәч шикелле түгәрәк битле кызлары шәһәр мәктәпләрендә дә укыйлар иде.

Игенчелек белән шөгыльләнүче татарларның хуҗалыгы гадәттә тәртипле, эш кораллары төрле һәм төзек булалар. Шуңа күрә алар башкаларга караганда уңышны күбрәк алып, өстәвенә нәселле сыер һәм ат маллары да тоталар иде. Авыл хуҗалыгына яңа техник чаралар кертү буенча да, кагыйдә буларак, татар һәм рус игенчеләре алдан барганнар, шунысы белән алар ул яклардагы авыл хуҗалыгы хезмәтен камилләштерүгә сизелерлек өлеш керткәннәр (ТКТ, 23 б.).

Ниһаять, кайбер татар байлары авыл хуҗалыгы чималларын ахыргача эшкәртү, ягъни базарга әзер продукция чыгару белән дә шөгыльләнәләр иде. Мәсәлән, Галиәхмәт Садри, беренчеләрдән булып, сыйфатлы товар чыгара торган күн заводының хуҗасы иде (соңрак Голҗада уйгыр капиталистлары Сумабаевларның тагын да зуррак күн заводы эшли башлый).

Түбәннән чыккан бай Миркасыйм хаҗи Миршановның май заводы төрле үсемлек майлары чыгару белән мәгълүм булып, озак эшләгән заводларның берсе иде...

* * *

Чүгүчәктә һәм Голҗада төпләнеп озак яшәгән татарларның бәгъзеләре бакчачылык эшләре белән дә яратып шөгыльләнгәннәр. Аларның кайберләре бакча тотудан матди мәнфәгать кенә түгел, эстетик ләззәт тә алган булырга охшый. Әлбәттә, матди мәнфәгатьнең әһәмиятен дә истән чыгарырга ярамый. Әгәр Чүгүчәктәге оста бакчачы Гает Мөхәммәт, 1910 еллардан башлап, җиләк-җимеш агачларының, бигрәк тә алмаларның, яңа төрләрен чыгарып, шуларның үсентеләрен халыкка саткан икән — моның аерата мәгънәсе бар. Шулай ук Чүгүчәкле татар бае Галим Еникеев нигезләгән зур парк хәзергә кадәр «Алимның багъчасы» дип аталып, шәһәр халкы өчен ял урыны булып хезмәт итә икән (ТКТ, 24 б.).

Зур бакчаларга Голҗа тирәләре аерата бай иде. Голҗа татарларыннан Җәлилйөзе дигән уйгыр кышлагындагы Гаделшаһ байның, Таҗетдиневлар-

ның һәм Ваһаповларның ничә йөз гектарлы зур җимеш бакчалары, мәсәлән, бигрәк тә мәшһүр иде. Җәйге бәйрәм һәм ял көннәрендә, мөмкинлеге булган кешеләр, хадук арбаларга төялеп, исеме кыскартылып «Җилйөзе» рәвешендә әйтелә торган әлеге Җәлилйөзе бакчаларына «пикникка» киләләр иде. Байлыгы, матурлыгы ягыннан Кәшфеләсрар хәзрәт Ваһаповның бакчасы бөтен тирәдә дан тотып, җирле халык телендә «Нугай дамелла багы» диган исемдә мәшһүр иде.

Узган гасырның ахырларыннан ук Голҗада яшәгән Фазылҗан Юничнең (андагы татарларның җәмәгать башлыгы булганга «Фазылҗан аксакал» дип мәгълүм шәхеснең) Дардамты дигән авылдагы зур бакчасы бизәкле келәм рәвешендә планлаштырылган иде. Төз-төз аллеяләр белән бүлгәләнгән бакчаның бер җирендә алма, аннары чәчәклек, икенче төшендә өреклек, йәнә кызыл гөлләр, аннары төрле төстәге розалар... Болардан тыш каенлык, аның янында зәңгәр чыршылар... Бу бакчага барып бер ял итеп кайтуны Голҗа кешеләре аерата горурлык итәләр иде.

Җиләк-җимеш пешкән вакытларда агач төпләренә басарлык түгел — таеп егылырлык. Бигрәк тә өрек-абрикос, аннары алма пешкән чакларда. Аларны җыеп өлгерүче, базарларга илтеп сатучылар юк дәрәҗәсендә — анда алар, кем әйтмешли, болай да «шалкан бәясе». Бары бер-ике гаилә генә җәйләрен зур бакчаларның берәрсен арендага алып, как кою, алма киптерү, кышларын шулар белән сәүдә итү белән шөгыльләнә иде. Ләкин мондый кәсеп артык ышанычлы булмаган. Чөнки:

халыкның сиксән-туксан проценты гел үзләренең хосусый йорт-кураларында яшәгәнлектән;

һәрбер кура-йортта диярлек үз бакчасы, иң кимендә өч-дүрт төрле җимеш агачы үскәнлектән;

һәр гаилә үз хаҗәтенә җитәрлек какны, кайнатманы үзе хәзерләгәнлектән;

җиләк-җимешне күпләп эшкәртерлек махсус комбинат-заводлар юклыктан;

башка җирләргә илтеп сатар өчен яхшы юллар, җайлы транспорт булмаудан;

өйләрдә күпләп кайнатыр-пешерер өчен шикәр кирәклегеннән;

шикәрнең исә чит илдән — Союздан гына китерелгәнлегеннән һ. б. һ. б. һ. б.

* * *

Бу бүлеккә йомгак ясап, шуны гына өстәргә кирәк. Кодрәтле сәүдәгәр, милек һәм зур җир ияләре булган татарлар һәр җирдәге, һәр халыктагы кебек үк иң элек хезмәт ияләрен эшләтеп, үзләренең акыл-җегәрләрен, хәйлә-мәкерләрен, бетмәс-төкәнмәс энергияләрен эшкә җигеп баеганнар. Уртарак хәллеләре, ярлыраклары исә, кул көче, үз һөнәре, маңгай тире белән ризыкларын аерганнар. Дөньяның барлык почмакларындагы шикелле.

Икенче чиратта мондагы халыкларның һәммәсен дә диярлек, димәк, татарларны да, чагыштырмача тук ризыкландырган көчләрнең берсе ул — бу яклардагы иркенлек (халыкның нисбәтән азлыгы), юмарт кояш белән уңдырышлы, бәрәкәтле җир-сулар, ягъни табигый байлык иде. Мондый шартлар һәр җирдә дә, һәр заманда да булмый, әлбәттә.

Илдәшләребезнең Шәркый Төркестан җирләрендә тамагы тук, өсте-башы бөтен генә түгел, бәлки кешеләр, бер халык вәкилләре сыйфатында башкалар белән тигез хәлдә, үзләренә лаеклы дәрәҗәгә, хөрмәткә ия булып яшәүләренең өченче мөһим чыганагы да бар иде.

Бу хакта киләсе бүлектә...

*(Ахыры киләсе санда)*

# ТАНЫШТЫРУ СҮЗЕ

*Резидә Әхтәмованы мин Казан дәүләт университеты студенты чагыннан ук беләм. Минем янга беренче мәртәбә килгәндә ул әле беренче курста гына укый иде. Шигырьләрне шул вакытта ук яза торган булган, ләкин тыйнаклыгы аркасындамы, шигырьләрен күрсәтми иде. Соңрак инде Резидәнең барлык шигырьләре белән танышканнан соң, мин аңардан: «Нишләп моңа кадәр аларны яшереп йөрдең?» — дип сораган идем. Ул: «Моңарчы күңелне кәгазьгә бушатсам шул җитә иде», — дип җавап бирде.*

*Әйе, һәр шагыйрь бу этапны үтә. Башта үз күңелен бушатыр өчен яза, ә инде кешеләргә әйтер сүзе күбәя башлагач, күңел байлыгын башкалар белән дә уртаклашасы килә башлый.*

*Ә Резидәнең кешеләр белән уртаклашыр байлыгы бар. Хәзергесе вакытта ул нәшрият өчен үзенең җыентыгын әзерләп йөри. Резидәнең кайбер әсәрләре белән «Идел» журналы, «Татарстан яшьләре», «Вакыт» газеталары укучылары таныш та инде. Шулай ук аның шигырьләре радио һем телевидение аша да яңгыраганы бар.*

*Резидә Әхтәмова шактый үзенчәлекле яза. Ул шигъри образларны артык шәрәләндерми, фикерен кыска һәм тыгыз итеп бирергә тырыша. Ә инде осталык җитеп җитмәгән җирләрдә шагыйрәне хисләр кайнарлыгы һәм эчкерсезлек коткара.*

*Резидә хәзергесе вакытта 3 нче татар гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бүген, хөрмәтле укучылар, Резидәнең сезгә берничә шигырен тәкъдим итәм, бәлки алар сезгә дә кызыклы тоелыр.*

Фәнис ЯРУЛЛИН

# Резидә Әхтәмова

## Ә син беләсеңме?

Ә син беләсеңме —
Бу язларны
Минем сөю алып килде бит.
Хәтта Кояш, минем сөюсмә
Жылы бирче, диеп килде бит.

Ә син беләсеңме —
Хыялыңны
Минем сөю бизәп китте бит.
Агачларда иркә-йомшак бөре
Минем сөю булып типте бит.

Ә син беләсеңме —
Сөюемнән
йолдызлар да бит нур сорады —
Сиңа бирү өчен...
Исәр җил дә
Сөюемнән минем наз алды —
Сине үбү өчен...

* * *

Хаталандым.
Тагын хаталандым.
Тик бу юлы яшьләр
Чыкмады.
Бары көлдем генә.

Болытлы күк,
Саф яңгырын коеп,
Яңа хатам белән...
«Котлады».

* * *

Мин сине яраттым.
Аннан соң югалттым...
Ләкин түгел сине,
Мәхәббәтне.

* * *

Мин алдандым.

Кинәт кенә түгел —
Кечкенәдән.
Бәхетле бул, кызым, дигәндә,
Аның нәрсә икәнлеген
Әнием дә никтер әйтмәде.
Башкалар да аны аңлатмады.
Минем бала күңелемдә
Бәхет төшенчәсе
Алсу буяуларга буялды,
Үсте, зурайды.
Алсу томан беркөн таралды.
Бар да соры төстә икән.
Шыксызлыкны күрмәс өчен
Тиеш идем мин йомарга күзем.
Ә мин, тиле, аның саен
Зуррак ачып күзем карадым:
Мин алдандым мыни?!.

Ә нигә соң
Алсу томан кинәт таралды?

* * *

Җилдән туган сөю түгел иде,
Хисләремне җилдән җыймадым,
Җир һәм күктән алдым.
Яфрак очларыннан җанга җылы тамды.
Кочак-кочак ак болытлар назы
Йөрәгемә сеңеп калды.
Җил бөтерелеп урап килде,
Сөюемне, дулый-дулый,
Тамыры белән тартып алды.
Татлы газапларны, сагышларны
Утка, суга салды.

Хисләремне җилдән җыймасам да,
Хисләремне җилләр тартып алды.

ПУБЛИЦИСТИКА

# ХӘЛЕҢ НИЧЕК, ИЛ КЫЗЫ?

*Мәгълүм ки, без, дистәләгән еллар буена, совет илендә яшәүче хатын-кызлардан да бәхетлерәк җаннар юк, дип, тәкърарладык. Бигрәк тә көннәр язга авышкач, март керел, аның сигезе якынлашканда, ил кызларына мәдхияләрнең ниндие генә ямьый торган иде?! Гомум җыелышларда аларга гына багышланган докладлар укыла, газета-журнал сәхифәләренә аларның сурәтләре басыла, мактау сүзләрен раслау өчен, әллә нинди зур саннар китерелә: «...СССР промышленностендагы барлык эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең — 45, врачларның — 76, укытучыларның 70 проценты хатын-кызлар. Капитализм шартларында кол ителгән, җәберләнгән һәм изелгән хатын-кызлар безнең илебездә, Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә, үз язмышының тулы хокуклы хуҗасына әверелде...»*

*Рәсми органнар гына түгел, кызларыбыз үзләре дә трибунасына да, матбугат битенә дә, чәчрәп чыгып, ярып салалар иде.*

*Шул рәвешле азмы шапырындык?! Бары тамак туклыгын, тәннең шәрә булмавын гына зур бәхеттән санап азмы шөкер иттек?! Шулай яши-яши бүгенге ачыктан-ачык сөйләшү көннәренә, җитешсезлекләребезне барлау мөмкинлекләренә аяк бастык. Нәтиҗәсен чыгар да, кабаттан ялгышмаслык иттереп, киләчәккә юл суз!*

*Табигатьтә — яз, яшәру-яшьнәү чоры. Тагын март керде, хатын-кызларыбызның халыкара күләмдә билгеләнә торган олуг бәйрәмнәре җитте. Шул уңайдан да, илдәге бүгенге хәлләргә хатыннарча бәя бирү йөзеннән дә журналыбызның публицистика бүлеге редакторы* Кояш ТИМБИКОВА *җөмһүриятебезнең кайбер хатын-кызларына мөрәҗәгать итте.*

— Хөрмәтле укытучым, хәерле көн! Хәлләрегез ничек?

**Диләра ТУМАШЕВА, КДУның көнчыгыш телләре кафедрасы мөдире, академик:**

— Хәерле көн! Хәлләрем ярыйсы. Мин гомумән дә зарланырга яратмыйм. Бу язгы көннәрдә, үзебезнең бәйрәм вакытында башны иеп утыру бөтенләй дә килешмәс иде инде.

Сүземнең башында ук гомерләрен туган телебезне өйрәнүгә, аны башкаларга да өйрәтүгә багышлаган галимәләребезне бәйрәм белән котлар идем! Аларга киләчәктә дә уңышлар теләр идем! Безнең хезмәттә җанны рәхәтләндерә торган бер бик нык таяныч бар: ана теле, туган моң, җыр баланың күңеленә шәфкать сала. Мин ышанам: ана теленең җылылыгын тойган бала явызлыкка бара алмый.

Мин бөтен барлыгымны татар телен, аның байлыгын, нечкәлекләрен өйрәнүгә багышладым. Тирәнгәрәк кергән саен туган телебезнең камиллегенә таң каласың. Хәзер безгә татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мөмкинлеге бирелде. Тик бу бары укытучылар кулыннан гына килә торган эш түгел. Бу бөек бурычны, һичшиксез, дәүләтебез үз кулына алырга тиеш. Чыгымнардан да курыкмаска иде. Кадрлар әзерләүгә, әлбәттә, күп чыгымнар кирәк булачак.

Дөрес, галимәләребез арасында да, студентлардан да бу эшкә әзер көчләребез шактый. Мин әле, бу очракта, потенциаль мөмкинлекләрне күздә тотам. Кайберәүләрдә фәнне берьяклырак өйрәнү сизелә. Наданлык көчле. Студентларның да кайберләре кулга тизрәк диплом эләктерү ягын гына чамалый. Галимнәр арасында да җитешсезлекләр — шөкер. Чит ил галимнәре белән авыр аңлашабыз, чит ил телләрен өйрәнүгә тиешле әһәмият бирелмәгән. Сәбәбе социаль шартлар, дияр идем.

Хәзер менә мәктәпләрдә генә түгел, техникум-училищеларда да, хәтта кайбер югары уку йортларында да татар теле кертелә башлады. Кадрларның әзерлеге начар. Кайбер очракларда, бары татарча сөйләшә белгәннәре өчен генә, укытучы булып алалар. Яңа наданнар әзерләнә, дигән сүз. Те-

лебезнең абруен төшерәләр. Кызганычка каршы, милләттәшләребезнең башка тармактагы галимнәре бары тик урысча гына эш алып бара. Монысы да системага барып төртелә инде. Чөнки урысча язылмаган диссертацияне яклау мөмкин түгел иде. Хәтта татар теле яки әдәбиятына караган диссертацияләрнең дә урысча язылуы таләп ителә торган иде. Хәзер генә бу чикләүне туктаттылар. Үзебезнең Академиябез дә оешып килә. Мине дә хакыйкый әгъза итеп сайладылар. Эш җинел булмаячак.

Фәндә хатын-кызга аеруча авыр.

Хәзер мин университетның көнчыгыш телләре кафедрасын җитәклим. Яратып, теләп алынгач авырлыгына чыдарга туры килә инде. Безнен һәммәбездән фидакарьлек таләп ителә шунсыз татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мөмкин түгел, әмма бу эшнең башында дәүләт эшлеклеләре торырга, мәсьәләне дәүләткүләм масштабта хәл итәргә кирәк. Дәреслекләр, кулланмалар, сүзлекләр бик күп кирәк булачак. Чөнки татарчаны җөмһүриятебезнең һәр әгъзасы өйрәнергә тиеш булачак.

Мин әле соңгы вакытта Себер татарлары сүзлеген төзедем. 10 000 сүз теркәлгән аңа. 20 табаклы хезмәт. Ничек чыгарып җиткерермен?! Без бит язган хезмәтне бастыра алмый интегәбез.

— Диләрә ханым, сезнен турыда мин мондый сүз ишеткән идем: «Аңарда шундый киң эрудиция, үзе татар теле белән шөгыльләнә, гаҗәп хәл!» — диләр. Хәтта безгә, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап чыккан башка кешеләргә дә, шундый ук кимсетүне тоярга туры килә.

— Бу нәрсә милләтебезнең абруе хакында сөйли. Ничәмә-ничә еллар буена астыртын сәясәт алып барылды: янәсе, бөтен телләр кушылачак, вак халыкларның теле «йотыла»чак h. б. Әмма тарихны алдап булмый. Безнең халык бервакытта да түбәнлеккә төшмәде. Аның хатын-кызлары арасында да горурланып сөйләрлек шәхесләр җитәрлек: Галимәтелбәнат Биктимерия, Ханифә Гыйсмәтия, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрия, Газизә Сәмитова, Маһруй Мозаффария, Мәхүбҗамал Акчурина... Әдәбиятыбызга зур өлеш керткән бу шагыйрәләрнең иҗаты тирәннән өйрәнүне көтеп ята.

Минем үз әнием дә заманының укымышлысы иде. Ул Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган. Татар теле укытучысы иде. Әтием исә, һөнәре башка булса да, бик моңлы һәм көчле музыкаль талантка ия иде. Гаиләдә милли рухи байлыкның кыйммәтен бик тирәннән аңлыйлар һәм балаларга да аңлаталар иде. Шулай да, күрәсең, сәясәтне алдан аңлап, мине әнием урыс мәктәбенә бирде. Шул ук вакытта музыка мәктәбенә да йөрдем һәм аны уңышлы тәмамлап чыктым. Әмма, һөнәр сайлар вакыт җиткәч, хәтта Мәскәүдәге институтка керү бәхетенә ирешкәч тә, татар телен — анам телен сайлап алганмын. Сабый чактагы тәрбия җиңеп чыккан, милләткә тугрылык җиңгән.

Безнең халык бик көчле бит ул. Милли горурлыгын саклап калучылар да җитәрлек. Мин, мәсәлән, Ленинградта яшәүче Ситдыйка ханым Габдулла кызы Бубины яхшы беләм. Ул үзе — французга, кызы урыска чыкты. Әмма кызы да, хәтта оныгы да паспортларына, милләтем — татар, дип яздырганнар. Ситдыйка апа һәрчак татарча сөйләшә иде. Үзе ул — биология фәннәре кандидаты, әмма телне онытмады.

Сез бу сүзләрдә сәясәт күрәсезме? Шулайдыр шул. Хәзер безнең һәр адымыбыз сәясәткә барып тоташа. Әйтергә кирәк, татар кызлары бу өлкәдә дә актив. Электән үк шулай булган бит: Әминә Мөхетдинова, Заһидә Бурнашева, Абруй Сәйфи, Зөһрә Баймбетова кебек көрәшчеләр бөтен төрки дөньясына мәгълүм. Әмма бүгенге «кайнар» көннәрдә хатын-кызга халкыбызның иң күркәм тагын бер сыйфаты — сабырлыкны, түземлелекне дә истән чыгарырга ярамый. Ул, минемчә, гаиләсенә терәк булырга, ә иҗтимагый омтылышларында, иң беренче чиратта, илдәге тынычлыкны күздә тотарга тиеш.

Көнкүрешме? Анысын мактап булмый инде. Шулай да, әллә ни сыгылып төшмәдек. Без гаиләдә җидәү: балалар, кияү, оныклар бик тату, берберебезгә ярдәм итешеп яшәгәч, ваклыклардан котыла киләбез. Дөресен әйткәндә, миңа җиңел тормыш күрү, гомумән дә, туры килмәде бит. Бишенче класста укыганда ук әнием вафат булды. Ул сугыш еллары, ул генсеклар, рәисләр алмашыну, акча бәяләренең төшүе — әллә ниләр кичереп бетердек инде. Күңелне авырлык баса башласа, хезмәттәге нәтиҗәләрне күз алдыма китерәм дә җиңел булып кала. Без шулай тәрбияләнгән бит инде: илнең кай тарафында гына юк ул без укытып чыгарган белгечләр! Гади укытучылар да, фән кандидатлары да...

Беләсез бит: миңа, татар теле өлкәсендәге хезмәтем өчен, илнең иң зур бүләген — Ленин орденын бирделәр. Мин генә түгел, барлык коллегаларым моны телебезгә карата күрсәтелгән хөрмәт дип кабул иттеләр.

— Сез КПССта да озак еллар әгъза булып тордыгыз бит, әйеме?

— Әйе, утыз елдан артыграк. Бу хәлгә мин бик тыныч карыйм. Без аның уставына, программасына язылган иң яхшы сүзләргә, алга куелган изге максатларына ихластан ышандык. Инде шул документларны иҗат итүчеләр үзләре үк аларны аяк асларына салып таптаганнар икән... бигайбә. Без монда татар теленең абруен күтәрү, аның дәрәҗәсен дәүләт теле дәрәҗәсенә меңгезү өчен күп чыгымнар кирәклеген телгә алдык. КПСС оешмаларында тупланып калган миллионнар, минемчә, нәкъ менә шул максатка тотылырга тиеш иде.

Нишләмәк кирәк, безгә гаделсезлекләрне шактый кичерергә туры килде, тик барын да тыныч кына хәл итәргә өйрәнергә кирәк. Аңлашып яшәүләргә ни җитә?! Бүгенге көннәрдә бу сыйфат аеруча кыйммәт. Бөтен илне сәяси агымнар урап алды. Саксыз гына ычкындырылган бер сүз халык белән халык арасында сугыш чыгарырга мөмкин.

— Диләра ханым, инде боларның барын да онытып торып, иң яраткан ашыгызны әйтсәгез иде!

— Бик теләп ризалашамын. Беләсезме: мин итле ашларны яратам. Иң тәмлесе — үзем әзерләгән пылау. 300 грамм үсемлек маен махсус казанымда кыздырам. Шуңа 600—800 грамм чамасы суган турап салам. Ул да шактый вакыт кыза, алтынсуланып чыга. Аннары маеннан, сөяк-ярыларыннан араландырылган, шакмаклап туралган 1,5 кило ит кушып җибәрәм. Итнең ике төрлесен: сарыкныкын да, сыерныкын да алам. Анысы бик кыйрылып китмәсен өчен азрак су да өстим. Ит йомшарыр алдыннан 800 граммлап кишер (токмачлап турала) салам.

Кишер йомшый төшкәч, дөге исәбенә карап (бер стакан дөгегә — стакан ярым чамасы) су салам. Дөгенең озынча орлыклысы яхшырак. Гадәттә, мин өч стакан дөге әзерлим: бик чистартып юам. Тоз, борыч, аннары, балкашык очына элеп кенә, зерә (әнис орлыгы) дөгегә кадәр сибелә. Шуларга әле тагын 200 граммлап ак май да кушам. Дөгем шулпаны «йотып» бетергәч, арага биш-алты бүлбе сарымсак та төрткәләп куям. Шуннан, өстен каплап куям да, берәр сәгатьтән соң, хуш исле пылау әзер була. Аңа мин йөзем салмыйм. Өрек белән кара җимеш өстим. Аларны аерым әзерлим. Бераз парландырам да сары майда кыздырып алам. Пылауны олы тәлинкәгә соскач, әлеге җимешләрне иң өскә матурлап тезәм. Алар ялтырап, авыздан сулар китереп, пылауны бизәп торалар. Рәхим итеп, авыз итәргә килегез!

— Яраткан артисткам, Наилә ханым, сезнең хәл-әхвәлләр ничек?

**Наилә ГӘРӘЕВА, ТССРның халык артисткасы, җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге бүләге иясе:**

— Хәлләр барыбызда да бер төрледер инде хәзер. Шулай уйлыйм. Һәркем күбрәк көнкүреш, тамак туклыгын тәэмин итү турында кайгыртырга мәҗбүр. Мин сәнгатьтәге матурлыкларга сокланып кына яши идем. Инде шомлана башладым: әллә соң бөтен гомер алданып узганмы? Бу базар икътисады дигәннәре бөтенләй каушатып калдырды. Баштарак, ач итмәсләр әле, хөкүмәтебез бер чарасын табар, дип ышанып яшәдем. Талоннар өләштеләр. Тик, аларга ризык алып кайтыр өчен, көн чиратта уза.

Көзен бөтен театр белән бәрәңгегә йөрдек, колхоз-совхозларга. Хезмәтләре ашамлык тирәсендәге тамашачылар хәлне сорашалар: сиздереп куялар, миңа берәр ризык кирәкмиме?! Кирәкмәгән кая инде!? Күз карашыннан үк аңлашыладыр, мөгаен. Шул да булдымы халык артисткасының хәле?! Үзем табынган сәнгатем алдында ояла башладым әле мин.

Улым Фәрит (ул да театрда эшли, режиссер), минем шулай тирәннән борчылуымны тоеп, үзенчә киңәш бирә: «Син, әнием, укы, укы, тынычлан!» — ди. Укуын да укыйм инде, тик күңел түрендәге шомлы уйлар бер генә мизгелгә дә артка чигенми. Кайчан гына тынычлап иҗат итәргә мөмкинлек булыр?

Үч иткәндәй, соңгы вакытта бөтен барлыгыңны багышлап өйрәнә торган тирән эчтәлекле рольләре дә азаеп китте. Дөрес, соңгы вакытта Т. Миңнуллинның «Илгизәр плюс Вера» исемле пьесасы буенча куелган спектакльдә Мария ролен башкардым. Көнкүреш ыгы-зыгыларыннан арынып торырга ярап куйды. Иҗади рухлану булмаган чакта аеруча кыен, колак төбемдә гел Тукаймның:

*«...Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чонки ак ди алмадым.*

*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, остеннәрне яклый алмадым.*
*Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, доньяны пакьли алмадым,*

— дигән сүзләре яңгырап тора.

Әле, Тукай булып, ул да шундый төшенке дәверләр кичергән. Безгә ни сан инде? Мин бу очракта хатын-кызларыбыз өлешенә тигән тигезсез корәшне күз алдында тотам. Җомһүриятебезнең җитәкчеләре арасында да хатын-кызлар юк дәрәҗәсендә. Башка тигезсезлекләр шуннан киләдер, мөгаен. Чөнки безне чын күңелдән аңлаучы юк. Ничә еллык тарихы булган театрыбыз нинди талантлы кызларны үстерде, әмма рәсми төстә бәяләнүчесе юк. Кая СССРның халык артисткаларыбыз? Ул исемне алган Хәлил ага. Фоат абый кебекләргә тиң торырлык кызларыбыз юк идемени безнең?! Бар иде бит, талантлары һич тә ким түгел иде, әмма исем бирсенә дә эләкмәде. Нинди фидакарь җанлы Сара ханым Садыйкованы күпме интектерделәр? Мөнә шулай... Сөйләсәң — сүз, тортсәң — күз, дигәндәй, бу коннәрдә җанны әнә шуңа охшаш авыр уйлар телгәли.

Шулай да әңгәмәбезне гел караңгы фикерләр белән генә очлыйсым килми. Артистларыбыз тәмам бетешкәннәр икән, дип уйламасын укучылар. Театр әһелләре элек-электән халыкка шәфкать күрсәтү юлында бәхет тапкан. Әле дә шул гадәткә тугрылыклы без. Билет бәясен күтәрмәскә тырышабыз. Халыкны биздермәскә иде!

Кайберәүләрне безнең театр эшлекләләре берлегенең РСФСР берлегеннән чыкмавы аптырата. Мин моның сәбәбен өзеп кенә әйтә алмыйм, чонки бу мәсьәлә уртага салып тикшерелмәде. Һәрхәлдә, мин андый гомуми җыелышта булмадым. Татарстанга тулы мөстәкыйльлек даулаганда бары артистлар гына, безгә акча җитми, дип, халыктан аерылып калмаслар, шәт. Рәсәйнең үзендә дә әллә ни зур байлыклар күренеп тормый бит әле: Петербург булып Петербургта ипигә чират торалар. Рәсәйнең мөлкәте, безнекедәй кечкенәрәк җомһүриятләрнең малын җыеп барганга гына, күбрәк булып күренәдер инде. Икенчедән, безгә әллә ни күп кирәкми бит, мулдан яшәргә өйрәнмәгәнбез. Арыш ипие белән сөтле чәй булса, шөкер итә безнең халык. Азат тормышта шунысы да татлы тоела. Халык ни кичерсә, безгә — шул. Минемчә, татар артистлары — мөстәкыйльлек ягында. Бөтен шатлыгыбыз да, кайгыбыз да — туган халык, туган җир бит безнең, шулардан аерылырга ярамасын!

— Инде соңгы сорау, Наилә ханым — яраткан ашыгыз?

— Мин мич ашларын бик яратам. Бигрәк тә гөбәдияне. Мин аны пешерергә дәү әниемнән үк өйрәнеп калган идем. Дөрес, хәзер мондый ризыклар белән артык мавыгырга туры килми, шулай да үземә генә хас кайбер якларына тукталып китим әле.

Мин гөбәдия пешерүне корт кайнатудан башлыйм. 1 литр сөт, 1 литр катык, ярты кило чамасы эремчекне, бергә кушып кайнатам. Кызарып, куера башлагач, тәмене карап — шикәр комы, 100 грамм чамасы атлан май салам. Акрын гына кайный бирә. Суы беткәнче. Минем пылау пешерә торган казаным бар, корт кайнатырга да бик шәп ул.

Аннары чүпрә, бераз шикәр комы, атланмай, үсемлек мае, 1 йомырка, җылы сөт кушылган камыр куям. Камырым бер-ике тапкыр күпергәч, ул әзер, дигән сүз.

2 стакан чамасы дөгене, бик шәпләп юып, бөрттереп алам. Аны өч тигез өлешкә бүләм. Аннары йөзем җимешен, 3—4 йомырканы әзерлисе генә кала инде. Башкаларныкыннан аермалы иттереп, мин җәймәгә иң әүвәл бераз май сибәм һәм кортны түгел, дөгемнең бер өлешен җәям, аның өстенә кортны тигезләп салам. Корт өстенә дөгемнең икенче өлеше төшә, аннары — йомырка (аны кыргычның эре тишекләресеннән удырып чыгарам) шуңа калган дөгене җәеп җибәрәм. Иң өскә — йөзем җимешләрен тезәм. 400 грамм чамасы эретелгән ак май сибәм.

Гөбәдияне бары тик табада гына пешерәм. Талгын утта бәрәр сәгать тора ул. Мин аны, гадәттә, кунакларым табынга утыргач, мичкә тыгам. Салкыннарын, шулпалы ашларны ашаган арада, гөбәдиям бик матур булып пешеп җитә. Кырыйлары челтәрләнгән, өстенә әлбә оны сибелгән бу ризык сәнгатьнең бер әсәрен хәтерләтә сыман...

— Фәния ханым, сезнең хәлләр ничек?

**Фәния ХУҖАХМӘТ, «Милләт» газетасының мөхәррире:**

— Хәлләрем ярыйсы. Газетаның яңа санын чыгару мәшәкатьләре артыннан йөрим. Беләсез бит инде: безнең бу газета укучыга Бөтенсоюз та-

тар иҗтимагый үзәгенең кылган эшләрен, максатларын, киләчәккә планнарын җиткереп бара. Аны чыгара башлаганда иң көчле теләгем бер генә кебек иде: автор ни язса, шуны, һичничек тә үзгәртмәгән хәлендә, укучыга ирештерү. Җөмһүриятебезнең зур-зур газета-журналларында эшләдем, күбесендә әсәрләремне бастырдым, тик бер генә язмам да үзгәрешсез чыкмады. Йә кыскарталар, йә төзәттертәләр. Иң яманы — бөтенләй кабул да итмиләр. Басмауның сәбәбе — әсәрнең начарлыгы, дисәләр бер хәл иде. Алай түгел. Мөхәррирргә синең фикер ошамый. Шул сәбәпле, әйтер сүзең укучыга ирешми кала торган иде.

Шундый гаделсезлекләргә чик куелыр көнне көтә-көтә күпме гомер узды?! Һәр яңа фикергә аяк чалып утыручылар кайбер газета-журналларны һаман үз кулларында тота әле. «Милләт» газетасы шушындый фикри артталыкка каршы чыгучы рәвешендә дә үрнәк булырга тиеш.

Иҗат якларымы? Хәзерге көндә, иҗат, дип, нәрсәне генә санарга икән соң? Миңа калса, «Милләт»не бастырып тарату да бу эшкә иҗади мөнәсәбәт таләп итә. Кемгә барып, сүзне ничегрәк башлау турында төннәр буе баш ватып ятам. Инде, газета мәнфәгатьләре артыннан йөргәннән соң, бераз буш вакыт тисә, язарга тотынам. Мәкаләләрем газеталарда күренә тора. Зуррак күләмлерәкләре яки әдәби әсәрләрем киләчәктә чыгар әле, дип уйлыйм.

Хәзерге көннәрдә Америка язмаларымны рәткә салып утырам.

Белгәнегезчә, мин бит күптән түгел, АКШка барып, кунак булып кайттым. Сәфәремнән алган тәэсирләр мондый кыска әңгәмәгә генә сыймый. Әңгәмәгә генәме соң? Әле үз башыма да сыеп бетмиләр. Бу — чит җирләргә минем беренче чыгуым. Башта Европаны, Африканы-фәләнне күреп кайтып, аннары АКШка очсаң — бер хәл иде. Җитмәсә, илебездәге тормыш-көнкүрешнең дә тәмам соң чигенә килеп терәлгән чагы булды. Әүвәлгечә йокымсырап кына яшәгән, чагыштырмача тамак тук, өс бөтен дәверләрдә чыгып китсәм дә, бу кадәр үк тәэсирләнмәс идем.

Анда күргәннәр бөтен көткәннәрдән дә, укыган-ишеткәннәрдән дә узып китте. Кайтып, үзебезнең ачлы-туклы җиребезгә аяк баскач, элекке эзгә төшеп, яши башлаганчы, берничә ай вакыт кирәк булды. Адәм баласының тегендәгечә дә, бездәгечә дә яши алуын үз күзең белән күрү бик мөһим, минемчә. Ә бит бездәге миллионнарча кеше адәмчә яшәүнең ни икәнен дә белмичә, белә алмыйча якты дөньядан кичә.

Мин Калифорния штатында яшәүче татарларда кунак булдым. Күбесенең үз йорты бар. Ул йортларның әфлисун агачлары үсеп утырган бакчада икәнлеген дә, шул бакчалардагы бассейннарда коенып көн башлауларын да, гаиләдәге һәр кешенең махсус машинасы булып, әле тагын, андыймондый хаҗәт өчен, артык бер машина тотуларын да әйтеп тормыйм. Шуны гына гаҗәпләнеп уйлыйм: без хәтта үзебезнең хәерчелек дәрәҗәбезне дә чамалый алмый яшибез икән...

Төзелештә эшләүче, үз һөнәрен биш бармагыдай белүче дус кызларым бар минем. Берәр объектны тизрәк тапшырырга кирәксә, аларны ялсыз-нисез эшләтәләр. Соңыннан мастер аларга унар сум өләшеп чыга. Әй сөенәләр шуңа минем дуслар.

Мин йөргән җирдә, американнар берәр эшкә алынса, эш кушучының аларга сәгатенә 5 доллардан да кимрәк түләргә хакы юк. Закон шундый. 5 доллар, безнең бүгенге бәяләр буенча, 550 сум дигән сүз! Сәгатенә бу!

Берсендә мин асфальт тигезләүче хатыннарны шәйләп алдым. Озата баручым Рифат әфәндедән машинаны туктатуын үтендем. Карап торам: бездәгечә көрәкләп измә ташу да, авыр ботинка белән таптану да, коточкыч цилиндрны тартып азаплану да юк. Барысын да машиналар эшли. Шулай да сорадым:

— Ник сез бу кадәр авыр эштә интегәсез? — дидем.

Хатыннарның барысы бергә көлеп җибәрделәр. Анда, гомумән, бөтен кеше гел көлеп-елмаеп йөри. Әлеге хатыннар миңа болай җавап бирде:

— Юри алындык без бу эшкә,— диләр.— Моңарчы бездә хатыннарга бу хезмәт тыела иде. Протест белдереп, үз тигезлегебезне яклап чыктык. Инде менә шул «авыр» эштә йөрибез — бер авырлыгы да юк, бөтенесен машина башкара...

— Хезмәт хакыгыз күпме соң? — дим.

— Сәгатенә — 35 доллар,— дигән җавапларын ишеткәч, егылып китә яздым. Бу бит, безнеңчә, сәгатенә — 3850 сум. Долларның берсен йөз дә ун сумга саталар бит!..

Калыргамы? Анда — АКШтамы? Юк. Андый теләк туса, мөгаен, җае да чыккан булыр иде. Анда бөтен нәрсә эш кылуга бәйле, мин исә монда

да бик күп һөнәрләргә өйрәнгән идем. Урам себерүдән башлап, озын манаралы краннарны йөртүгә кадәр — барысын да беләм. Өстәвенә, АКШта татарларны эшкә бик теләп тә кабул итәләр икән. Әүвәлрәк килүчеләр сынатмаганнар, күрәмсең. Тик чит илдә калу турында бөтенләй уйлаганым юк минем. Нигә әле андый адым ясарга тиеш мин? Аерым ташпулатым-фәләнем, машинам булмаса да, кешедән ким яшәмим. Хәзер сәясәтебез дә уңайга барып ята. Гап-гади авыл баласы килеш тә океан артларыннан әйләнеп кайттым бит әле! Анда да безгә әллә ни кызганып-мескенләштереп карау сизмәдем. Барысы да миңа телен, моңын, җирен саклап калган милләтебезнен үз җирендә үзе яраткан эшне башкарып яшәү бәхетенә ирешкән горур кешегә карагандай булдылар. Алып барган бүләкләремне дә: Арча читекләрен, Чистай сәгатьләрен, хәтта урыс аракысын бик теләп кабул иттеләр.

Шулай да телне белмәү бик начар икән. Баксаң, университет бетердем бит инде — бернигә дә өйрәнмәгәнбез кебек. Чит илдә сукыр кеше кебек йөрисең. Чит телләрне белмәү — системабызның махсус сәясәтедер, мөгаен.

АКШтагы татарлар ике-өч чит ил телендә сөйләшә. Гарәп, латин, хәрефләрендә басылган татар китапларын да рәхәтләнеп укыйлар. Ислам диненең нечкәлекләрен дә безгә караганда мең мәртәбә яхшырак аңлыйлар. Мин аларның фикер йөртүләрен уйлап-уйлап карадым да, шундый нәтиҗәгә килдем: бездән он суы да, тоз суы да юк икән. Биртелсә дә биртелер икән адәм баласы! Тәмам коргаксыганбыз...

Яраткан ашларым күп минем. Итле, эче-төче ризыкларны хуп күрәм. Бу юлы итләч чебештән (яшь тавык булса да ярый) кыздырма пешерүне искә төшермәкче булам.

Тавык түшкәсен ике яки дүрт өлешкә бүлеп, агач тукмак белән төйгечлисең. Сөякләр, буынтыклар яргаланырга кирәк. Шул төелгән кисәкләрне, «аджика» дигән ботка белән буташтырып, 2—3 сәгать тотасың. «Аджика» булмаганда, бутар өчен, суган, борыч, сарымсак, лавр яфрагы кебек тәмләткечләр алына. Бераз аш серкәсе бөркесәң дә ярый. Шул әзер кисәкләрне сары май эретелгән кызган табага тезәсең. Ит кисәкләре өстенә яссы капкач, бу капкач өстенә тагы бер авырлык (әйтик, су тутырылган чәйнек) куеп итне бастырыклыйсың. Унбиш-егерме минуттан соң тавык ите кисәкләрен әйләндерү кирәк. Тагын шул кадәр вакыттан соң әчкелтем-төчкелтем тавык ите әзер була. Аны өлешләп биргәндә, тәлинкә читенә яшел борчак, тозлы кәбестә, сарымсаклы помидор боткасы, керән, тырма кебек тәмләткечләр өстәү яхшы.

— Хәлләр ничек, Диләра?

**Диләра ЗӨБӘЕРОВА, язучы:**

— Бүген татарның барлык хатыннары нинди хәл кичерсә, минеке дә шундый. Күзләр тәмам ачылды. Без өч мәртәбә «шок» хәлендә, ягъни өнсез хәлдә калдырылганбыз. Башта 1917 елгы революциядә, аннары Хрущев-Брежнев чорында, соңыннан Горбачев-Ельцин алып барган сәясәттә. Башта Ленин безгә оҗмах вәгъдә иткән: Хрущевы, Сталинны сүгеп, үзенә ышаныч казанды; Горбачев исә Лигачев һәм Ельцин белән ыгы-зыгы килештеләр... Илдә тулы демократия булырына ышанып шатланыштык. Әлегә берсе дә барып чыкмады кебек.

Бик күп укыйм. Ашарга да вакытым юк. Укый-укый Ельцинның да кемлегенә төшендем. Минемчә, анысы да гап-гади карьерист. Тәмам суындым. Хәзер без — дәрья уртасындагы ишкәксез коймәдә йөзүчеләр кебек. Нинди ярларга барып тукталырбыз — һич белерлек түгел.

Матди якны әйтәсенме? Без моңарчы ул хакта телгә алып та сөйләшми идек, хәлкә хәтта. Сорауның урынсыз түгеллеген аңлыйм. Эчтән генә шөкер итеп яшим: ярый әле әби-бабадан, дигәндәй, электән калган юрган-мендәрләр бар, күлмәк-ыштан да җитәрлек. Брежнев заманында фатир биргәннәр иде... Пенсиям, кеше-кара килмәгәндә, үземне ач итмәскә җитә. Иртәгә ни буласын белгән юк. Базарга йөрим, анда бөтен бәяләр көн саен үсеп, үзгәреп тора, пенсиянең киләчәктә җитмәве дә бик ихтимал.

Зарланасым килми, шулай да гарьлек: сугыш юк, ни юк илдә — ярымачлык. Мин — сугыштан соңгы карточка системасын кичергән кеше, тик яшьләр ни уйлар?! Гарьлек.

КПССка мөнәсәбәт шуннан чыга инде. Аның кинәттән бетерелүе хәтта миңа да сәер тоелды. «Хәтта миңа да» дию шуннан — мин аның бер мәтәләчәген сизенә идем инде. Күзәтә килдем: иң алдынгы фикерле кешеләр анардан чыктылар. Генсеклыкка Горбачев килгәч, ул барын да аңлатып биргәч, акыллыларның күпчелеге китә башлады. Аларны тәнкыйтьләргә тотындылар: көймәне ташлап китүче күселәр, диделәр. Тик мин

аларны аңладым. Бу — беренче китүчеләр — партиягә иң ихлас ышанган жаннар иде, алдануларын аңлап чыктылар. Шул чакта ук миңа: «Син ник һаман китмисең?» — дип сорау бирүчеләр булды.

Китмәдем. Хикмәт шунда: мин бит, партиягә кергәндә үк, аның нинди коточкыч оешма икәнлеген белә идем. Әтием репрессиягә эләкте. Аның аркасында әниемне дә интектереп йөрттеләр. Мин үсеп житкәндә, илдә партия бердәнбер власть иясе иде. Комсомолына көчләп керттеләр. Партиягә, әштә башкача ижат мөмкинлеге булмаганга, үзем кердем. Диплом бар, язу сәләтем бар, партбилет булмаганга гына, теләгән эшкә алмыйлар. Кердем. Аннары, бу кәмитнең азагы ни булып бетәр икән, дип, соңгы сәгатенә кадәр чыкмадым инде.

Кырыгынчы еллар ахырында Алабуганың педучилищесында укыдым. Шунда Кырымнан сөрелгән шагыйрь Кәрим ага Җаманаклы белән таныштым. Ул миңа Сталинның кабахәтлекләре турында сөйләде. Башында андый явыз кеше торган партиянең озак яшәргә хокукы юк икәнлеген мин шунда ук аңлаган идем.

Инде ижатым турында да әйтим. Соңгы вакытта менә шул бөтен кичергәннәремне йөрәктән уздырып автобиографик кебегрәк бер әсәр яздым. Елый-елый. Әле кемгә тәкъдим итәргә дә белмим. Узган ел «Халкым хаклы» исемле очерклар жыентыгым чыкты. Теләгәннәремнең яртысын да кертмәгәннәр. Китап нәшер итә башласаң, кемнәр алдына барып кына баш ияргә туры килми?! Минем андый «осталык» юк, үзең беләсең. Инде бу — үзәкне ярып чыккан документаль әсәремне нишләтерләр?

Шулай да утыз елдан артык язган әсәрләремдә үкенерлек нәрсә күрмим. Күп елларым «Азат хатын» журналында узды. Гел авыл кешеләре турында яздым. Авылда «ура!»лар бик күп булмады бит ул. Күбрәк тәнкыйть итә идем. Шулай да, әгәр ул журналда хәзер эшләсәм, бөтенләй башкача язар идем, дип уйлыйм. Әле «Огонек» журналыннан рәссам Натан Альтманның — Ленинның портретларын ясап дан алган Альтманның — истәлекләрен укыдым. Теләсәң ничек аңла: «...Мин ул кешене бервакытта да яратмадым,— дип яза шул рәссам.— Беренчедән, ул коточкыч вак жанлы, күпсүзле иде. Икенчедән, ул үзе берәүне дә тыңлый белми һәм берәүгә дә сөйләргә ирек бирми иде. Халык вәкилләрен тыңлый, кабул итә, дигән уйдырмалар — адәм көлкесе. Өченчедән, ул — гомумән, безнең кеше түгел...»

Мин, жүләр, Ленинга ышана идем бит. Телем дә: «Лилин бабай», дип ачылган. Гажәп: хәзер астрологларга, Мөхәммәт пәйгамбәргә ышана башладым. Иманнар үзгәрә. Беләсеңме, бер астролог хәтта Октябрь революциясен дә алдан әйткән: «Бик күп кан коелыр, дөньяның алтыдан бер өлешендә афәт булыр»,— дигән. Без шул афәтне бәхетле киләчәккә тиңләдек. Бүген әнә «Аргументы и факты» газетасында Рязаньның О. Васильева дигән маржасы, баласына кием сорап, бөтен илгә белдерү яза. Кешеләрнең моннан да түбәнрәк мәсхәрәгә төшүен тагын кайсы жәмгыятьтән эзләргә икән?!

Менә сиңа марксизм-ленинизм! Маркс тәгълиматы ике йөз елга да житмәде. Ленинныкы аннан да аз. Ә Мөхәммәт пәйгамбәрнең «Корьән»е өр-яңадан өскә калкып чыкты. Әллә ниләр бар — белмибез генә. Оча торган тәлинкәләр турында сөйлиләр — ышанмадык. Мөхәммәт пәйгамбәр бу хакта әйткән бит. Аңа да колеп карадык. Хәзер әнә христианнарның да бер өлеше мөселманлыкка күчә. Безгә караганда, күп мәртәбә укымышлырак кешеләр. Без көләбез. Ә аларның тәгълиматы гади: исламдагы сафлык-пакьлек, намаз, тән күнегүе, ураза-жанны чистарту, урлашмау, үтермәү, олыны олылау, кечене өйрәтү һәм башка иң изге гадәтләр...

Табигать безгә бөтен серләрен дә ачып бетерми һәм... дөрес эшли, без, кешеләр, андый олылауга лаек түгел.

Жәмгыятебезнең ун елларча көткән өметен чүплеккә чыгардылар, барысы да власть өчен көрәшкә әйләнде. Минем күзне Окуджава, Сахаров, Солженицын кебекләр ачты. Горбачевның иң якын киңәштәшләре гап-гади әчкечеләр булып чыкты, ГКЧП ясадылар...

— Диләрә дустым, синең яраткан ризыгың бармы?

— Менә сиңа мә! Син кинәттән такыр жиргә төшереп бастырдың бит әле. Яраткан ризыклар күп. Тик мин бу юлы укучыларыма мине ачлыктан саклап калган, бүген дә яраткан ашларым рәтендә йөргән, сугыш елы ашын тәкъдим итәр идем. Хәер, аларның бүген дә кирәк булуы бик ихтимал.

Иң беренчесе — умач. Аны, без кечкенә чакта, чип-чиста суга гына пешерәләр иде. Шулпасын да, умачын да. Мин аны хәзер тәмләбрәк пе-

шерәм. Сөяклерәк итләрне сәгать буе кайнатып бик тәмле шулпа ясыйм. Шуна бәрәнге турап салам, суган. Умачны бер йомыркага уам. Йомырканы туглыйсың да туглыйсың, бераз тоз сибәсең. Шуңа күп кенә он саласың. Әлеге катнашма камырга әйләнмәсен, уалып, бөтерчекләнеп торсын. Шул катнашманы уасың-уасың да, умач әзер була. Анда тары ярмасы, солы ярмасы, борчак сымаграк бөтерчекләр барлыкка килә. Бераз ваграклары да була, бөтенләй он хәлендә калганыннан да куркырга кирәкми. Шуны шулпаңа салып җибәрәсең дә, күперен чыгуга, утны сүндерәсең. Катык катып ашасаң, тәнеңне йотудан сакланырга кирәк инде!

— Әссәламегаләйкем, Рәшидә остабикә! Хәлләрегез ничек?

**Рәшидә ИСХАКОВА, Казандагы Мәрҗани мәчетендә хатын-кызларга дин сабагы өйрәтүче остабикә:**

— Вә галәйкемәссәлам, кардәш. Хәлләр аллага шөкер, зарланырга язмасын, ни барына шөкер итә белергә кирәк, рәсүлебез Мөхәммәт пәйгамбәр шулай өйрәтә. Әлхамделилләһи шөкер раббил галямин! Адәм баласына һәрчак сынаулар килеп тора, кыенлыклар китеп тора. Бер генә халәт тә мәңгелек түгел: шатлыклары да, кайгы хәсрәте дә, малы да, хәерчелеге дә — һәммәсе уза. Безгә хәзерге, көнкүрештәге гамәли читенлекләрне үткәреп, рухиятебезне тәрбияләргә бирелгән мөмкинлекләр өчен мең шөкер уку тиеш. Әле кайчан гына бихисап мөэмин-мөселман кардәшләр, хезмәтләренә хилафлык килүдән, ач калудан шикләнеп, мәчетләребез ягына борылып карарга да куркып яшиләр иде. Хатын-кызны әйткән дә юк. Бүгенгесе көнне — Аллаһе тәгаләнең биргәненә мең шөкер — барысы да үз ихтыярыбызга тапшырылды. Җөмһүрияттә мәчетләр арта, аңа йөреп тәрбияләнүчеләр ишәя.

Мин үзем хатын-кызларыбызны дин сабагына өйрәтәм. Инде минем кебек үк мөгаллимәләр дә ишәйде. Бүгенге көндә җиде йөзләп хатын-кыз җәмәгате безнең сабакларны ала. Шәригать йолаларына, иң әүвәл, намаз укырга өйрәтәбез. Гарәп хәрефләрен төшендерәбез. Коръән Кәримне укырлык дәрәҗәгә ирештерәбез.

Берничә ел рәттән Мәккә-Мәдинәгә барырга рөхсәт сорыйды. Беренче елны кызым белән киявем барып кайттылар. Ике балалары миндә торып торды. Ходаның бирмеш көне, берсендә, хаҗ юлына чыгучылар зур афәткә тап булганнар, дип хәбәр тараттылар. Коелыплар төштем, бихисап корбаннар арасында минем газизләрем булуы да бик ихтимал иде бит. Шулай да сабыр итәргә булдым. Ислам динендәге иң күркәм өйрәтмәләрнең берсе — сабыр итү. Шөкер, ул коточкыч афәткә безнең Татарстан хаҗи-хаҗияләре эләкмәгән булып чыкты.

1991 ел. Аллаһе тәгаләнең ризалыгына тапшырып, үзем дә хаҗ юлына сәфәр чыгып, исән-имин әйләнеп кайттым. Мең шөкер. Шул изгелекләрне миңа ирештергәне өчен динебезгә тагын да бирелебрәк хезмәт күрсәтергә телим.

Безгә гел дин белән генә шөгыльләнеп утырырга да туры килми, кайбер хатын-кызларга киңәш-табыш, ярдәм күрсәтүне дә кайгыртам. «Татар кызлары» кичәләренә дә катнашам, хәтта сәяси митингларда чыгыш ясарга да туры килә.

Әле күптән түгел бер мәҗлестә катнаштым. Мәрхүмәне искә алу мәшәкатьләре беткәч, донья хәлләрен сөйләшүгә күчтеләр. Тыңлап кына торам. Берсе әлеге кыйммәтчелек заманында беләзек-йөзекләр ала алмый калуына офтанды. Икенчесе ризык табыштыру мәсьәләсенә күчте, гәүдәсенең юанаеп китүеннән, нәрсә генә ашап караса да, билен нечкәртә алмавыннан зарланды. Сүзләрен бүлеп кисәтеп куйдым:

— Мал җитмәүгә офтанмагыз,— дидем.— Табылмаган мал тау хәтле. Әмма ләкин барысы да кала. Доньяда гадел яшәү өчен тырышырга кирәк. Буй-сыныгызны зифа-күркәм итәсегез килсә, менә безнең ислам дине тәрбиясен тотыгыз: 6 мартта сәхәргә керәбез, 7 сеннән ураза башлана. Бөтен артык авырлыкларыгыздан арынырсыз, җиңеләеп, сихәтләнеп калырсыз,— дидем.

Кызыксындылар. Сәхәрдә, авыз ачканда ниләр ашарга яраганлыгын сораштылар. Менә сезгә дә әйтәм: мөселман кешесенә ризык аерырга рөхсәт юк. Хәләл көч белән табылган, хәрәм булмаган һәр ризык тәнгә сихәт бирә. Сәхәрдә дә, авыз ачканда да һәммәсе ярый. Арыш ипие белән сот ашыйсыңмы, бәрәңге пешереп аласыңмы, манный болгатасыңмы, коймак чыжлатасыңмы — барысы да үз ихтыярыңда.

Безнең халык ураза чорында авыз ачу мәҗлесләре үткәрүчән. Укый белгәннәрне, алдан ук хәбәр биреп, чиратлап кунакка йөртәләр. Казанда кайберәүләр, өендә кунак-төшем уздырырлык мөмкинлеге булмаганнар,

бөрәр төрле ризыкны, ишләрәк пешереп, мәчеткә китерә. Мондагы кайбер карт-карчыклар ике намаз арасында, өйләренә кайтып тормастан, мәчеттә генә авыз ача.

Кичерә күргез: мин бу очракта бер генә ризыкны алып аерып күрсәтә алмыйм. Әйтәм бит: хәләл көч белән табылган һәр ашамлыкны ләззәт белән кабул итәргә кирәк. Гомерем буе эшләп ашадым, пенсиягә чыктым, хәзер, әлхамделиллаһи шөкер, иң изге юлларда йөрер мөмкинлегем бар.

— Фәридә ханым, хәлләрегез ничек?

**Фәридә ГАЙНУЛЛИНА, профсоюзларның җөмһүриятебез советы рәисе:**

— Минем хәлләр — икеле. Шәхси яктан, гаиләмне исәпкә алганда, шөкер! Барыбыз да исән-сау, ирем миңа булыша... Эшемне телгә алсак, мондагы авырлыклар — һәр кешенең тормышындагы кыенлыкларга килеп тоташа. Бик тырышып, әллә нинди зур эшләр башкарган булып йөрим — халык көнкүрешенең авырлыгы белән чагыштырып караганда, барысы да бик кечкенә булып кала. Бер кешенең пенсиясенә бер сум гына арттыру өчен дә миңа мең ишекне шакырга туры килә. Безнең профсоюзлар эше менә шундый. Шушы хәл миңа үз эшемнән канәгатьләнергә мөмкинлек бирми.

Хатын-кызларның хәлен җиңеләйтү, сәләтлеләрен җитәкче постларга күтәрү — тагын да четереклерәк. Бу юлда без, хатын-кызлар, үзебез дә бер-беребезгә гел аяк чалабыз. Уйлап кына карыйк: Даимә ханым Шакирҗанова, Дания ханым Хөсәенова һәм башкалар, вакытында, бик зур урыннарда түрә иделәр. Шуларның берсе берәр татар кызын югарырак постка күтәрү турында авыз ачтымы? Юк. Безнең бөтен бәлабез дә шунда. Бер-беребезне олылый белмибез, ярдәм кулы сузмыйбыз, дәү әнием әйтмешли, «олыгаймыйбыз». Бер-беребезне «олыгайтмагач», безне кем күтәрсен?! Милли кадрлар арасыннан татар хатыннарын үстерү турында бернинди дә кайгыртучанлык күрсәтелмәде. КПССның иҗтимагый фәннәр академиясенә җибәрелә торган шәкертләр рәтенә дә гел урыс марҗалары гына теркәлә иде. Милли кадрлардан анда барган берничә ханымны беләм. Тик алар, үз урыннарын яулап алгач, үзләренә көндәш тудырмау хакында гына баш ваттылар.

Мин бу бушлыкны тутыру өчен җан атам атуын, тик электән килгән гадәт аякка тышау сала. Син — милләтче, дип, күз дә ачырмыйлар. Татар кызларын күтәрә башласам, мине милләтчелектә гаеплиләр. Әле Баштанюк заманында ук. Ул әйтә:

— Син бит — милләтче,— ди.

— Уйлап кара әле! — дим.— Мин, туган телемә кирәкле вакытымны бүлеп, сезнең урыс телен камил өйрәндем, хәзер һәр ике телдә дә рәхәтләнеп сөйләшәм. Урысча аңлашуы җиңелрәк тә әле. Ә син миңа татарча сәлам бирә аласыңмы, ичмасам?! — дидем.

«Шым» булды Баштанюгым. 1972 елдан бирле, КамАЗ төзелешенә дип, безнең җиребезгә килеп урнашкан кеше безнең телдә «әлифне таяк дип» тә белми. Шул шәхес, татарлар исеменнән Мәскәүгә китеп, әллә кем булды. Мин мондый «милли дуслык»ны яклый алмыйм, әлбәттә. Татарстанда җитәкче постларны биләүче кешеләребез татар телен, һичшиксез, белергә тиеш. Без бу камиллеккә ирешә алмадык әле. Аларга, иң кирәкле сүзләрен әйтергә дип, безнең әби-карчыкларыбыз килә. Аңлаша алмыйча китеп баралар.

— Фәридә ханым, авыл җирендә яшәүче кызларыбыз турында да бераз сөйләшсәк иде. Мин яңа гына Югары Осланның саф сулы чишмәләр, урман каплап алган таулар куенына сыенып яшәүче Берек авылында булып кайттым. Сугышка кадәр гөрләп яшәгән шул авылда бүген мәктәп тә, медпункт та, клуб та, кибет тә юк. Бары пенсионерлар гына торып калган. Ике яшь гаилә бар барын. Шуларның берсендә бала үсеп житкән — мәктәп юк, ул өйдә утырырга мәҗбүр булган.

Мондый кыенлыкларның күбесе хатыннар җилкәсенә төшә. Терлек азыгына бутар өчен ашлыкны да, сез — пенсионер, дип, совхоз аларга аз бирә икән. Ашлыкны мул алучылар исә аны бары тик аракыга гына алыштыра, ди. Аракыны күрше авыл кибетчесе, шәфкатьләнеп куйса, бирә, теләмәсә — юк. Кыскасы монда һичнинди закон да санга сугылмый...

— Мондый ук хәлгә калган авыллар күп түгел. Киресенчә, хәзер тормыш-көнкүреш ныклыгы авыллар кулына күчеп бара. Шәһәрдә тамыр җибәрә алмый интеккән яшь гаиләләр кабат ата-ана йортына, авылга китү ягын карый башлады. Тик мин әлеге ачык мисалдан да качып котыла алмыйм. Бу очракта профсоюз гына әллә ни зур үзгәреш кертә алмас, әлбәттә, шулай да мин кызыксынырмын. Төп җавапны Советлар, депутатлар бирергә тиеш.

Профсоюзлар хатын-кызга жиңеллек булдыру юнәлешендә шактый-га иреште кебек: төнге сменаларны киметү, авыл хуҗалыгында пенсияне алданрак бирү, күп балалы аналарга ярдәм... Әле соңгы вакытта мин бик алга киткән илләрдә — АКШта һәм Швейцариядә булып кайттым. АКШта профсоюз әгъзасы саналган хатын-кызларның съездында катнаштым.

Безнең омтылышларда аерма шактый икән. Без бит, мәсәлән, хатын-нарны авыр эшләрдән азат итәргә тырышабыз, кайбер предприятиеләрдә (әйтик, металлургия, шахта һ. б.) аларны эшкә алу тыела хәтта. АКШ хатын-кызлары исә мондый чараны дөрес дип тапмыйлар. Алар: «Безнең үз карамагыбызга калдырыгыз! Без барысын да үз ихтыярыбыз белән сайлап хәл итәргә тиешбез!» — диләр. Тагын шунысы бар: ул илләрдә без авыр дип санаган хезмәтләр бик җайлы технологиягә көйләнгән, барын да автоматлаштырганнар. Мин уйлап куйдым: мөгаен, безгә дә хатыннарны авыр эштән тыйганчы, ул эшләрнең технологиясен камилләштерергә кирәктер... Сүз дә юк, бу илләрдә көнкүреш шартлары кешенең һәммә ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән. Ул кибетләр!.. Берсендә мин кофенең генә утыз алты (!) сортын санадым — җаның теләгәнен сатып ал!

АКШта мин ярты сәгатьлек пресс-конференция ясадым. Башта, ни турындарак сөйләргә, дип аптырабрак калган идем. Аннары нәкъ менә үзебезнең профсоюз мәшәкатьләрен санап чыктым. Беренче сүзләремнән үк барысы да тынып калды. Бала табарга җыенган хатыннарга бирелә торган елларны, кайбер эштә 45—50 яшьтән үк пенсиягә китәргә мөмкинлек булуларын, ялгыз аналарга күрсәтелә торган кайгыртучанлыкларны телгә алдым. Һич арттырмыйча. Илдә ни — шуны тасвирлап күрсәттем. Авырлыкларыбызны да калдырмадым. Хәзер бәяләрнең артуын, икътисадның базар юлына, ирекле бәяләр челтәренә таба баруын да әйттем.

Тын да алмый тыңладылар. Соңыннан, бөтенесе бер авыздан:

— Базар икътисады сезнең хатын-кызга күрсәтелә торган яклау ысулларыгызны җимереп ташлый күрмәсен! — диделәр.— Без менә шул базар системасында яшибез. Бу шартларда барысы да кешенең бары тик үз сәләтенә генә кайтарып калдырыла, социаль яклауның ни икәнен дә тоймыйсың. Бала табарга теләсәң, иң әүвәл аны үстереп житкерерлек мая туплау кирәк, ял да, ниндидер акчалата ярдәм дә юк.

Кайберләре хәтта кисәтеп тә куйды: «Әллә соң ул базар мөнәсәбәтеннән тыелып торасызмы? Бөтен шәфкатьлелекне йотачак бит ул».— диләр.

Менә аларның мондый карашлары гаҗәпләндерде дә хәтта, чөнки АКШта да, Швейцариядә дә кешегә рәхәт яшәү өчен күп каралган, тик алар барысы да акчага, кешенең үзе туплаган байлыгына бәйле.

— Ә-ә, яраткан ашым кызыксындырамы? Алар күп инде. Мин дәү әнием пешергән милли ашларыбызны ашап үстем. Шуңа, хәзер дә, күңел гел үзебезнең татар ашларына тарта. Иң кадерле кунакларым килгәндә, гаилә тантаналары вакытында өчпочмакны бик теләп пешерәм...

— Нихәл, чибәркәй!

— Нәрсә булды, ник миңа бәйләнәсең? **(Ишек төбендә, егетләр төркеме арасында, тәмәке көйрәтеп, хахылдап торучы кала кызы).**

— Хәлегезне beләсем килде, сез бит безнең йортта яшисез, әйеме? Исемегез ничек әле?

— Сиңа нәрсә кирәк?

— Интервью, «Казан утлары» дигән журнал өчен.

— Ой, бусы кызык! Ха-ха-ха, малайлар, күрдегезме: миннән — интервью сорыйлар! Әйдә, сора! Сөйлим — исем дә китми. Татарча белмим белүен, нәрсәгә инде ул, аңлыйсыздыр ич?! Исемемме — Ира. Иркуш, әбичә әйтсәм, Иркә. А-а, фамилиямне үк әйтмим инде, пардон! Фатирымны да әйтмим. Беркайда да эшләмим. Ике ел рәттән институтка керергә йөрдем — алмадылар, «ике»ле куялар. Репетитор елларга рәт булмады. Хәзер кирәге дә юк. Эшлисем килми, бездә бит коточкыч эксплуатация, шул мәсхәрәгә барып кабасым килми. Әти-әни карый. Кием-салымны үзем алам, әнинең зәвыгы башка. Акча гына бирәләр. Алар өйрәнгән инде. Утыз-кырык тәңкәгә эшләп башлаганнар, хәзер әти мең сумлап ала.

Милләт мәсьәләсе менә гел кызыксындырмый. Нигә хаҗәт?! Болай татар кызы саналам инде. Татарча белмим. Нигә кирәк? Аңлашыла бит инде. Урысча бөтен кеше белә — тагын нәрсә?!

Кияүгә чыгасым килми. Нәрсәгә кирәк? Кемгәдер кер юар өченгәме? Минем әни кебек. Кухнядан чыга алмый. Үзенең туган көне була, бер өй кунак җыялар, әни арып хәлдән тая — менә сиңа бәйрәм! Аның бәйрәме! Әле күпме ризык табыштырырга кирәк!

Бу биш егетнеме? Берсен дә яратмыйм. Ник дигәндә — берсенең дә кесәсендә сукыр бер тиен акча юк, машиналары да — алла кулында, фатир дигәнен әйтмим дә инде. Бөтенесе — ата-ана чабуы астыннан чыкмаган мәхлүкләр. Хәзер бит — миллионерлар модада. Ә бу йолкышлар мине видеосалонга да алып бара алмыйлар. Берсе дә беркайда да эшләми. Кайчак минем видеосалонга барасым килә. Ике билет сатып алам да башка берәүне чакырам. Үзем. Улмы? Ул, бичаракаем, эшләп йөри шул. Юаш. Татар егете. Кичен институтта укыган булып та йөри әле. Ни пычагыма кирәк инде? Пенсия барыбер бөтенесенә тигез бирелә.

Ул хакта уйлавы иртә, дисезме? Шулаен шулай. Мин әнием сүзләрен кабатлыйм. Ул ярымач хәлендә институт бетергән. Кырык бер ел эшләгән. Хәзер пенсия яшендә дә эшләп йөри. Шул сөйли: «Безнең лабораториядәге җиде класс тәмамлаган машинистка да нәкъ минем кадәр пенсия ала».— ди. Менә шуннан уйлагыз инде: ни пычагыма ул югары белем? Бүгенге кооператорларга игътибар итегез: башы эшләгән кешегә белемнең гел кирәге юк, ун меңнәрчә хак алалар. Шуңа күрә мин әлеге «юаш»ыма институтын ташларга киңәш бирәм. Ул тыңламаган була. Вакыты да юк, акчасы да...

Ярату?! Ха-ха-ха! Көләсем килеп китте... Алай да кайчак бик нык яратасы да, яратыласы да килә. Кемне? Әнә шул юаш татар егетен хыялга әйләндереп йөрим инде, тик ул мине яратмый. Болай тупасланмас өченгә генә, мин чакыргач кына, килеп йөри ул. Берсендә мине митингка чакырды. Суверенитет турында нидер сөйләделәр. Аңламыйм бит мин. Туңып беттем. Кызыгы булмады. Минем сәясәт белән шөгыльләнәсем килми, шул гына җитмәгән тагын!

Максатмы? Чит илгә китеп яшәр идем! Анда бит, савыт-саба юсаң гына да, байларча яшәп була, ди. Өйдәме? Юк, мин өйдә савыт-саба юмыйм, тырнак буявы куба, ул бит хәзер бик кыйммәт. Тегендәме? Аларда бит тәлинкә юулар-фәләннәр — барысы да машинага көйләнгән, ди.

Тол калудан курыкмыйм. Ирләрнең кирәген күрмим. Азат яшәүгә ни җитә?! Аш-сумы? Юк, пешереп тә караганым юк...

— Сарә ханым, сезнең белән якыннанрак танышасым, хәлләрегезне беләсем килә!

**Сарә Нури кызы АБДУЛЛИНА, экономика фәннәре докторы, КФЭИ профессоры.**

— Рәхим итегез! Мин Казанның финанс-экономика институтында производство һәм маркетинг кафедрасы мөдире булып эшлим. «Маркетинг» дигәне — инглиз сүзе, үз эченә җитештерелгән әйберләрне урнаштыру мәгънәсен дә сыйдыра.

Бүгенгесе көндә хәлләремне канәгатьләнерлек дияр идем. Гаилә ягым, күз тимәсен, бик әйбәт. Балаларым тәмам үсеп җиттеләр: Рубиным — Казан консерваториясенең ректоры, кызым Гүзәл шунда ук фортепьянодан укыта, доцент. Оныкларымның да борчуга салганнары юк. Ирем белән дә бик аңлашып, бик тату яшәп ятабыз.

Татарстан минем тырышлыгымны бик олылады. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем бирделәр. Мин моңа бик шат һәм шул исемне акларга тырышып хезмәт итәм. Төп вазифадан тыш бик күп җәмәгать эшләренә дә катнашам. Предприятиеләрдә булам, лекцияләр укыйм. Әле соңгы вакытта мине дәүләт милке идарәсендәге Коллегиягә әгъза иттеләр. Көннәребезгә хас бинһая җаваплы реформаларны тормышка ашыруда катнашырга туры килә. Мәсәлән, без Татарстан Югары Советы карамагына җөмһүрият шәһәрләрендәге торакны хосусыйлаштыру (приватизацияләү) турындагы документлар пакетын тапшырдык.

Бу эшне башкарып чыкканчы моңа охшаш бик күп мисалларны тикшереп, Польша, Чехословакия, Балтыйк буе илләрендәге экономик үсеш юлларын өйрәнеп чыктык. Татарстан өчен кулай чараларны үзләштерә бардык. Шактый камил проект әзерләдек. Югары Совет шуннан чыгып эш йөртә. Без арада иң гадел ысулны сайлап алдык. Менә төшендерим әле. Безнең документ нигезендә, торакны хосусыйлаштыру алдыннан, һәр кешегә (фатирлысына да, фатирсызына да, кооператив фатир иясенә дә) чама белән 20000 сум акча күчерелячәк. Гаиләгә шактый мая керә. Бу акча бары тик фатир яки дәүләтнең бер кече предприятиесен, яки акцияләр сатып алырга гына ярый. Фатирлар, биш-алты категориягә бүленеп, бәяләнеп куела. Әйтик, иң югары категориядәгесенең бер кв. метры — 1200 сум, түбәнрәкләренеке — 900-800 сум булуы мөмкин. Бөтенләй фатиры булмаганнарның чираты саклана, чират җиткәч: алар шулай ук аны сатып ала алалар. Сатып алу-алмау кешенең үз ихтыярына куела. Мин үзем кешеләргә фатирлы булып калырга киңәш бирер идем. Чөнки, бердән, син фатирыңа тулы хуҗа

буласың, аны сатарга да, бүләк итәргә дә, мирас итеп калдырырга да ярый. Икенчедән исә, бәяләр бәйдән ычкындырылгач, фатирга түләүләр кинәттән нык күтәреләчәк, аңа түли-түли син тәмам бөлгенлеккә төшеп бетәчәксең.

Торакны хосусыйлаштыру планы ике елга каралган. Кеше шул арада әлеге акчасыннан файдаланмаса, аның кыйммәте югалачак.

— Сарә ханым, бәяләрнең бәйдән ычкындырылуына ничек карыйсыз?

— Бик уңай карыйм. Шул чараны башкарып чыкмаганда без экономиканы рәткә сала алмыйбыз, байлыкка әллә нинди астыртын көчләр ия булу, спекуляция, мафияләр, житешмәүчәнлек, кыскасы, төрледән-төрле гаделсезлек хөкем сөрәчәк. Бәяләрне үз көенә ычкындыру һәр товарның чын хакын билгеләячәк, экономик кануннар тәртипкә киләчәк. Дөрес, башта бик авыр булыр. Әмма, күрше илләр тәҗрибәсенә караганда, биш-алты айдан соң бәяләр төшә башлаячак. Тик моңа шартлар тудырырга кирәк! Без кибетләргә мал тутырырга тиешбез, кайдан табып булса да: күршеләрдән, чит илләрдән... Бу юнәлештә эшләр алып барыла инде.

Акча реформасымы? Минем уйлавымча, ул реформа без моңарчы күргәннәргә охшамаячак. Хәзергә шуны гына әйтә алам.

— Кафедрагыздагы эшләр ничек бара, Сарә ханым?

— Яхшы. Без бит институтның 60 еллык юбилеен билгеләп үттек. Шул бәйрәмебезне тагын да нурландырып минем ике студентым Халыкара олимпиадада җиңеп кайттылар: Марат Сафиуллин белән Володя Абрамов. Анда 48 илдән җыелганнар иде бит! Марат, кешеләрнең эш белән ни дәрәҗәдә тәэмин ителү мәсьәләсен, ә Володя предприятиеләрне акционерлаштыруны өйрәнде. Маратның чыгышын «Бу — диссертациягә торырлык!» — дип тапканнар. Беренче урын һәм алтын медаль алып кайтты. Володяга да мактау кәгазе биргәннәр. Маратны кафедрада калдырдык. Бик сәләтле егет. Инглиз телен су кебек эчә, компьютерларны камил үзләштереп бара, татарчасын да һич онытмый. Арча ягыннан ул, анда да гел кайтып йөри, үзе бик тыйнак та, житмәсә!..

— Инде кабат өй хәлләренә кайтып, аш-су бүлмәсенә керик әле, Сарә ханым! Сез нинди ашны, бик теләп, яратып пешерәсез?

— Иң яратканым — вареньелар кайнату. Арада иң тәмлесе — айванныкы!

— Хөрмәтле шагыйрәбез, хәлләр ничек?

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, ТССРның Г. Тукай исемендәге бүләге иясе:**

— Хәлләрем ярыйсы. Сәламәтлегемнән дә, көнкүрешемнән дә зарлана алмыйм. Без бит чыдарга өйрәнгән. Алай да ачу китергән чаклар була: тәртип кимеде, законнар тормышка ашырылмый. Без, бер властька буйсынып, тыныч кына яшәргә өйрәтелгән идек. Бу гадәт бетте. Бер көнлек сәясәт белән яшибез шикелле.

Шигырьләр, җырлар языла анысы. Шулай да, кибетләрдә чиратларда тору, талоннар артыннан йөрү иҗатны бүлә. Мин бит әле халык алдында чыгышлар ясарга да тырышам. Юл мәшәкатьләре, балаларга ярдәм итү — болар барысы да шигърияткә, күпмедер дәрәҗәдә, комачаулыйлар инде, тик, нишләмәк кирәк, без бит әллә нинди рәхәтлекләргә өйрәнгән затлар түгел. Миңа бер шагыйрә турында сөйләгәннәр иде, элекке елларда инде ул, «Бәрхет халатын киеп, бәрхет диванга кырын ятып, ул бәрхеттәй ялтыравыклы шигырьләр яза».— дип. Кая инде безгә андый бәрхет шартлар!?

Мин, җөмһүриятебезнең артистлары белән бергә, бик күп авылларда булам. Яшәү чыганагын үз куллары белән булдыручы кешеләр арасында авылларда йөрү күп нәрсә бирә. Шунысы аяныч: анда һаман бик авыр хезмәт шартлары хөкем сөрә. Дөрес, йокысызлык, авыр хезмәт хакына кешеләрнең хәзергә тамагы тук. Тик хәзер алар алдында да билгесезлек: җир язмышы ничек хәл кылыныр?

Аннары, мин кайбер авылларда халыкның гореф-гадәтләре тискәре якка үзгәрүне күреп гаҗизләнәм. Безнең халыкның иң матур гореф-гадәтләрен нигездә авылларыбыз саклый бит. Олыны олы, кечене кече, дип белү юкка чыгып бара. Юл йөргән кешегә ачык йөз күрсәтү, бер кечкенә кунарга кертү дә хәзер четерекле мәсьәлә кебек... Авылның элеккеге ямьяшел чирәмле урамнары, һәр кон каты себерке белән себерелеп торган такыр капка төпләре, ишегаллары күп җирдә сагынып сөйләргә генә калган.

Элек авылда өй артында мичкә-мичкә су тотуны, һәр авылда буа булдыруны мәҗбүр итәләр иде. Хәзер берсе дә юк. Ут-көз чыкса — кычкырып елалар. Су юк. Чишмәләр урынына колонкалар ясадылар, тик алар бик тиз сафтан чыга, кешеләр сусыз интегәләр. Колонкалар эшләми, чишмәләр каралмаган. Аяныч хәл.

Шигъриятемә Тукай бүләге бирүләренә мин каушап калдым бугай.

— Әйе, бу бүләк хатын-кыз язучыларыбыздан иң беренче Сезгә бирелде, сез беренче һәм хәзергә бердәнбер...

— Бу хөрмәт миңа зур җаваплылык өстәде. Андый зурлауларга лаек хатын-кызларыбыз күп бит безнең арада. Әлбәттә, миңа да бу көннәргә ирешү шулай ук җиңел килмәде. Бар иде заманнар: әдәби иҗатта яман мисал кирәк булса, гел мине телгә алалар иде. Әмма мин иҗат эшемне туктатмадым. Күңел төшенкелегенә бирелмәдем.

Сәясәт белән шөгыльләнү турында әйтәсезме? Мин сәяси эшлекле түгел. Сәясәт белән махсус шөгыльләнмим. Әмма ләкин сәясәттән читтә дип санамыйм үземне. Безнең һәр хәрефебез сәясәткә хезмәт итәргә тиеш. Халыкка аңлатырга кирәк: тулы мөстәкыйльлек булмаганда, нинди тормыш алга китсен инде?!

Кызларыбыз язмышында мине тол аналар, хәтта тол калган кызлар мәсьәләсе бик нык борчый. Бу совет чоры дигәнебез бигрәк тә шәфкатьсез, гел кан коюлардан, сугышлардан гына торган дәвер булды. Ирләр, егетләр гел корбан булып калдылар. Әлеге тыныч саналган көннәрдә дә армиядән табутлар кайта тора. Һәр корбанга — бер тол хатын яки кыз, дигән сүз бит бу. Мин шул хакта бер шигырь язган идем. Җыр булыр бәлки дип уйлаган идем. Вакытында Сара апага тәкъдим дә итеп карадым. Ул, бик пессимистик шигырь дип, музыка язмады. Сара апа бик оптимист иде бит ул. Менә ул шигырь:

*...Сугышта калды безнең егетләр,*
*Сагыну-сагыштан кипте җилекләр.*

*Шат елмайсак та, ут яна эчтә,*
*Безнең күңелләр и нечкә, нечкә.*

*Эшкә бирдек без йөрәк ярсуын,*
*Йөрәк янганда, эчтек кар суын.*

*Талчыбык иде безнең дә буйлар,*
*Үтте яшь гомер, булмады туйлар.*

*Сугышта калды безнең егетләр,*
*Күз яше булып акты өметләр...*

Бу сүзләремә әле дә музыка язылмаган. Бәлки композиторларыбыз укыса, битараф калмаслар, бәлки көе дә туып куяр.

Күп сөйлибез, күп язабыз — нәтиҗәсе күренми. Шулай да өметсез шайтан, дигәндәй, киләчәкнең матуррак булуына ышанам мин.

Аш-сумы? Аны, мае, ярмасы булса, мин пешеренергә яратам. Үзебезнең татар ашларының барысын да пешерәм. Ә менә, мәсәлән, кыстыбыйны мин болай пешерәм: җылы сөткә йомырка сытып камыр басасың. Маргарин да салам мин. Бу инде төче камыр. Бу — җәймә камыры. Эчен бәрәңгедән дә, тары боткасыннан да ясарга ярый. Мин тары боткасын үземчә пешерәм. Башта ярманы бик яхшылап юам, аннары ике мәртәбә суда кайнатып алам. Кайнаткан саен, салкын суда яхшылап юам. Ярманың бөтен әчесе бетә, төсе дә гәрәбә төсле сап-сары булып, матурлана. Аннары шул ярмадан, гел сөткә генә ботка пешерәм. Кыстыбый җәймәсе, юка гына иттереп, плитә өстендә пешерелә. Аннары куе сөт, май салып изелгән бәрәңгене, яки әлеге тәмле ботканы шул җәймәләр эченә кыстырасың инде. Маең булса, әйбәтләп майлыйсың да кайнар килеш табынга куясың кыстыбый дигән милли ризыкны!.. Үзебезнең милли ризыкларыбыз татар хатынын чын мәгънәсендә татар хатыны итеп күрсәтә, минемчә. Милли ризыкларыбызны пешереп, исән-имин яшәсәк иде!..

# МИЛЛИ МӘДӘНИЯТНЕ ЯКЛАП

Татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов иҗат мирасыннан озак еллар буе «юкка чыгарылып торган» олы хәзинәнең халыкка кайтарыла башлавына дүрт дистәгә якын ел узып китте. Шөкер, шушы вакыт эчендә аның сакланган кадәресен эзләп табу, бастырып чыгару, гыйльми яктан өйрәнү юнәлешендә җитди генә омтылышлар ясалды. Болар арасында иң мөһиме — әдипнең сигез китаптан торган «Әсәрләр»е дөнья күрү (1974—1986 еллар). Торгынлык чорының идеологик күрсәтмәләре басымы астында аны төзү, текстларны сайлап алу, әсәрләргә искәрмә һәм аңлатмалар язу күптөрле ясалма киртәләрне, догмаларны җиңә-җиңә генә эшләнде.

Вәләкин Г. Ибраһимов язганнарның якынча яртылашы әлегәчә таркау килеш ята. Галим-голәмә үзләренең фәнни хезмәтләрендә ошбу сигез томлыкка кертелмәгән әсәрләргә азмы-күпме мөрәҗәгать итсәләр дә, гади укучының алардан берниндн дә хәбәре юк дияргә була. Бу иҗатның гаять тә зур әдәби-эстетик, фәнни һәм тарихи әһәмиятен таныйбыз икән, гомумән, әдәби һәм мәдәни мирасыбызга битараф түгелбез икән, әдипнең унике-унбиш томлы академик басмасын әзерләү эшенә керешү кирәклеге бик ачык рәвештә күз алдына килеп баса.

Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләре, мәкаләләре, гыйльми хезмәтләре үз заманының иҗтимагый-сәяси фикер көрәшен, хәят сулышын гәүдәләндерү белән бергә, бүгенге тормышыбызны да тирәнрәк аңлауга, фаҗигале язмышлы миллэтебезнең бүгенгесенә, киләчәгенә нисбәтле уй-фикерләребезне, омтылышларны ачыклауга хезмәт итәрдәй хосусиятләрен дә югалтмыйлар. Моны шуларның фәкать берсенә — әдипнең «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» исемле докладына (тезисларына) тукталу да исбатлый ала.

Бу хезмәтнең нинди иҗтимагый халәттә, нинди олы максат белән язылуы турында сөйләп тору ихтыяҗы юк. Чөнки текстның үзендә үк болар хакында беркадәр мәгълүмат бар. Ә менә хезмәтнең китап рәвешендә (әүвәл ул стеклографта күбәйтелеп, кулъязма хокукында кулланылган) басылып чыгуына бәйле бер-ике генә хәбәрне әйтми китү ярамастыр.

Татар мәдәниятенең киләчәк язмышы хакында фикер алышу ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан җыелган киңәшмәдә башланып, Сәлах Атнагулов һәм Галимҗан Ибраһимов тезислары «тирәсендәге бәхәсләр... файдалы булудан бигрәк, кирәгеннән артыграк кызулыгы һәм үткенлеге» (М. Хатаевич) белән күзгә ташлана.

Киңәшмәдә соңра Г. Ибраһимов тезислары партия өлкә комитеты раславыннан башка гына дөнья күрә (Бу аерата зур ялгыш дип бәяләнгән!). Һәм бераздан мондый рухтагы икенче киңәшмә үткәрелеп

[1] Урысча исеме: «О судьбе татарской культуры в условиях пролетарской революции и социалистического строительства».

(ул чак әдип каты авыру, Кырымда), анда партия өлкә комитетының беренче секретаре Мендель Хатаевич үзе чыгыш ясый («Кызыл Татарстан», 24.V.1927). Ул, Г. Ибраһимов тезислары С. Атнагуловныкына караганда партиянең карашына якынрак дип санаса да, әдип фикерләрендә байтак зур ялгышлар таба (Г. Ибраһимов, хат язып, урысчага тәрҗемәсенең начарлыгын искәрткән дә була югыйсә).

Бераздан, 1927 елның 14 июнендә, милли мәдәният мәсьәләсе ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросына куеп тикшерелә һәм махсус резолюция кабул ителә. Анда С. Атнагулов тезисларындагы хаталар да (милли мәдәният үсешен гадиләштерү, вульгарлаштыру, ассимиляцияне яклау һ.б.) әйтелгән. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов тезисларының да җитди ялгышлары бар дип танылә.

Менә аларның кайберләре:

— милли мәдәниятнең мөстәкыйльлеген зурайтып күрсәтү, беркадәр идеаллаштыру;

— татар милли мәдәниятенең үсешендә пролетариат ролен кечерәйтү, ә милли интеллигенциянекен исә зурайту;

— фикер алышуда тыелган алымнар куллану.

Соңгысында күздә тотылган нәрсә: милли мәдәниятkә мөнәсәбәтләрендә татар морзаларын совет учреждениеләрендә эшләүче партия члennары һәм партиясезләр белән чагыштыру, урыслаштыру сәясәтен уздырган патша чиновникларын совет аппараты хезмәткәрләре белән бер тактага кую. Чынында исә Г. Ибраһимовның бу хактагы уй-фикерләре бүгенге көндә дә актуаль яңгырый.

Г. Ибраһимов тезисларындагы (китабындагы) «җитешсезлекләр»не башка кайберәүләр дә ачып салырга омтылган. Шуларның берсе — Гомәр Толымбайский. Солтангалиевчелеккә каршы кискен көрәш, репрессияләр дулкыны башлануга, ул «Безнең юл» журналында (1929, № 11) «Искәрмәгән бер уңлык турында» исемле мәкаләсен бастыра. Олы әдипнең шәхесенә, иҗатына нинди генә мөһерләр сугылмый анда. Аныңча, автор милли мәдәниятнең сыйнфый эчтәлеген күрми, буржуа тегерменәнә су коя, китабында башыннан ахырына кадәр безгә чит караш үткәрелә, сыйнфый көрәш кискенләшүенә игътибар итми, либерал вак буржуазия сазлыгына төшкән һ.б. «Сул фразаларга каршы көрәшүне һичбер туктатмастан, бу китаптагы реакцион фикерләргә каршы көрәшүне хәзерге вакытның зур бурычларыннан итеп алырга туры килә» (25 бит), — ди Толымбайский.

Киресенчә түгел микән? Минемчә, Г. Ибраһимов хезмәтендәге фикри байлыкны тирәнтен өйрәнүне хәзерге вакытның мөһим бурычларыннан берсе итеп санарга кирәк!

Зөфәр РӘМИЕВ

# Галимҗан Ибраһимов

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ НИНДИ ЮЛ БЕЛӘН БАРАЧАК?

*Мөхәррирдән*

*Пролетариат революциясе һәм социализм төзелеше эчендә милли мәдәниятләрнең, аеруча татар мәдәниятенең, ничек барышы мәсьәләсе партия өчен дә, Татарстан өлкә комитеты өчен дә, әлбәттә, күптән ачык иде, билгеле иде.*

*Ләкин шуңа карамастан, 1918—1920 елларда милли җөмһүриятләрне төзүгә каршы барып, партия аңлавыннан аерылучылар булган кебек, аерым халыкларның үз телләре нигезендә мәдәниятләрен үстерү, күтәрү турында да партиянең Татарстан оешмасы тоткан юлын әле һаман үзләштерә алмаучылар, татар мәдәниятенең үз теле нигезендә үсүенә, күтәрелүенә, аның киләчәгенә начар карап, башка мәдәниятләр эчендә йотылу, урыслашу ягына авучылар килеп чыктылар (урысчы Сәлах Атнагулов, Гомәр Әлмөхәммәдев, Мортазин... латыйнчы Фатих Сәйфи, Хөснетдин Кәримов кебекләр).*

*Менә шул уңай белән партия Татарстан өлкә комитетының матбугат бүлегенә тарафыннан киңәш ясалды. Татар активының иң мәсьүл хезмәтчеләре катнашкан бу киңәш өч көн (25.I,11.II.15.II,1927) дәвам итеп, һәр ике як үзләренең тезисларын-докладлары белән чыктылар. Озак аңлашулар барды.*

*Нәтиҗәдә, ачык ике капланмалы урыслашучылар бик нык җиңелделәр. Партия карарларының һәм ун еллык совет тәҗрибәсенең җимешләрен күз алдында тотып төзелгән тезис-доклад зур күпчелек белән нигез буларак кабул кылынды (бу якта—96 тавыш, тегеләргә—4 тавыш).*

*Кулыгыздагы әсәрем—менә шул тезис-докладымның үзгәртмә чыгарылуыдыр.*

Г. И. 19 февраль, 1927 Казан.

## Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?

(1927 елның 25 гыйнварында ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты матбугат бүлегенең киңәйтелгән җыелышында тикшерелгән мәсьәлә уңае белән).

В. И. Ленин мәкаләсеннән:

*Чуждо ли нам, великорусским сознательным пролетариям, чувство национальной гордости? Конечно, нет! Мы любим свой язык и свою родину, мы больше всего работаем над тем, чтобы ее трудящиеся массы (т. е. 9/10 ее населения) поднять до сознательной жизни демократов и социалистов». И. В. Сталин сүзеннән: «Пролетарская по своему содержанию, национальная по форме—такова та общечеловеческая культура, к которой идет социализм».*

Марксист профессор Покровскийдан:

*«Культуру определяет язык, главнейшее и необходимейшее оружие культурной передачи орудие, без которого культура просто немыслима.»*

## Мәсьәләнең куелышы

1927 елның 25 гыйнвар җыелышы пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышлары турында хәзер бу дәрәҗәгә кадәрле гаҗәп тоелырлык хата фикерләрне мәйданга чыгарып куйды. Без. бу мәсьәләдә революциянең юлы һәммә иптәшләр тарафыннан ачык үзләштерелгән. дип уйлый идек. Һич булмаса, төп карашларда зур ялгышлар беткәндер, дип ышана идек. Алай түгел икән әле. Арада кайбер иптәшләрдә бик тирән адашулар. хәрби коммунизмнан калма зур саташулар бар икән әле. Мәсәлән. берәүләр әйттеләр: «Татарның теленә, мәдәниятенә әһәмият бирмиләр, аны кирәксез түбән бер әйбер саныйлар, урыслашу юлында баралар, урыска йотылалар, дип артык кайгырырга ярамый. Бу сүз — зәгыйфь мәдәниятне ташлап, зур мәдәниятә кушылу дигән сүз генә. Моңа каршы көрәшү хаҗәт түгел. Курсларда, техникумнарда артта калган, өлгермәгән шәкертләр өчен ачылган вакытлы әзерлек группаларының кыйммәте, әһәмияте, роле ни дәрәҗәдә булса, татар мәдәниятенең дә, татар теленең дә тарихи әһәмияте тормышта шул чаклы гынадыр».— диделәр. Икенче бер иптәш: «Татар теленең, татар мәдәниятенең хәзергә кирәге артта калган крәстиян массасын безнең дәрәҗәгә (урта тип татар коммунисты сөйли) күтәрү өчен генәдер. Югары мәктәпләрдә (вузларда) татар теле дип маташу — юкка баш авырттырудыр...» — ди. Өченче берсе әйтә: «Монда мәдәният дип һаман мәктәп, тел, әдәбият, сәнгать, гыйлем тирәсендә генә кайнашалар. Минемчә, культура дигән сүз — развитие производительных сил, дигән сүз. Паровоз, электр, трактор — болар һәммә милләтләргә бер дәрәҗәдә кирәк нәрсәләр. Шуңа күрә төп асылда милли татар мәдәнияте дип йөрергә күп урын да юк. Без бу хакта мәсьәләне ачык куярга тиешлебез: әгәр бер тел, бер мәдәният артта булса, халыкның хуҗалыкта күтәрелүенә киртә булып, буяп, туктатып торса, аны ташлап, турыдан-туры югары мәдәниятә кушылу чарасына кирәргә кирәк».— ди[1]. Бу өч иптәшкә тагын бер-ике иптәшнең шул югарыдагыга охшаш фикере ычкынды, докладчының да бу мәсьәләдә ачык билгеле карашы юклыгы күренде (тик соңыннан гына аның урыслашучылык ягында икәне бөтенләй ачылды).

Бу 20—30 кешелек бер җыелыштагыларныкы шулай. Болар үзләре шул агымны тиеш дип куәтләүчеләр. Әмма партиясезләр арасында сөйләшсәң, аларда буңа кушылу юк, бәлки бөтен партия шулай карыйдыр, дип куркынып уйлаучылар очраштыргалый. Аларның кайберләре әйтәләр: «Пролетариат революциясе интернационализм юлы белән бара. Аның максуды аерым милли мәдәниятләрне бетереп, уртак, гомуми, бәйнәлмиләл мәдәният тудырудыр. Хәзерге көндә, гәрчә, милли мәдәниятләргә юл бирелсә дә, ул вакытлы бер тактика гынадыр...» — диләр.

Кыскасы, бу хакта һәр ике якта тирән бер аңлашылмау бара. Кайбер ихлас күңелләр дә монда бер каршылык күрәләр: имеш, бер яктан, без интернациональ максудлар өчен каты көрәш алып барабыз, икенче яктан, советның, партиянең ярдәме белән бик күп аерым халыкларга милли мәдәниятләр тудырырга, үстерергә тулы ярдәм күрсәтәбез. Моның аркасында электән барлар зураеп, чәчәкләнеп китәләр, сүнгәннәр, басылганнар яңадан терелеп, яңадан күтәрелеп чыгалар. Бу — бер кулың белән ясаганны икенче кулың белән җимерү түгелме? Интернационалистның кайбере, милләтченең байтагы менә бу турыда шөбһәле карашлардан котыла алмый. Шул гомуми мәсьәлә эчендә аерым татарныкы да үзеннән-үзе килеп чыга: бу зур пролетариат хәрәкәте эчендә, бу интернациональ дулкыны арасында татар мәдәнияте язмышы ничек булачак? Бу милли мәдәният нинди юл белән барачак? Үз ана телендә, үз нигезендә үз хаҗәтләренә хезмәт итүче татар мәдәнияте туктаусыз үсәр, зураер, халыкның тормышына актыйлык бирер дәрәҗәгә җитәчәкме? Яки башкалар тарафыннан йотылачакмы? Йотса, кем йотар? Урысмы, чувашмы, немец, французмы? Әллә юкса барлык милли хасиятләрдән саф төзелгән берәр бәйнәлмиләл гомуми мәдәният килеп чыгар да, шул йотармы? Без тарихның сукыр агышына бирелеп, кул кушырып карап торырга тиешме, әллә бу мәсьәләләрдә мәгълүм бер принцип буенча, тарихның бер якка таба үзгәрүе өчен билгеле бер план астында активист булып эшләргә тиешме? Безнең активистлыгыбыз, кайсы якка юнәлер: йотылуга, урыслашуга, чувашлашуга, тизрәк йоттыругамы, әллә башкачамы?

---

1 «Югары мәдәният» сүзе алар телендә конкрет урыс мәдәнияте иде.

Югарыдагы шөбһәле мәсьәлә эченнән менә шундый тармаклар килеп чыгадыр. Болар — татар өчен генә түгел, әрмән, әзербайҗан, үзбәк, казакъ, грузин, чуваш, украиннарның һәрберсенә уртак мәсьәләләр. Бу хакта хәтта урысларда да шөбһә бар. Чөнки аларда да: «Урыс халкы Коминтернның интернационал байрагына корбан ителә, милли урыс мәдәнияте җимерелә, бетә», — дип караучылар бар.

Димәк, мәсьәлә — бер татарныкы гына түгел, киң гомуми мәсьәлә. Шуңа күрә моны үзенең бөтен киңлеге белән шул рәвештә карарга һәм шул гомуми җавалтан аерым татарныкына килергә кирәк. Мәсьәлә болай куела.

— Интернационалист пролетариат хәрәкәте, пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышы ни булачак? Болар үзләренең төсләрен югалтачакмы? Яки шул нигездә үскән хәлдә интернационал максудлар өчен хезмәт кылачакмы?

— Болар эчендә татар милли мәдәнияте нишләр? Башкалар үскән, күтәрелгән хәлдә безнеке сүнеп калмасмы? Татар халкы, үзенекен ташлап, башка берәр көчле мәдәниятка кушылу чарасын күрергә тиешле түгелме? Яки тарихның сукыр агымына буйсынып, ни булса, шул булыр тактикасын тотаргамы?

## II

## Яңа һәм иске тип мирзалар карашы

Партиянең XII съезды карарларыннан:

***«В этих условиях разговоры о преимуществах русской культуры и выдвигание положения о неизбежности победы более высокой культуры над культурами более отсталых народов (украинской, азербайджанской, узбекской, киргизской, и пр.) является ничем иным, как попыткой закрепить господство великорусской национальности».***

Алда куелган мәсьәләгә сүздә һәм гамәлдә берничә төрле җавап бар.

Боларның беренчесе — иске һәм яңа тип мирзаларныкы (үз халкыннан мәдәни аерылган татар совет чиновникларыныкы).

Иске патшачылык заманының татар мирзалар типлары һәркемгә мәгълүм: болар урыс хөкүмәтенең чиновниклары иделәр. Ихлас күңел белән шуңа хезмәт кылдылар. Үзләренең сыйныфдашлары урыс дворяннары белән бергә, бер рәвештә тәрбияләнеп, урыс мәдәнияте эчендә кайнап, татар халкыннан аерылып яшәделәр. Боларның бөтен көнкүрешләре урыс мәдәниятенә, урыс теленә бәглы иде. Менә шул бытие татарның бу катлавында, тик урыс мәдәнияте аркасында гына яшәргә мөмкин, татар мәдәнияте юк, булса да — кыйммәтсез, аны күтәреп, үстерергә тырышып маташу — нәтиҗәсез эш, дигән сознание тудырды. Болар татар телен белмиләр, аны кирәксенмиләр, татарның мәктәбе, әдәбияты, тарихы, тормышы болар өчен чит нәрсәләр иде.

Урыс җәмәгатьчелеге, урыс зыялысы, урыс мәдәнияте эчендә кайнап яшәү сәбәпле, безнең хәзерге татар совет хезмәтчеләренең — чиновникларының бер өлешенә дә шул иске мирзалык чире вакытлыча кайтып йокты. Икенче төрле әйткәндә, бездә хәзер яңа тип мирзалар мәйданга килде.

Болар әйтәләр: татарларның теле, әдәбияты урысныкына караганда ярлы, татар мәдәнияте урыс мәдәниятеннән түбән, татар тормышы урысныкыннан артта. Боларга үзеңне һәм халыкны баглау — аны тарихи үсүдән туктату була. Татар мәдәнияте барыбер күтәрелә, үсә алмас, ул урыс мәдәнияте дулкынында эрер, йотылыр, диләр. Кайберәүләре шулай ачык әйтә: икенчеләре, теле белән әйтмәсә дә, бөтен гамәле белән шул юлда бара. Курсларда, мәктәпләрдә татар теленә әһәмият бирмәскә, аны иске заманның закон божий дәресләре кебек, бер күңелсез мәҗбүрият кебек кенә карарга азапланучы кайбер татар егетләре — менә шул дулкынның бер мисалыдыр. Бездә хәзер бу яңа мирзалар аерым бер катлау булып киләләр: болар татар әдәбиятын, татар матбугатын укымыйлар, татар те-

лендә язарга белмиләр, моны үзләре өчен кимчелек дип тә карамыйлар, үзенең бу наданлыгын ул ниндидер эчке бер «мәдәни» мактану белән әйтеп куя. Балаларын, якыннарын, әлбәттә, урыс мәктәбенә, урыс йортына, урыс курсларына бирәләр. Иске заманда татар мәктәбе начар булганга, бер төрле динче, милләтче катлау да балаларын урыс мәктәпләренә кертәләр иде, ләкин алар, һич булмаса, үзләре ике мөгаллим китертеп, өйдә ана теле дәресләрен укыталар иде. Әмма безнең хәзерге «мирзалар» моны да эшләмиләр, үзләре, татар газитәсенә мәкалә бирергә туры килсә, аны урысча яздырып җибәрәләр. Болар — әгәр коры уйламаудан, әзерлексезлектән генә килгән бер чир булса, чарасы җиңел булыр иде, ләкин 25 гыйнвар җыелышы боларның гади чир генә түгел икәнен, бәлки аерым бер агым рәвешенә кереп барганын күрсәтте. Ягъни гамәли мирзалык үзенә нәзари[1] нигез эзли башлады.

Бу ике заманның ике тип мирзалыгының тамыры бер үк җиргә бара, ләкин язмышлары башка булачак.

Иске тип мирзалар урыслаштыру, башка һәммә милләтләрне христиан, великорус мәдәнияте эчендә йоту сәясәтен алып баручы патшачылыкның ялчылары иде. Татар хезмәт халкыннан мәдәни аерылган булучылык аларның чиновниклык карьерлары өчен беренче шарт иде. Алар татар мәдәниятеннән ничаклы ерагайган булсалар, великорус мәдәниятенә сукырларча табынып урыслашуны ничаклы нык, тирән гамәлләштергән булсалар, шулчаклы уңай һәм уңышлы буладыр иде. Әгәр дә бу татар мәдәниятеннән аерылу һәм урыслашуны чиркәүдә чукынып, муенына тавык аягы тагу дәрәҗәсенә җиткергән булса, ул иске мирзаның карьерасы тагы да ныграк тәэмин ителәдер иде.

Менә шуңа күрә дә татарның ул мирзалык катлавы берничә йөз еллар буенча үзләренең урыслашу фикерләрен саклап, гамәлдә урыслашып, сүздә бу хәлне урыс мәдәниятенең югарылыгы белән аңлатып, бер дәрәҗәгә хәтле көчле хәлдә яшәп килделәр.

Әмма безнең революция чорында да мәйданга килеп чыккан ул яңа калыптагы мирзаларның — совет мирзаларының хәле алай түгел: чөнки совет һәм партия һәр халыкның үз эченнән шул милләтнең телен, әдәбиятын, гадәтен, тарихын, тормышын белгән хезмәтчеләр җитештерүне планга куйган. Бу хакта, һәр җөмһүриятнең үз конференцияләрендә чыгарылган бик күп резолюцияләрдә ачык рәвештә бик күп мәртәбәләр әйтә барган кебек, партиянең XII съездында милли мәсьәлә уңае белән чыгарылган карарга да кертелгән. Анда менә шул сүзләр бар:

«... Д/ Органы национальных республик и областей строились по преимуществу из людей местных, знающих язык, нравы и обычаи соответствующих народов»[2].

Күрәсез, советның, партиянең карашы, тоткан юлы бөтенләй башкача: үз халкыннан мәдәни ераклашкан чиновниклар түгел, бәлки аның телен, әдәбиятын, гореф-гадәтен, тарихын-тормышын белгән хезмәтчеләр кирәк. Идарә тик шулар кулында гына булырга тиешле дип карала. Һәм бөтен сәясәт шуңар корыла. Бу сәясәтнең бер тармагы яшь буынны киләчәк хезмәткә әзерләү мәсьәләсенә кайта: безнең мәктәпләребез татар мәдәнияте белән нык таныш, нык бәйләнешле хезмәтчеләр әзерләргә тиеш.

Шулай итеп, бездә яңа тип мирзалар — урыслашкан татар совет чиновниклары киләчәктә йә акрынлап карьераларын, тәэсирләрен югалтырлар, йә татарның телен, әдәбиятын, тормышын өйрәнергә, татар халкы белән даими мәдәни бәйләнеш ясарга мәҗбүр булачаклар.

Бу — киләчәкнең мәҗбүри хәле. Ләкин хәзер дә әле ул яңа тип урысча надан «мирза» чиновниклар байтак киң урын тоталар әле. 25 гыйнвар җыелышы әнә шул яңа тип «мирзалар»ның яки шулар фикерендәгеләрнең карашларын да тыңлап үтте. Болар да, нәкъ иске заманның чын, тарихи мирзалары кебек, үзләренең татар мәдәниятенә әһәмиятсез, өмидсез, имансыз карашларын урыс мәдәниятенең югарылыгы белән тигезләргә азапланалар. Боларча, татар мәдәниятеннән ваз кичеп, урыс мәдәнияте эчендә йотылу, шуңа кушылу мәсьәләсе, гүя, тарихның якындагы бер бурычы, имеш. Кыюраклары моны ачык әйтә, хәйләкәрләре эчләрендә яшеребрәк саклый.

---

[1] Нәзари — теоретик

[2] Тәрҗемәләрнең дөрес һәм тулы булу-булмавы турында сүз кузгатып маташырга урын калдырмас өчен, һәр урында турыдан-туры урысча оригиналлар үзләре китерелделәр. (Г. Ибраһимов искәрмәсе).

Ләкин, һәрхәлдә, мирзалыкның бу яңа рәвеше бездә хәзергә бар әле. Бу мәсьәләгә партиянең ничек карашы турында бу II бүлекнең башына китерелгән эпиграф ачык әйтә. Анда ак өстенә кара белән болай язылган:

«Бу шартлар эчендә урыс мәдәниятенең өстенлеге турында сөйләнүләр һәм украина, әзербәйжан, үзбәк, казакъ һәм башка артта калган халыкларның түбән мәдәниятләрен урысның югары (гали) мәдәниятенең җиңүе мәжбүр икәнлеге турындагы сүзләр великорус милләтенең хакимлеген тәэмин итәр өчен бер чара эзләүдән башка нәрсә түгелдер».

Партиянең XII съезды менә шулай дип әйтте. Бу — великоруслрга карата әйтелә. Безнең чиновник татар «мирзалары» исә, үзләре дә аңламастан, әнә шул тирә-якны чолгап алган великоруслык «мәдәни» шовинизмы тәэсиренә төшәләр.

## III

## Иске һәм яңа тип милләтчеләр

И. В. Сталин сүзеннән:

*«Лозунг национальной культуры был лозунгом буржуазным, пока у власти стояла буржуазия, а консолидация наций происходила под эгидой буржуазных порядков. Лозунг национальной культуры стал лозунгом пролетарским, когда у власти стал пролетариат, а консолидация наций стала протекать под эгидой советской власти. Кто не понял этого принципиального различия двух различных обстановок, тот никогда не поймет ни ленинизма, ни существа национального вопроса с точки зрения ленинизма.»*

Икенче караш — иске һәм яңа тип милләтчеләрнеке.

Болар үзләренә нигез итеп иске заманның идеалист социологиясе доньясында аерым бер мәктәп булып танылган мәшһүр принципны — «адәмнәр тарихы — милләтләрнең гайрыкларның[1] үзара көрәшеннән гыйбарәт» дигән нәзарияне[2] алалар. Һәм әйтәләр: тарих — милләтләрнең үзара тартыш мәйданыннан башка нәрсә түгел, кем көчле — шул җиңә, җиңелгән — изелә, йотыла. Башка милләтләр белән көрәш мәйданында җиңелеп югалмас өчен бердәнбер чара — көч, куәт җыярга тырышудыр. Мәдәният шул юлда бер корал. Изелеп тапталмас өчен мәдәнияттә өстен булу лязем, диләр. Бу хакта Хәнәфи Мозаффар әфәнде үзенең әле басылмаган бер китабында («Дин, миллият мәсьәләләре») болай яза (1922): «Һәр милләт үз милләтен уздырырга тырыша, үз милли хосусиятләрен бөтен тәфсиләте белән сакларга, тәрәккъый кыйлдырырга иҗтиһад итә иде. Куәтле милләтләр арасында көчле ярыш бара иде. Куәтле милләтләр зәгыйфь милләтләрне йотарга вә аңлар хисабына үсәргә омтылалар, вә аңлар өстенә атылалар, аңларны үзләренә савым сыер ясыйлар вә аңларны хәйван урынына да күрмичә җәберлиләр иде. Табигый, бу вакыйгаларны күреп торган, бу сәясәтнең золымы астында изелгән вә аның ачы газапларын татыган зәгыйфь милләтләрдә дошманлык көчәя, мөдафәгә[3] хисе уяна, аңларда милләтләрен саклау чараларына керәләр. Бөтен милли хосусиятләрен тәмам үткенлеге берлә ачып салып, милләтләрнең милли хисләрен кабарткан өстенә кабартырга тырышалар иде». — ди.

Әгәр иске заманның бөтен милли матбугатын — бер татарныкын гына түгел, бөтен доньяныкын — карасагыз, һәммәсендә сез шул бер нәрсәне күрерсез. Алар һәммәсе тарихның үткәне, киләчәге тик милли көрәшләр каны эчендә булганлыгын, үләргә теләмәгән милләтләр бу көрәшкә әзерләнү тиешлеген, бөтен тормыш шулай барганлыгын, шуңа күрә һәр милләт үзен бетерергә, йотарга, изәргә әзерләнеп яткан дошман милләтләр эчендә икәнен онытмаска кирәклекне, һәркайчан менә шул милли көрәш фронты астында торганлыгын җырлыйлар.

---

[1] Гайрык — раса.
[2] Нәзария — теория.
[3] Мөдафәгә — саклану, каршы тору.

Безнең татарның да иске тип милләтчесе шулай иде. Тик пролетариат революциясе дулкыннары арасында бу хакта тирән бер үзгәреш булды. Совет эчендә милләтләрнең үзара талашлары бетте, элек бер-берен, гүя, җәберләп, дошман күреп килгән халыклар, урыс һәм үз милли буржуаларын куып яңа хәят башлагач, тыныч мәдәни төзелеш хәрәкәтенә бирелделәр. Менә бу хәл бик күпләрнең күзен ачты, мондый могҗизаның тик пролетариат революциясе аркасында гына була алганлыгын үз тәҗрибәләре белән кичергән киң бер катлау демократ милләтчеләрнең игътикадында[1] алмашу ясалды. Болар: милли азатлык, милли мәдәният тик советның, пролетариат диктатурасының канаты астында гына тәэмин кылынуы мөмкин икән, дигән иманга килделәр. Һәм шуның буенча совет белән бергә вөҗдан теләгәнчә эшләп баралар. Әмма кечкенә бер туң катлау ихласлыкта болардан читтә калды. Бу катлау уйлый: революция бер дулкын, ул килер дә китәр, ләкин шулай да аңа каршы көрәшеп маташырга ярамый, киресенчә, совет белән килешеп, аңардан милли азатлык, милли мәдәният өчен алырга мөмкин булган һәммә нәрсәне суырып калырга кирәк, дигән тактиканы тоталар. Болар: алда яңадан кузгалачак зур милли тартышлар, милли көрәшләр вакытында җиңеп чыгар өчен, пролетариат канаты астында мәдәниләнеп, әзерләнеп азмы-күпме көч җыйыйк, диләр. Бөтен идеологияләре, бөтен төп игътикадлары, дөньяга милли, сыйнфый карашлары — һәммәсе тәмам иске тип милләтчеләрнеке нигезендә калган бу кечкенә шайка үзе бик акыллыбаш булып кылана. Ләкин, берәүнең әйтүенчә, тактикалары — карта уеннарында алдашып акча отарга азапланган принципсыз шулерлар тактикасы булганга, совет белән бөтенләйгә кушылып, вөҗдан буенча эшләп килгән чын яңа киң катлау милли татар зыялысы ул акыллыбашлар тирәсеннән китеп беттеләр. Югарыда куелган мәсьәләгә җавап эзләгәндә, милләтчеләр арасыннан менә шул төрле катлауларны нык аерып йөртергә кирәк:

1/ Чын иске тип милләтчеләр; 2/ Шулай ук игътикадында иске, әмма тактикасында «яңарган» кечкенә группа пролетариат революциясе эчендә милли мәсьәләнең чишелү рәвешен һаман да үзләштерә алмаганнар: болар — иске алпавыт, буржуа дәверенең хәзерге археология музейлары өчен калдырылган ватык-сыныкларыдыр. 3/ Әмма хезмәт халкы эченнән чыккан өченче киң катлау күптән газаплап, борчып килгән милли язмыш мәсьәләсен тик пролетариат революциясе аркасында гына халык өчен уңышлы рәвештә чишәргә мөмкинлек барлыгына нык игътикад иттеләр.

Димәк, монда интернациональ пролетариат хәрәкәте эчендә милли мәдәниятнең үсә алуын аңламаучы искечеләр һәм бөтен эшләре белән милли мәдәниятнең тик пролетариат революциясе аркасында гына үсүе тәэмин кылыначагына таянган яңачылар бер-береннән нык аерылалар. Бу соңгылар гамәлдә шулай барганнары хәлдә, болар эчендә кайберәүләрнең кайбер вакыт: «Пролетариат революциясенең интернационализм нигезендәге лозунглары, принциплары белән милли мәдәниятләрне үстерү гамәле арасында бер каршылык юкмы икән, моның киләчәге ничек булыр икән?» — дигән мәгънәгә охшашлы шөбһәләр очраштыргалап куя. Димәк, бу фронтта гамәли эшкә нәзари нигез бирүгә тирән бер хаҗәт бар.

## IV

## Пролетариат юлы

### I

Русия эшче социал-демократия партиясе эчендә милли мәсьәләдә бик зур каты тартышлар булып килгәнлеге мәгълүм. Аерым оешмалардан Польша социал-демократлары вакыт-вакыт милли мохтариятка каршы күтәрелделәр. Люксембург белән Ленин арасында бу хакта өлкән полемикалар кичте. Урыслардан Пятаков, Бухарин иптәшләр әле Октябрьдән соң, 1919 елның партия съездларында шул иске каршылыкларны яңартып чыктылар.

---

[1] Игътикад — ышаныч.

Лэкин Ленин юлбашчылыгы астында бик күптэн үк зур күпчелек белэн бу мэсьэлэ чишелэ килде. II съезд (1903). VIII съезд (1913—1914) моның ачык моментлары иде. Октябрь революциясе булу белэн, бу хакта аерым декларациялэр игълан кылынып, конституциягэ дэ кертелде. Икенче яктан, канлы гражданнар сугышы бетэр-бетмэс бу милли программа гамэлгэ, тормышка керэ — һэркайда милли җөмһүриятлэр төзелэ башлады.

Бу вакыт партия эчендэ нэзари көрэш беткэн, сүздэ һэммэсе милли мохтариятка буйсынганнар иде. Лэкин җирле халык күпчелек булган урыннарда аерым конкрет җөмһүрият мэсьэлэсе күтэрелү белэн гамэлдэ моңар каршылык кузгалды. Каршылар ике горуһ иде: 1/ урыс коммунистлары, 2/ җирле халыкның үз коммунистларының сул канаты.

Татарда бу соңгыларының башында Гали Шэмигулов иптэш булды. Шуның буенча ул хэрэкэт шэмигуловчылык дип аталды да. Болар, элбэттэ, татарда гына түгел иде. һэр халык эчендэ үз коммунистларыннан бер горуһ та, кайбер урыслар да аерым җөмһүрият төзүне интернационализмга каршы бару дип, миллэтчелек дип уйладылар. Шул нигездэ көрэшлэр барды. Лэкин съездларның нэзари көрэшлэрендэ ленинизм җиңгэн кебек, гамэли совет төзелешендэ дэ ул өстен чыкты: бер горуһ урыслар белэн үтэ сул канат шэмигуловчыларның каршылыкларына карамастан, милли җөмһүриятлэр мэйданга килделэр.

Партиянең милли программасы шулай итеп гамэлгэ куела башлады.

Димэк, мэсьэлэ чишелде, лэкин бөтенлэй түгел, бигрэк тэ ачык сэяси булган ягы белэн чишелде, эмма милли программаның мэдэни моментларына киленсэ, монда бетмэс-төкэнмэс аңлашылмаулар, хаталар эле һаман да бик күплэр. Партиянең милли программасын гамэлгэ куюда милли җөмһүриятлэргэ каршы барганлыклары өчен урыс иптэшлэр Ленин һэм Үзэк Комитет тарафыннан бик нык орышылдылар. Шул сабакны бөтенлэй онытмаганга, аннан шул милли программаның мэдэни моментлары һэммэсе сэяси яклар белэн бөтенлэй бэйланып беткэнгэ күрэ, алар хэзер сүздэ ачык чыкмыйлар, чыгарга телэмилэр дэ. Чөнки тагын ялгышудан куркалар. Лэкин аларда милли мэдэниятлэр мэсьэлэсенэ бик тирэн шөбһэ белэн караучылар, гамэлдэ һэр адым саен киртэ салучылар, элбэттэ, барлар. Болар теге вакыт милли җөмһүриятлэрне интернационализмга каршы дип хыял кылалар, җөмһүриятне идарэ кылырга җирле халыктан большевик көч табылмас, дип саташалар иде. Хэзер инде: ул украина, үзбэк, казакъ, азербэйҗан, татар, эрмэн, грузин, чуваш халыкларының теллэре, мэдэниятлэре бик зэгыйфь бит, болар белэн маташканчы, югары, бөек урыс мэдэниятенэ кушылып китү — бу миллэтлэр өчен зур файдалы булмас идеме, дигэн шөбһэдэлэр.

Шундый шөбһэлэр, хыяллар кайбер урыс иптэшлэрдэ булган кебек, җирле халыкның үз эченнэн чыкканнарда да юк түгел. Бездэ шэмигуловчылар теге вак милли җөмһүрияткэ каршы кузгалсалар, аның кирэгенэ, файдасына, нэтиҗэле булуына ышанып җитмэсэлэр, хэзер милли татар мэдэнияте дигэнгэ шундый ук шөбһэ белэн, ышанмау белэн карыйлар, ягъни сэяси шэмигуловчылык артыннан мэдэни шэмигуловчылык килэ. Бу соңгының кешелэре дэ, нигезлэре дэ, элбэттэ, башкалар, лэкин тамырлары бердер.

Без югарыда яңа һэм иске тип мирзалар аналогиясен йорткэн идек. Милли мэдэниятлэргэ эһэмиятсез караучылар үткэн тарихта да булганын сөйлэп, шуннан мисал алган идек. Хэзер күрэбез, бу агым үзенең икенче бер канаты, дөресе, тамыры белэн шэмигуловчылык хэрэкэтенэ кайтадыр. Димэк, бу агым ике чишмэдэн су ала. Эмма болар бэхетсезрэк шартларга туры килделэр. Чөнки милли җөмһүриятлэр төзү үзе милли мэдэниятне нык нигезгэ утырту — шуңа таба туры юл ачу, дигэн сүз иде.

Лэкин, шулай булса да, бу агым җөмһүриятлэрдэ милли мэдэниятлэрнең эһэмияте, кыйммэте күтэрелергэ, үсэргэ бик нык киртэ булачаклар. Шуның өчен боларга каршы даими, озак көрэш куярга туры килми булмас. Моның бик нык ачык мисалы үткэндэ дэ күрелгэн иде. Берничэсен хэтерлик.

1924 елның февралендэ Мэскэүдэ җөмһүриятлэргэ кермэгэн татар-башкорт мэгариф эшчелэренең съезды булган иде. Шунда мэктэплэрдэ ана теле мэсьэлэсендэ зур талаш чыкты, секция тарафыннан һэммэ беренче баскыч татар мэктэплэрендэ уку теле — ана теле дип тэкъдим кертелгэн иде. Шуңа берничэ иптэш: «сэнагать[1] теле» кирэк, дип каты каршы чыктылар. Алар эйтте: эшче төбэклэрдэ татар теленең файдасы юк, анда берен-

---

[1] Сэнагать — промышленность

че баскычларда ук уку теле сәнагать теле— урыс теле булсын, диләр. Без моңа каршы бик каты сугыш ачарга, кат-кат полемика ясарга мәҗбүр булдык. Шуның аркасында гына ана телен үткәрә алдык. Шул ук съездның вәкилләреннән аерым киңәшмә ясалып, әдәби тел һәм атамалар тикшерелгән иде. Анда өч агым булды. Берәүләр искедәге кебек гарәпчәлекне саклауны якладылар, әмма берәүләр, һичбернәрсә белән чикләнмәстән, урыс сүзләренә капка ачуны тәкъдим кылдылар. Безгә бу мәсьәләдә бик күп көрәшкәннән соң дөрес тезисларга күпчелек җыярга мөмкинлек булды[1].

Мин уйлыйм, моннан 3-4 ел элек кузгалган әнә шул кечкенә дулкыннар татар һәм урыс мәдәниятләре мәсьәләсендәге хәзерге талашларның ерак беренче кузгалышы иде. Хәзер ул киңрәк рәвештә үзен күрсәтә башлады: аерым кешеләрнең хатасыннан үтеп, укучы яшьләрнең бер өлешенә дә бу чир йокты. Һәрбер начар йогышлы чир кебек, урыслашу сәясәте чире дә тиз таралыр. Шуңа күрә, ул мәсьәләне ачык куеп, аңа кискен җавап кирәк. Зарарлы хаталар белән көрәшергә кирәк. Көрәшнең беренче планында, әлбәттә, бу мәсьәлә дә пролетариатның тоткан юлын аңлатудан башланырга тиешле.

## 2

Беренче баскыч мәктәпләрдә уку ана телендә булу кирәклеге мәсьәләсе турында хәзер ике сүз ишетелми. 1924 елның Мәскәү съездында урыс телендә булсын дип чыгучылар Донбасска таянырга уйлаганнар иде. Аннан бирле үткән өч-дүрт ел эчендә Донбасстан, Уралдан, Себердән һәм татар эшчесе күпчелек булган башка һичбер җирдән үз ана телен ташларга диеп күтәрелү күренмәде. Димәк, бу беренче нигез момент хәзер инде өзелгән.

Өлкәннәр арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә дә бераз аңлашылмаучылык бар иде. Кайбер урыннарда, бигрәк тә урыс күпчелеге эчендә калган эшчеләр арасында, кайбер иптәшләр урыс телендә генә үткәрергә чамалыйлар иде. Хәзер ул да тынычланды. 1913-14 елларда, бигрәк тә сугыш чорында, Русиядә урыс милләтчелегенең аеруча котырган заманы иде. Бу исереклек социал-демократиянең дә бер катлавын үз эченә алган иде. Менә шул заманда Владимир Ильич Ленин «О национальной гордости великороссов» исемендә бер мәкалә язды. Анда шул сүзләр бар иде:

«Без аңлы великорус пролетарийлары өчен милли горурлык чит бер нәрсәме? Әлбәттә, түгел. Без үзебезнең телебезне, үзебезнең туган илебезне сөябез. Без башка һәрнәрсәдән артык үз туган телебездәге хезмәт массасын, ягъни андагы халыкның уннан тугыз өлешен аңлы демократлар һәм социалистлар дәрәҗәсенә күтәрү өчен эшлибез».

Монда мәсьәлә партия программасы ягыннан бигрәк, пролетариатның үз теленә, үз иленә карашы ачык бирелә. Арада аеруча мөһим момент соңгысыдыр. Анда һәр революционерның, һәр коммунистның өстендәге бурыч, башлыча, үз илендә, үз халкының хезмәт массасы эчендә эшләү икәнен аңлата.

Без югарыда партиянең XII съезд карарларыннан берсен укып үттек (II бүлектә). Аның тәрҗемәсе болай:

«Милли җөмһүриятләрнең һәм өлкәләрнең органнары, башлыча, җирле халыклар эченнән чыгып, шуларның горефләрен, гадәтләрен, тормышларын, телләрен белгән кешеләрдән төзелергә тиешле».

Менә бу момент, бер яктан, милли җөмһүриятләрнең эшләрен башкаручылар — шул җирле халыкның үзеннән куелу гына җитмәвен, бәлки бу кешеләр шул халыкның тормышы, гореф-гадәте, теле белән таныш булуларын лязем итә. Урыслашкан «мираз» татар чиновниклары партия, совет өчен үзләренең милли җөмһүриятләрендә кыйммәтләрен бетерәләр. Икенче яктан, моның белән мәктәп-тәрбия мәсьәләсендә төп бер принцип бирелә: мәктәпләр тормыш өчен кеше әзерләргә тиеш. Бу халыклардан әзерләнүчеләрдән йөзгә берсе бәлки башка милләтләр эчендә эшләргә кирәк. Әмма калганнары, әлбәттә, үз илләрендә, үз милләтләре арасында эшләячәкләр. Мәктәп исә аларны, югарыда күрсәтелгәнчә, үз теле, үз

---

[1] Бу тезислар, хәзер Гыйльми үзәк тарафыннан рәсми кабул кылынып, гамәл өчен таратылдылар.

мәдәнияте белән сугарып чыгарырга бурычлы була. Ул һәм үзенең программасын шуңа карап төзергә мәҗбүр. Беренче баскычларда, икенче баскычларда, техникумнар, курслар, институтлар һәм югары мәктәпләрдә партиянең — советның әнә шул принцибы буенча, үзләрен җирле тел, мәдәният белән тәрбияләнгән хезмәтчеләр чыгарырга, димәк, дәресләрен шуңа карап куярга тиешле булалар.

Без бу китапның башында, эпиграф рәвешендә, мәшһүр марксист-большевик профессор Покровскийның «Урыс мәдәнияте тарихы» дигән китабыннан бер сүзне китергән идек. Аның тәрҗемәсе болай була:

«Мәдәниятне аерып билгеләүче нәрсә һәм мәдәният алуда иң баш, иң кирәкле корал — телдер. Бу тел коралыннан башка мәдәният һичбер төрле була да алмый». — ди.

Октябрь революциясе менә бу якны бик нык ачып бирде. Милли телләрне үстерү, милли әдәбиятларга киң юл һәм зур ярдәм бирү, милли телләрдә гыйльми-сәяси, әдәби атамалар тудыру моментлары хәзер совет милли җөмһүриятләрендә дөньяның һичбер җирендә күрелмәгән рәвештә кайнап, җанланып китте. Гади вакытларда, бәлки, ничә ун еллар кирәк булачак өлкән эшләр хәзерге диктатура заманының рухы буенча, берничә ел эчендә мәйданга киләләр. Казагыстанда, Татарстанда, Кырым һәм үзбәкләрдә аз бер заманда хисапсыз күп нәтиҗә алдылар. Мәдәни әзерлеге, икътисади куәте зуррак булганнар исә инде телләре, мәдәниятләре белән университетларгача барып тулдылар.

Төрки җөмһүриятләрдән Әзербәйҗан үзендә университет ачып, аның көнчыгыш факультетында төрки телдә лекция укуны гамәлгә куярга ирешә. Үзбәкстанның Ташкент университетында да көнчыгыш факультеты ачылып, анда төрек халыкларыннан беренче мәртәбә мөдәррисләр кертелеп, төрки телдә эш булганлыгы күрелде. Үзенең мәдәни әзерлеге зур булган Грузия, санының азлыгына (миллионнан кимнәр) карамастан, аппаратларны һәм гыйлем йортларын да ана телендә куйды. Хәзер грузин профессоры грузин телендә университетта дәрес алып бара. Саны күп, гыйльми әзерлеге югары булган Украина каты кул белән үз телен күтәрде. Университетларны украинлаштырды. Ул гына түгел, аз бер заман эчендә, пролетариат революциясенең ярдәме аркасында, украина телендә эшли торган Гыйльми академия мәйданга китерде. Болар, шөбһәсез, пролетариат хәрәкәтенең милли мәдәниятләр үстерү юлында күрсәткән могҗизаларыннандыр.

## Сталин формуласы

Дөньяның алтыдан бер өлешендә туктаусыз кайнап, кызып, үсеп торган бу милли мәдәниятләрне күз алдына китергәндә, кайбер күңелләрдә шөбһәләр уяна: интернациональ максудлар өчен туган революция бөтенләй милли теләкләргә корал булып китмиме? Бу милли мәдәниятләрнең киләчәге ни булыр? Боларны киләчәктә гомуми мәдәниятка кушу мәсьәләсе тагы зур бер комачау тудырмасмы?

Бу мәсьәлә төрле фикер кешеләрендә төрлечә калыпланып чыга. Шуңа күрә бу хакта бер җавап кирәк. Минемчә, моңа иң ачык һәм тулы җавапны И. В. Сталин иптәш бирде. Көнчыгыш хезмәт халыклары университетында сөйләгән сүзендә ул болай диде[1]:

«Мин көнчыгыш совет җөмһүриятләрендә милли мәдәниятләрне күтәрү турында әйткән идем. Ләкин милли мәдәният дигәне нәрсә ул? Милли мәдәният белән пролетариат мәдәниятен ничек бергә җыярга мөмкин? Ленин бит сугышка чаклы ук әйткән иде: бездә ике төрле мәдәният бар — берсе буржуазия мәдәнияте, икенчесе социализм мәдәнияте. Милли мәдәният дигән лозунг — реакция лозунгысы. Буржуазия бу лозунг белән халык массасының аңын милләтчелек агуы белән зәһәрләргә тели, дигән иде. Шулай булгач, милли мәдәният төзү, ана телендә курслар, мәктәпләр үстерү, җирле кешеләрдән кадр җитештерү кебек эшләрне социализм төзү белән, пролетариат мәдәнияте төзү белән ничек бергә сыйдырырга була? Монда үтеп чыгара алмаслык каршылык юкмы? Әлбәттә, юк!!

Без пролетариат мәдәнияте төзибез. Монда һич шик юк. Ләкин үзенең мөндәриҗәсе буенча социализм нигезендә булган пролетариат мәдәнияте,

---

[1] «Правда», 1925, 22 май буенча алдым. Бу хакта аерым китап та бар. «Биш ел эчендә» китабында да бар (Казан. 1925. Комбинат басмасы). (Г. Ибраһимов искәрмәсе).

социализм төзелешенә катнашкан төрле халыкларның тормышларында, телләрендә булган башкалыкларга карап, үзенең тышкы калыбында, шәкелендә бик төрлечә була: мөндәриҗәсе белән пролетариатча, форма буенча милли — менә социализм бара торган гомумадәм мәдәнияте шулай булачак. Пролетариат мәдәнияте милли мәдәниятне бетерми (юкка чыгармый), бәлки аңар форма бирә». Шул ук төп фикерне ачуда дәвам итеп, Сталин әйтә:

«Буржуазия властьта булып, халыкларның милләт булып оешулары аның канаты астында ясалган дәвердә милли мәдәният лозунгысы — буржуазия лозунгысы иде. Пролетариат властьны алып халыкларның милләт булып оешулары совет канаты астында ясала башлагач, милли мәдәният лозунгысы — пролетариат лозунгысы булып әверелде. Ике дәвердә ике төрле хәл булган бу принцип аермасын аңламаган кеше ленинизмны һичбер вакыт аңлый алмас, шулай ук ленинизм каршында милли мәсьәләнең үзге ничек булганын да аңлый алмас».

Милли мәдәниятләр мәсьәләсендә оппортунистларның карашларын һәм социализм вакытында телләрнең ни хәлдә булачагын аңлату юлында Сталин бу рәвешле сөйли: «Кайберәүләр (мәсәлән, Каутский) социализм вакытында башка һәммә телләр бетеп, бөтен кешеләр өчен уртак булган бер телнең туүы турында сөйләнәләр. Мин мондый бөтен дөньяны эченә алган бер тел була алу нәзариятенә аз ышанам. Тәҗрибә, һәрхәлдә, бу нәзариятне куәтләп түгел, бәлки моңа каршы сөйли, моңа чаклы хәл шулай барды — социализм революциясе телләрнең санын киметмәде, бәлки арттырды гына. Чөнки адәм дөньясының иң тирән яткан түбәнге катлауларын кузгату, боларны сәяси мәйданга күтәрү сәбәпле, социализм революциясе аңа кадәрге бөтенләй мәгълүм булмаган яки аз мәгълүм булган милләтләрне яңа тормышка уйгатып чыгарадыр. Иске патшачылык заманында Русиядә илледән артык милләт һәм этнографик группалар бар дип кем уйлар иде? Октябрь революциясе иске богауларны өзде, мәйданга бик күп онытылган халыкларны чыгарды, шуның белән аларга яңа тормыш, яңа хәрәкәт бирде. Хәзер Һиндстан турында бөтен бер милләт кебек сөйлиләр. Ләкин анда революция булса, мәйданга аңарчы (киң дөньяга) мәгълүм булмаган, ләкин үзләренең мәдәниятләре белән яшәп килгән бик күп милләтләр баш күтәреп тарих мәйданына чыгарлар. Әгәр бу төрле милләтләрне пролетариат мәдәниятенә кушарга уйланылса, бу кушылу, ул милләтләрнең тормышларына, телләренә муафикъ ясалган рәвештә генә булачагында шөбһәләнергә ярамый...» — ди.

Бөтен коммунистларның сөальләренә җавап итеп, Сталин болай ди:

«Бурят иптәшләр гомуми адәм мәдәнияте төзелгәндә аерым милләтләрнең ассимиляциясе (йотылуы) турында мәсьәлә куялар. Шөбһә юк, кайбер милләтләрнең йотылулары мөмкин, бәлки йотылдылар да. Андый процесслар элек тә була иде. Ләкин кайбер милләтләрнең йотылу процессы башка милләтләрнең зур, көчле булып күтәрелүләренә каршы булмый, бәлки шуны куәтли генә. Чөнки аерым берәүләрнең йотылуы башка милләтләрнең гомуми тәрәккый итүләренең нәтиҗәсенә башка нәрсә түгелләр. Менә бу безнең алдагы фикерләребезгә куәт кенә арттырадыр. Кайбер аерым милләтләрнең йотылу мөмкинлеге безгә шуны ачып бирә: гомумадәм өчен булган пролетариат мәдәнияте милли мәдәниятләрне җимерми, бетерми, бәлки боларның булуын лязем итә һәм боларга яшәргә ризык бирә. Шулай ук милли мәдәниятләр дә гомум адәмнең пролетариат мәдәниятен бетерми, юкка чыгармый, бәлки аны тутыра, аңа байлык арттыра гынадыр...» — ди. Сталин фикерләре аеруча шәрех теләмиләр. Монда һәммә мәсьәлә якты көн кебек ачык куелган. Шуларга ачык кискен җаваплар бирелгән: пролетариат революциясе милли мәдәниятләргә үсәргә киң мәйдан бирә. Социализм вакытында да милли мәдәниятләр бетмәячәкләр, баеп, зураеп күтәреләчәкләр: «милли» белән «пролетариат» мәдәниятләрен бер-беренә каршы куярга ярамый. Болар бер-беренә дошман түгел, болар бер-берен бетермиләр, бер-беренә каршы көрәш ачмыйлар, киресенчә, болар бер-берен тутыралар, бер-берен баеталар, боларның бер-беренә мөнәсәбәт рәвеше — мөндәриҗәсе белән пролетариатча, әмма формасы белән милли булачак.

Бу формула турында озак тукталып торырга хаҗәт юк дип беләм. Моның мәгънәсе, аңлаешлы һәм форма буенча милли булыр дигән сүздән морат нәрсә икәнлеге, әлбәттә, һәркемгә ачык: халыклар үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, тормышлары, тарихи язмышлары буенча берберләреннән тышкы калыпларда байтак аерылалар. Шуңа карап, аларның һәрберенең мәдәнияте, мәдәни хәрәкәте дә тышкы төстә үзенә башка аерым рәвештә гәүдәләнәләр. Мәсәлән, мәктәп, сәнгать, гыйлем, әдәби-

ят — болар һәммәсе милләтнең үз телендә булырлар. Үз телендә киңәеп, тирәнәеп үсәрләр, үз зәукына, үз хаҗәтләренә карашып туарлар, үзенә уңгай, аңлаешлы калыпларга салынырлар, үз тормышы белән сугарылып, үзләренең аерым тарихи моментлары, тудырган мәсьәләләре юлында эшләрләр; менә бу яклар буенча үзбәкләрнең, урысның, казакъның, әрмәннең, татарның, грузинның, башкортның, украиннарның, әзербәйҗан төрекләренең мәдәниятләре бер-береннән бик нык аерылырлар, бу тышкы калыпларда һәр халыкның мәдәнияте үзенең милли нигезендә, үз ана телендә, үз тормышының аерым хасиятләре белән сугарылыр, аерым рәвешләнер. Ләкин эчке идеологиядә, төп нигез принципларда, алдагы максудларда бу төрле телдә, төрле төстә, төрле калыпта булган бу күптөрле милли мәдәниятләр һәммәсе берләшәләр: пролетариат революциясе аркылы коммунизмга бару, моның өчен интернационал байрак астында, тел аермаларына карамыйча, киң эшче-крәстиян коллективы буларак көрәшү; үз буржуасына һәм бөтендөнья капитализмына каршы сугыш фронты тоткан хәлдә социализм төзү юлында эшләү, моның өчен бөтен мәдәниятләрне, гыйлемнәрне, сәнгатьләрне материализм нигезенә салып, буыннарны киләчәк гомумадәм максудлары рухында тәрбияләү, мәктәпләргә, техникага, җәмгыятькә, көндәлек гаилә тормышларына, кыскасы, бөтен мәдәни хәрәкәтләргә менә шундый һәммә телдәге хезмәт халыкларының якты, азат киләчәкләре өчен уртак булган мәнфәгатьләре ягыннан карап юлбашчылык кылу — менә аерым мәдәниятләрдә шундый нигез, уртак мөндәриҗәләр булыр. Бөтен икътисади, сыйнфый хәятнең тимер кануннары үзләре шуңа алып барачаклар. Чөнки телләре теләсә нинди генә булса да, һәммә хезмәт халыкларының чын азатлыклары аларны шундый нигезләрдә, шул рәвешле берләшеп хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә. Мәдәниятләр моңа буйсыналар гына. Монда, әлбәттә, буржуазиянең, вак буржуа элементларының төрле якка тайпылулары буржуазиядән калган мирас буенча мәдәниятькә, идеологиягә милли дошманлыкларны уйгатып, арада милли талашларны, буржуа дөньясындагы кебек яңадан кыздырырга омтылулары күп замангача була торыр. Ләкин, төрле телләрдәге халыкларның хәзерге сәяси-икътисади фронтларында җиңеп чыгуы өчен аңлы пролетариатның туктаусыз ярдәме кирәк булган кебек, бу мәдәни төзелешләрдә дә ул лязем булачак. Мондый юлбашчылыктан да башка, бигрәк тә беренче адымнарда, беренче баскычларда хәл мөшкел булачак. Мондый крәстиянне пролетариат белән элемтә мәсьәләсе аеруча үткенләшкән хәлдә килеп чыгадыр. Шуңа күрә мәдәни төзелешләрдә Сталинның югарыгы формуласы, «менә шундый сызык сыздык та юлга төшереп җибәрдек, ничә төрле төстә җыелган бу машина мәшәкатьсез коммунизмга барып житәр», дип уйлау хата булачак. Монда тик сыйнфый-икътисади анализ нәтиҗәсендә тарихның кая таба һәм ничек барачагы турында диагноз куела: тарихның тенденциясе бирелә, әмма ул юл теге сәяси-хәрби моментлар кебек үк каты көрәшләр аркылы барылачак. Монда да пролетариатның юлбашчылыгы аерым бер каты рәвештә лязем булачак.

## VI

## Безнең өчен кайсы юл?

Сталин иптәш тик пролетариат революциясе һәм социализм хәрәкәте чагында милли мәдәниятләрнең язмышлары ничек булачагы турында гомуми формула бирә. Әмма аерым, конкрет бер мәдәният турында анда җавап юк. Киресенчә, ул бурят студентларына карата әйткән сүзендә ассимиляция мәсьәләсен кузгата. Кайбер халыкларның башка мәдәниятләргә кушылып китүе мөмкинлегенә ишарә ясый. Димәк, мәсьәләнең бу аерым конкрет моментын, һәр халыкның үзенең сыйнфый-икътисади, тарихи-мәдәни хасиятләренә карап, аерым чишәргә кала. Чыннан да, бу зур мәдәни хәрәкәт дулкынында, шөбһәсез, күп милләтләр үзләренең моңарчы кысылып торган мәдәниятләрен нык үстерерләр, адәм дөньясына яңа мәдәни кыйммәтләр иҗат кылырлар, әмма кайбер халыклар, бәлки, үз мәдәниятләреннән язып, башкаларга йотылырлар. Арада урыска кушылып китүчеләр булган кебек, грузинга, үзбәккә, казакъка, әзербәйҗанга катнашып, шулар мәдәнияте эчендә эреп китүче кечкенә кабиләләр дә булыр.

Бу мәсьәлә татар өчен ничек тора?

Татарлар, бу пролетариат хәрәкәте нигезендә милли мәдәният үстереп, социализмга баручы милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып дәвам кылырлармы, әллә татар хезмәт халкы, мәнфәгате ягыннан караганда, башка берәр мәдәни хәрәкәт эченә кушылып китү файдалырак булачакмы? Кушылса, кемгә? Чувашкамы, французгамы, башкорткамы, урыска яки үзбәккәме? Менә бу — бик нык уйланырга һәм бик сак җавап бирелергә тиешле бер мәсьәләдер. Без милләтчеләр түгел. Мәсьәләгә милли идеология, милли-дини фанатизм ягыннан имәс, бәлки югарыгы сүзендә Ленин әйтмешли, үз милләтебезнең 9/10 ы булган хезмәт мөәссәсенең[1] сыйнфый мәнфәгате ноктасыннан карап анализ ясарга бурычлыбыз. Монда уйланырга тиешле байтак моментлар бар.

Француз мәдәнияте зур, бай, югары. Ләкин без икътисади һәм сәяси якларда алардан бөтенләй өзелгәнбез. Шуңа күрә ул мөмкин түгел, диярләр. Чувашлар, башкортлар — якыннар, күршеләр, кардәшләр, безгә көнкүрештә дә бик нык баглылар. Ләкин болардагы мәдәни хәрәкәт һәм икътисади-сәяси куәт татардагыдан зәгыйфь, диярләр.

Урысның теле бик бай, әдәби, гыйльми теле бөтенләй эшләнгән һәм матур. Урыс әдәбияты дөньяның иң алдынгы әдәбиятларыннан санала. Урыс мәдәнияте безгә караганда бик күп, бик күп дәрәҗәдә югары. Соңгы ун ел исә урыс әдәбиятына, урыс гыйлеменә, урыс мәдәниятенә бик көчле рәвештә пролетариат элементы кертеп, аеруча зур, яңа кыйммәтләр арттырды. Бу югары (гали) мәдәният безгә якын булу гына түгел, һәммә яктан безне чолгап алган. Без аның эчендә, диңгездәге бер атау кебек, уралып алганбыз, тарихи яктан караганда, мең еллар буенча бу мәдәнияткә күрше яшәдек, 3-4 йөз ел инде бөтенләй моның уртасында калдык. Бу мәдәният бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемләребез, безнең революция хәрәкәтләребез — һәммәсе бу урыс мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр. Икътисади, сәяси яктан да без бөтенләй диярлек береккәнбез. Хәзер безнең тормышыбызның һәммә ягында бу югары урыс мәдәниятенең элементлары туктаусыз арта баралар. Урыс мәдәнияте туктаусыз дулкыннар белән безгә керә, тула бара. Шулай булса?.. Шулай булса, татар өчен, үзенең иске колакчынын утка ягып, бу яңаны кию файдалырак булачагы үзеннән-үзе ачык түгелме?

Татарның саны бик аз. Үзе бик таркау. Мәдәнияте, урыс мәдәнияте белән чагыштырмас дәрәҗәдә түбән! Татарның әдәбияты, татарның театры, татарның мәктәбе, матбугаты — болар бит һәммәсе Мәскәүнеке белән үлчәштергәндә бөтенләй югалып калалар. Татарның хуҗалыгын, икътисадын тикшереп караучылар якын киләчәктә дә бик тиз генә татар мәдәниятенең гөрләп үсеп, тиз генә югары менеп җитүенә өмет ачмыйлар түгелме?

Бурят егетләре үз халыкларының мәдәниятләре турында күп уйлаганнар булса кирәк. Сталинга аерым хат язып, җавап сораулары шуны күрсәтә, әмма бездә бу әле нәзари рәвештә куелмаган, уйланып, тикшереп ачык юл сызылмаган, таяклар кадалмаган.

Ләкин гамәлдә бу мәсьәләгә төрлечә җавап бирелә. Төрле төркемнәр үзләренең эшләре белән моңа ничек җавап биргәнлекләрен күрсәтәләр.

Әһәмиятле, роле аз булган бер төркем — фатализм иманындалар. Алар, тарихның «сукыр» агышын барыбер үзгәртеп булмый дип, бу хакта бертөрле активистлыктан ваз кичкәннәр: ни булса, шул булыр!

Икенче берәүләр, аңлап яки аңламастан, уйлап яки уйламастан, теләп яки теләмәстән, бу зур мәсьәләдә тормышның кечкенә бер катлавында сизелгән агымга яталар. Тикшереп гыйльми бер нәтиҗәгә килүне көтмәстән, татар мәдәниятенең киләчәк язмышын җиңел кулдан чишеп ташлыйлар.

Техникумда татар малаеның: «Әй, татарда нәрсә булсын? Мин лутче урысчага бирелэм».— дип, татар китабын атып бәрү вакыйгасы — менә моның байтак очрый торган кечкенә, тупас мисалларыннан берсе була алыр. Бик зур мәшәкать белән татар дәресләре кертелә алган Казан югары мәктәпләренең берендә (вузда) укучы шәп татар егете гыйлеме белән бик чамалы булган урыс теле мөгаллиме алдында тирләп, куркып, калтырап зачет биргәне хәлендә, квалификациясе буенча тегеннән өстен торган татар теле, әдәбияты укытучысы алдына барып зачет бирергә хурлануы, шуны «булса да, булмаса да ярый ла» дип каравы — тагы шул бер нигезнең төрлечә күренүеннән башка нәрсә түгел. Кайбер татар егетенең үз теле, үз каләмен белмәвен кимчелеккә санамавы, татар әдәбиятын укымауны ниндидер бер «мәдәни» мактану белән сөйләнеп йөрүе кебек хәлләр дә — шуның

[1] Хезмәт мөәссәсе — хезмәт иярләре.

үрнәгедер. Татар җөмһүриятенең мәсъүл[1] татар хезмәтчесе Татарстан мәсьәләсе турында татар редакциясенә бирәчәк мәкаләсен урыс телендә язып яки яздырып җибәрүе дә әнә шул аңлап яки аңламыйча дәвам кылган урыслашу нәмунәләреннән[2] бередер.

Татарның мәктәбе, татарның әдәбияты, татар телендәге гыйльми әсәрләре, татар театры һәм татар мәдәниятенең башка күп тармаклары да татарның җилкуаррак бер нечкә катлавы алдында шундый бер хөрмәтсезлек белән каралалар: башка бик күп рәсми урыннарда да татар теле, татар мәдәнияте әле һаман эчке тирән мәгънәви кыйммәт һәм авторитет алмаганлыгын монда нечкәләп тикшерсәң, урыс мәдәнияте алдында татарныкын кадерсезләү галәмәтләре очраганлыгын, әлбәттә, яшерергә ярамый. 25 гыйнвар җыелышында кайбер иптәшләр уйламыйчарак ычкындырган моның сүзләрендә серләрен бераз ача да төштеләр.

Берәүнең:

— Татар теленең, татар мәдәниятенең кирәге — караңгы крәстиян массасын үз телендә агартып, безнең дәрәҗәгә күтәрү өчен генә,— дигән сүзе;

Икенче берәүнең:

— Татар теленең, мәдәниятенең роле, кыйммәте мәктәпләрдә артта калган группалар өчен ясала торган вакытлы хәзерлек группаларының кыйммәте, әһәмияте дәрәҗәсендә генәдер,— дигән фикере;

Өченче берәүнең:

— Татар мәдәниятенә әһәмият бирмәү һәм руслашу дигән нәрсә белән кешеләрне артык куркытырга урын юк. Моның мәгънәсе зәгыйфь. Кечкенә мәдәнияттән зур мәдәниятк‍ә кушылу дигән сүз генә,— дип, ачыктан-ачык мәшһүр тарихи руслашу сәясәтен аерым бер нәзари нигезгә салуы — болар һәммәсе әнә шул татарның яңа тип мирзалары аерым бер дулкын — аерым агым рәвешендә гәүдәләнеп килгәнлеген күрсәтүче хәлләр булалар.

Димәк, безгә татар мәдәниятенә каршы үзенең сәлби[3] карашын ачык билгеләгән бер нечкә катлауның барлыгын бер факт итеп карарга туры килә. Бу бер як.

Ләкин татар хезмәт массасы, татар эчендәге мәдәни-иҗтимагый агым нинди юл белән бара? Революция һәм тормыш бөтенләй шул югарыгы дулкындамы, әллә моңа каршымы?

Моннан 8—9 еллар элек үк революция дулкыны эчендә бер агым бөтен хәрәкәтне шул якка таба борып алып китәргә теләде. Җөмһүрият булсынмы, юкмы дигән мәсьәлә — менә шуның күләгәсе иде. Татар җөмһүрияте гәрчә ул вакыттагы талашларда тик сәяси бернәрсә кебек күренсә дә, асылда аерым милли җөмһүрият белән татар мәдәниятенең киләчәге һәм бу мәдәни хәрәкәтнең формасы билгеләнә иде. Чөнки җөмһүрият төзү, димәк, милли татар мәдәниятенә төп нигез салмак, татар мәдәниятенең совет хуҗалыгы һәм икътисади нигезенә һәммә тармакларында эшләп, баетып торучы бер машина кормак дигән сүз иде. Җөмһүриятк‍ә каршы баручылар, аңлап яки аңламастан, уйлап яки уйламастан, пролетариат революциясе эчендә татар мәдәниятенә юл куймау, татарның аерым мәдәниятле булуыннан бигрәк, югары урыс мәдәниятенә кушылып китүен яклаучылар иде.

Партия үзенең бу саташкан улларын акылга утыртты. Үзенең бөтен мәдәни-сәяси нәтиҗәләре белән берлектә җөмһүриятне төзеп бирде. Милли мәдәниятенең нигезләреннән берсен рәсмиләштерде. Элекке заманда татарның урыслашуын, үз мәдәниятеннән ваз кичеп, урыс мәдәнияте эченә йоту сәясәтен алып баручылар коры мәдәни яктан кысу белән тукталмадылар, бәлки татарны милли мәдәниятенең нигезе булган хуҗалык-икътисад ягыннан да изәргә, зәгыйфьләтергә тырышалар иде.

Пролетариат революциясе милли мәдәниятк‍ә ирек биреп, аңа җөмһүрият кебек рәсми нигез салу белән генә калмады, бу мәдәни хәрәкәтнең икътисади фундаменты һәм хуҗалыкның ныгуы турында да татар өчен бик күп ярдәмнәр ясады.

Революция аркасында татар крәстияненең җире артты. Моның белән мәдәни хәрәкәт нигезе — икътисади бер дәрәҗәгә күтәрелде, элек татар авыллары шәһәрләргә, зур елгаларга, тимер юлларга якын җирләрдән читкә, аз табышлы урыннарга сөрелгәннәр иде. Пролетариат хәзер бу зур тарихи җәбергә каршы чара күрү юлын тотты — татар крәстияннәренең бер

---

[1] Мәсъүл — җаваплы.
[2] Нәмунә — үрнәк.
[3] Сәлби — тискәре.

өлеше Волгага, Казанга якын урыннарга, элекке мәшһүр кенәз Гагариннар, маркиз Паулуччы җирләренә күчерелә башланды. Хәзер ул туфракларда яңа үсеп чыккан — «Йолдыз»лар, «Үрнәк»ләр, «Нариман», «Кызыл байрак», «Идел», «Чулпан», «Мулланур Вахитов», «Кызыл юл», «Игенче», «Берек», «Маркс», «Татарстан», «Салкын чишмә», «Яңа тормыш» кебек татар авыллары — болар әнә шул киләчәк зур эшнең кечкенә башлангычлары булалар.

Күп басуга күчә башлау, татар авылына яңа культуралар, агрономнар, тракторлар килү, авыл кооперациясендә татарның нык катнашуы — болар һәммәсе татар авыл хуҗалыгында совет вакытында ныгаюны, димәк, мәдәният көчәюне күрсәтәләр. Элекке изелеп яшәү бетеп, татар крәстияненең авылда, волыста, кантонда, губерна яки җөмһүриятгә, аннан үтеп бөтенсоюз күләмендәге зур совет съездларында активист буларак катнашуы — шөбһәсез, көчле мәдәни галәмләрдер. Моны коры декларация дип уйларга ярамый. Бер ак сакаллы татар картының Мәскәүгә Бөтенрусия советлары съездына барып президиумда утырулары, әллә ни чаклы гади татар крәстияннәренең шунда катнашулары — болар иске, басылып, тапталып яшәгән татар хезмәт массасының активистлыгын, гайрәтен уятуда бик зур роль уйныйлар, болар мәдәни хәрәкәткә зур булышлык кылалар.

Электән татар эшче катлавы да аерым авыр хәлдә иде. Революция соңында аңа азмы-күпме үзенең квалификациясен күтәрергә, яшь буыннарны фабзавуч аркылы әзерләргә юл ачылды. Совет-партия эшләренә активист рәвешендә кушылу белән монда сәяси һәм мәдәни аң киңәюгә мәйдан булды. Бу хәлләр татар мәдәни хәрәкәтендә юлбашчы катлауның көнкүрешендә һәм әзерлек ягында үсәргә ярдәм бирделәр. Хәзерге көндә эшче районнарында кызу мәдәни хәрәкәт гөж килеп кайный. Татар пролетарийлары, бигрәк тә яшьләре, бу хәрәкәттә бик нык катнашалар. Монда һәммә нәрсә ана телендә бара.

Әгәр татарның интеллигенциясе хәленә килсәк, Октябрь аркасында, бигрәк тә җөмһүрият сәбәбеннән, монда тирән алмашу булды. Элек татар зыялысы үзенең зур күпчелегендә кем иде? Байның кәефенә карап яшәгән укытучы яки язучы иде. Дәүләт хезмәте белән тәэмин кылынганнар меңгә бер генә иде (аз-маз чиновник, юрист, доктор, бернечә инженер).

Бу хәл аларның матди тормышларында тәэминсезлекләренә, җәмгать хәрәкәтләрендә билгеле бер роль уйный алмауларына сәбәп була иде. Әмма хәзер татарларның барлык зыялы көче рәсми дәүләт механизмы эчендә иң кирәкле һәм тулы хокуклы элемент булып урын алды. Ул канцелярия хезмәтчесеме, комиссармы, командирмы, язучымы, укытучымы, укучымы, партия аппаратында, хуҗалыкта, кооперациядә эшләүчеме, кыскасы, кем генә булса да, ул хәзер — үзенең профсоюзы, месткомы канаты астында, рәсми совет аппаратының рәсми декретлары белән тәэминле челтәрендә билгеле шартлар буенча, мәгълүм бурычны үтәп баручы бер куәт. Моның аркасында бездә электән килгән зыялы көчнең хезмәте канун эченә кереп, матди тәэмине рәсмиләште, ныгайды, шуның белән бергә пролетариат революциясе эчендә бу катлау бик зурайды, киңәйде һәм боларга һәртөрле курслар, янадан әзерләүләр белән үзләренең квалификацияләрен күтәрүгә киң мөмкинлек туды. Болар гөжләп кайнап торган мәдәни куәтләргә әйләнделәр. Боларның аяк баскан тупраклары ныгыды. (Хәлбуки, элекке зыялы — урысның кысуыннан зарланып, елап йөргән бер кызганыч бәндә иде). Шулай итеп, татар мәдәни хәрәкәтендә зур роль уйнаячак бу өченче кыйммәтле катлау революция соңында үзенең матди ягын ныгытты, рәсми хокуклы, тәэминле бер көч булып, татар тормышында зур роль уйнарлык хәлгә таба юл алды.

Мәдәни хәрәкәтнең көчәюе яки түбәнәюе мәсьәләсендә болар үзләренең куәтләрен бик нык сиздерәчәкләр.

Ләкин монда шуны тагын хәтердән чыгармаска кирәк.

Милли мәдәният дигәннән, кәләпүш киеп, без өч йөз ел изелгән, дип, хәсрәт җыры җырлап йөрүне генә алу хата булачак. Шөбһә юк, милли мәдәниятнең төп элементлары эченә башлыча халыкның үз тормышыннан алып, үз теле нигезендә, үз хаҗәтләренә каратып, үзе тарафыннан иҗат кылынган кыйммәтләр керәчәкләр. Ләкин милли мәдәният чиген моның белән кыскарту бик зарарлы идеализм булыр иде.

Дөньяда һичбер халык башкалар белән алмашудан башка яши алмый. Тик товар алмашу гына түгел, техника, гыйлем, сәнгать, һөнәр, тәҗрибә, гадәт, методлар алышу мәдәни хәяттә беренче рольне уйнаучылардан була. Трактор хәзер — бәйнәлмиләл бер техника җимеше. Ләкин аны татар авылына китереп, җир сөрерлек хәлдә кузгатып, шуның белән эш эшләү — менә бусы инде милли мәдәният хәзинәсенә яңа байлык арттыру була. Татарча гадәтләнү дип алыйк. Урысчада навык диләр. Менә бу — ха-

лыкның тормышында, хуҗалыгында бик зур роль уйный. Асылда бөтен тәрбия нигезе яшь буынга мәгълүм навыкларны үзләштерү максудына корыладыр. Матди тормышта моның зур кыйммәте бар. Татар эшчесенең мәгълүм квалификациясе, татар крәстияненең яңа техника белән хуҗалыкны алып бара белүе, зыялының мәгълүм бер һайда мәгълүм бер дәрәҗәдә әзерлекле булуы — болар һәммәсе милли мәдәният хәрәкәтендә кирәкле рольләрне уйныйлар. 25 гыйнвар җыелышында бер әйтте: трактор, индустрия, паровоз — болар бәйнәлмиләл нәрсәләр, ди. Бу дөрес. Ләкин бөтенләйгә түгел: трактор берәр коллектив тарафыннан чыгарылганмы, әллә берәр милләттәнме? Ни өчен ул Чувашстанда түгел, Америка милләтләрендә башлап ясалган? Чөнки ул милләтнең мәдәниятендә шуңа шартлар, әзерлекләр булган. Тракторның чыгуына байтак еллар инде. Күп башка милләтләрнең крәстияннәре аны әллә кайчан үзләренең тормышларына керттеләр. Әмма татар крәстияне моны 3 елдан бирле генә ишетә башлады. Әле шуны китерергә, файдасын аңларга, йөртергә яңа өйрәнә. Димәк, техника, гыйлем, сәнгать бәйнәлмиләл хәзинә булсалар да, болардан файдалана белү — файдаланырга өйрәнә алу — менә бу навык һәм тәҗрибә — милли мәдәниятнең бер тармагы булып саналадыр. халык моны үзе тырышып, үзе теләп өйрәнергә — үзләштерергә тиешле. Менә шул мәгънә белән милләтнең һәртөрле специалистлары — милли мәдәният хәзинәсендә аерым кыйммәтләр булып урын алалар. Боларда мәдәни хәрәкәт гәүдәләнә, болар шуны ташучылар булалар. Менә бу яктан татар милли мәдәнияте, революция вакытында гадәттән тыш күп җимеш алды, татар эшче-крәстияннәре үз эчләреннән бу мәдәни гадәтләрне, мәдәни кыйммәтләрне ташучыларны җитештерде. Җөмһүрият төзү моңа гаҗәп бер тизлек һәм киңлек бирде. Безнең кебек революциягәчә дә татар мәдәни хәрәкәтендә эшләп килгән карт буын бу юлдагы уңышлы тизлекләргә кайбер вакыт хәйран булып гаҗәпсенеп карыйлар.

Мәсәлән, татардан трест башлыклары, заводларда, фабрикаларда билгеле бүлекләрне алып баручылар, татарлардан җөмһүрияттә генә түгел, бәлки Россия үлчәвендә яхшы-яхшы администратор, яхшы кооператор, тәҗрибәле урыслар яки яһүд белән бер дәрәҗәдә барган банк директоры, әзерлекле командир, эшлекле комиссар, дөрес юлбашчылык кылучы партком секретаре, ячейка секретаре, акыллы комсомол, яңа заманча тәрбияле укытучы, марксист язучы, материалист тарихчы, пролетариат рухында сугарылган шагыйрь, әдип, яңа студент, революцияче артист, масса белән бәйләнешле профсоюз хезмәтчесе — менә болар һәммәсе бит мәдәниятнең җанлы кешеләрдә гәүдәләнгән кисәкләре, элементлары дигән сүз. Татар эчендә бу гәүдәләнүләр, бу кисәкләр ни чаклы күп булса, шулчаклы милли мәдәниятнең нигез шартлары нык утырган булачаклар.

Пролетариат революциясе үзенең зур хәрәкәтләре вакытында, бер яктан, шулай хезмәт халкы эченнән тартып чыгарып, гамәли көрәш аркасында андый көчләрне үстерсә, икенче яктан, төзелгән план буенча татардан гыйльми, мәдәни көчләр әзерләү эше бик нык куелды. Казанның, Мәскәүнең, Ленинградның югары мәктәпләрендә байтак татарлар югары мәктәпләр янында гыйльми хезмәткә калдырылдылар. Болар эчендә татар мәдәни хәрәкәтендә, Татарстанның югары мәктәпләрендә татар теле-әдәбиятын кертү эшендә аеруча рольләре булачак. Татар лингвистлары, филологлар үзләренең квалификацияләрен арттыру юлында эшләгән кебек, докторлар, инженерлар, педагоглар, икътисадчылар, хуҗалыкчылар, агрономнар, техниклар, механиклар, физиклар, математиклар бар. Бу эш хәзер инде СССР чигеннән үтте. Бу 1927 ел эчендә Татарстан җөмһүриятенең өч гыйльми хезмәтчесен заграницага озатачак. Кыскасы, татар мәдәниятенең җанлы нигезләрен, җанлы терәкләрен һәм юлбашчыларын әзерләү, кадрны күбәйтү, күтәрү мәсьәләсе хәзер элекке кебек, бездә кеше юк дип елап, газетада хәсрәт мәкаләсе язудан үтте. Дәүләтнең рәсми планнары буенча, эшкә, гамәлгә кертелде. Әгәр бу планлы эшләребезне хәзерге рәвешендә дәвам иттерә алсак, без тагын өч елдан инде татардан байтак профессорлар күрәчәкбез.

Әгәр статистика теләүчеләр булса, без монда бер дә мәшәкатьсез милли татар мәдәнияте революция аркасында күпме эшләр кылганын, мәктәпләр, техникумнар, рабфаклар, югары мәктәпләрдә татарлар, анда татар дәресләре ничек артып үсеп барганын цифрлар аркылы күрсәтә алыр идек. Ләкин болар һәркайчан басылып торганга[1], моны кирәксенмәдем.

---

[1] Бу хакта аеруча тулы мәгълүмат «Биш ел эчендә» дигән зур мәҗмугада бар. Урысча, татарча аерым чыкты. Казанда 1925 елда басылды.

Без югарыда. Покровский сүзенчә, тел — милли мәдәниятнең иң баш коралы икәнен күрдек. Революциягә кадәр татар теле һәркайдан куылган, хокуксыз бернәрсә иде. Пролетариат диктатурасының каты хөкеме белән ул әлекке коллыктан азат кылынды гына түгел, рәсми дәүләт теле булып әверелде. Ләкин коры рәсмият аз иде. Аны чыннан да реаль бер көчкә әйләндерү лязем иде. Бу хакта башта күп шөбһә булды. Имансызлар, татар телен гамәлгә кую әнә шул яңлыш язылган вывескалардан үтмәс, диделәр. Бу хактагы беренче декрет (1921 ел, 25 июнь) бик курка-курка гына беренче адымны атлаган иде. Байтаклар һаман да моны кәгазьдә калыр дип уйладылар. «Тат» дигән көлке дә чыгарганнар иде. Ләкин революция үзенең принциплары белән шаярырга теләмәгәнен күрсәтте. 1925 елда инде, кичерелгән гадәттән тыш авыр ачлык фаҗигасенә карамастан, җөмһүриятнең биш елы тулганда түбәнге хәлне күрдек:

Татар авылларындагы советларда
татар телендә кәнсәләрия эше түбәндәгечә:

| 1922 | 1923 | 1924 | 1925 |
|---|---|---|---|
| 20% | 50% | 80% | 85% |

Волбашкарма аппаратының миллиләшүе:

| 1921 | 1922 | 1924 | 1925 |
|---|---|---|---|
| 30,4% | 40,4% | 51,4% | 52% |

Бу татарлашу югары киткән саен кими, җөмһүриятнең үзәк наркоматларында әле хәзер дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә түгел. Ләкин бернәрсә ачык: алда торган зур киртәләргә, әзерлексезлекләргә карамастан, пролетариат революциясе үзенең программасын үткәрүдә туктаусызлык белән бара. Милли мәдәниятнең бер тармагы — администрацияне миллиләштерү моменты туктаусыз үсә бара.

Без югарыда бер вакыйга күрдек: 1924 ел февраль аенда Мәскәүдә булган татар мәгариф эшчеләренең съездында бер төркем иптәшләр башлангыч татар мәктәпләрендә дәресләрнең ана телендә түгел, бәлки эшче районнарында урыс телендә булуы кирәклеген алга сөрделәр. Без бик каты көрәш аркасында ул принципны җимерә алдык. Менә бу вакыйга җөмһүрияттә нык урынлашып барган татар телен, һич булмаса, читтә урыс теле белән алмаштыру өчен бер тартышып караулары иде — монда урыслашу программасы үзенә бер почмак алмакчы иде, булдыра алмады. Шуннан соң, һичкемнең һичкайда татар мәктәбендә уку теленең ана теле булуына каршы сүз әйткәне ишетелмәде. Димәк, революциянең ул принцибы һәркайда хөкем алган иде. Җиңгән иде.

Русиянең бик күп җирләрендә дәүләт хисабына урта татар мәктәпләре яшиләр, боларда барган саен телне дә, дәресләрне дә, укытучыларны да татарлаштыру көчәя бара иде. Соңгы ике ел эчендә элек тик исемдә генә булган берничә техникум бөтенләй татарлашып беттеләр.

Әле монда зур җитешмәгәнлекләр бар. Әле идеалдан ераклар, ләкин бернәрсә факт — милли мәдәният революция аркасында урта мәктәпләрен бөтенләй үз элементы белән тутырып бара, көннән-көн үсә, тирәнәядер. Киләчәктә мәсьәлә тагын югарырак куелачак. Моның өчен Татарстан Өлкә Комитетының 1026 ел 13 декабрь карары аеруча шаһид булып чыкты. Анда башка күп төрле кирәк карарлар эчендә шул сүзләр бар[1]:

«4 — проф. техника мәктәпләрен, эшче факультетларын, югары тип техникум һәм курсларны тәмам итүчеләрнең укуны бетерүләре урыс телен яхшы белүләре белән генә тәмам булмаганын, бәлки татар телен белү — укуны бетерер өчен куелган топ шартлардан берсе итеп куелырга тиеш икәнен каты рәвештә тормышка үткәрергә, тиешле булган мәктәпләрнең программаларын төзәтү-үзгәртүләрне Өлкә Комитетының агитация-пропаганда бүлеге белән мәгариф халык комиссариатына тәкъдим итәргә. Мәгариф халык комиссариаты татар телендә булмаган барлык уку программаларына татар теле кертү өчен кирәкле булган каты чараларны күрергә һәм бер ай вакыт

1 «Кызыл Татарстан», 1926, декабрь 19.

эчендә карарны үтәр өчен күргән чараларын Өлкә Комитетына хәбәр итәргә тиеш.

5—Халык Комиссарлары Советы һәм Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты фракциясенә татар телен эшкә ашыру чараларын үтәү өчен җирле бюджеттан акча бирүне көчәйтергә һәм шушы ук вакытта татарлардан эшчеләр әзерләү, татарча язу машиналары белән тәэмин итү, татар телен гамәлгә кую курсларының куелышын төзәтү эшләрен яхшырту өчен милли фондтан бирелә торган акчаның арттырылуы турында үзәккә мөрәҗәгать итәргә кушарга...

Безнең күз алдыбызда Казанның ике югары мәктәбендә (ВПИ белән ТКУ) татар теле, татар әдәбияты, татар дәресләре урын алдылар. Бу әлегә беренче адым. Ләкин инде моннан үтеп, Казанның 125 ел яшәгән карт университетына татар теле керергә әзерләнеп бара. Якын киләчәктә моны да күрәчәкбез.

Кыскасы, революция шаярырга теләми, үзенең принципларын каты кул белән гамәлгә куюда дәвам кыла. Дөрес, монда зур кимчелекләр, хаталар, кайбер вакыт акыллыбаш имансыз Мефистофельләр өчен көләргә материаллар да була торгандыр. Бардыр. Ләкин дөньяның нинди зур хәрәкәте бөтен, камил рәвештә тулы нәтиҗә биргәне бар? Һәркайда ялгышлар, уңышсызлыклар табигый. Безнең өчен бу милли мәдәният төзү хәрәкәтенең революция ярдәме аркасында туктаусыз баруы, барган саен зураю, тирәнәюе, шулай итеп, моның вакытлы бер бизгәк яки вакытлы бер тактика булуыдыр.

Җиде еллык бу тәҗрибәдә бу эшкә җитди керешелгәнлек күренде. Һәм татар хезмәт массасы үзенең шул тарихи бурычларын аңлап, белеп гамәлгә куйганлыгы ачылды. Русча әйткәндә, татар мәдәнияте бөтен мәгънәсе белән үзенең жизненность һәм жизнеспособностьләрен күрсәтте. Вакытлы җил түгел, тормыш нигезеннән туган хәрәкәт.

## 4

Без югарыда мәдәниятнең баш коралы—тел икәнен күргән идек. Бичара татар теле үзен саклауда, үзен үстерүдә дә зур мәшәкатьләр, газаплар кичерде. Иске замандагы мирзалар һәм муллалар карашы турында тукталмыйм, миссионерларның бу телгә һәм татар язуына ни дәрәҗәдә ачу белән карап, бетерү өчен чаралар эзләгәненә кайтып тормыйм. Патшачылык хөкүмәтенең мәшһүр урыслаштыру сәясәте аркасында татар теленең нинди кысрыкылыкларга төшүен сөйләргә дә керешә алмыйм.

Менә болар һәммәсе татар теленә киртә булдылар. Бердән, аның таралуына, икенчедән, үзенең үсүенә, эшләнүенә юл куймадылар. Югарыда без Октябрь революциясе соңында татар теленең рәсми хокуклы дәүләт теле булганын күрдек. Гамәлгә керүен дә тикшердек. Әгәр без бу телнең, бу мәдәни коралның үзенең эшләнүенә килсәк, бу бездә тик Насыйри бабайдан гына башлана. Әмма революциядән соң бу эшләнү бик зур адымнар белән алга атлап, татар мәдәниятенең баш коралы камилләшү юлына төште.

Ләкин урыслашу моменты да үзен күрсәтеп үтте. Әмма аңа каршы татар әдәби активы үзенең дөрес принципларын куеп, татар телен дөрес юлда саклап калды. Бу юлдагы ачык нәзари көрәш шул ук 1924 елның Мәскәүдәге татар-башкорт мәгарифчеләр съездына бағланадыр. Монда әдәби тел һәм атамалар мәсьәләсе куелган иде. Өч агым көрәште. Берәүләр иске гарәпне саклау юлында булдылар, берәүләр гарәпне бөтенләй чыгарып, аның урынына урыс сүзләренә капканы бөтенләй киң ачып куярга тәкъдим кылдылар. Күпчелек боларның берсен дә кабул итмәде. Башлап шул съезд киңәшендә, андан соң 1924 елның 16 сентябрь Казан киңәшендә тикшерелеп сызылган юл соңра Гыйльми үзәк тарафыннан 1925 ел, 6 ноябрь рәсми кулланма тезислар булып чыгарылдылар. Монда татар теленең гарәпләшүме, урыслашумы яки татарлашумы кебек агымнардан каюсын тотачагы, ягъни милли мәдәният мәсьәләсендәге принциплардан ниндиен алга куячагы ачык күрелде. Бу кулланма тезисның төп моментлары болар:

1) татар әдәби теленең тик төп материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиешле татарча сүзләр була торып, болар урынына башка телдән һич сүз алынмас;

2) гарәп сүзләреннән, урыс сүзләреннән татар телен тазартырга кирәк (кулланмада күрсәтелгән билгеле шартлар, билгеле чикләр буенча гына бу гарәп, урыс сүзләрен кулланырга мөмкин булыр);

3) татардан сүз тапмаса, мәдәни милләтләрдә уртак йөрегән бәйнәлмиләл сүзләр һәм атамалар безнең матбугатыбызда кулланырлар, ләкин болар татар калебенә, татар теле төзелешенә салынырлар[1].

Күрәсез, татар теле үзенең төзелешендә беренче нигез кылып үз ана теле элементларын ала. Икенче нигез — бәйнәлмиләл сүзләр (революция, трактор, интернационал, пролетариат, математика һәм башкалар). Менә монда да татар теле үзенең урыслашу ягында бармавын, иске гарәпчелек нигезендә калырга да теләмәвен күрсәтте. Менә ничә ел инде шул югарыгы нигезләрдә тел үсеп, эшләнеп, баеп килә. Урыслашу тенденциясе бөтенләй җиңелде. Шул татарлашу нигезендә хәзер безнең әлифбаларыбыз, уку китапларыбыз, тел сабаклары, имлялар, сарыф-нәху — татар грамматикалары, әдәбият кануннары һәм әдәбият тарихлары тәмам эшләнеп чыгып юлга салынды. Хәзер инде, татар теленең тулы сүзлеге эшләнмәктәдер.

Хәзер әнә шул нигез буенча атамалар эшләнә, шуның буенча халык өчен гыйльми, сәяси әсәрләр таратыла. Хәзер шул аз вакыт эчендә дә татар теле бик нык күренер дәрәҗәдә баеды. Татар телендә бу соңгы 3—4 ел эчендә чыккан китаплар, дәреслекләр, гыйльми әсәрләр үзләренең мөндәриҗәләре буенча да, эшләнүләре буенча да элеккеләрдән бик күп алдалар. Хәзер без инде электә исеме дә булмаган сәяси әсәрләр өстенә урта мәктәпләрдә дәреслек булырлык бик күп гыйльми китаплар басып чыгардык. Мәйдандагы биология, физика, химия, математика, һәндәсә, җәбер, өчпочмаклылар, гигиена, Русия тарихы, революция тарихы, татар әдәбияты тарихы, ботаника, зоология һәм башка күп китапларыбыз да хәзер татар мәдәниятенең бу тармагында да үсү, күтәрелү, тирәнәю барганын күрсәтәләр. Без югарыда, форма буенча милли, мөндәриҗәсе белән пролетариатча булачак, дигән идек. Әлбәттә, матбугат дөньясында без менә моның ачык мисалын очратабыз. Һәммә китаплар татар өчен татар телендә, татар аңына каратып басылалар. Ләкин мөндәриҗәләре һәм методлары буенча һәммәсе материализм нигезендә баралар. Һич булмаса, шуңар омтылалар. Әдәби әсәрләрдә, яңа әдәби талантларда бу момент тагын да ачык күренәчәк. Бу соңгы 4-5 ел безгә байтак яңа талантлар бирде. Болар әдәбиятка үз сүзләре, үз мәгънәләре, үз формалары белән килделәр. Милли әдәбиятка байлык арттыралар.

Дөрес, боларда байтак кимчелекләр бар. Боларда акыллыбаш Мефистофельләр өчен көләргә урын юк түгел, ләкин төп бер нәрсә факт — татар әдәбияты югалуга түгел, урыслашуга түгел, үзенең татарлык нигезендә пролетариат рухы белән сугарылган хәлдә үсеп, тирәнәеп, күтәрелеп бара. Моны вакытлы бизгәк дип атарга урын юк, бу тормышның төбеннән килгән тарихи хәрәкәт, монда йотылу галәмәте түгел, адым саен үсү, көчәю билгесе күренеп бара.

Дөрес, кайбер заманнарда, кайбер әсәрләрдә, ашыгычлык, игътибарсызлык аркасында төп, дөрес нигездән читкә тайпылу, урыс сүзләренә кирәксез урын бирү күренергә мөмкин.

Ләкин бу иттифакый[2] моментлар. Әмма хәзер әдәби телнең, әдәби әсәрләрнең тенденцияләрен — барышларын караганда, без гарәпчәдән дә, урысчадан да мөмкин кадәрле котылуга таба юнәлгәнлеген күрәбез. Матур әдәбият бу юлда беренче булып бара. Анда саклык зуррак, яңа татар сүзләре арта тора. Тарихи-иҗтимагый әсәрләрдә дә шул ук юнәлеш хөкем сөрә. Әгәр моннан 7—8 ел элекке белән хәзергене чагыштырсак, без югарыгы фикернең дөреслеген күрәбез. (Ләкин шуны хәтердән чыгармагыз: әлбәттә, бер кешенең әсәрләрен тикшерү кирәк, юкса, язучының башкалыгыннан, урысча, яки татарча булуыннан бер үк замандагы әсәрләр дә бер-береннән аерылырга мөмкин. Шелтәгә, рәнҗүгә төшмәс өчен үз китапларымдагы үзем аңламастан килгән үзгәрешләрне алам)*.

---

[1] Бу хакта Татарстан мәгариф комиссариаты басып чыгарган имля, әлифба, тел, халык әдәбияты турында инструкцияләр мәҗмугасы.

[2] Иттифакый — очраклы.

*Мисалга Г. Ибраһимов 1919 елда басылган «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле китабы буенча таблица китерә. Анда китапның 33 битендә урысча сүзләр — 8% , бәйнәлмиләлчә — 11%, гарәпчә — 18%, татарча — 63% булса, 1927 елда басылган «Урал» һәм уралчылар» китабының 27 битендә урысча сүзләр — 4%, бәйнәлмиләлчә — 10%, гарәпчә — 9%, татарча сүзләр — 77% тәшкил итә, дип күрсәтеп үтә. (Автор китергән таблицаны техник сәбәпләр аркасында тулысынча баса алмадык. Редакция искәрмәсе.)

Әгәр дә без соңгы елларда чыккан әдәби әсәрләрне карасак, аларның байтагында татар сүзләренең процентлары 92—98 гәчә житкәнен күрәчәкбез.

## VII

## Нәтиҗәләр

Докладта сөйләнгәннәрнең барын бергә җыеп күз алдына куйсак, безгә менә шул түбәнге нәтиҗәләр мәҗбүри рәвештә килеп чыгалар.

1) Партиянең программасыннан, милли мәсьәләдәге барлык карарларыннан, ун елга якын дәвам кылган гамәли тәҗрибәләрдән аңлашылуы буенча, пролетариат революциясе аерым милли мәдәниятләрне бетерми, бәлки боларның үсүенә һәм көчәюләренә зур иркенлек биреп, туктаусыз ярдәм итеп килә. Революциянең алдында торган интернациональ максудлар белән бу аерым халыкларның мәдәниятләренең милли булулары арасында каршылык юк: Сталин иптәшнең ачык формуласы буенча, совет һәм социализм эчендә куәтләнеп барган бу аерым мәдәниятләр үзләренең формалары буенча милли булсалар, мөндәриҗә белән пролетариатча булачаклар һәм мәдәниятләр пролетариатның юлбашчылыгы астында, гомумадәмнең киләчәк тормышка баруына хезмәт кылачаклар.

2) Пролетариат революциясе һәм социализм төзелеше эчендә яшәп, күтәрелеп барган ул милли мәдәниятләр арасында татар мәдәнияте дә үзенә урын ала. Революциянең тиздән ун ел тулачак зур хәрәкәте, төзелеше, пролетариатның туры милли программасы татар халкына сәяси хокуклар, декларация һәм рәсми иркенлекләр, тигезлекләр бирү белән генә канәгатьләнмәде, бәлки һәрнәрсәдән элек татар хезмәт массасының хуҗалыгын күтәрү, икътисади тормышын юлга салу өчен чаралар күрде. Моның белән татар мәдәниятенә матди нигез салынды. Татар төзү эшенә активист булып катнашырга өйрәнде. Менә болар нәтиҗәсендә татар халкы пролетариат принциплары нигезендә үз телендә мәдәният үстерү, көчәйтү эшенә керешерлек куәт-хәрәкәт алды. Шуңар күрә татар мәдәни хәрәкәте үзенең хәзерге хәле, рәвеше белән Октябрь революциясенең җимеше итеп каралырга тиешле.

3) Кичерелгән гражданлык сугышларына, каты ачлык трагедияләренә һәм татарның электән әзерләгәненең бик кечкенәлегенә карамастан, бу аз заман эчендә дә татар мәдәни хәрәкәте, советның нык булышлыгы аркасында үзенә дөрес юл сызып, яңа тормыш төзегәндә төпле нәтиҗәләр бирде. Киләчәк өчен перспектив хәрәкәт планнарын билгеләп куярга өлгерде. Бу мәдәниятнең нигезе кон-төн ныгый, тармаклары үсәләр, зураялар, тамырлары тирәнәяләр, шуның белән бергә татар массасы бу мәдәни хәрәкәт эченә киң рәвештә кереп бара. Менә болар барлыгы татар мәдәниятенең вакытлы бер кузгалыш яки нәтиҗәсез бер җил генә түгел икәнен, бәлки татар тормышының сыйнфый-тарихи шартларыннан мәҗбүри, канунн рәвештә килеп чыгып, көчәеп киткәнен күрсәтәләр. Шуның белән бергә, хәзер бу мәдәният үзен иҗади хезмәте белән танытты: татар халкы үз телендәге мәдәнияте аркылы җиңелрәк, уңайрак рәвештә яңа тормышка күтәреләчәге, бу милли инструмент революция төзелешләренә киң татар хезмәт массасын катнаштыруда бик нык файда итәчәге ачык күрелде.

4) Әнә шул югарыгы өч момент революция һәм социализм төзелеше эчендә татар мәдәниятенең урыны, кыйммәтен билгеләләр. Татар халкы башка мәдәниятләргә йотылу юлы белән түгел, үз теле нигезендә, үз мәдәниятен үстерү юлы белән барачак. Ассимиляция һәм урыслашу перспективалары татарның киләчәк көннәренең мөндәриҗәсеннән алып ташланырга, йотылу яки урыслашу хәрәкәтләрен аерым бер агым итеп мәйданга кую эшенә каршы каты көрәшергә, моны революция принципларын аңламаучылык итеп каралырга, татар хезмәт массасының революция эчендәге хәрәкәтенә зарарлы реакциячылык саналырга тиешле. Партиянең XII съезд карарларында ачык әйтелгәнчә, бу шартлар эчендә урыс мәдәниятенең татар мәдәниятеннән югарылыгы, шуңар күрә татарлар өчен зәгыйфь мәдәнияттән югары мәдәниятка күчү тиешлеге турындагы сөйләнүләр — великоруслык милләтенең элекке өстенлеген саклар өчен чыгарылган караш кынадыр. Татар арасында мондый карашларның булуы — иске замандагы русификаторлык сәясәтенең татар зиһенендә калдырган күләгәсе, үзенә түбән, ышанычсыз карарга өйрәнүенең хата нәтиҗәсе генәдер.

5) Бу нигез принциплар безгә аерым гамәли чаралар күрергә мәҗбүр итәләр. Татарга һәм аның мәдәниятенә элекке кебек мәсхәрәле карашлар, аның белән хисаплашмаска теләүләр революция аркасында байтак кимеделәр. Ләкин бетеп җитмәгәннәр әле. Татарның үз эчендә дә, башкаларда да татар теленә, татар мәдәниятенә әһәмиятсез, төп асылда кирәксез бер нәрсә итеп караучылар, шуңар күрә, боларга багланган хезмәтләрне үтәргә теләмәүчеләр, шөбһәсез, әле дә юк түгел. Элекке заман великоруслыкның башка милләтләргә начар каравыннан сеңеп калган ул иске сөремнәргә каршы чара күрелергә тиешле. Әлбәттә, моңа каршы иң төсле чараларның берсе — татар мәдәниятенең мөмкин кадәрле тиз күтәрелүе, шулай итеп, түбән карауга урын калдырмавы, татар теленең, татар дәресләренең башка халыкларныкы дәрәҗәсендә яхшы эшләнеп җитүе, икенче — тышкы яклары белән канәгатьләнерлек дәрәҗәдә үсүе, һәм татар телен, татар дәресләрен укытучыларны квалификацияләре буенча башкалар белән бертигезләнерлек дәрәҗәдә әзерләп өлгертү кебек гыйльми моментлар булса, икенчесе итеп, монда дәүләтнең канун кодрәте дә үзен күрсәтергә тиешледер. Иске заманда татарны, аның эшен түбәнәйсетү психологиясен тудыруда патшачылык хөкүмәтенең, аның полициясенең, аның сатлык матбугатының зур роле булды. Менә шуның агуын бетерүдә революция үзенең дәүләт низамнарыннан, дәүләт аппаратлары көченнән файдалану да зыян булмаячак.

6) Партия XII съездының карарларында да әйтелгәнчә, җирле халыкларның үз эчләреннән гореф-гадәтләрен, телләрен, тормышларын белгән хезмәтчеләр чыгару кирәк булганга, Татарстанның мәктәпләрендә, югарыдан түбәнгәчә, татарны өйрәнүгә, татарның теле, әдәбияты белән танышуга гаид[1] гыйлемнәр, әлбәттә, беренче дәрәҗәдә әһәмиятле дәресләрдән итеп куелырга, бу хакта һичбер төрле җиңел карауларга бирелмәскә, бу эшләрдә дәүләтнең рәсми куәтләре ярдәмдә булырга тиешледер. Шуның белән бергә, бюджет вакытларында татар телен, татар мәдәниятен үстерү һәм гамәлгә кую бурычларына каратып аеруча акча билгеләнелмәсә, күп карарларның кәгазьдә калуы мәҗбүри булып чыга. Мәсьәләнең реаль ягы моңа терәлгәнгә, дәүләт аппаратларының хезмәтләрендә менә бу нокталарга әһәмият бирелү чараларын күрү лязем була.

7) Мәдәниятләрдә, алда Покровский әйтмешли, аерып билгеләүче һәм төп корал тел булганга, татар телендә сөйләшүче халыклар, теләсә кайда яшәсәләр дә, бер мәдәни коллективның кисәге булып танылалар. Шуңа күрә җөмһүрияттән тыштагы татарлар белән даими контакт саклау мәсьәләсе татар мәдәниятенең үсүендә, көчәюендә аерым урын тоткан моментларның берсе булачак. Шуның белән бергә, татар мәдәнияте үскән, күтәрелгән саен, башка төрки халыклар белән мәдәни, гыйльми тәҗрибәләрне алмашу нокталары да күз алдында тотылачактыр.

8) Тарихның бәйнәлмиләл хәзинәсеннән алынган гыйлемнәр, техникалар, сәнгатьләр ярдәме белән пролетариат юлбашчылыгы астында, үз теле, үз тормышы нигезендә үзенең мәдәниятен көчәйтү, бу мәдәниятне татар хезмәт халкының социализм төзелеше хәрәкәтләрендә корал булырлык дәрәҗәдә югары күтәрү һәм шул социализм төзелеше эчендә башкалар белән бер унайдан бер мәдәни отряды булып бара алырлык хәлгә җитү — менә татар халкының мәдәни мәсьәләдә тоткан юлы, алдагы маягы шул рәвеш булачак, тарих һәм революция татарны шул юл белән алып барачак.

*Текстны басмага* **З. РӘМИЕВ** *әзерләде.*

---

[1] Гаид — кагылышлы, бәйләнешле.

# ЯЗУЧЫ АРХИВЫННАН

«КПСС Үзәк Комитетына
СССР Мәгариф министры М. А. Прокофьевка
РСФСР Мәгариф министры А. И. Даниловка

РСФСРдагы күпчелек милли мәктәпләр тоташтан урыс теленә күчерелгәннән соң шактый вакыт үтте. Инде бу алымның нәтиҗәләре турында да сөйләргә мөмкин. Нәтиҗәләр, әйтер идем, мактанырлык түгел. Бу очракта мин авыл мәктәпләрен генә күздә тотам әле. Авыл баласы, тууыннан алып мәктәпкә барып кергәнче, бары тик ана телендә генә сөйләшә. Мәктәп бусагасын атлагач, бала аптырап кала: укытучысы ул белмәгән телдә нидер аңлатып маташа, китапларга да ул ишетмәгән сүзләр язылган. Урыс телен өйрәнгәләгәнче, шактый вакыт уза, бала мәктәп программасын үзләштерә алмый, барын да өстән-өстән генә йөгертеп уза.

Тел хикмәтләре — сәяси мәсьәлә генә түгел. Совет педагогикасы классигы Н. К. Крупская: «Тел мәсьәләсе — педагогик мәсьәлә ул, — дип аңлата. — Чөнки яңа төшенчәләргә өйрәнү, төрле гыйлемнәрне үзләштерү бары тик җанга иң якын һәм иң аңлаешлы телдә генә мөмкин. Шулай булмаганда бөтен авырлыклар бары берьюлы килеп бөялә: әллә үзеңә аңлаешсыз телне өйрән, әллә шул аңлаешсыз телдә язылган фәнгә төшенергә тырыш...» (Сайланма әсәрләр, 1957 ел, 564 бит.)

Чыннан да шулай бит инде.

ВЛКСМның 50 еллыгы уңаеннан мине, егерменче еллар комсомол-егетен, туган ягыма — Ульян өлкәсенең Чардаклы районы комсомол җыелышына чакырдылар. Шунда ук Татар Колмаеры авылы урта мәктәбе укучылары белән очрашу да оештырганнар. Мин шул мәктәптә укыган идем. Бу — бик зур авыл, анда бары тик татарлар гына яши. Хәзер шуның мәктәбендәге бөтен фәннәр урыс телендә генә алып барыла башлаган. Мине мәктәп директоры — урыс иптәш каршы алды. Ул авыл халкы телендә ләм-мим, бер сүз дә белми. Ата-аналар тәрҗемәче ялларга мәҗбүр икән. Күршедәге Чуваш Колмаерында да, башка авылларда да шундый ук аяныч хәл хөкем сөрә. Татар Урае авылында гына берданбер татар урта мәктәбе сакланып калган. Монда урыс телен, бик күп сәгатьләр биреп, фән буларак өйрәнәләр. Шушы берданбер татар мәктәбе, барлык күрсәткечләре ягыннан, төбәктәге иң алдынгы мәктәп санала. Югары уку йортларына керүчеләрнең иң күбе дә — шушы мәктәптән. Ә теге, тоташтан урыс теленә күчерелгән татар мәктәпләрен тәмамлаган балалар, әзерлекләре начар булганга, белемнәрен ары күтәрә алмыйлар, аларны вузлардан кире боралар.

РСФСРдагы милли мәктәпләрне урыс теленә күчерү дәверендә берьяклы үгетләү уздырылган: бала урысча укыса, югары уку йортларына имтихан тоту аңа җиңелрәк булачак, янәсе. Чукча язучысы Юрий Рытхэу болай яза: «Матбугатта вак халыкларның теле үлүгә йөз тота, дигән фикерләр куертыла... Чукча теленең кирәге бармы соң, дигән догматик фәлсәфә калкып чыкты. Чукчалар урысча аңлый лаба-са, диләр. Мәктәпләрне тикшерүчеләр дәлилләр дә тапкан — кичекмәстән урысча гына укуга күчү, янәсе, кешегә киләчәген уңышлырак көйләргә ярдәм итәчәк. Әмма мәктәпләрдәге өлгереш күрсәткечләре, әлеге «ачыш»ны кире кагып, һаман түбәнгә тәгәри. «Өлгермәгән» укучыларны исә сигезьеллык мәктәпләрдән генә түгел, хәтта башлангыч класслардан ук куып чыгаралар...» («Литературная Россия», 31 январь, 1969 ел.)

Кыскасы, РСФСР мәгарифенең элекке министры Г. И. Афанасенко тарафыннан кертелгән бу алым безнең конституциягә дә, ленинчыл милли сәясәт рухына да һич туры килми, рус булмаган милләтләрдә яшь буынны тәрбияләүдә коточкыч тискәре роль уйный. Афанасенко моны теләгәндерме-юктырмы, әмма әлеге алым безнең яшьләрне вузларга керүдән тәмам мәхрүм итә.

Юл башыбыз бөтенләй башка булган бит. Партиянең X съезды кабул иткән карарда мондый юллар бар: «...үз дәүләтчелекләре, хуҗалыклары һәм культуралары ягыннан артта калган халыкларга, фактик тигезсезлекне бетерү юнәлешендә ярдәм итү буенча программа булдырырга кирәк... Бу халыкларның туган телендә матбугатын, мәктәпләрен, театрларын һәм клуб эшчәнлекләрен вә, гомумән, культура агарту хезмәтен үстерергә!» («КПСС — резолюцияләрдә», 1 кисәк, 7 басма, 559 бит.)

Укытучылар арасында мондый мәзәк йөри. Имештер, министр Афанасенко Дагстанга барган. Менә радио сөйли башлаган, ди. Тапшырулар, тау халыкларының ихтыяҗынча, әле бер телдә, аннары икенче, өченче телләрдә алып барыла икән. Министр әфәнде берни дә аңламаган. Соңыннан ул:

— Кара инде, без шул ахмаклыкка илле ел буе чыдап торганбыз! — дип әйтеп куйган.

Бу хәл булгандырмы-юктырмы, әмма мәзәк министрның милләтләр язмышына карашын шәп ачып сала. Тик, кызганыч, министр үз сүзендә нык торган — федерация мәктәпләрен тоташтан урыс теленә күчерергә әмер биргән. Моны бит халык

ларны көчләп урыслаштыру дип тә бәяләргә мөмкин. Гаҗәп: партиябезнең программасында мондый максатның куелганы юк бит! Киресенчә, революция патша режимы тарафыннан алып барылган урыслаштыру сәясәтен бертавыштан тәнкыйть итте. Барлык халыкларның тигезлеге конституциябезгә дә теркәлгән. Халыклар тигезлеге — телләрнең дә тигезлеге ул.

Ленин үзенең васыятьләрендә, милли мәсьәләгә кагылып, болай язган: «...безнең союзга кергән милли республикаларда милли телне куллануга карата бик төгәл кагыйдәләр кертергә һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга кирәк. Тимер юл хезмәтенең, әләкчелек-чагу челтәре хезмәтләренең уртаклыгы һ.б.ларны сылтау итеп безнең чор аппаратына саф урысларга хас бозыклыклар үтеп керәчәге көн кебек ачык. Бу төр яманлык белән көрәштә аерым сизгерлек сорала: ә нәкъ шул эшкә алынган кешеләрнең бигрәк тә саф күңелле булырга тиешлеген әйтеп тә торасы юк...» (В. И. Ленин, Сайланма әсәрләр, IY басма, 36 том, 558 бит.)

Ленин бу мәсьәләдә ифрат та игътибарлы булырга өндәгән: «...Шунлыктан изүче «бөек» милләтнең интернационализм («бөеклек»не ул көчләү юлы белән казанган), — дип яза ул үзенең васыятендә, — милләтләр тигезлеген формаль тануга гына кайтарып калдырмыйча, изүче, зур милләт белән чагыштырганда, чынбарлыкта барлыкка килгән тигезсезлекне тануда да ярылып ятарга тиеш. Моны аңламаганнар милли мәсьәләгә пролетарча карашны, гомумән, аңламый, андыйлар вак буржуаз караштa торып кала һәм теләсә кайчан буржуаз карашка тәгәрәргә мөмкин, дигән сүз...»

Ленин, әлеге фикерен дәвам итеп, бу өлкәдәге ялгышларның, бозуларның безне халыкара күләмдә көлкегә калдыру ихтималын да искәрә: «Әгәр без, көнчыгышның яңалыкка йөз тотуы, аның уянуы алдыннан, үзебездәге башка милләт халыкларына карата гаделсезлек күрсәтеп, тупасланып, абруебызны төшерсәк, бу кичереп булмаслык оппортунизмнан саналачак...»

Афанасенконың кылган гамәлләре, әлбәттә, аның сәяси яктан ифрат тар карашлы булуыннан килеп чыккан. Күпмилләтле республика мәгарифенең министрына урысча гына түгел, чын коммунистларча фикерләү кирәк иде! Аның бу адымы интернационализм принципларына капма-каршы килә. Мондый нәрсәләр безнең матбугатта да тәнкыйтьләнеп тора югыйсә. Без, мәсәлән, шуңа охшаш яманлыклар кылучы кытай шовинистларын әледән-әле эттән алып этә салабыз. Мәсәлән, «Литературная газета»да Н. Мар дигән автор үз мәкаләсендә Кытайдан безнең якка чыккан укытучы Маһинурның сүзләрен китерә:«... Безнең уйгыр, казах балаларын Синцзяндагы кытай мәктәбенә куып керттеләр дә бары кытайча гына укырга мәҗбүр иттеләр...» Мәкалә авторы бу хәлне Кытай шовинизмының котырынуы дип аңлата. («Литературная газета», 27 август, 1969 ел.) РСФСРдагы нәкъ шундый ук күренеш исә матбугатта да, педагогик киңәшмәләрдә дә гел мактала, тагын да киңрәк пропагандалана. Инде Оренбург өлкәсендә дә бөтен милли мәктәпләрне урыс теленә күчерү турында карар кабул ителгән.

Урыс теле, СССР гражданнарын монолит бер союзга туплау өчен, бик кирәк, әлбәттә. Тик аңа мәктәпләрдәге аерым бер фәнгә өйрәнгәнче дә ирешергә мөмкин бит. Гасырлар буенча күзәтелеп расланган бер хакыйкать бар: ана телен яхшы белү башка телләрне үзләштерүдә төп таяныч булып тора. Безнең милли мәктәпләр моңарчы югары белемле һөнәр ияләрен тәрбияләде. Алар рус телен дә бик яхшы беләләр.

Аңлашыла: безнең максат — СССР кешеләренең мәгърифәтлелек дәрәҗәсен күтәрү. Мәҗбүри урта белем турында да сүз алып барабыз. Тик бу юлда нигә туган тел мәсьәләсен читләтеп узабыз соң? Акыллылык галәмәте түгел бу. Хәтта халыкларны махсус урыслаштыру белән шөгыльләнгән явыз затлар да туган телгә бу кадәр үк илтифатсыз кыланмаганнар. Миссионер профессор Ильминский, мәсәлән, чукындырылган татарлар өчен христианнарның дини китапларын татарчага тәрҗемә иттергән. Шул юл белән христиан динен татарларга аңлатырга теләгән. Ә фәннәрне аңлату баланың туган телендә алып барылса, начар булыр идемени? Нигә без бу максат өчен ана теленнән файдаланмыйбыз?

Бик тә сәер килеп чыга: конституциябезгә күз салсаң, илдәге барлык халыклар да тигез хокуклы, әмма союздаш җөмһүриятләрдәге халыкларның мөмкинлекләре чагыштыргысыз зур. Аларның урта мәктәпләре генә түгел, хәтта югары уку йортлары да туган телләрендә дәрес алып бара. Аларда ана теле — дәүләт теле. Шунлыктан бу халыкларның абруе да югарырак.

Кайчандыр автономияле җөмһүриятләрдә дә хәлләр шундыйрак иде. Барлык кешеләр җирле милләт халкының телен өйрәнә, чөнки бөтен эш шул телдә алып барыла иде. Бу хөррият 1937 елларга кадәр дәвам итте. Нәкъ шушы акыллы сәясәт аркасында милли автономияле җөмһүриятләрдә төрледән-төрле халыклар тәмам туганлашты. Бу дуслык Бөек Ватан сугышы елларында кырыс имтихан тотты һәм сынатмады.

Хәзер исә милли телләргә мөнәсәбәт бөтенләй башка. Беренче карашка, бик зыялы күренгән дәү-дәү агайлар да аз санлы милләт вәкилләрен, афанасенкоча,

мыскыл итәргә генә торалар. Чын мәгънәсендәге «бөек руслык» тәкәбберлеге баш калкыта. Мәгълүм ки, атамасына ук милли ташлама салынган «бөек рус» дигән бу төшенчә, Ильич тәкъдиме белән, безнең сөйләмнән алып ташланган иде бит инде.

Кичерегез, җин читкәрәк киттем.

Татар халкы, сан ягыннан, Советлар Союзында бишенче урында тора. Һәм шул күпсанлы халыкның ана телендә бер генә махсус урта яки югары уку йорты да юк. Халык саны, Татарстанныкына караганда, күпкә азрак булган союздаш җөмһүриятләр исә андый уку йортларыннан файдаланалар. Бу бик яхшы. Тагын шунысы да бик әйбәт: бу җөмһүриятләрдә милли телне монда яшәүчеләрнең һәммәсе өйрәнә. Бернича тел белү шәхеснең карашын гына киңәйтә ләбаса! Нигә соң автономияле җөмһүриятләрдәге милләтләрнең теленә генә кимсетеп карыйлар?

Татарстанның автономиялелеге турында аерым ассызыклап әйтәсем килә. Сталин совет конституциясе турындагы докладында: «...Татарстан, мәдәни һәм икътисади яктан, әйтик, Казахстаннан өстенрәк торса да, чит илләр белән чикләнмәгәнлектән һәм СССРдан аерылып чыгу мөмкинлеге юклыктан, һаман автономияле генә булып кала бирә»,— дигән иде. (И. В. Сталин. «Ленинизм мәсьәләләре», 1952 ел, 566 бит). Бер генә союздаш җөмһүриятнең дә әлегәчә СССРдан аерылып чыгу турында сүз кузгатканы юк, шунлыктан гына да әлеге фикерне искергән диярге мөмкин. Әмма, бу кагыйдә көчендә калганда да, хәл үзгәрде бит инде: хәзер Украина да, Белоруссия дә, хәтта шул ук Казахстан да социалистик илләр чолганышында калды, димәк, аларны да автономияле җөмһүриятләрдән исәпләргә мөмкин. Мин ышанам: үз вакытында Конституциябезнең бу кагыйдәсе кабаттан каралыр һәм үзгәртелер. Татарстан исә, автономиялеме ул яки союздашмы — барыбер, үз ана телендә мәктәпләр, махсус урта һәм югары уку йортлары булдыруга ирешер.

Милли мәктәпләрне тоташтан урыс теленә күчерүнең ялгыш адым икәнлеге инде хәзер үк ап-ачык. Аяныч хәлләр артык тирәнгә киткәләгәнче, бу хатаны төзәтергә кирәк. Тәкъдимне ерактагы төбәкләрдән көтәргә ярамый, чөнки кайберәүләр мәктәпләрне урыслаштыруга каршы чыккач, милләтчелектә гаепләп, аларның авызларын томалаганнар. Халык бик нык куркытылган. Гаҗәп: ни өчендер «милләтчелек» тамгасы аз санлы халык вәкилләренә генә сугыла, ә партиянең X съездында каралган төп мәсьәлә онытыла. «...Съезд үзенең төп һөҗүмен иң куркыныч күренешкә — «бөек урыс» шовинизмына каршы юнәлтә»,— дигән сүзләр истән чыга (Зур энциклопедия, 11 басма, 14 том, 117 бит.)

Шуларның барысын да күз алдында тотып, хаталарны төзәтсәк, бу эш Сезнең тәкъдим белән башкарылса, Россия федерациясендәге мәгарифтә ленинчыл гамәлләр тормышка тизрәк ашырылыр иде. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан РСФСР мәгарифе челтәрендәге барлык хезмәткәрләр, бигрәк тә җитәкчеләр, милли мәсьәләдә ленинчыл кагыйдәләрнең үтәлүен тәэмин итсеннәр. Юлбашчыбызның милли мәсьәләгә карата биргән күрсәтмәләре алар өчен төп кагыйдә, хаталардан саклап торучы төп таяныч булсын иде!

Коммунистик сәлам белән — ШАМУКОВ А. Р.
Адресым: Казан, 15, Зур Кызыл урамы, 59 йорт, 8 фатир.
1969 ел, 2 октябрь».

---

Габдулла Рухулла улы ШАМУКОВ (1909—1981) күпкырлы талант иясе: үзе СССРның халык артисты, үзе СССР Язучылар берлеге әгъзасы һәм бик актив җәмәгать эшлеклесе иде. Театрыбыз сәхнәсендә ул тудырган образлар, аның әдәби әсәрләре, тәрҗемәләре — барысы да безнең күңел түрендә саклана. Габдулла ага эшчәнлегенең һәр тармагында милли мәдәниятебезне камилләштерүне, туган телебезнең байлыкларын күз карасыдай саклауны алга сөрде.

Бу сәхифәдәге хат та — шуңа дәлил. Кызганычка каршы, аңа җавап алыну-алынмавы редакциягә мәгълүм түгел.

Китап күзәтү

# ИХЛАС ҖАН

Үзе әле университетта укыганда ук, Илсөяр Иксанованың иҗаты шигырь яратучылар күңелендә якты өметләр уята башлаган иде инде. Бервакыт мин университетның «Әллүки» исемле әдәби түгәрәге җитәкчесе Мөхәммәт Мәһдиевтән:

— Ничек соң, Мөхәммәт абый, талант иләренең яшь төркеме күренәме анда? — дип сорадым.

— Мактанырлык түгел, — дип Мөхәммәт абый, гадәтенчә, чыраен сытты. Аннары елмаерга тырышып дәвам итте. — Берәү барын бар... Ихлас күңелдән шигырь язучы бер кыз бар. Илсөяр исемле, Иксанова фамилияле... Тик аңа безнең «Әллүки»нең һич кирәге юк. Бу балага талантны табигать үзе биргән, иҗат түгәрәгенә эшне калдырмаган...— диде.

Мин Илсөярне ул вакытта ук белә идем инде. Аның турында шундый зур сүзләр ишетсәм дә, кызның гади бер авыл баласы булуыннан чыгып, (ул — Лаеш районының Татар Сараланы авылыннан) иҗатының тиз генә күтәрелеп китүенә әллә ни зур ышаныч баглամадым. Яшь чакта, университетның әдәбият бүлегендә дә укыгач, саф күңелле кыз баланың шигырь язуы гаҗәпмени?! Кайсыдыр бер акыллы башы әйтеп калдырган бит: имеш, унҗидесе тулган адәм баласы шигырь язмаса, аны врачка күрсәтергә кирәк...

Шигырьне язуы — бер хәл. Аны бит әле укучыңа җиткерәсе, ягъни матбугатта чыгарасы бар. Безнең шартларда моңысы шигырь язудан да читенрәк. «Язучы күп, без — бер генә!» — дип җибәрәләр нәшриятта. Җиде миллионлы татар халкына нибары бер китап нәшрияты эшләгән шартларда шагыйрь җанлы кешеләргә бик үк әйбәт түгел шул. Матбугатта чыкмаган әсәрнең исә, яумаган болытның куәте кебек, файдалымы-юкмы, яхшымы-яманмы икәнлеген кем ачыкласын?! Яшьлегендә шигырьләрне көлтәләп-көлтәләп язып та, соңра бөтенләй башка һөнәр юлыннан атлап китеп, әдәбиятны санга да сукмый яшәүчеләр шактый.

Бәхеткә диик, Илсөяр Иксанованың иҗат язмышы киртәсез юлларга килеп керде — күз тимәсен! Ул әле кайчан гына шигырьләрен безгә яттан гына сөйләп йөри иде:

*...Сары яфрак оча — алтын яфрак.*
*Моңсу сагыш иңгән күзләремә.*
*Мин, җәйләрне сагынып, сиңа киләм —*
*Җәйнең яшеллеге — күзләреңдә...*

Башта әллә ни игътибар да бирелмәде. Аннары исә... Илсөярнең шигырьләрен тоташ кабул иттеләр. Студентлыгыннан арынырга да өлгермәде кыз бала, шагыйрә булып танылды. Беренче китабы да басылып таралды. «Ышанасы килә» — китабын шагыйрә әнә шулай атаган. Китапка кереш сүзне шагыйрь Зөлфәт язган. Ул хәер-фатиха биргән икән, яшь автор, чыннан да, өметле димәк. Зөлфәт әфәнде — акны карадан бик оста аера белүче шагыйрь.

Илсөяр туташның бу беренче китабы иң изге хисләргә, иң якты теләкләргә багышланган юллар белән ачылып китә:

*...Кешеләргә ышанасы килә,*
*Бушанасы килә күңелнең.*
*Ышанычым аклар дустым булчы,*
*Йолдызы бул күңел күгемнең!..*

Шигырь яратучылар, әгәр бу мәҗмуганы кулга төшереп, аны укып чыгу бәхетенә ирешсәләр, беренче юллардагы якты теләкнең китаптагы соңгы сәхифәләргәчә дәвам иткәнлеген күрерләр. Шагыйрәнең авыз ачып әйткән беренче омтылышы китап бите саен үсә, яңа бизәкләргә байый, катлаулана бара.

Китап — Илсөяр Иксанова иҗатын миллионлаган укучыларыбыз дәрьясына илтеп салган сынау шарты. Гадәттә шулай була: беренче китаптан соң каләм әһелен, кабат бу өлкәгә әйләнеп карамаслык хәлгә җиткереп, кимсетеп ташлаулары да, иҗатка җиңел карау ялгышлыгына этәреп, күккә чөеп мактаулары да ихтимал. Барысы да — укучы һәм тәнкыйтьчеләр хөкеменә тапшырылган.

Минем исә шагыйрәнең мөстәкыйль фикер йөртә алу сәләтенә һәм аның табигый талантына ышанычым зур. Болар барында, авторны һичнинди көч тә иҗат газабыннан аера алмаячак. Ил-

сәярнең үз шигырьләрендә дә бу фаразга охшаш мәгънә ярылып ята. Әнә нәрсә ди ул:

*...Юрамагыз язмышымны*
*Язылмаган ул тузларга,*
*Билгесез ул йолдызларга,*
*Күзләремә, йөзләремә —*
*Беркая да язылмаган*
*Язмышымны үзем язам...*

Әйбәт! Шагыйрә туташыбыз һичнинди ташламалар да сорамый, шома юллы язмыш котеп утырмый. Барына да үзе хуҗа булып, яхшысына-яманына әзер килеш, күкрәк киереп, каршы тора. Әйтерсең лә, замананың бу катлаулы елларына да үзе чакыру ташлый, матбугатындагы, нәшриятындагы мең дә бер низаглардан да курыкмый. Гүяки ул: «Кулыңнан килми икән, ярдәм итмә миңа, басма шигырьләремне! Теләсәгез нишләгез! — ди кебек. — Әмма мин барыбер туктамаячакмын. Хөрлекне, саф күңелләрне, шәхси азатлыкны, яктылыкка ышанычны зурлап җырлаячакмын!»

Мин бу шагыйрәнең «Ышанасы килә» китабын әнә шулай аңлыйм, шулай кабул итәм.

Мондый ышанычны Илсөяр Иксанованың гражданлык сыйфатлары да раслый шикелле. Ул, университетны тәмамлагач, җөмһүриятебезнең зур-зур газета-журнал редакцияләрендә эшли башлады. Вакытлы матбугатны күзәтеп баручылар беләләрдер: ул башта — «Казан утлары»нда, аннары «Яшь ленинчы»да эшләде. Хәзер — «Шәһри Казан» газетасының әдәбият бүлегендә. Күп кенә шагыйрьләр, үзләренең шигъри дөньяларына бикләнеп, проза яки публицистикада каләм тибрәтә алмас хәлгә киләләр. Илсөяр мондый чикләнгәнлекне сикертеп үтте. Аның публицистикасы да шактый үткен. Җөмһүриятебезгә суверенлык таләп итүгә багышланган язмалары да, әдәбият-сәнгатебезгә хөрлек теләгән мәкаләләре дә җанга ятышлы. Киләчәктә бу житди мәсьәләләр аның шигырьләренә дә күчәр, мөгаен.

Кыскасы, шагыйрәбез — шигырьләрендә генә түгел, тормыш чынбарлыгында да ихласлыгы, гаделлеккә омтылуы белән аерылып тора. Поэтик образлары авторның шәхси сыйфатларына да тәңгәл килә икән, мондый шагыйрәне әдәбиятыбыздагы бер табыш итеп каршыларга кирәк!

**Кояш ТИМБИКОВА**

---

*Котлыйбыз!*

## Азат Вергазовка — 60 яшь



Азат Фатих улы Вергазов 1932 елның 8 мартында хәзерге Пенза өлкәсенең Неверкин районы Карновар авылында укытучы гаиләсендә туа. 1937 елда аларның гаиләсе Татарстанга күчеп килә һәм хәзерге Зеленодол районының Зур Карауҗа авылында төпләнә. 1949 елда А.Вергазов Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. 1951—54 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

1970 елда А.Вергазов Зеленодол шәһәренә күчә һәм шуннан йөреп Казандагы 36 һөнәр-техника училищесендә укыта. Казан телевидение студиясенең әдәби-драматик редакциясендә өлкән редактор (1974—1985) булып эшли. Хәзерге вакытта ул Зеленодол шәһәрендә «Аҗаган» исемле яңа әдәби-нәфис журнал чыгаруга көчен сала.

Азат Вергазов әдәбиятка мәктәп дөньясыннан килеп керде. Егерме биш еллап балалар тәрбияләгәндә һәм укытканда ул күп сандагы шигырьләрен, хикәяләрен язды. Алар вакытлы матбугат битләрендә дә, аерым җыентыклар булып та басылып чыкты. Соңгы елларда һөнәр училищесе тормышын чагылдырган «Дулкыннар ни сөйли» (1976), колхозлашу чорының драматик вакыйгаларын тасвирлаган «Ташу» (1979), яшүсмерләр тормышыннан «Уяну» (1984) повестьлары дөнья күрде.

Азат Вергазов — 1984 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр!*

# Рафаэль Мостафин, Рәис Даутов

## РЕПРЕССИЯЛӘНГӘН ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

### Мәхмүт Галәү



Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани 1886 елның сентябрь аенда Казан губернасының Арча өязе Ташкичү авылында мөгаллим-хәлфә гаиләсендә туа.

Иҗатын 1906—1907 елларда Баку һәм Әстерханда чыга торган газеталарда кечкенә мәкалә-фельетоннары белән башлый. Соңыннан Оренбургта публицистик мәкаләләр, иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган брошюралар бастыра, үзе мөхәррир булган «Кармак» исемле көлкс журналда сатирик, юмористик язмалары, фельетоннары белән катнаша. Егерменче еллардан башлап нәфис әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеген киң җәелдереп җибәрә. Очерклар, хикәяләрдән тыш, берничә пьеса иҗат итә (алар арасында иң җитдиләре «Саламторханнар», «Пугач явы») һәм «Канлы тамгалар» исемле зур тарихи эпопея өстендә эшли башлый. Туктаусыз эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә дүрт томлык эпопеянең беренче ике китабы гына язылып тәмамлана. Алары да ул елларда татарча басыла алмый, 1931 һәм 1933 елларда Мәскәүдә «Муть» һәм «Мухаджиры» исемнәре белән русча басылып чыга. Татар әдәбиятында тарихи реалистик прозага нигез салган бу романнарның татарча оригиналлары язучыны кулга алганда конфискацияләнеп юкка чыга. Фәкать житмешенче елларда гына алар, русчадан кабат тәрҗемә ителеп, беренче тапкыр Казанда татарча басмада дөнья күрделәр.

М. Галәүнең кайчан һәм ничек кулга алынуы төгәл билгеле түгел. Истәлекләргә караганда, аны Мәскәүдән Казанга сорау алырга китерәләр. Махсус киңәшмә (ОСО) утырышы 1937 елның 4 ноябрендә була (карары билгесез). НКВД белешмәсенә караганда, язучының гомере 1938 елның 12 ноябрендә өзелә.

### Ләбиб Гыйльми



Ләбиб Гыйльман улы Гыйльманов 1906 елның 12 июнендә Татарстанның Әлмәт районы Иске Баграж (Елховой) авылында крестьян гаиләсендә туа.

Әдәбиятка утызынчы еллар башында килә. 1930 елда аның «Сәнәкләләр» исемле поэмасы аерым китап булып басылып чыга. Аннан бер-бер артлы балалар һәм зурлар өчен язылган шигырь җыентыклары, проза әсәрләре басыла. Язучы-прозаик буларак, ул укучыларга бигрәк тә үзенең «Чын мәхәббәт» (1934—1936) исемле романы белән билгеле. 1935—1937 елларда ул «Яшь ленинчы» газетасы һәм «Пионер каләме» журналында мөхәррир булып эшли.

Л. Гыйльми 1937 елның 21 сентябрендә кулга алына. Контрреволюцион эш алып баруда гаепләнә, Казан төрмәләрендә җәфа чигә. 1938 елның 9 маенда СССР Югары судының күчмә сессиясе аны үлем җәзасына хөкем итә. Карар шул ук көнне Черек күл подвалында башкарыла. Кабере Казанның Архангел зиратында дип уйланыла.

---

Дәвамы. Башы 2 нче санда.

## Аяз Гыйләҗев



Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа.

Беренче хикәясе 1948 елны ук басылса да, кулга алынуы сәбәпле, әдипнең актив иҗат эшчәнлеге җиде-сигез елга тоткарланып тора.

Хәзерге көндә Аяз Гыйләҗев — өч дистәгә якын пьеса, дистәләрчә хикәя, берничә роман авторы. Әмма аның художниклык осталыгы һәм кырыс реализмы аеруча повесть жанрында ачылды. Егермеләп повесть арасында «Өч аршын җир» (1962), «Язгы кәрваннар» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973), «Җомга көн кич белән» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1980) кебек үзенчәлекле повестьлары әдәби тормышта зур вакыйга буларак яңгырадылар. 1987 елда ул повестьлары өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, ә тагы берничә елдан РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

А. Гыйләҗев КДУ студенты чагында, 1950 елның 22 мартында кулга алына. Аны Совет властена каршы пропаганда алып баруда гаепләп. Чынында исә бу Берия ялчыларының милли интеллигенцияне юк итү, аның сәләтле яшь вәкилләрен җыеп алу максаты белән башлап җибәргән яңа җинаяте иде. Шул ук елның декабрь аенда ябык суд (ОСО) А. Гыйләҗевны җиде елга иреккнән мәхрүм итә. 1951 елның башыннан алып 1955 елның августына кадәр ул Казагыстанның төрле лагерьларында — кирпеч заводында балчык казучы, төзелештә ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник булып эшли. Сталин үлеменнән соң амнистиягә эләгеп, 1955 елның көзендә Казанга кайта, университетта укуын дәвам иттерә.

## Галимҗан Ибраһимов



Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында элекке Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе Солтанморат авылында мулла гаиләсендә туа.

Атаклы язучы, зур галим, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булган Г. Ибраһимов гаҗәеп бай әдәби һәм фәнни мирас калдыра. Утыз еллык иҗат гомерендә ул егермеләп хикәя (алар арасында — «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «Мәрхүмнең дәфтәреннән» һ. б.) өч повесть («Татар хатыннылар күрми», «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр»), дүрт роман («Безнең көннәр», «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар»), бер пьеса («Яңа кешеләр»), тарихка, тел белеменә караган дистәдән артык фәнни хезмәт, биш йөзгә якын тәнкыйть һәм публицистик мәкалә яза. Аларның шактый өлеше әдипнең 1974—1987 елларда чыккан сигез томлык әсәрләр җыелмасында урын алганнар. Фән, культура өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Ибраһимов 1928 елда Дәүләт Сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. 1932 елда аңа Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты карары белән Хезмәт Батыры дигән мактаулы исем бирелә.

1927 елдан башлап Г. Ибраһимов, көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында, даими рәвештә Кырымда, Ялтада яшәргә мәҗбүр була, берничә җитди операция кичерә. 1937 елның 29 августында каты авыру килеш ул кулга алына һәм, Казанга китерелеп, Пләтән төрмәсенә ябыла. Аны 58 статьяның унынчы (беренче бүлек) һәм унберенче пунктлары буенча, ягъни контрреволюцион троцкийчы оешма төзеп, совет-партия җитәкчеләренә каршы һөҗүм әзерләүдә гаепләләр. Әмма аңа гаепләү актын тапшырырга өлгермиләр — төрмә шартларында тәмам азып соңгы ноктасына җиткән үпкә авыруы әдипне 1938 елның 21 гыйнварында төрмә шифаханәсендә дөньядан алып китә. Кабере Казанның Архангел зиратында.

## Газиз Иделле

Габделгазиз Сәлах улы Усманов 1905 елның 26 декабрендә Әстерхан шәһәренең Тияк бистәсендә эшче гаиләсендә туа.

Беренче хикәяләре, очерклары һәм фельетоннары 1925—1926 елларда Свердловск шәһәрендә чыга торган татар газета-журналларында басыла. Г. Иделле укучыларга иң элек проза әсәрләре авторы буларак билгеле. Аның «Ерак Чытырманлыда», «Рәүфнең балачагы», «Комсызлык», «Очрашулар», «Күпер», «Терсәк» кебек хикәя-повестьлары заманында укучылар тарафыннан җылы каршыланган. «Дәүләт Бәдриев» исемле драмасы исә утызынчы елларда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә зур уңыш белән бара. Язучының публицистика, мемуар, әдәби тәнкыйть, тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаек.

Г. Иделле 1937 ел ахырында, М. Әмир белән бер вакытларда кулга алына. 1939 ел ахырларында иреккә чыга. Ләкин исәнлеге шактый какшаган була, рухи яктан да аны сындырып, горурлыгын таптап чыгаралар. Сиксән яшенә чаклы яшәсә дә, шуннан соң ул әдәбиятта әллә ни зур эшләр башкара алмады.

Газиз Иделле 1985 елның 27 июлендә Казанда вафат булды.

## Гата Исхакый

Гата Камалетдин улы Исхаков 1887 елда Уфа губернасының Бөре өязе Габдулла авылында крестьян гаиләсендә туа. 1904 елдан Троицк мәдрәсәсендә, 1909 елдан Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укып белем алгач, Бөре, Дүртөйле мәдрәсәләрендә милли әдәбият дәресләре алып бара. Күпьеллык педагогик тәҗрибәсенә таянып язылган «Әдәбият юллары» дигән дәреслек китабы 1920 елда Казанда «Сабах» нәшриятында басылып чыга. Татар әдипләренең биографияләренә кагылышлы мәгълүматларны да үз эченә алган бу хезмәт, әдәби-фактик чыганак буларак, хәзерге көндә дә әһәмиятен югалтмаган. Авторның 1913 елда дөнья күргән «Нота мөгаллиме» (мандолинада уйнарга өйрәткеч) дигән хезмәте дә үз заманында яшьләр арасында киң популярлык казана.

Гата Исхакый халык авыз иҗатын җыйнау, тәртипкә салу буенча да нәтиҗәле эшли, әмма аның җыйган материаллары матбугатка чыкмый кала. 1937 елда ул кулга алына. Аның шуннан соңгы язмышы турында әлегә төгәл мәгълүматлар табылмады.

## Мансур Крыймов



Мансур Кәрим улы Крыймов 1898 елда Татарстанның хәзерге Апас районы Чүри-Бураш авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.

1918 елдан яза башлый, егерменче елларда Мәскәү һәм Казан көндәлек матбугатында еш басылган агитацион-публицистик рухтагы шигырьләре, мәкаләләре, рецензияләре белән исеме таныла. Соңга таба «Кызыл Бәдавам», «Яңа кеннәр алдында», «Кызыл лачыннар», «Онытылган җырлар», «Фатыйма», «Партизаннар» кебек поэмалары һәм күпсанлы тезмә агиткалары, җырлары, маршлары, декламацияләре тупланган ике дистәдән артык китабы дөнья күрә.

Утызынчы елларның икенче яртысында, сәламәтлеге начараю һәм матбугатта тәнкыйть сүзләре ишәю сәбәпле, аның иҗат активлыгы шактый сүлпәнләнә. Ул Мәскәүдән Уфага күчеп (Афзал Таһиров чакыруы буенча), гомеренең соңгы айларын шунда яшәп уздыра. Ләкин НКВД тырнагыннан качып котыла алмый. А. Таһиров кулга алынганнан соң, М. Крыймовка да чират җитә. Аны 1938 елның 1 августында Уфа төрмәсендә атып үтерәләр. Кабере билгесез.

## Фатих Кәрим



Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов 1909 елның 9 гыйнварында элекке Уфа губернасының Бәләбәй өязе Аст авылында мулла гаиләсендә туа.

Әдәбияттагы беренче иҗат тәҗрибәләре 1926—1929 елларга карый. Шул чорда Казан җир төзү техникумында укучы студент егетнең республика мабугатында көндәлек темаларга багышланган мәкаләләре, фельетоннары, хикәяләре һәм балалар өчен язылган шигырьләре күренә башлый. Әмма үзенчәлекле каләм иясе буларак формалашуы, укучыларга киң танылуы 1929—1937 еллар арасына туры килә. Шул җиде-сигез ел эчендә яшь авторның ике проза китабы, сигез шигъри җыентыгы басылып чыга.

1938 елның 3 гыйнварында, Ф. Кәримне кулга алалар һәм контрреволюцион оешмада торып, Советка каршы пропаганда алып баруда гаепләләр. ТАССР Югары судының 1939 ел, 14 мартындагы утырышы шагыйрьне ун елга төрмәгә ябылуга һәм шуңа өстәп тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләү җәзасына хөкем итә. Шулай да, өч елга якын вакыт үткәннән соң, тоткынның туктаусыз җибәреп торган язма шикаятьләре-җалобалары тәэсирендә, СССР Югары суды алдагы хөкем карарын нигезсез дип табарга мәҗбүр була. Ф. Кәримнең «җинаять эше» яңадан тикшерүгә куела. Нәтиҗәдә 1941 елның 1 декабрендә әдип акланып иреккә чыгарыла. Берничә атнадан ул фронтка китә, башта солдат, аннары взвод командиры сыйфатында сугышның соңгы айларына кадәр алгы сызыкта була, берничә тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

Фронт тормышының хәтәр һәм авыр шартларына карамастан, Ф. Кәрим һәр буш минутын әдәби иҗат өчен файдалана. 1942—1945 еллар арасында ул тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык шигырь яза. Әдипнең фронт шартларында шигъри иҗаты, М. Җәлилнең Моабит циклы шигырьләре белән бергә, шул чор татар поэзиясенең иң югары ноктасын тәшкил итәләр.

Ф. Кәрим Кенигсберг шәһәре өчен барган каты сугышлар вакытында, 1945 елның 19 февралендә һәлак була.

## Фатих Кәрими



Фатих Гыйльман улы Кәримов (Ф.Кәрими) 1870 елның 18 мартында Бөгелмә өязе Миңлебай авылында ахун гаиләсендә туган.

Ф. Кәрими — татар мәдәнияте, әдәбияте, татар халкының иҗтимагый фикере үсеше тарихында тирән эз калдырган мәшһүр шәхесләрдән берсе. Иң элек ул үзенең унтугызынчы гасыр татар тормышының аерым күренешләрән, милли үзенчәлекләрен реалистик җирлектә, гуманистик рухта тасвирлаган әдәби әсәрләре белән билгеле. Аның 1899—1902 еллар арасында басылып чыккан «Бер шәкерт илә студент», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы», «Мирза кызы Фатыйма», «Салих бабайның өйләнүе» исемле хикәя-повестьлары татар мәгърифәтчелек әдәбиятының классик үрнәкләреннән саналалар. Икенчедән, талантлы оештыручы, ялкынлы публицист-журналист буларак, Ф. Кәрими татар халкының революциягә кадәрге милли азатлык хәрәкәтендә актив катнаша, татар милләтенең гражданлык хокукларын, мәнфәгатьләрен яклап, аның мәдәни-милли үзенчәлекләрен, милли телей саклап калу өчен патша хөкүмәтенең колониаль сәясәтенә каршы армый-талмый көрәш алып бара, үзе житәкләгән нәшрияты-матбагасы, мөхәррирлек иткән «Вакыт» газетасы аша халык арасында гыйлем-мәгърифәт тарату эшенә үзеннән зур өлеш кертә, шул рәвешчә халыкның иҗтимагый-милли аңы үсүенә уңай йогынты ясый. Әдипнең милләт язмышы, аның демократик чаралар белән мостәкыйльлеккә омтылуы турында алга сөргән фикер-карашлар әле хәзер дә заманча яңгырыйлар.

Әдипне 1937 елның 4 августында Мәскәүдә кулга алалар. 1937 елның 27 сентябрендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе Ф. Кәримине үлем җәзасына хөкем итә. Хөкем карары шул ук көнне гамәлгә кергән булырга тиеш. Кабере билгесез.

## Галим Мөхәмитшин



Галимҗан Мөхәммәтша улы Мөхәмитшин 1911 елның 7 февралендә Татарстанның хәзерге Биектау районы Олы Солабаш авылында крестьян гаиләсендә туа.

Утызынчы еллар балалар һәм яшьләр поэзиясендә бик актив эшләгән Г. Мөхәмитшиннең иҗат гомере бик кыска, нибары биш-алты ел (1930—1936) гына дәвам итә, әмма шул кыска вакыт эчендә ул балалар өчен икс, яшьләр тормышына багълы өч шигъри җыентыгын бастырып чыгара. Талантлы шагыйрьнең романтик рухтагы шигырь һәм поэмалары (Язгы чәчәкләр», «Масаюсыз кыз», «Очучыга», «Безнең яшьлек», «Яңадан корылу», «Мәхәббәт хикәясе» һ. б.) шул заманның яшь буын укучылары тарафыннан да, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннын да җылы кабул ителәләр.

Г. Мөхәмитшин — Г. Ибраһимовка илле яшь тулу уңае белән язылган мәгълүм котлау хатына кул куючыларның берсе. Шуңа нигезләнеп, 1937 елның 26 октябрендә аны кулга алалар һәм адәм ышанмаслык җинаятьләрдә гаеплиләр (58 статьяның 7, 8, 11 пунктлары — ягъни яшерен оешма төзү, совет һәм партия җитәкчеләренә каршы һөҗүм әзерләү һ. б.). 1938 елның 10 маенда СССР Югары судының күчмә сессиясе Г. Мөхәмитшинне үлем җәзасына (атарга) хөкем итә. Хөкем карары шул ук төнне гамәлгә керә. Күмелгән урыны Казанның Архангел зиратында дип уйланыла.

## Галимҗан Нигъмәти



Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин 1897 елның 26 июлендә хәзерге Башкортстанның Чишмә районына кергән Үдрәкбаш авылында крестьян гаиләсендә туа.

Иҗат эшчәнлеге Гражданнар сугышы чорыннан ук башланып, егерменче елларда яшь совет матбугаты һәм әдәбиятының теоретик һәм практик мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре һәм брошюралары белән исеме таныла («Октябрь һәм әдәбият», «Ленин һәм пролетариат революциясе», «Коммунизм турында», «Әдәбият мәйданында», һ. б.). 1927—1932 еллар арасында ул аеруча нәтиҗәле эшли: дүрт китап, иллегә якын мәкалә бастыра. Бу хезмәтләрендә тәнкыйтьчегалим татар язучыларыннан М. Гафури, Г. Колахметов, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, К. Нәҗми, Һ. Такташ, А. Шамов, И. Гази, Г. Толымбай һ. б. иҗатларына тирән анализ ясый, аларның иҗтимагый һәм эстетик карашларына шул чорның әдәбият белеме принципларыннан чыгып бәя бирергә омтыла. Г. Нигъмәтинең бай әдәби мирасы хәзәрге көндә дә тарихи һәм фәнни кыйммәтен югалтмаган.

Г. Нигъмәти 1937 елның 16 сентябрендә кулга алына. Берничә елга сузылган тикшерү барышында Казан һәм Алабуга төрмәләрендә утыра. Аны троцкийчы контрреволюцион оешмада әгъза булып торуда гаеплиләр. 1940 елның 17 гыйнварында Махсус «очлек» («тройка», ОСО) әдипне биш елга иреге ннән мәхрүм итәргә диган хөкем карарын игълан итә. Язучы-галимне Устьвымлаг исемле тоткыннар лагерына җибәрәләр. Шунда ул 1941 елның 4 декабрендә вафат була (ачлыктан, хәлсезләнүдән булса кирәк) һәм Коми АССРның Тимер Юл районы Вожаель поселогы каберлегенә күмелә.

## Кави Нәҗми



Кави Һибәт улы Нәҗметдинов 1901 елның 15 декабрендә элекке Сембер губернасы (хәзер — Нижний Новгород өлкәсе) Петрякс районы Красный Остров авылында крестьян гаиләсендә туа.

Беренче шигырьләре 1918 елда «Эшче» газетасы битләрендә басыла. Егерменче елларда, зур иҗади активлык күрсәтеп, әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайный, поэзия өлкәсендә дә, проза жанрында да шактый уңышларга ирешә. Аның «Чыныгу» (1923), «Иң соңгысы» (1924), «Шобага» (1925), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1926), «Таштугайга кайтмыйбыз» (1928) исемле хикәяләре һәм бигрәк тә «Яр буенда учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929), «Язгы ләр яңгыр» (1930) повестьлары шул чор татар прозасының житди казанышлары буларак кабул ителә.

1932 елдан К. Нәҗми Татарстан Язучылары берлеген оештыру буенча зур эш башкара һәм 1934 елда татар язучылары оешмасының беренче рәисе итеп сайлана. 1934 елның августында Мәскәүдә үткән Бөтенсоюз язучыларының Беренче съездында ул татар матур әдәбияты турында зур доклад ясый, татар язучыларыннан беренче буларак, СССР Язучылар берлеге идарәсенә әгъза итеп сайлана.

1937 елның язында К. Нәҗмине кинәт рәислектән төшерәләр, партиядән чыгаралар, ә 2 июльдә ул кулга алына. Ике елга якын дәвам иткән сорау алулар, кыйнау-мыскыллаулар, тәүлекләр буе аяк өсте бастырып торулар, юеш-салкын карцерларга ябып җәфалаулардан соң, ТАССР Югары судының 1939 ел. 16—19 мартта үткән утырышы аны ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән хөкем карары чыгара. Әдип, бу карар белән килешмичә, бер-бер артлы гариза-шикаятьләр яза. Ниһаять, эш яңадан каралып, шул ук елның 29 декабрендә әдипне, тулысынча аклап, иреккә чыгаралар, матбугат аша аның гаепсез булуын игълан итәләр.

1948 елны К. Нәҗми үзенең иң күләмле һәм иң житди әсәрен — «Язгы җилләр» исемле тарихи-революцион романын тәмамлый. 1951 елда бу әсәр СССР Дәүләт премиясенә лаек була, бик күп телләргә тәрҗемә ителә.

К. Нәҗми 1957 елның 24 мартында Казанда вафат булды.

## Мәҗит Рәфыйков



Мәҗит Мәгъсүм улы Рәфыйков 1925 елның 17 апрелендә Башкортстанның хәзерге Күгәрчен районы Күгәрчен авылында укытучы гаиләсендә туа.

Беренче иҗат тәҗрибәләре (татарча һәм русча язылган шигырьләре) 1944—1945 елларда, Ватан сугышында каты яраланып (арка сөяге имгәнеп) кайтканнан соң, Күгәрчен район газетасында басыла. Әдәби иҗат эшен Башкорт дәүләт педагогия институтында (1944—1946) һәм Казан университетында (1946—1950) укыган елларында дәвам иттерә. Ләкин сугыштан соң кабат көчәеп киткән репрессияләр студент шагыйрьне зур сынау алдына китереп бастыра: 1950 елның 1 апрель төнендә, диплом эшен якларга нибары берничә көн калгач, М. Рәфыйковны кинәт кулга алалар. Аны җинаятьләр кодексының дәһшәтле 58 нче статьясы (10 һәм 11 пунктлары) буенча, янәсе контрреволюцион яшерен оешмада әгъза булып торуда һәм Совет властена каршы пропаганда алып баруда гаепләп һәм, Махсус киңәшмә карары белән ун елга ирегеннән мәхрүм итеп, Иркутск өлкәсендәге төзәтү-хезмәт лагерена җибәрәләр. 1951 елның языннан алып 1955 елның июленә кадәр ул сәяси тоткын сыйфатында Тайшет-Братск юлы төзелешендә эшли. Фәкать Сталин үлгәннән соң гына, амнистиягә эләгеп, иреккә чыгарыла.

М. Рәфыйков лирик җылылык белән өретелгән документаль-мемуар характерындагы повестьлары һәм нәсергә тартым кыска хикәяләре белән танылды. Ул шулай ук сәләтле тәрҗемәче дә иде. Аның тәрҗемәсендә рус телендә үз әсәрләре тупланган берничә җыентык һәм күп кенә татар язучыларының аерым әсәрләре (Г. Тукай прозасы, Ш. Камал, Н. Дәүли, Хәсән Сарьян роман-повестьлары, М. Әмир, И. Гази, Г. Әпсәләмов һәм башка авторларның хикәяләре) китап булып басылып чыкты.

Әдип гомеренең соңгы елларында каты авырудан җәфаланды һәм 1986 елның 24 гыйнварында Казанда вафат булды.

## Сөббух Рәфыйков



Соббух Һади улы Рәфыйков 1913 елның 15 июлендә Татарстанның хәзерге Сарман районы Нөркәй авылында туа. Әдәби иҗат эшчәнлеген журналистикадан башлый: 1931—1937 елларда «Колхоз гәзите» (Казан), «Комбайн» (Сарман), «Кызыл яшьләр» (Казан) газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, редактор урынбасары, бүлек мөдире булып эшли. Шул чорда аның шигырь һәм хикәяләре тупланган өч җыентыгы («Үсү җырлары», «Соңгы талпыну», «Үсмерчак») дөнья күрә.

1937 елның 17 октябрендә әле егерме дүрт яше тулып кына өлгергән язучы, китап нәшрияты редакторы С. Рәфыйков НКВД органнары тарафыннан кулга алына. Сәбәбе: ул, Г. Мөхәмитшин, И. Салахов һ. б. яшь язучылар белән бергә, Г. Ибраһимовның илле еллык юбилее уңае белән язылган котлау хатына имза куйган икән. Ә бу вакыт — Г. Ибраһимов инде кулга алынып, җәмәгатьчелеккә «халык дошманы» дип игълан ителгән. Менә шул «җинаять»не сәбәп итеп, 1938 елның 12 маенда СССР Югары судының Хәрби коллегиясе С. Рәфыйковны ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән хөкем карарын чыгара. Яшь әдип башта Соловки концлагерена, аннан Норильскидагы металлургия комбинаты төзелешенә җибәрелә. 1947 елда хөкем срогын тутыргач та аңа туган якларына кайтырга рөхсәт итмиләр. 1951 елның 9 июнендә шул ук элекке «җинаятьләре» өчен яңадан бер суд ясалып, Махсус киңәшмә (ОСО) карары белән әдип Красноярск краена гомерлек сөргенгә озатыла. Туган якларына ул фәкать егерме ел үткәч — 1957 елда гына кайту бәхетенә ирешә.

Тоткынлыктан кайткан елны ук С. Рәфыйковның «Ак төннәр» исемле шигъри китабы басылып чыга. Әмма язучы буларак ул киң җәмәгатьчелеккә үзенең «Беренче яз» (1958) исемле романы белән танылды. Гомеренең соңгы елларында әдип «Тын елга буенда» исемле яңа роман төгәлләде (аерым басмасы 1972 елда дөнья күрде).

Егерме ел тоташтан тоткынлык җәфаларыннан сәламәтлеге какшаган С. Рәфыйков 1971 елның 21 ноябрендә Татарстанның Яңа Зәй эшчеләр поселогында вафат булды.

*Дәвамы бар*

## ПРЕЗИДЕНТ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Узган елның декабрь азакларында Татарстан җомһүрияте Президенты М. Шәймиев иҗат берлекләре вәкилләре, мәдәният һәм сәнгать әһелләре, республика газета-журналлары, радио һәм телевидение редакторлары белән очрашкан иде. Анда икътисади кризис һәм инфляция шартларында халык берничә дистә ел дәвамында туплаган рухи кыйммәтләрне саклап калу, иҗат әһелләренең тормыш хәле начарлануга юл куймау турында җентекле сөйләшү булды.

Президент М. Шәймиев, республикада яшәүче бөтен халык һәм шул исәптән иҗат интеллигенциясе өчен дә базар мөнәсәбәтләренә күчүнең кыенлыкларын йомшарту өчен хөкүмәт радикаль чаралар күрә, дип белдерде.

Очрашуда катнашучылар Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстан халык язучысы Ә. Еники, драматург Т. Миңнуллин, Театр әһелләре берлеге идарәсе рәисе Р. Тажетдинов, Качалов исемендәге драма театры директоры Г. Первин, Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәримуллин, Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе Н. Әлмиев, Татарстан Дәүләт радиосы һәм телевидениясе рәисе И. Хәйруллин телне, милли традицияләрне һәм мәдәниятне саклап калу турында борчылып сөйләделәр. Чыгышларда кәгазьләргә чамасыз югары бәяләр куелган шартларда нәширлек эше, газета-журналларның язмышы аеруча куркыныч астына куела, дип әйтелде.

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары М. Хәсәнов һәм Казан шәһәренең администрация башлыгы К. Исхаков иҗат союзлары эшчәнлегенең икътисади проблемаларына, аларны матди тәэмин итүгә, торак шартларын яхшырту мәсьәләләренә тукталдылар.

Әлеге очрашу Татарстан Республикасы Президенты каршында мәдәниятне үстерүнең махсус фондын булдырырга кирәклеген ачык күрсәтте.

Очрашуда Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм вице-президент В. Лихачев катнашты.

• • •

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең 1992 ел, 17 февраль Указы нигезендә, җөмһүриятебез илбашы каршында мәдәниятне үстерү фонды булдырылды. (Указның тулы эчтәлеген журналыбыз тышлыгыннан укый аласыз).

## СЕССИЯНЕҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫНДА

3—8 февральдә Татарстан Республикасы Югары Советының сигезенче сессиясе эшен дәвам иттерде.

Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев «Агымдагы хәл һәм 1992 елның февраль-мартында халыкны социаль яклау чаралары турында» доклад ясады һәм аның буенча махсус карар кабул ителде.

Татарстан Конституциясе комиссиясенең дәүләт символикасы буенча эзерлек группасы рәисе Р. М. Харисов белдерүе нигезендә Югары Совет Татарстан республикасының Дәүләт гербын раслады.

Белеме буенча журналист һәм хезмәтләре белән шактый ук танылган Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары итеп сайланды.

Сессиядә Татарстанның дәүләт һәм коммуналь милкен хосусыйлаштыру, шулай ук республикабызның икътисади һәм сәяси тормышына кагылышлы байтак кына закон һәм карарлар кабул ителде.

19—21 февральдә сессия эшен тәгалләде.

## ХӨКҮМӘТЕБЕЗ МӘДӘНИЯТ ТУРЫНДА КАЙГЫРТА

Татарстан республикасы Министрлар Кабинеты 1995 елга кадәр мәдәниятне үстерү буенча җомһүриятебезнең Мәдәният министрлыгы тәкъдим иткән Дәүләт программасын раслады.

Дәүләт программасы халыкның мәдәни мирасын, традицияләрен, рухи кыйммәтләрне саклау һәм үстерү, тарихи-мәдәни һәйкәлләрне торгызу, яшь буынга әхлакый, тарихи-патриотик һәм эстетик тәрбия бирүдә театр һәм музыка сәнгатенең ролен күтәрү, китапханә һәм музейлар эшен бүгенге көн таләпләренчә үзгәртеп кору, базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында мәдәният учреждениеләрен үстерү мәсьәләләрен киң колачлый. Шулай ук татар халкы тупланып яши торган республикалар һәм өлкәләр белән бәйләнешләрне шактый киңәйтү күздә тотыла.

Бу колачлы программаның төгәл пунктлары республика матбугатында бәян ителде. Бу — чын мәгънәсендә мәдәни һәм милли күтәрелеш баскычлары булачак.

Татарстан хөкүмәте кадрлар проблемасын хәл итү һәм республикада мәдәниятне үстерү буенча дәүләт программасын финанс-хокук ягыннан тәэмин итү юлларын да билгеләде.

## МӘДӘНИЯТНЕ ЯКЛЫЙ ТОРГАН УКАЗ

Матбугатта Татарстан Президенты М. Шәймиевнең мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләрен социаль-икътисади яклау буенча кичектергесез чаралар турындагы 1992 ел, 11 февраль Указы басылып чыкты.

Указ карарында әйтелгәнчә, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренең эшчәнлеген финанслауны яхшырту, Мәдәният министрлыгы буйсынуындагы иҗади оешмаларны керем өчен салым түләүдән азат итү, матди-техник тәэмин ителеш һ. б. әһәмиятле мәсьәләләр хәл ителергә тиеш. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «1990—1995 елларга мәдәният, сәнгать учреждениеләренең һәм иҗат берлекләренең матди-техник базасын ныгыту, анда эшләүчеләрнең социаль-көнкүреш шартла-

рын яхшырту чаралары турында»гы карары-
на өстәмәләрне бер ай эчендә кабул итәргә, дип күрсәтелгән.

Әлеге максатларны финанслау Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фонды хәзинәсе исәбенә гамәлгә ашырылачак.

## ТАТАРСТАННЫҢ БЕРЕНЧЕ АКАДЕМИКЛАРЫ

Мөстәкыйль Татарстанның Фәннәр Академиясенә гамәли әгъзалар һәм әгъза-корреспондентлар сайлану уңаеннан оештыручы-президент М. Хәсәнов һәм оештыручы совет әгъзалары 6 гыйнварьда матбугат конференциясе үткәрделәр.

Чыгыш ясаучы галимнәр Татарстан Фәннәр Академиясен төзүнең максаты, аның бурычлары, киләчәге, Россия Фәннәр Академиясе белән үзара мөнәсәбәтләр һәм кайбер оештыру чаралары турында сөйләделәр. Журналистларның күп кенә сорауларына җавап бирделәр.

Ниһаять, 21 январьдагы сайлаулардан соң Татарстан Фәннәр Академиясенең беренче академиклары игълан ителде. Менә алар: гуманитар фәннәр буенча — Ә. Кәримуллин, Р. Нәфыйков, Д. Тумашева, Н. Әхмәтов; биология, авыл хуҗалыгы һәм медицина фәннәре буенча — Д. Зобәеров, И. Лещинская; математика, механика һәм машина төзелеше буенча — М. Закиров, Т. Сиражетдинов; физика, энергетика һәм җир турындагы фәннәр буенча — Н. Сәхибуллин, Ш. Чабдаров; химия һәм химия технологиясе буенча — А. Мазгаров, Р. Сәйфуллин.

Калган урыннарга сайлаулар дәвам итә.

* * *

Татарстан Фәннәр Академиясе әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Анда Фәннәр Академиясенең Президентын сайлау каралды. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәсендә Фәннәр Академиясе Президенты итеп күренекле җәмәгать эшлеклесе, Язучылар Союзы әгъзасы, академик Мансур Хәсән улы Хәсәнов сайланды.

## МИЛЛИ МӘҖЛЕС СӘЯСИ МӘЙДАНГА ЧЫГА

Февраль ае тарихи вакыйгаларга гаять бай иде. Шулар арасыннан җәмәгатьчелекне иң кызыксындырганы, мөгаен, Бөтентатар корылтае булгандыр. Корылтай 1—2 февраль көннәрендә Казанда, Камал театры бинасында үтте. Аның эшендә Татарстаннан һәм элекке СССРның төрле төбәкләреннән җыйналган 877 рәсми делегат катнашты.

Татар халкы корылтае эшенең башында ук Татарстанның дәүләт бәйсезлеге турында закон кабул итте. Анык нигезендә Татарстан халыкара хокук субъекты дип игълан ителә. Корылтай, шулай ук, дөнья парламентларына җөмһүриятебезне тануны, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Куркынычсызлык советына Татарстанны БМОның тулы хокуклы әгъзасы итеп алуны сорап мөрәҗәгать итте.

Корылтай Милли Мәҗлесне сайлады. 100 кешедән торырга дип уйланылган бу югары орган составында Татарстан Югары Советы депутатлары да бар.

Икс көн дәвамында барган бу җыен милләтнең, Татарстан республикасының язмышы белән бәйләнешле күп кенә резолюция һәм карарлар кабул итте.

Милли Мәҗлеснең рәисе итеп Татарстан халык депутаты, Алабуга автомобиль заводы генераль директоры урынбасары Тәлгать Абдуллин сайланды.

## «ДӨНЬЯ» ДӨНЬЯГА ЧЫКТЫ

Татар матбагасы тагын бер яңа баскычка күтәрелде. «Ватан» җәмгыяте «Дөнья» исемле халыкара татар газетасы чыгара башлады. Ул латин хәрефләре белән басыла һәм дөньяның татарлар яши торган һәр төбәгенә тарала. Кече форматлы, 12 битле бу басманың баш мөхәррире Рәмзил Вәли газетаның беренче санында «Татарның иле кайда?» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Автор, бөтен дөньяга таралган татар халкына — милләттәшләргә сәлам юллау белән бергә, бу газетаның Австралиядә яшәүче эшкуар Рөстәм Садри һәм Германиядә яшәүче журналист Фәридә Хәмит ярдәме белән чыгарылуын хәбәр итә. Газетаның төп максаты итеп түбәндәгеләр әйтелә:

«Татарстанның һәм татар халкының тарихын, рухи һәм милли байлыкларын, икътисади һәм иҗади мөмкинлекләрен күрсәтү;

халкыбызның һәм Татарстанның халыкара бәйләнешләрен чагылдыру, халкыбызны киң дөньяга чыгару, өзелгән кардәшлек җепләрен ялгау;

дөнья илләрендәге алдынгы фикерләрне, заманча техника, конкуреш һәм демократия тәҗрибәсен Татарстанга бәйле төстә уртаклашу h. б.

«Дөнья» газетасы әнә шундый изге ниятләр белән дөньяга чыкты. Хәерле юл аңа!

## ГОМУМТАТАР УКЫТУЧЫЛАРЫ КИҢӘШТЕ

9—10 январьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында, халкыбыз тарихында беренче мәртәбә, дөньякүләм татар укытучылары бергә җыйналды. Анда гомумтатар «Мәгариф» ассоциациясенең оештыру корылтае булды. Корылтайга Башкортстан, Оренбург, Пенза, Алма-Ата, Саратов, Төмән, Литвадан h. б. төбәкләрдән җиде йөзгә якын укытучы килгән иде. Корылтайны «Мәгариф» комитеты президенты, профессор Г. Даутов ачты. Мәгърифәтебезнең сәяси-хокукый халәтен һәм төп принципларын чагылдырган доклад белән «Мәгариф» комитетының уку-укыту бүлеге мөдире И. Әмирханов чыгыш ясады.

Корылтайда ассоциациянең уставы, платформасы кабул ителде. Җитәкче органнары сайланды.

Корылтайда Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары М. Хәсәнов чыгыш ясады.

## ЯЗУЧЫЛАР ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫНДА

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында барлыгы 16 каләмдәшебез берлек сафына әгъза сыйфатында кабул ителде. Шулай ук язучылар оешмалары һәм «Туган тел» җәмгыятенең әдәбият һәм иҗтимагый өлкәдәге Гаяз Исхакый исемендәге бүләгенә яңа кандидатлар күрсәтелде. Алар — танылган язучы Ибраһим Нуруллин һәм шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов.

Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә исә драматург Шәриф Хөсәенов, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов һәм тәрҗемә остасы Семен Липкин кандидатуралары тәкъдим ителде.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

26 декабрьдә Мәскәүдә Муса Җәлил яшәп киткән йортка истәлек тактасы кую тантанасы булды. (Столешников тыкрыгы, 11 йорт). Истәлек тактасына мондый сүзләр язылган: «Бу йортта 1936—1941 елларда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты каһарман шагыйрь Муса Җәлил яшәде». Тактага татар халкы улының барельеф-рәсеме дә уелган.

Бу тантананы ТССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Анда Мәскәү дәүләт университеты профессоры Р. Бикмөхәммәтов, халыкара мөнәсәбәтләр институты профессоры А. Әхмәтҗан, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Мәскәү оешмасы рәисе У. Шәрипов, Мәскәүдәге «Туган тел» иҗтимагый мәдәният үзәге рәисе Г. Арифулов, Муса Җәлилнең хатыны Әминә ханым, кызлары Чулпан һәм оныгы катнашты.

## ТАТАРСТАНДА ЯҢА ПАРТИЯ

Быелның январь азагында яңа фиркә — Татарстанның Республика партиясе (ТРП) оешты. Ул үзенең төп максаты итеп халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен яхшыртуы, сәяси һәм рухи мәдәниятне үстерү, шәхес һәм милләтләр хокукын саклау һәм Татарстанның тулы бәйсезлеген яклау мәсьәләләрен куя.

ТРПның рәисе итеп Татарстан Югары Советы депутаты, профессор Рүзәл Йосыпов сайланды.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

Күренекле татар язучысы Шәйхи ага Маннурның васыяте нигезендә, аның туган ягында — Мамадыш районының «Чулпан» колхозында Ш. Маннур исемендәге премия булдырылган иде. Ул һәр елны, шагыйрьнең туган көнендә, яшь әдипләргә һәм колхозның хезмәт алдынгыларына тапшырыла.

14 январь көнне Олыяз авыл культура йортында Ш. Маннурны искә алу һәм әлеге премияне тапшыру тантанасы булды. Жюри карары белән, колхозның Шәйхи Маннур исемендәге 1991 ел премияләре «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хроника өчен язучы Рашат Низамиевка, «Оча җырлар» дигән китабы өчен шагыйрь Газинур Моратка, Шәйхи Маннур әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүдәге хезмәтләре өчен Светлана Гыйльметдиноварга, колхоз алдынгыларыннан Зөлфәт Мөбәракшин, Хатип Кәрамов, Нурфия Идрисова, Нәзимә һәм Әлфинур Зиннәтоваларга, мәдәният өлкәсендәге эшчәнлеге өчен Юрис Мөхлисовка бирелде. Яңа лауреатларга премия һәм дипломны «Чулпан» колхозы рәисе Фәрит Хисмәтов, Ш. Маннурның мирас комиссиясе рәисе шагыйрь Илдар Юзиев иптәшләр тапшырды.

Шагыйрьнең якташлары алдында Рөстәм Мингалимов һәм Шаһинур Мостафин да чыгыш ясадылар.

# МӘҢГЕЛЕК МӘХӘББӘТ ОБРАЗЫ

Сынлы сәнгатьнең төп һәм мәңгелек темаларыннан берсе, мөгаен, хатын-кыз образы, шул исәптән, Ана образыдыр. Төрки халыкларда Алиһә — ана образы һәрвакыт аерым бер символик мәгънәгә ия булып торган. Ул үзенә табындыручы гади сын-сурәт кенә түгел, ә бәлки кешенең туган көненнән алып үлеменә кадәр аңында даими яшәп килүче, көндәлек тормышында һәрчак күңел түрендә йөрүче иң изге һәм иң олуг зат булган.

Журналыбыз тышлыгында сез бу юлы Санкт-Петербургта яшәп иҗат итүче, үзенчәлекле талантка ия татар рәссамы Рәшит Нуруллин әсәрен күрәсез. Рәссам аны «Төрки Мадонна» дип атаган. Ихтимал, бу исем Европа илләре сәнгатендә бик киң чагылыш тапкан Моданна образы йогынтысында бирелгәндер. Бәлки, бик үк уңышлы исем дә түгелдер. Әйтик, «Татар алиһәсе» булса, безнең колакка ятышлырак ишетелер иде шикелле. Кемгәдер әсәрнең эчтәлеге һәм композициясе күп кабатланган, стереотип бер сурәт булып тоелырга мөмкин. Әйе, дөнья сынлы сәнгатендә баласын кочкан ана образы күптәннән яшәп килә һәм һәр зур рәссам үзе генә белгән кабатланмас Мадоннасын иҗат итә.

Әмма Рәшит Нуруллин Мадоннасы,— әйдәгез, без моны Алиһә дип атыйк: шулай шигърирәк һәм кулайрак булыр,— әйе, Рәшит Нуруллин Алиһәсе яңа төсмерләре, яңа сурәтләү чаралары, яңача фәлсәфәсе белән безне җәлеп итә. Безнең алда барыбызга да аңлаешлы, күңелгә якын образ-сурәт бит. Аңарда үзенчәлекле холык-характер, татар хатын-кызының — Алиһә-ананың милли төсмерләр белән өртелгән романтик йөзе чагыла. Алиһә-ананың куенында газиз баласы, ул сабыйның да йөз чалымнарында, күз карашында милли сыйфатлар төсмерләнә. Ананың да, баланың да йөз сызыклары, килеш-килбәте, өсләрендәге киемнәре детальләштереп, анык-ачык сурәтләнмәгән. Юкса Европа традицияләренә турылыклы сынлы сәнгатьтә бу тематика гадәттә бик тәфсилләп, образның һәр детале, һәр сызыгы аерым бер тырышлык куеп сурәтләнеп килә. Ә менә Рәшит Нуруллин андый юнәлештән китмәгән, ул үзенең Алиһәсен, әйтерсең лә, үтә күренмәле җиңел өрфиягә төргән, шуның белән образны тамашачы күз алдында серле дә, сихри дә бер югарылыкка күтәргән. Юк, бу Алиһә-ана һәм ананың сабые без көндәлек тормышта күреп-белеп яшәгән гади хатын-кызлар гына түгелләр. Болар — изгеләр, болар безне үзләренә табындыралар. Бу образлар шәрык сәнгатенә, мөселман дөньясына якыннар: нәкъ менә шәрык сәнгате кеше сурәтен ачыктан-ачык ясаудан тыеп килгән, чөнки ул зур гөнаһ саналган. Бар дөньяны яраткан, терекләкне, шул исәптән, адәмнәрне дә бар иткән Аллаһы тәгаләнең бөек серләренә тыкшыну мөмкин эшме соң?! Аннары әле шунысы да бар: син ясаган сын-сурәтләр кыямәт көнендә синнән җан сораячаклар икән бит...

Менә шуңа күрә дә Рәшит Нуруллин әсәрендәге образлар бер үк вакытта изге дә, серле дә итеп кабул ителәләр. Без ул образларны, бик теләсәк тә, тулысынча аңлап бетерә алмыйбыз, аларда һаман да ниндидер әйтелеп бетерелмәгән сихрилек кала.

Безгә калса, Алиһә-ана һәм бала образы җыелма образ, ул үзенә бик күп мәгънәдәге символларны сыйдыра. Төп символ ана белән баладан нурланыш булып балкып торучы ак төстә. Ак төс — пакьлек-сафлык төсе, ана мәхәббәтенең изгелеген, олуглыгын гәүдәләндерүче төс. Әсәрдә Татар халкының фаҗигале тарихи символына әверелгән легендар Сөембикә белән аның Улы Үтәмеш образлары да төсмерләнә шикелле. Алар да безнең өчен изге һәм олуг затлар...

Рәшит Нуруллин Ленинград өлкәсенең Волхов шәһәрендә туган. 1974 елда Санкт-Петербург сәнгать училищесын тәмамлаган. Әсәрләре, безнең илдән тыш, Греция, Төркия, Италия, Франция, Англия кебек илләрдәге төрле күргәзмәләргә куелган. Америка, Франция, Германия, Швеция, Израиль, Финляндия сәнгать сөючеләренең шәхси тупланмаларында да Рәшит Нуруллин әсәрләрен очратырга була.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**
сәнгать белгече.

Тышлыкның дүртенче битендә: танылган язучы Мәдинә Маликова.

**Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ** фотосы.

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Укып-ишетеп торасыздыр: базар мөнәсәбәтләре, бәяләрнең айлап-көнләп үсә баруы газета-журналлар өчен дә күтәрә алмаслык авыр йөк булып төште. Шул исәптән безнең «Казан утлары» журналының да хәле бик кысен — быел май аенда 70 еллыгын билгеләп үтәчәк журналыбызга ябылу куркынычы яный.

Кәгазь бәяләре ун-унике мәртәбә, журналны типографиядә бастыру һәм укучыларга тарату чыгымнары сигез-ун мәртәбә артты. Моңа кадәр табышлы басма буларак яшәп килгән журналыбызның чыгымнары хәзер миллионнар белән исәпләнә.

Үзегезгә мәгълүм: журналның аерым саны нибары 1 сум 80 тиен иде. Хәзер бу бәягә кайбер көндәлек газеталарның бер санын да сатып алып булмый. Сезнең бер елга дип түләгән язылу акчаларыгыз журналыбызның шушы өченче санын бастырып тарату белән түгәрәкләнә.

Безгә нәрсә эшләргә? Ни рәвешле сезнең һәм безнең уртак журналыбызны саклап калырга? Башка газета-журналлар язылу бәяләрен арттырырга торганда без читтә кала алырбызмы?

Ни авыр булса да, белдерергә мәҗбүрбез: елның икенче яртысына журналга язылу бәясен күтәрергә туры киләчәк. Ул, мәгаен, ярты елга (6 айга) 48 сум тәшкил итәр.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Газиз кардәшләребез! Ил-халыклар ирекле-бәйсез тормышка, яңача яшәргә омтылганда килеп туган вакытлы кыенлыкларны иңгә-иң торып, бергәләп күтәрешсәк, җиңеп чыгарбыз, иншалла! «Казан утлары»ның яктысын сүндермәсәк иде. Журнал алга таба да рухи дөньябызны баетсын, милләтебезгә хезмәт итсен!

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210

Аерым сатып алучылар өчен 3 сум



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог